# казан утлары

5

МАЙ-1976

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

5

МАЙ
1976


## Бу санда


Ф. ТАБЕЕВ. Илһам чыганагы . . . . . . . . . 3

И. ЮЗЕЕВ. Яңа шигырьләр . . . . . . . . . 8
Ә. БАЯНОВ. Төлке тоту кыен түгел. Повесть . . 14
Ф. САФИН. Ак канатлы егет. Поэма . . . . . 87
Ә. МОХТАР. Тап. Хикәя . . . . . . . . . . 92
И. КӘЛИМУЛЛИН. Дан ордены. Поэмадан өзекләр. 104

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . 108
Б. КАМАЛОВ. Ферма — лауреат . . . . . . . 110
С. ШАКИР. Муса белән очрашкан баһадир . . 114
З. ӘХМӘТҖАНОВ. Дала егете . . . . . . . . 119

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Грузин шагыйрьләре . . . . . . . . . . . 125
М. МӨШФИКЪ. Җилләр. Шигырьләр . . . . . 131

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

И. АБДУЛЛИН. Кыйммәтле документлар . . . 136
А. АЙНЕТДИНОВ. Фронттан хатлар, фронтка хатлар . . . . . . . . . . . . . . . 145

Р. МОСТАФИН. Этюдлар . . . . . . . . . . 154

КИТАП КҮЗӘТҮ

А. ИСКӘНДӘР. Сүз тәртибенең серләре . . . 161

КОНКУРСКА КИЛГӘН РЕЦЕНЗИЯЛӘР

Р. НИЗАМИЕВ. Хикәяләр бакчасында . . . . . 166
Ф. САФА. Яшь күңелләргә шифа булсын . . . 170



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Г. ЛАТЫЙП. Акбабай.** Шигырьләр . . . . . . 173

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Сугыш еллары юморыннан** . . . . . . . . . . 177
**Ү. САТТАРОВ. Телевизор тирәсендә.** Хикәя . . . 185

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

---

Производствога бирелде 2/II-1976 ел. Басарга кул куелды 6/IV-1976 ел. ПФ 09012. Кәгазь форматы 70×108[1]/[16]. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91744 экз. Заказ К-52. Бәясе 50 тиен.

---

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1976 ел.

**Фикрәт Табеев,**

КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре, КПСС Үзәк Комитеты члены

# ИЛҺАМ ЧЫГАНАГЫ

*Партиянең XXV съездындагы речь*

Иптәшләр! Безнең Ленин партиясенең тарихи XXV съезды ике бишьеллык чигендә үтә. Партиянең иҗади эшчәнлегендәге гомумиләштерелгән тәҗрибә киләчәктә булачак социаль үзгәрешләрнең җанлы чыганагына әверелер.

Без барыбыз да КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Леонид Ильич Брежнев ясаган докладны — партиябез Үзәк Комитетының тирән эчтәлекле, нигезле отчет докладын зур игътибар белән тыңладык.

Докладта без ирешкән гаять зур казанышларга чын мәгънәсендә фәнни, марксистик-ленинчыл позициядән йомгак ясалган, якын киләчәкнең сугышчан бурычлары билгеләнгән. Ул докладтагы положениеләр һәм нәтиҗәләр фәнни коммунизм теориясенә һәм практикасына яңа мөһим өлеш булып тора, алар партиянең һәм бөтен совет халкының рухландыргыч программасы булып хезмәт итә.

Татарстан коммунистларының, барлык хезмәт ияләренең ихтыярын чагылдырып, безнең делегация съезддагы барлык делегацияләр кебек үк, Үзәк Комитетның генераль линиясен, партиябезнең эчке һәм тышкы политикасын тулысынча хуплый. КПССның бөек гуманизм идеяләре белән сугарылган, ленинчыл революцион принципларга турылыклы булган политикасы совет халкының төп интересларына, гомуми тынычлыкны һәм халыкара иминлекне ныгытуга җавап бирә.

Ораторларның чыгышларыннан күренгәнчә, без барыбыз да КПССның XXIV съезды куйган төп социаль-экономик бурычларның уңышлы үтәлүен гаять зур горурлык хисе белән билгеләп үтәбез. Үткән биш елга җитәкчелекнең ленинчыл принципларын тагын да үстерү, партиябез авторитетының чагыштыргысыз дәрәҗәдә үсүе хас.

Үзәк Комитетның совет халкына тыныч иҗади хезмәт итәргә уңайлы тышкы политик шартлар тудыру өчен нык торып һәм принципиаль көрәшүе безнең барыбызны да сөендерә. КПССның XXIV съезды эшләгән Тынычлык программасын эзлекле рәвештә тормышка ашыра барып, ул халыкара киеренкелекне киметү, бөтен дөнья социализм системасын, халыкара коммунистик һәм милли азатлык хәрәкәтен ныгыту һәм тагын да туплау эшенә бик зур өлеш кертте. Партиябез Үзәк Комитеты пролетар интернационализм байрагын

югары тота, үз азатлыклары һәм милли бәйсезлекләре өчен көрәшүче барлык халыкларны яклау өчен бөтенесен эшли.

Шул ук вакытта Пекин лидерларының раскольниклык, милләтчелек позицияләре барлык намуслы кешеләрдә законлы рәвештә ачу тудыра. Маоизм, эчке һәм тышкы политикасында явыз антисоветизм белән сугарылган хәлдә, империализм һәм реакциянең аеруча мәкерле көчләре белән тыгыз берләшә.

Безнең эчке һәм тышкы политика өлкәсендәге барлык казанышларыбыз — совет халкының фидакарь хезмәте, партиянең, аның Үзәк Комитетының, Леонид Ильич Брежнев җитәкчелегендәге Политбюроның бик зур политик һәм оештыру эшчәнлеге нәтиҗәсе ул. Илебездә коммунизм тантанасы хакына һәм гомуми тынычлыкны ныгыту хакына иптәш Леонид Ильич Брежневның ару-талуны белмәс чын мәгънәсендә титаник һәм нәтиҗәле эшчәнлеге аңа бөтен партиябездә, совет халкында, җирдәге барлык прогресс һәм тынычлык көчләрендә лаеклы мәхәббәт һәм ихтирам тудырды.

Иптәшләр! КПСС Үзәк Комитетының даими игътибары һәм зур ярдәме нәтиҗәсендә республикада бик эре промышленность комплекслары барлыкка килде. Татарстан хезмәт ияләре промышленность продукциясен реализацияләү күләме буенча тугызынчы бишьеллык заданиеләрен уңышлы үтәделәр. Бишьеллыкта республика халык хуҗалыгына 9 миллиард сумнан күбрәк капитал салынды. Терлекчелек продуктлары җитештерү планнары үтәлде һәм аларны дәүләткә сату шактый артты. Мәгълүм булганча, бу — берничә ел кабатланган корылык шартларында эшләнде. Культуралы сугарулы көтүлекләр, җирләрне мелиорацияләү һәм специальләштерү буенча күп нәрсә эшләнде.

Машина төзү югары темплар белән үсте, промышленностьның бу тармагы илебезгә бөтен уңайлыгы булган ИЛ-62 лайнерларыннан һәм хәзерге заман электрон-хисаплау машиналарыннан алып яңа техника һәм прибор средстволарына кадәр йөзләрчә яңа машина җитештерде. Алар Ватанныбыз экономикасын һәм куәтен күтәрүдә бик әһәмиятле. Нефть промышленностен бик нык үстерү масштаблары ягыннан уникаль булган нефть химиясе һәм шин тармагы, энергетика предприятиеләре төзергә ярдәм итте. Тугызынчы бишьеллыкта Казанда бик зур химия комплексы, шул исәптән иң куәтле полиэтилен җитештерү предприятиесе төзелде. Бөтен партия оешмасы партия ихтыярын үтәүгә — зур йөк күтәрешле автомобильләр җитештерү буенча Кама комплексын төзүгә гаять зур күтәренкелек белән кереште.

1970 елда ук безнең нефтьчеләр, Ватанныбыз нефть индустриясе тарихында беренче тапкыр буларак, илнең бер районында — Татарстан республикасында — 100 миллион тонна нефть чыгардылар. КПССның XXIV съездында без тугызынчы бишьеллык дәвамында ел саен чыгарыла торган нефть күләмен шушы дәрәҗәдә сакларга сүз биргән идек. Тирән канәгатьләнү хисе белән съездга бу кыен бурычның уңышлы үтәлүен белдерәбез. Татарстан нефтьчеләре үткән биш елда Ватанныбызга 514 миллион тоннага якын нефть бирделәр, бу — сигезенче бишьеллыктагыдан 50 миллион тоннага күбрәк.

Бу сокландыргыч җиңүгә, югары техник-экономик һәм сыйфат күрсәткечләрен саклаган хәлдә, нефтьчеләр һәм төзүчеләрнең — отчет докладында Леонид Ильич гаҗәеп дәрәҗәдә җылы һәм зур ихтирам белән сөйләгән чын бишьеллык батырларының — тырышлыгы белән ирешелде. Аларның киеренке фидакарь хезмәтенә КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы котлавында югары бәя бирелде.

Түбән Кама комбинаты коллективы бишьеллыкта җитештерү күләмен тугыз тапкырдан күбрәк арттырды, ул җитештерә торган

продукциянең сыйфатын шактый күтәрде һәм проекттагы куәтләрне сафка бастыру срокларын бик нык кыскартты. Түбән Кама нефтехимикларын бу хезмәт җиңүе белән КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Л. И. Брежнев кайнар котлады. Сезнең, Леонид Ильич, котлау сүзләрегезне һәм теләкләрегезне Татарстанның нефтехимиклары һәм барлык хезмәт ияләре гаять зур рәхмәт хисе белән кабул иттеләр һәм Ватаныбызны тагын да чәчәк аттыру хакына яңа үрләр яуларга әзер торуларын белдерделәр.

Унынчы бишьеллыкта тулаем алганда республиканың нефть химиясендә җитештерү күләме өч тапкыр артырга тиеш. Бу — синтетик каучук җитештерүнең Бөтенсоюз күләмендәге үсешен кырык процентка, шиннар җитештерү күләме үсешен 60 һәм полиэтилен җитештерү күләменең үсешен 30 проценттан күбрәккә тәэмин итәчәк. Якын арада гаять зур «Этилен-450» установкасын сафка кертү бурычы тора, нефть химиясенең зур бурычларын тормышка ашыру өчен күп эшләргә туры киләчәк. Нефть промышленностенда бик зур резервлар бар әле. Яңа нефть ятмаларын эзләп табу һәм файдалануга кертү белән беррәттән, катламнарның һәм битумлы токымнарның нефть бирүен арттыру ягулык энергетикасын үстерергә зур мөмкинлекләр ача. Күрсәтелгән резервларны файдалану — бер безнең районда гына да йөзләрчә миллион тонна нефтьне халык хуҗалыгы әйләнешенә кертү дигән сүз. Ләкин интенсивлаштыруның техник, бигрәк тә химик средстволары булмау яңа технологиянең һәм басымга тәэсир итүнең инде эшләнгән проектларын да киң промышленность масштабларында кулланырга ирек бирми. Кызыксынган министрлыклар һәм ведомстволар бу тармакның нәтиҗәле эшчәнлеген күтәрү өлкәсендәге бик мөһим проблемаларны хәл итүдә безнең нефтьчеләргә булышырга тиешләр.

Иптәшләр! Чаллыда Кама автомобиль комплексын — тугызынчы бишьеллыкның бөтенхалык төзелешен уңышлы башкару — соклангыч хезмәт җимешләренең берсе. XXV съездга, КПСС Үзәк Комитетына һәм Совет хөкүмәтенә зур йөк күтәрешле автомобильләр җитештерүче Кама заводлары комплексын төзүдә катнашкан төзүчеләр һәм монтажчылар, автозаводчылар, проектчылар һәм конструкторлар коллективларының партиябез XXIV съезды карарларын тормышка ашырып, партиянең XXV съездын лаеклы каршылау өчен социалистик ярышны киң җәелдереп, соклангыч хезмәт җиңүенә ирешүләрен зур шатлык хисе белән хәбәр итәбез. Автомобиль комплексының төп конвейеры көйләү режимында эшли башлады, быелның 16 февралендә аннан «КамАЗ» маркалы беренче автомобильләр төште. Төзелеш башланганнан бирле төзүчеләр һәм монтажчыларның 120 меңле коллективы КамАЗны коруда 3 миллиард сумнан күбрәк капитал салулар үзләштерде, шуларның 1800 миллион сумы төзүмонтаж эшләрендә үзләштерелде. Автомобиль комплексының төзелгән алты заводы корпусларында 1,5 миллион квадрат метрдан күбрәк производство мәйданнары файдалануга тапшырылды. Аларга беренче класслы технология җиһазлары куелды. Завод корпуслары янәшәсендә 230 меңгә якын кеше яши торган заманча корылган Чаллы шәһәре үсеп чыкты, культура-көнкүреш объектлары, юллар һәм коммуникацияләр эшләнде, шәһәр яны авыл хуҗалыгы зоналары, зур куәтле база предприятиеләре булдырылды.

Кама комплексын төзү масштабы, темплары һәм технологик җиһазларны үзләштерү сроклары буенча Ватаныбыз һәм чит илләр капиталь төзелеш практикасында тиңдәш юк. Моның белән бөтен илебез горурлана ала. КамАЗны кору халык хуҗалыгының мөһим бурычларын комплексны рәвештә тормышка ашыруда, гүзәл эшчеләр сыйныфының фидакарь хезмәтендә, партия оешмаларының мас-

саларны туплауның иң яхшы формаларын эзләү буенча илһамлы һәм тырыш хезмәтендә, күп кенә социаль мәсьәләләрне һәм күп милләтле хезмәт коллективларын формалаштыруда үзенчәлекле бер мәктәпкә әйләнде. КамАЗда төзүчеләрнең, монтажчыларның соклангыч кадрлары зур тәҗрибә туплады һәм үсте. Алар бөек төзелеш алдынгылары һәм ударниклары сафларын тулыландырды. КамАЗдагы эшләрнең героикасы данлы бишьеллыкларның бөек батырлыгы елъязмасына керер.

КамАЗ СССР халыкларының дуслыгын һәм туганнарча хезмәттәшлеген аеруча яхшы гәүдәләндерә. Аны коруда бөтен илебез катнаша. Хәзер, автогигант өчен көрәштә беренче җиңүгә ирешкәч, бу куәтле индустриаль комплексны төзүдә гаять зур ярдәм күрсәткән барлык предприятие, проект оешмалары, союз министрлыклары һәм ведомстволары, СССР Госснабы һәм Госстрое коллективларына, комсомол Үзәк Комитетына, шәһәр төзүдә булышучы кадерле мәскәүлеләргә, тугандаш республикалар, өлкә, крайларның партия һәм хуҗалык органнарына, безнең сугышчан партия матбугатына, радио һәм телевидениегә аерата ихлас күңелдән рәхмәт әйтәбез.

Кама автозаводы КПСС Үзәк Комитеты, Союз һәм Россия Федерациясе хөкүмәтләренең игътибар үзәгендә. Төзелеш барышына көндәлек контроль урнаштырып һәм эшчеләр сыйныфы турында кайгыртучанлык күрсәтеп, КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы, Үзәк Комитет секретарьлары, Үзәк Комитет бүлекләре гаять зур төзелеш коллективының катлаулы производство һәм социаль бурычларын эшлекле хәл итүгә ничек итеп конкрет һәм оператив, алдан күреп һәм массаларның иҗади мөмкинлекләрен исәпкә алып якын килү үрнәге күрсәтәләр. Бу безнең барыбыз өчен дә политик һәм оештыру эшенең зур мәктәбе булды.

КамАЗ — СЭВ рамкаларында социалистик экономик интеграция программасын уңышлы рәвештә тормышка ашыруның ачык дәлиле. Ул КПСС Үзәк Комитетының тышкы политик эшчәнлек өлкәсендә ирешелгән позитив нәтиҗәләрне бөтен тулылыгы белән ача. Бу нәтиҗәләр Тынычлык программасын уңышлы рәвештә тормышка ашыру барышында халыкара киеренкелекне киметү һәм халыкара хезмәт бүленеше рамкаларында үзара файдалы экономик хезмәттәшлекне үстерү чараларын билгеләргә мөмкинлек бирде.

КамАЗга КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Леонид Ильич Брежнев зур игътибар һәм кайгыртучанлык күрсәтте. Ул автогигантка заманыбызның техник яктан иң камил комплексына әйләнергә мөмкинлек биргән бик зур эчке һәм халыкара экономик чараларны башлап йөрүче булды.

Кадерле Леонид Ильич, сугыштан соңгы бишьеллыкларның эре объектларын төзүне оештыручы буларак, Сезнең экономика һәм политиканың иң катлаулы мәсьәләләрен хәл итүдә ягымлылык һәм ленинчыл оптимизм күрсәтүегез, сезнең шәхси тәҗрибәгез һәр вакыт куелган бурычларны үтәүдә хезмәт уңышларына ирешергә мөмкинлек бирде. Без бу илһам чыганагыннан күп тапкырлар көч алдык.

Беренче машина чыгару уңае белән булып үткән митинг вакытында КамАЗ коллективы безнең делегациядән Сезгә, Леонид Ильич, заводларны төзүдә һәм җиһазлаудагы зур конкрет ярдәмегез өчен олы рәхмәт сүзләре әйтергә, нык сәламәтлек теләргә, бөек партиябез һәм бөтен совет халкының бәхете хакына зур уңышлар теләргә үтенделәр.

Яңа бишьеллыкның беренче көннәреннән үк КамАЗда хезмәт киеренкелеге яңа көч белән үсә. Әле күп нәрсә эшлисе бар. Елына 70 мең автомобиль һәм 115 мең дизель двигательләре җитештерүгә

исәпләнгән Кама автогигантының беренче чираты куәтләрен сафка кертү бьелга билгеләнгән. Өлкә партия оешмасы һәм аның делегатлары исеменнән КПССның XXV съездын бу бурычның уңышлы үтәләчәгенә ышандырырга рөхсәт итегез.

Автомобиль комплексын тулы куәтенә шушы бишьеллыкта эшләтә башлау өчен безнең бөтен мөмкинлекләребез бар. КамАЗ машиналары илебез экономикасының барлык тармакларында зур нәтиҗәләр белән эшләячәк. Беренче «КамАЗ»ларның бәхетле юлы Ватаныбыз башкаласы Мәскәүнең Кызыл мәйданыннан башланды. Алар съезд үзенең эшен башлаган вакытка бирегә килеп җиттеләр.

Иптәшләр! Тугызынчы бишьеллыкта Татарстан фән, культура һәм мәгарифне үстерүдә, халыкның тормыш хәлен яхшыртуда яңа үрләргә иреште. Биредә илебезнең барлык милләтләрен һәм халыкларын бөтен яктан чәчәк аттыруга һәм акрынлап бер-берсенә якынайтуга юнәлтелгән ленинчыл милли политиканың уңай йогынтысы яңа көч белән чагылды. Без бөтен уңышларыбыз өчен партиягә, совет халыкларының һаман ныгый барган дуслыгына һәм үсә барган хезмәттәшлегенә, өлкән туганыбыз бөек рус халкының ярдәменә бурычлы. Без киләчәктә дә халыкларыбызның какшамас дуслыгын һәм интернациональ бердәмлеген ныгыту өчен нык торып көрәшербез. Хезмәт ияләрен гомуммилли горурлык һәм Ватаныбызга мәхәббәт рухында тәрбияләрбез.

Киеренке иҗади хезмәт белән кайнаган бу елларда партия эшенең форма һәм методларын яңарту һәм үстерү, аның нәтиҗәлелеген арттыру, массалар белән элемтәне ныгыту процессы барды. Үзәк Комитетның партия төзелеше өлкәсендәге күрсәтмәләрен аның оештыру-партия эше бүлеге нәтиҗәле һәм оператив рәвештә тормышка ашырды, бу елларда ул җирле партия органнарының эш дәрәҗәсен күтәрүдә бик күп яхшы эшләр эшләде. Кадрларга эшчән һәм кайгыртучан мөнәсәбәт урнашты. Партия тормышының бу нормаларына зур әһәмият биреп, без партия һәм дәүләт дисциплинасын тагын да ныгыту, кадрлар һәм партия оешмалары эшенә таләпчәнлекне күтәрү зарурлыгын аңлыйбыз. Бу турыда КПСС Үзәк Комитетының отчет докладында бик ачык һәм нигезле итеп әйтелде. Эштәге ялгышлар һәм кимчелекләрне төзәтүдә сыналган метод булган тәнкыйть һәм үзара тәнкыйтьне һәрьяклап үстерү җәмгыять тормышының барлык якларына җитәкчелекне камилләштерү, яңа бишьеллыкта партиянең экономик политикасын, гаять зур төзелеш бурычларын уңышлы рәвештә тормышка ашыру максатларына торган саен ныграк хезмәт итәчәк.

Иптәшләр! Партиянең Татарстан өлкә оешмасы КПССның XXV съездына идея ягыннан тупланган, оештыру ягыннан ныгыган, хуҗалык һәм культура төзелешенең тагын да зуррак һәм катлаулырак бурычларын үтәргә әзер хәлдә килде. Ул киләчәктә дә данлы партиябезнең сугышчан отряды, ленинчыл Үзәк Комитетның ышанычлы таянычы булыр, дип съезд делегатларын ышандырырга рөхсәт итегез. Татарстан коммунистлары һәм барлык хезмәт ияләре КПССның тарихи XXV съезды карарларын тормышка ашыру өчен зур энергия белән эшләрләр, үзләренең бөтен көчләрен социалистик Ватаныбызның куәтен тагын да ныгыту эшенә бирерләр.

Илдар Юзеев

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

## Унике аккош

Бу нинди аклык,
Бу нинди балкыш?
Аяз күкләрдә
Унике аккош.
Илләргә кайта
Кошлар берьюлы —
Җәлилчеләрнең
Ахыргы җыры.
Илләр өстеннән,
Күлләрдән оча,
Егетләр туган
Җирләрдән оча.
Димнәрдән оча,
Сакмардан оча,
Илнең аклыгын
Сакларга куша.
Тирбәлә ул җыр
Яз, көзләрен дә
Халык күңеле
Диңгезләрендә.
Унике егет
Аккош юлында,
Алар гомере
Аккош җырында.
Аккошлар җырын
Аклыйсы иде,
Җирне саф килеш
Саклыйсы иде!
Саклыйсы иде!

## Өч авылдан чыккан өч гали җан

Өчиледән чыгып киткән Тукай,
Шигъриятнең серле йомгагын,
Очын табып ерак гасырлардан,
Миллион күңелләргә чорнадың.
Сыркыдыдан чыгып киткән Такташ,
Шигъриятнең серле йомгагын
Сүтә-сүтә, киләчәккә илттең
Заманыңның шашкын моңнарын.
Мостафадан чыгып киткән Җәлил,
Шигъриятнең серле йомгагын
Сүтә-сүтә, дөнья буйлап киттең,
Үлемсезлек җырын җырладың.
Өч авылдан чыккан өч гали җан
Биеклектән карап көтәрләр:
Серле йомгак очын, югалтмыйча,
Кемнәр кая алып китәрләр...

# Унөченче

*Баллада*

Егетләр унике булганнар
Аяусыз үлемгә барганда.
«Юк, унөч, унөч!» дип кабатлый
Күңелем һаман да.

Унөченче...
Ул булган егетләр янында
Иң соңгы йөзенче адымда,
**Башларын** югары күтәрткән
Һәлакәт алдында.

Дөньяның килерен хәл итеп
Булмыйдыр тәвәккәл ир-атсыз,
Һәрберсе белән дә үлемгә
Кергән ул чиратсыз.
Бер булып киткәннәр егетләр,
Сайларга бер генә юл калган.
Унөченче...
Ул калган
Һәм китеп... хәбәрсез югалган.

Унөченче...
Ничә ай, ничә ел эзлим мин,
Табалмыйм, җанда — бер үкенеч,
Әйтәләр: «Алар бит унике!»
«Юк, унөч!»
«Юк, унөч!»

Унөченче...
Җәлладның балтасы астыннан
Бердәнбер сау калган каһарман...
Мин беләм, ул — исән, табармын,
Ә бәлки табалмам...

Унөченче...
Иң көчле дошманны җиңдем дип,
Җай саен кычкырмый торгандыр,
Ул тыйнак, дуслары сымандыр,—
Табалмыйм шуңадыр.
Баһадир икәнен белмичә,
Тын гына, шау-шулар эчендә,
Янадыр, көядер, сөядер
Дуслары өчен дә.

Унөченче...
Ул калган
Һәм китеп... хәбәрсез югалган.
Иң соңгы йөзенче адымда
Мусалар җырлаган моңлы җыр...
Моңлы җыр — билгесез каһарман.
Мин беләм: син исән, табармын.
Ә бәлки табалмам...

●

Атлап киләм,
йомшак кына басып
яфрак-келәмгә.
«Алтын көз»...
Ә ник алтын?
Мин чагыштырмыйм
берни белән дә.
«Яфрак-тәңкә»...
Ә ник тәңкә?
Мин чагыштырмыйм
берни белән дә.
Атлап киләм,
йомшак кына басып
яфрак-келәмгә...

Ник алтын?
Ник тәңкә?
Юк!
Мин чагыштырмыйм
берни белән дә,—
Дөнья базарында
мин бу көзне
алыштырмыйм
берни белән дә!
Берни белән дә!
Атлап киләм,
йомшак кына басып
яфрак-келәмгә.

## Карбышев урамы

Өй — җылы.
Мин карыйм
тәрәзә аркылы.
... Тышта — кыш.
Зәмһәрир
декабрь салкыны.
Үзәккә үтәрлек
суык җил,
сызгырып,
килә дә әйтә күк:
«Кемнәрдер, кайчандыр
калганнар боз булып»...
Өй — җылы...

●

Күнеккәнбез:
һәр иртәне
Кояш калка да бата,
калка да бата,
китә дә кайта,
китә дә кайта...
Әйтик:
бердәнбер көнне
Кояш кире кайтмаса?
Чулпан калкып таң атмаса?
Кошлар сайрап уятмаса?
Шәфәкъ нурында җемелдәп,
агымсулар акмаса?
Җир йөзен,
бар Галәмне
караңгылык капласа?
Җан иясе бу дәһшәттән
чыгу юлын тапмаса?..

Бердәнбер көнне
Кояш кайтмаса?
Кеше нишләр иде?
Ул,
күкрәгеннән изге нурлар алып,
күккә ашар иде,
Кояш ясар иде.
Караңгылык мәңгегә
кайтмаска качар иде.
Бердәнбер көнне
Кояш кайтмаса?
Бу бары тик куркыныч бер уй гына.
Кояш калкыр да батар,
батар да калкыр,
мәңге нур чәчәр!
Ә менә Кеше күңелендә Кояш батса —
Җир ничек яшәр?!

• •

Дөньяда мин кырык яз күрдем:
Язларның авырын аз күрдем,
Карда да, бозда да яз күрдем,—
шунлыктан
мин риза
һәр елны кимегән яз, кыштан,
артыгын сорамыйм язмыштан.
Дөньяда мин кырык җәй күрдем,
Җай эзләп йөрмәдем, җай күрдем,
Эшемнән ямь табып җәй күрдем,—
шунлыктан
мин риза
һәр елны кимегән җайлардан,
тир тамган җәйләрдән.
Дөньяда мин кырык көз күрдем,
Дөньяда мин кырык кыз күрдем,
Шуларның тик берсен үз күрдем,—
шунлыктан
мин риза
һәр елны бер яфрак өзелгән
гомерем көзеннән.
Дөньяда мин кырык кыш күрдем,
Дөньяда мин кырык дус күрдем,
Дусларның ихласын хуш күрдем,—
шунлыктан
мин риза
һәр елны кимегән дуслардан
һәм кырыс кышлардан.
Белмим мин: бу җирдә тагын да
Ничә яз, ничә кыш үтәрмен...
Тик беләм:
бар кылган эшләрне,
кырык ел табылган дусларны,
кырык ел табылган ярымны
Дөньяга калдырып китәрмен.

●

Юеш тә дым... Дым да юеш...
Яңгыр да яңгыр...
Ә син яңгыр яуганда да
Яшен булып ян бер!
Нур да кояш... Кояш та нур...
Их, бер тамчы яңгыр?
Ә син бар җир янганда да
Яңгыр булып яу бер!

●

Икеләнми киттек сезнең арттан,
Басып эзер эзгә,
Фатихагыз һаман күңелебездә,
Аксакаллар,
Рәхмәт инде сезгә!
Ә без хәзер мөстәкыйльләр инде,
Сездән бераз үзгә,
Сез дигәнчә уйламасак әгәр,
Аксакаллар,
Рәнҗемәгез безгә,
Хакыйкатьне ярып салсак әгәр
Туры карап күзгә...
Сез үзегез безне өйрәттегез,
Аксакаллар,
Гадел, тугры сүзгә.
Рәхмәт сезгә!

●

— Әй, Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?..
— Чүлләрдә сусаган кешегә
Чишмәдән су илтеп барышым.

— Әй, Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?
— Ачлыктан тилмергән, йөдәгән
Балага нан илтеп барышым.

— Әй, Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?
— Диңгездә бәлагә очраган
Корабка ярдәмгә барышым.

— Әй, Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?
— Йорт-җирен су баскан кешегә
Диварлар төзәргә барышым.

— Әй, Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?
— Барасы юлыма корылган
Диварны сүтәргә барышым.

## Ай сонатасы

Төн.
Тын.
Тиздән — таң атасы.
Урамнарда
Илаһи моң:
«Ай сонатасы».
Җир тирбәлә
Галәм-бишегендә.
Ә Ай-әни
Көйли бишек җырын:
«Балам, уян,
Ишет әнкәң моңын».
Җир уянды
Һәм ишетте көйне...
Тик Ай соңгы нурын сипкән иде,
Бөтен моңын, нурын Җиргә биреп,
Ул таң белән сүнеп киткән иде...

## Әкияттән аерылу

Кавказ якларына килү белән,
Биек тауларына үрләдем.
Бала чакның шомлы әкиятләре...
Үзем мендем, үзем шүрләдем.
Каф тау артындагы диюләрне,
Алтын сарайдагы гүзәлне,
Аны өзелеп сөйгән шаһзадәне
Күрмиенчә күңелең түзәрме?
Кара болытларга үрләдем дә
Башым күккә тигәч шүрләдем...
Җен-париләр ләкин күрмәдем мин,
Сарайдагы кызны күрмәдем.
...Хыял кыясына үрләгәндә,
Тормыш тауларына менгәндә,
Әкият кебек садә, беркатлы чак
Югалдымы кырыс җилләрдә?
Нигә мендем Кавказ-тау башына?
Сабый җаным калды бушанып.
Бала чакның гаҗәп әкиятенә
Йөрер идем һаман ышанып.
Тау башына мендем бала булып,
Түбән таба төштем олаеп,
Каф тау артларына китеп барган
Кичке кояш кебек моңаеп...
Өлкәнлегем, реаль тауларга мен,
Тугры хыялыңнан каерылма.
Аерылсаң да серле әкияттән,
Сабыйлыктан әмма аерылма.

1973—1975.

## Әхсән Баянов

# ТӨЛКЕ ТОТУ КЫЕН ТҮГЕЛ

ПОВЕСТЬ

Тау ягының таулары,
Өзелә камыт баулары.
Камыт бавын ялгый-ялгый,
Сызыла йөрәк майлары.

*Халык җыры*

## Капка ачканда

Безнең этине ник Тата[1] дип мыскыллыйлар, әни?

— Мыскылламыйлар, Тата абый дип олылап әйтәләр аны, кызым.

— Ә-ә... Безнең эти бик көчле, бик олы.

— Гәүдәгә бик кечкенә, чебеш кенә.

— Ә мине кырлы курай дип мыскыллыйлар.

— Күп сикерәсең, аз ашыйсың, шуңа күрә бик ябыксың, үсмисең.

— Ә үссәм, мине дә Тата кеше диярләрме соң?

— Берәр төрле батырлык эшләсәң, әйтерләр.

— Эти батырлык эшләгәнмени? Ник аны көчле кеше диләр?

— Ул бер генә кешене дә рәнҗетмичә яши белә, кызым.

— И-и, алайса, юаш бит ул, көчсез.

— Аңламыйсың шул әле.

— Ә безнең эти өченче көн генә мине акыра-бакыра өй түбәсеннән куып төшерде. Кичә, үзеңнән олы малайларны кыйныйсың дип, чыбык чыжлата-чыжлата куды. Ярый әле, каты йөгерәм...

— Үскәч, үзең уйлап дигәндәй, төшенерсең әле, кызым.

**Хәтерләү**

---

[1] Тата — зур, көчле дигән мәгънәдә. Тата абый — зур абый. Тау ягы сөйләше.

*

* *

Хәзер инде аның әнисе дә юк, әтисе дә. Кырлы курай дигән ул кыз бала — үзе ана хәзер. Ләкин гомерләрнең алмашынуына ышанасы килми. Буш өйгә кунакка кайта да, хатирә күлләренә чумгандай, уйлана.

*

* *

Таң белән тәрәзә кактылар.

— Әйдә тизрәк!

Тата уянды. «Кем йөри икән болай иртүк?»

Уянгач та туган беренче уена җавап көтеп, шактый вакыт тыңланып ятты. Башта кемдер ишеккә таба атлагандай тоелса да, бераз гына кыштырдады да, никтер, эз алыштыргандай, тиз арада юкка чыкты.

Кышын кар өстендә шундый эзләр кала. Җор җәнлекнеме, аучынымы алдау нияте белән, куян кинәт кенә читкә сикерә. Сикергәч, карга күмелә дә дошманы узганчы шым ята. Куркыныч хәерле генә узып китсә, сак кына кузгала — аннары җан-фәрманга түгел, рәхәтлек өчен сикерә-сикерә, эзләр яңарта.

Таң кунагы да ишеккә җитмичә тукталды. Тукталды һәм юкка да чыкты. Тата тавыш кабатланмасмы дип көтсә дә, утар як тәрәзә йөзлеге калтыраудан башка тавыш һәм бернинди җан әсәре сизелмәде. Кунак дигәне бүре-мазар түгелдер ич? Алай дисәң, элеграк еш килсә дә, хәзер ул усаллар күренмәгәнгә байтак гомер инде. Төлке-мазармы? Төлке булса, сүз әйтмәс, шатланыр гына иде хуҗа. Ләкин төлке-шаян да хәзер сирәк күренә. Шаярып кына тавык-үрдәкне чәлдергән чаклары булгаламый түгел, булгалый. Мәгәр, кызганычка каршы, бик тә сирәк. Әллә тагын шул сирәк күренә торган сөекле кунак килгәнме?

Җавап табылмаган арада, Тата кулларын өскә күтәрде дә, бармакларын кыймылдатып, аякларын тарткалап-сузгалап ятты. Бу хәрәкәтләр — бала чактан ук килгән, көн саен кабатлана торган шөгыле. Үзен белә-белгәннән бирле беркайчан да кинәт сикереп тормас. Әнисе кечкенә чактан ук аны: «Кинәт сикереп торсаң, аяк-кулларыңнан төнлә чыгып киткән җан кире кайтып керергә өлгерми кала», — дип өйрәтә торган иде.

Җан кайтып җитәргә бик ашыкмаганлыктан, быел яз андый хәрәкәтләрне бигрәк тә тырышып ясый башлады ул. Хәзер язгы кояш, рәхмәт төшкере, өшән сөякләрне җылытып, яңадан тернәкләндереп җибәрде.

Шуңа күрә, нинди кунак булса да, күсәк күтәрү нияте юк иде Татаның. Хәтта бүре килсә дә. Күптән инде эшсезлектән тутыгып беткән сынык мылтыгын да бимазаламыйча, өстенә кыска тунын, аякларына гел кия торган кирза итеген элеп, ишеккә юнәлде.

— Кая барасың таң белән, сиңайтәм?

— Болай гына. Син йокла.

Ишекне ачуга, аяк арасыннан төн буе браматлыкта йөргән мәче кереп китте. Әллә шулмы тәрәзә каккан кунак? Юктыр, мәче шытырдый гына белә.

Белә-белгәннән бирле, каршысына мәче очраса, бигрәк тә юл чыгар алдыннан булса, Татаның кәефе челпәрәмә кырыла да төшә. Андый чакларда ул мәчене я башындагы бүрек белән бәреп егар, бәреп егарга өлгермәсә, үз гаебен белеп тиз генә сәке астына елдырган мәчене аякларыннан өстерәп чыгарыр да: «Икенче мәртәбә мин чыкканда кермә, каршы очрама», дия-дия суккалар һәм соңыннан җибәргәч тә: «Егылып үлгере», — дип өстәр. Бүген алай кызмады, тузынмады. Беренчедән, бик иртә — карчыгы, Кояш апагыз, ак өй караватында мыш-мыш йок-

лый бирсен. Икенчедән, юл чыгасы юк. Юл чыгулар сирәгәйде, бик нык сирәгәйде. Шуңа күрә мәчегә пыр тузмыйча:

— Үләт ялаган нәрсә! — дип кенә куйды.

Мәчеләрне тәки тәүфыйк-итәгатькә өйрәтү кыен икән. Башсыз җан икән ул мәче дигәнең. Ярата беләме, юхалана беләме, ә хөрмәт итә белми, юньсез.

Өйалдында күзгә ул-бу чалынмады. Ләкин ишекне ачкач...

Нияте бик тә салмак, әкертен генә булса да ишегалдына чыгу иде. Ләкин язгы җил «ә» дигәнче кулдан ишекне тартып алды да өйалды тактасына китереп орды. Ирек куйсаң, Татаның үзен дә күтәреп атар иде. Әмма андый ирекне бирмәс әле ул тиз генә, анысына ук көче җитмәс әле җилнең. Җитәчәк тә түгел. Татаны табигать алай ук мыскыл итә алмас. Һәм ул менә, тотыныбрак булса да, җиргә төште. Ишекне шакылдатып тинтерәтмәсен дип, тырышыбрак булса да аны ябып куя алды. Стенага таяна-таяна, капка төбенә үк килде.

Беркем дә юк иде. Урамда да ак-кара күренми. Абзарда сарыклар матур гына мышный, сыерның көйле генә күшәп яткан көне. Бүре яки төлке исе сизсәләр, күрер идең син аларның тынычлыгын!

Җәнлек тә, кеше дә килмәгән. Ләкин тавыш аермачык ишетелде ләбаса:

— Әйдә тизрәк! — Күктән килгән аваз түгелдер ич?

Күктән шундый яман хәбәр киләчәген Тата сизә. Ләкин көн саен шулай: бүген түгел, иртәгә дә түгел, соңрак, шактый соңрак. Дөрес, барыбер ишетеләчәк аңа күк чакыруы, ләкин ул тавыш ишетелер көн әле кайдадыр ерак, шактый ерак булырга тиеш...

Ишегалды һәм абзар-кура тирәсендә бөтен нәрсәнең тәртипле икәнен күргәч, Тата тынычланды диярлек. Шулай да күңелдә нәрсәнедер сизенү шомы барыбер калды. Икенче бер тәртипсезлек — үзенең нигәдер калтыравын, өшүен абайлады. Җил. Шактый ук холыксыз җил. Суык җил. Менә сиңа яз, менә сиңа гөрләвекләр аккан яз. Мөгаен, боз кузгалгандыр.

Тыңлый торгач, бер нәрсә ачыкланды — утар як тәрәзәнең какшаган тактасы кинәт-кинәт шакылдап куя икән. Таңда тәрәзә каккан дигәне шул булуы бик ихтимал. Әмма моңысын Тата кабул итмәде. Артык та гади нәрсә булып чыга бит. Ә күңел әллә нинди сер эзли. Күңел нәрсәдер сизенгәнгә күрә, әкрен генә бакчага, елга буена төшеп китте һәм... яр буена, өянкеләр янына килсә, бөтен нәрсә берьюлы аңлашылды. Нигә дисәң, өянкеләрдән биш-алты адым чамасында матур гына үсеп утырган алмагач өстенә, әнис дигән кып-кызыл алмалар белән бизәлә торган гүзәллек өстенә, өй хәтле, әйе, арттырусыз, өй хәтле боз килеп яткан иде. Алмагачның хәлен үзең шул боз астында калсаң гына чынлап аңларсың кебек. Җанлы кеше кычкырып яткандай...

Боз тавы...

«Әйдә тизрәк!» дип чакырган кунак, әлбәттә, шушы иде. Аны Тата бер күрүдә таныды...

Аркалары чымырдап, әчләре жу итеп китте. Өянкеләр жуылдаганнан һич ким түгелдер...

*
* *

Үләмә — кечкенә бер инеш. Җәй көне юаш кына, тыныч кына агып ята. Басмалар салынмаган булса, чалбар балакларыңны сызган да, бернидән шикләнмичә, чык аркылы. Кыш көне дисәң, ул бөтенләй юк шикелле, үзәннәр белән тигезләнә, мескенәя. Ләкин яз җитсә!..

Яз җитсә, тыныч һәм мескен яткан барлык көннәренең үчен кайта-

ра ул. Әллә кайлардагы биеклекләрдән, тау өсләреннән төшкән кар сулары дәррәү җыела да тыйнак төсле тоелган елгаларның астын өскә әйләндерә — үзәннәр кайчакларда Идел шикелле олы дәрьяга әверелә. Бозлар ага. Боз өсләрендә яна-яна учаклар ага... Терлекләр ага — һәлакәткә таба... Билгеле, мондый чакта олы-олы бозлар яр буйларында да утырып кала. Кечкенә инешләрдә шул хәтле зур бозлар каян чыга икән дип, гомер буе яшәп тә гаҗәпләнәсең.

Әйе, бозлар олы, бозлар күп, ләкин мондые сирәк. Монысы Татаның озын гомерендә ике генә тапкыр килде.

Язгы кара боз җибәргән өшеткеч тавыш:

— Әйдә тизрәк!..

Менә ни өчен салкын икән бүген, менә нинди шом Татаның күкрәген яндырып, бөтен гәүдәсен калтырата икән. Туганнан бирле туктаусыз яшәлгән гомер тәҗрибәсе, сизенү көче менә нәрсә әйтә: озын кыш буе укмашкан кара салкынлык Татаның чиста күңеленә үзенең инәлүсез имзасын төшерде, озакламый боз урынында җыелып калачак алама пычрак шикелле мөһерен аның язмышына чәпәде... Мәгәр Татаның бөтенләй югалып калырга нияте дә, хакы да юк.

Мөмкин кадәр ашыгып, ишегалдына кайтты Тата. Әлмисактан бирле келәт астында яткан ломын өстерәп чыгармакчы иде — көче җитмәде. Заманнар! Бар иде бит кулда бу тимерне агач таяк шикелле генә уйнаткан җинел чаклар! Ай-һай! Кая китте көч? Бер дә бетмәс шикелле иде бит, югыйсә!

Күтәрмә янында өй почмагына сөяп куелган көрәкне күтәреп караса, кәефе баягыдан да ныграк кырылды. «Калай белән тетәрсең тау хәтле бозны!» Ачуын көчкә тыеп, көрәкне чак атып бәрмәде. Кире урынына бастырып куйды да киртә эчендәге сәнәккә күз салды. Тагын үртәлүдән башка нәрсә тапмады.

Нәрсә соң, нәрсә сайларга? Татаның әле хәтере тишек иләккә әверелмәгән — анда кайбер әйберләр әле саклана. Әйтик, келәт астында ломнан ерак та түгел Тата яшь чакта Донбасстан алып кайткан шахтер кәйләсе ятамы! Артык авыр нәрсә түгел, кирәге чыгар әле дип, меңнәрчә чакрым җирдән күтәреп кайткан иде ул тимерне. Тиле тимергә кызыгыр дип, күрше-тирәнең мыскыллаганы да онытылмаган. Дөресе шул — кирәге бөтенләй чыкмады диярлек. Әмма бүген... Тимер сабырлык үз морадына ирешә — кәйлә хәзер еллар буе җыелган бөтен тутыгын берьюлы коячак! Бераз гына тамак ялгап алгач та.

Кояш апа өстәлгә парлары чыгып торган бәрәңге һәм самавар утырткан иде инде. Катырак һәм салкынрак булса да, ит тә бар иде. Тата куелган ризыктан әз-мәз генә авыз итте дә янадан киенә башлады. Иртәнге чәйдән соң бераз ятып тора торган гадәтен белгән карчыгы гаҗәпләнеп куйды:

— Синайтәм, эшем кешесе кебек кая ашыгасың?

— Кешенең үлгәч тә өч көнлек эше кала.

— Син калдырмаска дисеңме?

— Калдырмассың. Анда әнә яңа эш әле. Алмагач өстенә боз яткан. Өй хәтле.

— Менә сиңа... алла сакласын.

— Шуны ваткаларга кирәк.

— Синайтәм, булышма, ходай үзе китергәнне үзе алып та китәр. Эреп бетәр, алла кушса.

— Якын-тирәдәге күпме агачның тамырына суык җибәреп, бакчаны чәчәксез калдыргач эрер дә бит.

— Суык белән булышып, үзеңә салкын тияр, шул булыр.

Киенеп беткән ире тәрәзәдән көлеп торган кояшка хуш килерлек итеп елмайды гына:

— Я боз, я мин — икебезгә берьюлы урын юк.

— И-и, котырган!

Кояш апа кәйләсен аркасына күтәргән Татаны бакча капкасыннан кереп күздән югалганчы карап калды.

*
* *

Боз янына килеп җиткәч, Тата бер нәрсәгә илтифат итте: бозның кара гәүдәсе кояш җылысыннан инде юешләнә дә башлаган икән. Астагы бер почмагына итеге белән типкән иде, ким дигәндә йодрык хәтле боз кителде дә төште. Кителеп төшкән кисәккә итек очы белән генә баскан иде, боз кисәге валчыкларга, ә валчыклар исә күзгә күренеп тамчыларга әйләнде. Менә шулай итеп, кояш иптәш белән бергәләп эшли торгач, бу бөтен тау бихисап вак кисәкләргә әйләнеп, юкка чыгачак.

Тата кәйләсен күтәрде дә бөтен көченә китереп сукты, ләкин беренче юлы артык зур уңышка ирешмәде — кулы янгырап китте, ә боз чак кына, күзгә кырып салырлык кына дигәндәй, кителеп төште. Зурдан купмыйча, баягыча, почмаклардан башларга кирәк икән. Кайчандыр ерак заманнарда дөнья җылысы буларак тупланган ташкүмерләрне күз алдына китерде. Кайчандыр гомер башында шул күмерләрне җир астына төшеп вата белгән кеше хәзер, һөнәр яңартып, бозның үткен почмакларына сугарга керешге. Йодрык-йодрык бозлар читкә тәгәрәде.

Күпмедер эшләгәч, Тата ютәле кузгаласын сизде дә куыш артына, ышык урынга килеп утырды. Бераз йөткергәч, куышның коры саламына баш куеп, күзләрен йомды. Кояш битне рәхәт иркәли һәм бу рәхәтлек яшьлек елларына охшаган шикелле иде. Әллә шуңа, тиз арада Татаның күз алдына беренче хатыны Җиһан килеп җитте.

Җиһан...

Исеме генә дә ни тора бит — дөньяның үзе!

Хур кызларыннан да изгерәк һәм сафрак иде ул. Беренче мәхәббәт, саф һәм изге никах. Искә төшсә, дөньядан ямь оча, бәхетле тормышны салкын суккандай тоела.

Һай! Һәркемнең яшь чагы була, яшьлек өметләре, кабатланмас көннәре — канатсыз очкан чаклары була. Тата абыегыз да кайчандыр шук малай, шаян бер егет иде ләбаса! Бик күпләр кебек, гади җир, садә туфракны таптап йөрсә дә, өметләре кул җитмәс биектә иде. Хыял гына җитәрлек биеклектән елмайган кыз җиде чакрым ераклыкта, Әҗем дигән авылда яши. Якын-тирәне телгә дә алмастан, кызга еракерак җирләрдән яучылар килә. Әмма нигәдер әти-әниләре, кызыбыз яшь әле дип, беркемгә дә бирми торалар. Әллә тиңнәре табылмаган, әллә биш-алты ир бала арасында үскән бердәнбер кызны үз канатлары астыннан чыгарасылары килмәгән. Шулай яши торгач, кызга егерме тулганны сизми дә калалар. Ул чакта егерме яшьлек кыз! Һәм кызда ашыгу, курку хисе кузгала. Тата исә күз төшкән кызны тиз генә онытa торган, дөнья арбасыннан төшеп калган гамьсез егет түгел. Вакытын белеп бәхетен сыный. Ләкин кызны аңа да бирмиләр... Җай табып кызны күрә дә...

Тата кич белән берүзе ат җигеп, кыңгырау чылтыратмый гына Әҗемнең чишмә буена килеп туктый. Кыз да озак көттермичә килеп җиткәч, тиз арада җән-фәрманга чабарга керешәләр.

Җәйге кичнең җиләс җиле колакларда гармунсыз да искиткеч матур көй сыман чыңлый, битләрне генә түгел, күңелләрне кытыклый, аркаларны чымырдата — законсыз бәхет әчкелтем-татлы. Җитмәсә, артларыннан беркем дә куммый — сизмәгәннәр, ахрысы. Әмма егет атны һаман ашыктыра, куа, чаптыра. Тик ашкындынмы — хәерлегә түгел инде ул. Ярты юлны узгач... кинәт...

Ярый әле, арба астына тәгәрәмиләр. Ат арбадан ычкына. Ычкынса да, чабуыннан туктамыйча, Татаны өстери. Дилбегәгә уралып, бәлки ул очкан да булыр иде, ләкин ниндидер күз иярмәс хәрәкәт белән кыз дилбегәнең бер ягыннан эләктереп ала да атны кинәт читкә каера. Икесе дә аңга килгәндә шундый хәл: ат сәерсенгәндәй муенын сузып, кияү белән кызга карап тора. Тата тарантас утыргычына бәрелгән ияген уа, дилбегә кыз кулында, ат тугарылган.

Тата атны җиккән чакта ук ашыккан, каушаган икән. Әгәр хәзер шушында куа килсәләр? Беткән иде баш. Бәлки әле куа да торганнардыр? Кияү тагын ашыга, тагын каушый: дуганы камыт бавына кертә алмыйча җәфалана, чөелдерекне бәйли алмыйча интегә. Атны көч-хәл белән җигеп, тагын куарга керешә, ат тагын дулаган кебек чаба. Шулай чапса да, нигәдер, хур кызыдай чибәр, ләкин законсыз кәләшнең генә түгел, инде мут кияүнең үзенең дә сөмсерләре коела — әле кайчан гына җаннарны җилкендергән шатлык, колакларны чыңлата-чыңлата каядыр очкан кечке җил белән бергә, каядыр китеп югала. Салкынлык тоелмый тоелуын, юк, ләкин инде көләсе килми... Кайда ул көләсе килү, хәтта елыйсы килгән кебек.

Кыз алып кайтканда ат тугарылу хәтәр фал бит ул.

*
* *

Кияү белән кәләш законсыз хәлдән бик тиз чыгып, хәләлгә әйләнделәр — артык шаулатмасалар да, үзләренә күрә матур гына туй ясадылар. Кыш үтүгә, башка да чыктылар. Төп йорттан ике-өч кенә өй узгач, әлеге дә шул Үләмә буенда яңа өй калыкты. Һәм менә шундый көн җитте: тормыш кору мәшәкатьләре белән тәмам хәлдән таеп, аңсыз-фикерсез генә кич йокыга талса, иртән инде Тата үз өендә чын хуҗа булып уянды.

Ишегалдында — яңа тормыш.

Өй янына җыелган кар суында казлар юына. Тирә-якны яңгыратып ата каз каңгылдый, абзар тирәсендә тавыкбикәләр кытаклаша, әтәч тавышы, җиңгән гаскәр быргысы шикелле, яңа көн тууын бөтен галәмгә җиткерергә тырыша сыман.

Тата әтәч тавышын гомумән тыныч кына тыңлый алмый. Ул аңа барча кош-кортларга караганда да ныграк гашыйк. Әтәчсез крестьян тормышын бөтенләй күз алдына китерә алмый ул. Башка чыкканда әни-әтисе биргән барлык бүләкләрдән бигрәк, үз көче белән юнәткән шушы кылыч кикрикле әтәче шатландырды — хәтта тавыкка караганда да ныграк сөендерде.

Төп йорттан күчкән аталы-аналы казга һәм ике бөртек тавыкка менә шушы бер әтәч җитмәгән иде. Карагыз, дөньяны ничек ямьләндереп йөри, хуҗалары бәхетен бөтен дөньяга яңгырата. Башка кош-корт та шәп, әмма әтәч әтәч инде ул, иптәшләр!

Күрше Хәлил картка кар базы казып алган бер тәңкә акчасы бар иде — шуңа ул Бәки базарыннан, иш янына куш дип, шушы әтәчне — бәхет кошын сатып алды. Сатып алды да калын һәм шактый тупас киндер капчыкка салып, өенә алып кайтты. Өйгә кайткач, капчыктан чыгарып, ишегалдының нәкъ уртасына, чирәмгә куйды. Әтәч бераз аңгы-миңге селкенгәләп торса да, күп тә үтми, исәеп, тирә-якны караптикшереп чыкты. Тата дөньясын ошатты ул һәм, әлбәттә, тиз арада үзләшеп тә китте. Канатларын шап-шоп кагып, кычкырып ук җибәрде. Әтәче кычкырып җибәргәч, хуҗа шаркылдап-шаркылдап, аунуйаунуй көләргә кереште. Әгәр тирә-күршесеннән кем дә булса күрсә, акылдан язган бу дияр иде. Акылдан язмаган иде кеше — күкрәгендә җыелган шатлыкка чыдый алмыйча, дөньяның иркенлегенә, күк йөзе-

нең сафлыгы һәм биеклегенә, яшәү дигән нәрсәнең шушы якты көн шикелле матур булуына, ләззәтенә түзә алмыйча көлә иде. Күршеләре күреп, акылдан язмаганын аңласалар да, барыбер көләрләр, һич югы, бәет чыгармыйча калмаслар иде. Ул чакларда авылда була торган һәр мәзәк хәлгә бәет чыга иде. Шәһәргә баргач, шунда юлдашының тунын сатып эчкән Гариф дигән кешегә, Бәки базарыннан сарык дип тәкә алып кайткан Сөнгатькә эчең катып көлмәле бәетләр чыгаручы кеше — Тата үзе, Идел аша болынга печәнгә чыккан — паромнары таркалып суга баткан кызларга багышлап чыгарылган, типсә тимер өзәрлек ирләрне елатырлык бәетләрнең авторы да Тата иде. Көлкеләләрен күбрәк чыгара иде. Еларга сәбәп болай да күп, сөендерергә кирәк адәм баласын, ди торган иде ул бәет чыгара белгән бүтән кешеләргә дә.

Елауны яратмады, гомер буе көлкене яратты Тата. Авыл халкы әйтмешли, бигрәк йогаш, бигрәк кызык итеп сөйли дә белә иде. Бәет һәм вәгазьләр сөйләп колхоз идарәсе йортында күпме таңнар аттырган ул! Армиягә киткән егетләр хатында: «Авылны, Татаны сагынабыз», дигән сүзләр еш килә. Һич тә гаҗәп түгел. Тата — авылның җаны, күңелле мәгънәсе иде...

Язгы бер көнне кырда сука сукалап кайткач һәм чабаталарын чишеп каккач, Тата болдыр баскычына бераз гына тын алырга дип утырган иде, әлеге дә баягы, сөйгән кошы этәч утар буйлап күкрәк кагып дигәндәй йөри. Атлаулары — горурлык, тәкәбберлек вә мин-минлекнең нәкъ үзе, билләһи. Шулай матур гына йөри торган бермәлдә... Каршы як өйдән шундый ук тәкәббәрлек белән Хәлилләр этәче (кунакка кергәндә тиешле тыйнаклыкны башына да китерми, мәлгунь!) Таталар ишегалдына кукраеп та керде, канатларын шапылдата-шапылдата, хуҗа этәчен таларга да кереште. Этәч халкы шул чаклы әшәке нәмәрсә икән. Тата этәчен үз җиренә басып кереп талый бит, хуҗа этәченең кылыч сыман кикрикләрен кай арада кара канга батырды. Аннары урам буйлап куып йөртергә тотынды. Бу хәлне күреп торган Тата никадәр ачуы купканны үзе генә белә. Әйе, этәч бәгыре башта вакытлы бирешә, хуҗадан гына ояла сыман тоелды. Түзде хуҗа, ачуын тешләре белән кысып түзде. Әмма яшел урам киңлегенә чыккач, сөекле этәче бөтенләй мескенәеп сугыштан качарга, чабарга ук керешкәч, Тата өнсез-телсез калды. Кыйналган, канга баткан этәчедәй башын салындырып, капкага сөялде. Нәкъ шул вакыт сукадан Хәлил үзе кайтып килә икән. Бөтенесен күргән! Алай гына да түгел, күршесенең үзен дә, этәчен дә: «Адәм көлкеләре!» дип шәрран яра-яра, акыра-бакыра көлә башлагач, бүтән чакта җор телле Тата ләм-мим сүз әйтә алмады. Моннан да мыскыллырак, хурлыклырак җиңелүнең булуы мөмкин түгел иде. Үзен этәче сыман ук чукылган, канга баткан, мескенәйгән тоеп:

— Мин бу этәчне асрап ятаммы, мин аны суеп кына ашыйм! — дип мыгырдады.

Хурлыгын дөньяга икенче юлы чәчеп йөрмәсен дип, капыл урам уртасына килде дә авызлыклы йөгән белән күрше этәчен үзе бәреп екты. Егетлек түгел иде монысы, белде Тата, бик тә, бик тә яхшы сизде, әмма ләкин йөрәк ярсуын тыя алмады. Көчсезлек бәласе озак көттермәде: каршы капкадан Хәлил атлы күрше кыяфәтендә ялт килеп чыкты да, йодрыкларын төя-төя:

— Этәчемне имгәтсәң, судка бирәм, кяфер! — дип акырды. Акырып кына калмады, Тата дигән күршесенең якасыннан ук эләктереп алды. Әгәр үз гаебен сизгән күршесе үзен тыеп калмаса, нәкъ этәчләр хәленә төшәселәр иде.

Хәлилнең карчыгы, кыртлаган тавыктай, бигрәк тә чәпчеде, әллә ниләр сөйләп бетерде — ишетеп, истә калдырып бетерерлек түгел иде. Бер генә юлы калды Татаның — үч кайтару, бая күрше этәчен кыйнаган кебек, үз этәченең җанын алу. Дөрес, алай ук булмады. Этәчен,

кызгана-кызгана куып, үз ишегалдына кертте дә атна буе шөмерәеп йөрде.

Җиңелү әчесе! Әҗәл генә бардыр аннан әчерәк.

Бер көнне, иртән сабанга киткәндә, хатынына шәп итеп мунча ягарга, кибеттән аракы, Черныш дигән күрше авылның Петруха атлы кешесеннән кузаклы кызыл борыч алып кайтырга кушты:

— Җепкә тезелгән борыч Петруханың чормасы тулы — иң кызылларын гына сайлап бирсен,— диде.

Кич сукадан караңгы төшкәч кенә кайтыла. Өйгә кереп тә тормастан, инде кунакчага менеп утырырга да өлгергән сөекле кошын кыранлата-кыранлата, тәпиләреннән күтәреп алып та төште, хатыны кулындагы сөлгесе белән төреп, култык астына кыстырды да ындыр башындагы мунчага җилдерде. Чишенгәндә дә әтәчен кулдан ычкындырмый гына чишенде, кулдан ычкындырмый гына себерке пешерде һәм, мунча ташын шартлата-шартлата эссе салгач, утлы парда аны ныклап чабарга кереште. Сөекле кошы әлсерәп авызын ачканчы чапты һәм соңыннан аны мунча ишегалдына чыгарып яткырды да аннары җан-фәрманга үзе чабынды.

Сөякләре балавыздай йомшарганны сизгәч, нәкъ әтәче төсле авызын ачып, мунча алдына чыкты. Әтәч бераз исәйгән булса кирәк, хуҗасы кагылуга каркылдап, канатларын селкетеп, аннары жыеп ук куйды. Хуҗа исә мунча тустаганы төбенә азрак аракы һәм шунда ук кузаклы борычны уып салды да әлсерәүдән әле дә ачык яткан әтәч томшыгын шул тустаганга тыкты. Булыкмасынга дип, әтәчнең башын әледән-әле күтәргәләп торды. Бераздан тагын аракы өстәп, тагын шактый азаплангач, ак ыштан гына киде дә, калган киемнәрен һәм әтәчен култыкка кыстырып, өенә кайтты. Әтәчне мич астына ыргытты.

— Миннән башка урамга чыгарма бу юк нәмәрсәне,— диде Җиһанына.

Әтәч бер атналап «өтермәдә» ятты. Һәр көнне төшкә кайткач, ул әтәч белән шөгыльләнә — тустаган төбенә аракы сала, аракыга борыч куша да сыйны идән уртасына куеп, әтәчне чыгара. Беренче көннәрдә әчми аптыраткан кош хәзер озак кыстатмый, идән уртасында савыт күрүгә, мич астыннан җәһәт кенә чыгып, туп-туры шунда үзе килә һәм томшыклары белән савытны шакылдата. Савытны алмак булсаң, талап ук дигәндәй эчә башлый. Шак-шок эчә-эчә шулай күңеле булгач, алпан-тилпән йөри. Аннары бер почмакка бара да егыла. Атна-ун көн азаплангачмы дияргә, бәйрәм иткәчме... әтәч инде ирекә дә чыкты. Ә Тата аңлады шул чак: азаплана торгач, арттырыбрак җибәргән, ахрысы.

Җәйге ямьле көн.

Сабан сөреп талчыккан Тата, чабаталарын көч-хәл белән өстерәп, яшел урам буйлап кайтып килә — күзенә яшеллек тә, ямь дә күренми, әлбәттә. Үзе әйтмешли, эттәй арыган. Шулай үз турыларына якынлашса, чабаталары авырлыкны кинәт җуйды да үзйөрешлегә әверелде. Күзләргә киң урамның кинәт хөр киңлеге ачылды. Киң урамны тар итеп сөекле кылыч кикрик күрше Хәлил әтәчен — әйе, әйе, дөрес бу, хак сүз, әле кайчан гына үзен кыранлата-кыранлата талаган, баш идергән һәм куркудан оят дигән нәрсәне калдырып качарга мәҗбүр иткән ямьсез кара-соры әтәчен — өстенә куна-куна чукый лабаса! Тегесе бернишли алмый. Талашырга томшыкларын сузарлык та кыюлыгы юк — чәбәләнә-чәбәләнә кача. Качкан саен Тата абзаң әтәче аны куып җитә дә сөйкемсез чебешне чукыган кебек чукый гына. Чак кына кузгалырга иттеме, тагын чукый, тагын. Беркөнге хурлыгын, үчен кайтарганы әллә каян күренеп тора. Менә, ичмасам, тамаша! Менә, ичмасам, кәмит! Мондыйны бернинди шамакай адәмнәр дә күрсәтә алмый. Ә менә әтәч...

Тата кулындагы йөгәнен аркасына җай гына салып, койма буенда йөренә. Әйтерсең кемнедер көтә, әйтерсең этәчләр сугышына күз дә атмый, колак та салмый. Хәлбуки, сөенече бөтен авылны әйләнә: «Әй, шаян, әй, шук этәч, әй, сөекле кош! Баһадир, баһадирның баһадиры! Күрдегезме! Кем этәче икән бу, ә? Күрдегезме?! Этәч менә шушындый була ул — күреп калыгыз! Чын этәч күрәсегез килсә, чыгып калыгыз, күрегез!»

Бу сүзләрне кычкырсаң, нишләрләр иде икән — күңелдәген дә халык әнә ничек тиз ишетте, яшел урам «ә» дигәнче кәмит мәйданы булып алды! Халык көлә — бигрәк тә малай-шалай. Хәлил этәче артык боегып калса, шул шук малайлар аны куркытып урыныннан кузгаталар да Тата этәче аңа муеннарын кабартып туп-туры кадала һәм тегесе тагын мескенләнеп кала.

Ул арада Хәлил абзый үзе дә йөгереп чыкты. Йөгереп тә чыкты һәм, мәйданга күзе төшкәч, күргәнен аңына сыйдыра алмыйча, баганадай катты да калды — менә авар, менә гөрселдәп егылыр шикелле иде. Әмма аумады. Бөтен авылны тетрәтеп акырды гына:

— Кансызлар, үләт ялагырлары! Ни дип авыз ерасыз?! Ни дип шаркылдыйсыз?! Үз ахмаклыгыгыздан көләсезме?!

Ләкин шушы ярсынулы акыруга да колак салучы булмады — һаман көләләр, кычкыра-кычкыра көләләр иде. Аптырагач, абзый үз этәчен эттән яман тирги-тирги куа башлады.

— Көш, көш, харам булгыры, көш!

— Харам түгел, түгел, хуҗасына охшаган! — дип кычкырды Тата.

Күршесенең шундый мәсхәрәле сүзләренә дә җавап бирерлек хәле калмаган Хәлил үз этәченә таякны шундый яман атты, әгәр тигән булса, этәченең изге җаны күккә «әһ» дияргә өлгергәнче үк очасы иде. Ярый әле, иң кирәкле чакта ялгыша беләбез... Шулай да ярсуы басылмады — өенә кайта белми аптыраткан кешеләрдән куркып, кая керер тишек тапмый йөдәгән этәчне, ярый әле, бер малай хуҗасына сузды. Хуҗасы исә кошның тәпиләреннән бернинди ихтирамсыз гына (җиңелүчегә ихтирам кайда!) тотты да борыны белән җиргә тиярдәй өстерәп, кул хәрәкәте уңаена селти-селти, беркемгә карамыйча, туп-туры үз капкасына таба китте! Ә малайлар, олылар да, хәтта хатын-кыз да аның артыннан иярде — бөтенесе һаман көлә, һаман шаулаша. Шау-шуга исе китмәгән Хәлил абзагыз хатынына гына акыра алды:

— Чык тиз генә... Тиз бул — пычак чыгар. Пычак! Пычак чыгар дим, мәгънәсез! Сыер төсле әкрен кыймылдама!

Тата тиз генә капкадан кереп (мондый чакта күршегә ничек ярдәмгә килмисең инде!) җирдә аунаган ниндидер чүпрәкне бау итеп ертты да этәчнең аякларын бәйләп тә куйды. Чыраенда һаман көлү галәмәте юк. Кыяфәте хәтта артык җитди түгелме икән әле. Ник дисәң, тамаша кылган олылар, ерык авызларын көрәк куллары белән каплап, тиз арада үз өйләренә шылдылар. Хәлил хатыны пычак чыгаргач, малайлар да шаулашудан туктады. Башларын иеп, алар да кайсы кая тайды. Татаның күз алдында этәчнең гүзәл муенына пычак сузылды. Җиңелүче язмышы...

*

* *

Этәч — крестьянның сәгате. Этәч — крестьянның сәнгате. Иясенең кемлеге, бүтән маллары белән бергә, этәченә карап та беленә. Татага ихтирам бермә-бер артты дисәк, киметү булмаса, һич арттыру түгел. Монысы хак — валлаһи вә билләһи.

Ләкин тора-бара этәч үзенең сәнгатен артыккарак җибәрә башлады. Бөтен авыл этәчләрен куркытып, аларны үз күзенә күренмәскә өй-

рәткәч, бөтен авыл тавыкларын үз сөяркәсе иткәч, аңа монысы да җитми, аңа бөтен авыл урамнары да тар була башлады. Ягъни хәзер кешеләргә уктала Татаның әтәче.

Беркөнне хатыны сыер савып утыра икән, әтәч сыер астына кергән дә чиләккә башын сузган. Хатын аны кулы белән куркытмакчы, куып җибәрмәкче итсә, әтәч дөрләп кабына да шунда тотынмасынмы хатынның кулларын, битләрен чукырга. Тотынмасынмы канатлар белән бәргәләргә һәм суккаларга. Корсагы астында ачы сугыш купканга чыдамыйча, сыер чиләкне аудара да китә. Сөт түгелгән җирдә таеп, хатын артына лып итеп утыра. Утыру гына түгел, чалкан ук ята. Кычкыра, ярдәмгә чакыра. Ә әтәч... әтәч шап-шоп кыйнавын, чукуын белә. Менә шунда инде Тата әтәчнең арттырып җибәрүен аңлый да сөекле кошына беренче кабат кусәк күтәрә. Хуҗасының тупас мөнәсәбәтенә күнекмәгән әтәч башта гаҗәпләнеп торса да, аннары пырхылдап тиз генә абзарга шыла.

Икенче көнне хатын мәсьәләне кабыргасы белән куеп: «Я әтәчеңне юк ит, я минем эзләрем күренмәс бу ишегалдында», дигәч, Тата сөекле кошын тотып бәйләде, күтәреп өйгә керде, юк эшне бар итеп озак кына әйләнгәләп йөрде. Җан иясенең мөшкел хәлен күргәч, хатынының кызганасын: «Ярый, түзәрмен, суйма инде, бәгърем, әтәчеңне, бигрәк тә матур, гайрәтле бит», дип әйтәчәген көтсә дә, сөекле хатын әтәчкә түгел, аның иясенә дә әйләнеп бакмады. Һәм бер кулга пычак, икенчесенә әтәч тоткан хәлдә, ишегалдына чыгудан башка чара калмады. Ә Җиһан комган алган да — кай арада! — тыныч кына иярә килә. Менә сиңа йомшак күңелле хатын! Әтәчнең гүзәл муеныннан агачак кып-кызыл кан тынгач та, әтәчнең хәләл җаны белән бергә, иренең соңгы өметен дә юарга әзер. Юмый гына тор әле. Ирең гүзәл кошка яшәү биреп торган уттай муенга пычак тидермәс һәм тиеш тә түгел. Ник дисәң, үз гаебен әтәчтән кайтару килеп чыга. Һәм ирең әтәч муенын түгел, тәпи ирегеп буып торган кара бауны кисте. Кисте дә әтәчне абзар эченә кертеп җибәрде.

— Җиңүчегә суд юк! — диде ул берни аңламыйча шаккатып торган хатынына.

Әмма хатын аңларга һич тырышмады. Үзенең иң матур киемнәрен киеп, толымнарына чулпы такты да Әҗемгә элдерде.

Нишләмәк кирәк?!

Бөтенесенә түзәр иде, тик кош-корт һәм балалар ашарга сорый. Көтүдән кайткан сыер да мөгри — саварга кирәк. Һәм Тата сыер сава. Кай арада җыелган диген, бала-чага басып тора — аю биетәләрмени! Чыпчыклардай чыркылдашып көлешәләр, җитмәсә.

Татаның рәтләп юылмаган кара төкле беләкләре буйлап ап-ак сөт ага — чиләккә төшә, җиргә тама. Әтәч бәгырь комачау итми — кемнең кемлеген әллә каян күреп, белеп тора. Шулай да Татаның хәле барыбер мөшкел: чүгәләп күнекмәгәнгә, үрә катып күнеккәнгә, ботлар тала һәм егыласы килүдән ул җиргә таяна. Таянып тора да тагын сава, сава да тагын таяна. Мәгәр чиләк сөт белән тулмаса да, сыер да риза, бозау да. Аңа да шактый калгандыр ризык. Әмма балалар... Балаларга ярты чиләк сөт һәм ипи. Әмма өстәл әйләнәсендә тезелеп утырган балаларның, һич югы, берсе мөлдерәмә сөт тулы йомрыларының ник берсенә сузылса икән.

— Ягез, ашагыз, тагы ни көтәсез?

Сабыйлар ипине корылай гына ашарга керешкәч, яхшылык белән ризалашмагач, ата кеше җикереп тә карый, юк, ашамыйлар. Балаларының җилкәсенә берәм-берәм кундырып та чыга — барыбер файдасыз. Мышкылдый-мышкылдый йокларга яталар. Ярый, иртәгә сыйларга кирәк булыр.

Иртән балалар уянуга өстәлдә парланып ит тора. Барысы да ашыга-ашыга җыйналса да, кичәгедән дә яманрак чыр-чу — ризыкны тотып карагач та бөтенесе беравыздан елап җибәрә. Билгеле инде, ата кеше сәбәпне белмәкче итә. Иттә кан кызыллыгы бетмәгән. Менә сиңа нәзберекләр! Атагыз сезне өйрәтәчәк болай булгач чын тормышка.

— Ашагыз, я!

Акырып файда чыкмагач, тагын җилкәләргә кундыргалый, тагын шуның белән эш бетә. Балалар ипи белән салкын су чөмерәләр. Ә ипи бетсә? Киләчәкне күреп, чәчләре үрә тора Көчле кешенең.

Сепаратка кирәргә дип кичке сөтне караса, анысы каймакка әверелгән. Ходайның хикмәте!

— Менә карагыз, әниегезгә сыер сөт кенә бирә, әтиегезгә — прәме каймак!

Мәгәр балалар, каймакны күрәселәре генә түгел, ашыйсылары ук килсә дә, чыгып таю ягын гына карадылар. Яңа төр каймакны кош-корт улагына чыгарып салудан башка чара калмады.

Хатын булмагач, Тата өчен бер көн чыкмады кояш, ике көн, өч көн... Ә менә дүртенче көнне чыкты!

Әле булса күз алдында, кояш та чыга, абзар янына төлке дә килә. Ындыр яклап төлке күренүгә, тавыклар кыраклый-кыраклый киртәгә кереп качса, әтәч бәгырь исә егетлекне җуярга оялды, күрәсең, качмады. Качмады гынамы! Төлкегә каршы ук китте — арка-муеннарын кабартып, томшыгын зәһәр сузып, төлкене таламакчы! Ә төлке? Төлке әтәчне «ә» дигәнче әләктереп алды да ындыр артына, бакчага чапты. Кызыл төсләр күңелдә генә уйнап калды.

Билгеле, Тата кычкырган булды, ләкин соңга калды, ни өчендер алданрак куркытмады төлкене. Үзе эшли алмаганны басу күрке кызыл төлке эшлисен сизгәнгә һәм шуңа риза булганга түгелме? Сизде, түзде, күрәләтә урлатты һәм җаны да тынычланды... Чибәр җәнлек Җиһан апасы белән Татаны килештерергә дип килгән иде, мөгаен...

Ындыр буйлап чапканда, төлкенең төсе-кыланышында шаянлык белән бергә җорлык, зирәклек төсләре уйнагандай тоелды. Ир күңелендә иярле ат ятар дигәндәй, Тата үзенең күңелендә менә шушы төлкенең дә ятканын аңлады...

Аның юрирәк кычкырганын да ишетеп килгән Хәлил, Нәбиулла күршеләре чыраенда да чагылып китте шул җиңелчә көлемсерәү, башкаларның күзләрендә дә ялтырады шул ук зирәклек. Хәтта балаларныкында да. Кызыл төлке — җан күрке!

— Әйдә, әнине барып алыйк инде, — диде Кырлы курай.

Менә сиңа бала!

Пар ат җигеп, Тата Җиһан апагызны инде урламыйча гына чаптырып алып кайтты. Моннан соң бәхетнең кадерен беләчәк ул, әлбәттә!

*

* *

Әтәч калдырган тарихи сабак: оятсызлык һәм ерткычлык сине үзеңнән көчлерәкләрне дә җиңә алучы көч иясе итә икән. Менә моннан соң һәр җиңгән көчне гадел дип кара син. Әйе, шушында гомумән гаделлекнең нәрсә икәнлеге хакында фикер йөрт. Гаделлек? Кызык. Ләкин ул үзе дә табигатьтә бар. Ни дисәң дә, Табигать искитмәле гадел ул. Ни дисәң дә, иң әйбәт остаз — Табигать үзе...

Ишегалдын тутырып чебешләр чыркылдаша. Арада әтәч җенесе юктыр дип әйтү сәер тоелыр. Бардыр. Күптер. Шуларның берсен, иң шәбен сайлап, нәселгә калдыру мәгъкуль булыр. Кош-корт кына түгел, бүтән мал-туар да үрчи торыр, ходай язган булса. Сарык та бердәнбер генә тормас, бәрәннәр, алла бирсә, берне түгел, икене. Икесе дә

саулык бәрән булса, икенче елны өч сарык дигән сүз. Ат юклыгы гына бераз кимсендерә. Кимсену — егет эшеме? Тата һич тә андый егет түгел. Күңелдәге иярле ат, әлбәттә, җирдә туп-туп басып йөрер. Сыер инде булып килә. Ул да тик тормас, бозаулар. Тана бозау булса — шәбрәк, үгез булса да, сатып ат юнәтә башларга ярый.

Тата көз җиткәч тә тана бозау сатып алды. Кыш буе юкка гына печән әрәм итмәде — үсте мал. Язга чыккач, хәтта бозау чактагы хуҗасының көнчелеген үк чыгарды бугай. Хәер, монысы соңрак фаш ителде. Башта хәлне ачыклау җиңел үк түгел иде. Иртән торып караса, ишегалдында танадан, мең төрле өметләр һәм планнарны үзенә туплаган хәләл танадан җилләр искән иде.

Билгеле инде, Тата аны эзләргә тиеш һәм эзли Тата. Эзли торгач, таба да: элекке хуҗа лапасында мыш-мыш күшәп ята тана.

— Ник урладың минем малны, угры? — дип, бик табигый сорау бирә Тата.

— Ничек инде ул урладың?

— Ничеклеген беләсең — синнән дә шәбрәк белүче юк. Төнлә утарга кергәнсең...

— Утарыңны күргәнем дә юк.

— Алайса, капка ачык калгандыр да кайтып киткәндер тана элекке лапасын сагынып.

— Бар, тиз генә кайт та капкаңны шәп итеп биклә.

— Акыллы сүзеңә рәхмәт, кем, карак иптәш.

Шул сүзләрне әйтә-әйтә, Тата элекке хуҗа утарының җил капкасын ачмакчы. Ләкин иске хуҗа капканы чытырдатып тота да Татаны якын җибәрми:

— Җаның ике булса гына тотын кеше милкенә.

— Тана минеке.

— Ә мин әйтәм — минеке.

— Кара, егылып үлгере, саттың ич, алдың ич акчасын.

— Кайчан булды ул хәл?

— Соң син үзең белеп торасың лабаса, хәләл акчамны үз кулыңа тоттырдым.

— Гупчим истә калмаган, иптәш.

— Ярый, мин синең хәтереңә төшерәм, болай булгач.

— Төшер, туган. Әмма ләкин кәпә-көндез минем малны таларга йөрмә. Югыйсә, Себер җибәртәм мин сине. Җәяүләп китәрсең.

— Я, шаярма, җитәр. Бүтән болай ачык авыз булмам. Бир тананы.

— Икенче тапкыр шулай эшләрсең. Дөрес. Ә хәзер...

— Ә хәзер бир тананы.

— Чит кеше абзарындагы тана ул синеке түгел. Үзеңнекен үз абзарыңнан эзлә.

Ялынып та карый Тата, куркытып та карый. Күрше-тирәләренә дә кереп оялттырмакчы була тананың элекке хуҗасын. Әмма күршеләр берни күрмәдек дип тик торалар. Ә хуҗаның хатынына калса, бигрәк тә ансат: «Ирләр эшенә тыгылмыйм, үз мәшәкатьләрем дә тавык чүпләп бетермәле түгел», — диде дә чоланына тиз генә кереп тә китте. Шул рәвешле, кем әйткәндәй, сакалын тотып калды Тата абзагыз.

Ләкин Тата бөтенләй үк төшеп калганнардан, үзен оятсыз рәвештә рәнҗеттерә торганнардан түгел, үзегез беләсез. Икенче төрле әйткәндә, эшне судка тапшырды ул. Тагын да төгәлрәк әйтсәк, болай: тананың авыл Советында исәптә торганлыгы, ягъни инвентарь кенәгәсенә теркәлгәнлеге хакында (бәхеткә каршы, шул тирәләрдә мал исәбен алып йөргәннәр иде) мөһерле-имзалы кәгазь һәм Җәмәкинең барлык өе исәбеннән тананың Татаныкы икәнлегенә кул куелган исемлекне гаризага беркетте. Тик, гөнаһ шомлыгы, авыл Советыннан справка үк ала алмаса да, үз авылының барлык өе санынча элекке хуҗа да имза-

лы кәгазьне судка илтеп, өстәлгә шапылдатып салган иде. Исемлек Татаныкыннан да дәһшәтлерәк — йөз алтмыш кеше! Аптырашта калды бугай суд дигәннәре. Айлар буе рәтле җавап бирә алмадылар Татага.

Кыскарта төшкәндә болай: тиешле карар чыгара алмыйча, кешеләр ярты ел диярлек вакыт уздырдылар. Инде тәмам аптырашта калган Тата бер көнне иртә белән сыер мөгрәгәнен абайлап ишегалдына чыкса... Ни күзе белән күрсен, бәхәсле тана — әй, рәхмәт төшкере! — үзенең төкле аяклары белән үз хуҗасына үзе кайтып кергән ләбаса! Татаны күрүгә, бернинди ятсыну сиздермичә, борынын сузып мөңгерәп алды. Ашарга сорый язган мал.

Иске хуҗа яңадан мал даулап килергә җөрьәт итмәде бугай, нә көндез, нә төнлә бу тирәдә үзенең пычрак эзләрен калдыра алмады...

* * *

Гомер узу белән тана инде сыерга әйләнде, сарыклар ишәйде. Кошкорт хакында әйтәсе дә юк. Әмма ләкин ат һаман гүзәл киләчәк булarak алга чаба торды.

Язгы кыр эшләре беткәч, сабан туйлары алдыннан бала-чагаларга (билгеле инде, үзләренә һәм хәләл җефетләренә дә) ел саен өс-баш юнәтү нияте белән ирләр сарык суя һәм төркем-төркем булып Казан каласына китә. Тата да шул төркемнәрнең берсенә кушыла һәм базарда туаришләре белән бер рәткә тезелеп ит сата. Фатирга кайткач, уңышлы яки уңышсыз сәүдәне юу мәҗбүри хәл. Ә шайтан ширбәтен бераз авыз иттеңме, акыл һәм зирәклек дигәннең исеме үк онытыла, балаларга һәм хатынга бирелгән вәгъдәләр бөтенесе бергә җилгә оча. Ягъни авылга Татаның капчык төбендә вәгъдәләрне алмаштырган буш шешәләр генә шылтырап кайта. Тата бик каты борчыла һәм, әйтергә кирәк, хәләл җефетенең, балаларының күзләренә карый алмас дәрәҗәдә ояла, үкенә. Үкенсә дә бернишли алмый, тик үзен акларга гына көч таба:

— Сәфәр уңышлы булмады, сиңайтәм. Ит очсыз сатылды — китереп тутырганнар. Барганда да, кайтканда да билет бәһасы бик кыйбат торган трамвай-прахутка утырырга туры килде.

— Очсызлырак прахут көтеп булмадымыни? — дип, зәп-зәңгәр күзләрен тутырып карый Җиһан.

— Юк шул, юк, килми диделәр, бик көтмәкче идек.

Гомерендә бер тапкыр да авылыннан чыгып калага бармаган, йорт кошыдай тыныч хатын өчен «трамвай-прахут» дигән яңа сүз җитә һәм бүтән дәлилнең кирәге дә калмый. Күрше-тирә: «Ирең нилэр алып кайткан?» — дип сорагач та, нәкъ иренең үз сүзләрен кабатлап, аны кызгана, яклый торган иде мескенең.

Шулай да терлек ялындырмый гына үрчегәнгә күрә, тәки ат-канатка өлгеште ул. Күмәк хуҗалыкка, беренчеләрдән булып, пар атка утырып керде.

Беренчелекнең сәбәбе, дөрес, үзендә генә түгел, энесенең комсомол булуыннан, аның үгетләрен аяк астына салмаска тырышудан да иде.

Менә шушында терлек-туарның шәп үк үрчегән булуы Тата башына бәла да китерә язды, чөнки күмәк хуҗалык дигәннәренең ни-нәрсә икәнен күз алдына күпләр китерә алмый иде. Күпләр курыкканга күрә, көтүгә ияргән мал шикелле генә иярде: «Колхоз оештыручыларның берсе — Татаның энесе — начар эшкә үз абыйсын өндәмәс». Татаның да төп дәлиле шул иде. Бөтенләй ат илтмәгән кешеләр дә бар — миннән пар ат җитәр, дип исәп беркетте. Ә сыер-сарык, каз-тавык кебек малларны илтергә дигән хәбәр таралгач, Тата түзә алмады — бөтенләй

чырайдан язды, телсез калды. «Кем эше бу? Менә туган энекәш бөтенесен белеп эшлидер дип тыңла син аның сүзен. Ат тикле атны парлап кына бир син шундый ахмаклар кулына. Ничек кире барып алырга?» Барып та караган иде — якын да китермәделәр. «Колхоз малына кул тидерсәң, энең комсомол дип тормабыз, өтермәгә илтеп ябарбыз!» — дип акырды бер агай һәм тиз арада калган малларны китерергә боерды.

Тата әрепләшә торган кешә түгел. «Егылып үлгерләре, алдакчылар!» дип, эченнән генә тәкърарлый-тәкърарлый өенә кайтты. «Крестьян ничек сарыксыз, тавыксыз яши алсын? Сәке башында чыпчыклар шикелле чыркылдашып утырган бала-чагага оекбаш-бияләйләр өчен йон теләнеп тә әлеге шул тупас адәм каршына йөрергә калсынмы? Юк, крестьянны кешегә чутламаган бәндәләр ерак бармый ул. Үзенне ризыкка туендыра торган крестьянны зурлый, ихтирам итә белгән көчләрнең генә озын гомерле булуы мөмкин».

Бу сүзләрне Тата беркемгә сөйләмәсә дә, авыл кешеләре ашыгыпкаушап пычак ялтыратырга кереште — сугыш чоры булмаса да, кара яз кергәндә мал-туарны кыра башлады. Билгеле инде, Тата да читтә кала торганнардан түгел, ил белән бара торган кеше — ул да тутыгып беткән пычакларын табып, иң олы улыннан чар әйләндертергә тотынды. Икенче улын, кеше-кара керә калса, фәлән такмакны жырларсың дип, урам як төбенә чыгарып бастырды һәм үзе лапаста абына-сөртенә сарыкларын чала башлады. Хикмәт: дүрт сарыгының дүртесен дә чалып ташлагач ук, капка төбендәге малай җырлап җибәрде:

Абзый, атың бияме,
Туктаганда...
Бия булса, тот та сат,
Алаша ат ал да кайт.

Җаннары да чыгып бетмәгән сарыклар өстенә Тата олы бер кочак салам китереп салды. Ярый әле, өлгерде — нәкъ шул вакыт капкадан, берничә «актив»ны ияртеп, энесе килеп керде. Алар артыннан Татаның икенче улы баягы җырны такмаклый: «Абзый, атың бияме... Абзый, атың...»

Тата нишләргә белмичә аптыраган малаен арт ягына бәргәләп өйгә кертеп җибәрде дә, билгеле инде, хәйлә белән ишек төбендә туктады. Кунаклар шул тирәгә килерләр дип уйлаган иде ул. Ләкин энесе һәм кунаклар, кадаклагандай, абзар янында кымшанмый тора бирделәр. Тата ерактарак булса да гаҗәп хәл күреп, үзе үк телсез калды: абзар янындагы салам селкенепме-селкенә иде. Энесенең йөзендә чак кына елмаю шәйләп, аптырагач, үзен дә елмаерга мәҗбүр итте Тата. Ләкин сантый елмаю икәнен тиз тойгач, капкадан җәһәт кенә чыгып качмакчы иде, энесе туктатты:

— Качма әле, абый, качма.

Хикмәттер, шып туктады абыйсы. Туктады гынамы — янадан абзар катына ук килде. Әлбәттә, күзләре җирдә һәм салам ябылган сарыкларда иде.

Үзеннән берничә яшькә кече булса да, ул нигәдер энесеннән курка һәм гел буйсына. Бигрәк тә соңгы вакытта энесенең авыл кешеләре өчен катлаулы һәм авыр мәсьәләләрне гади генә аңлатып бирә алуы, адәм йөрәге җитмәстәй тоелган олы эшләр башкарып йөрүе белән эчтән генә хәтта горурлана да иде. «Әлмөхәммәт бабайга тартым, аннан бирелгән кан», дип уйлый иде ул. Әлмөхәммәт — аларның әтиләренең бабасы. Бу як авыллар өчен һаман да билгеле кеше. Озак еллар алты олыска баш кеше булып торган. Буй-сынга таза, ап-ак чырайлы, яшел күзле. Алты олыс аның яшел күзләренә карап кына яшәгән. Алты олыс-

ка баш кешенең өендә алты улы була. Улларыннан үзе теләгән кешеләр чыкмый, киресенчә, Әлмөхәммәт алардан күп җәфалар күрә. Олысы Пугачев хәрәкәтенә кушылганы өчен Себер җибәрелеп, хәбәрсез югала. Икенчесе, озак еллар читтә йөреп, марҗага өйләнеп чукына, һәм нәселе Спасск каласында хәзер дә яшәп ята. Тата, юл төшкәндә, аларга кереп хәл-әхвәл сорамыйча калмый.

Калган дүртесе дә аталарына кайгыдан башканы китерә алмаган, ахрысы. Үләр алдыннан Әлмөхәммәт карт: «Алты олыска баш булдым, алты улымның берсенә дә баш була алмадым», — дип уфтанган, имеш.

Шулай да Әлмөхәммәтнең сәләте, кешеләр белән аралаша белүе, катлаулы хәлләрне алдан күреп җайлырак мәлендә хәл итә алуы һәм башка шундый зирәк сыйфатлары барыбер нәселдә дәвам итә. Татаның энесе — шул сыйфатларның бүгенге көндә яшәп ятуыдыр.

Әйе, ул энесен хөрмәт итә, аның сүзеннән чыкмый. Бу нәрсә энесенең авыл халкы каршында дәрәҗәсен тагын да күтәрә төшә. Шуңа күрә борылып килде Тата селкенеп торган салам янына.

Энесе, кеше алдында абыйсын хур итмәс өчен, ахрысы, рәхәтләнеп бер көлде дә бик гади нәтиҗә ясап:

— Ниндидер дошман коткысына бирелгәнсең, ахмак! — дип кенә куйды.

— Атларны кире алырга баргач, әртил рәисе әйтте бит.

— Нәрсә әйтсен ул сиңа? Өйдә юк бит ул.

— Әйтте инде. Сыер-сарыкларыгызны, кәҗә-тавыкларыгызны да тартып алабыз, диде. Шуны ишеткәч, атларны да алып кайтмакчы булдык ие, ярый, анысын үзе бирмәде.

— Кулак ялчысы сүзе — алайса, ул эштән аны иртәгәдән үк куабыз. Күпме мал харап иттеләр бит кем сүзен тыңлап! Ахмаклар!

Тата, мин ахмак түгел, мин акыллы, дия алмады — каршы сүз әйтергә теле әйләнмәде. Үзе дә төшенә алмас мәгънәсез сүзләр генә мыгырдап капка төбендә калды.

Сарыкларны тунап, икенче көнне базарга китте, ләкин юлы уңмады: якын-тирә авылларда да нәкъ аның сыман тилеләр яши икән. Алар да шактый мал кырып базарга килгәннәр... Бөтен булган итен һәм өч сарык тиресен көч-хәл белән бер тере сарыкка, югалган ике сарыгын акыл һәм тәҗрибәгә алыштырып, өенә тыраклады Тата.

Ахырын хәерле кылсын дип, аллаһы тәгаләсенә энесе исеменә тел дә тибрәтмәскә антлар итте һәм антны бозмаска да тырышып яшәде. Ләкин тел генә түгел, хәтта кул да күтәрергә туры килде.

Сәбәп бәләкәй түгел иде, зур иде сәбәп, биек иде — мәчет манарасы биеклеге. Нәкъ үзе, билләһи. Әлегәчә, шушы көнгәчә үзен хаксызга кул күтәрде дия алмый Тата. Нигә дисәң, аның иманына кул күтәрделәр. Бер дә тайчанмыйча, караш-фәлән сорамыйча кизәнделәр.

Сәбәп шул — манара. Манараның түбәсендә, күптән инде ай янында Тата үз кулы белән элгән кызыл әләм җилферди. Тата ярдәме белән күптән инде анда мулла абзыйның аяк басканы юк. Ләкин...

Дин белән Татаның бәйләнеше бөтенләй юк дисәк, арттырыбрак җибәрербез. Бәйләнеш барын бар. Ләкин шушында ап-ачык бер нәрсәне әйтү фарыз: кемдер ходайга күңелдән ышана, ә кемдер гореф-гадәт буенча. Аллага тел тидерсәң, кемдер үзе белгән бөтен каһәрле сүзләре белән сине дөмбәсләргә тотына, кемдер колагына да элми. Менә шул. Бер гаепсез манараны төшерү Татаның аллага ышану хисләрен мыскыллады дисәк, монысы хатаның усалы, җәберлесе булыр. Ләкин Татаның күңеле җәберләнде, ачуы купты. Ул көннәрдә Тата беркемгә һәм бернигә карамастан үзен корбан итәр дәрәҗәдә тәвәккәл иде — изге (ләкин бая әйткәнчә түгел, үзе уйлаганча изге) иманына төкерергә җөрьәт иткән кешене... үз энесе дип тә тормады...

Мәчет алдында халык төркеме. Ник торганын, кемне каршылаганын халык белә. Халык арасында төрлесе бар: ходайга чынлап ышанганы бар, Тата ишеләр күп. Ихтимал, яңа тәртипләргә җаны-тәне белән каршылары да юк түгелдер әле. Татаның хисләре андыйлар яклы түгел, ләкин ул, нилектәндер, шундый адәмнәр белән бер рәттә булып чыкты. Бу юлы әллә Тата үзе, әллә аның энесе нәрсәнедер күреп җиткермәде шикелле.

Татага үз авылларындагы мәчет манарасын кисеп аударырга куштылар...

*
* *

Кошчылык фермасы мөдире булып эшләгән чагы иде аның. Кыш көне тавыклар күп үлгәнлектән... Ләкин... Юк, фикер ары китми — икенче якка китә һәм, тавык дигәннән, каз хакында уйлый башлый Тата һәм хәзер дә шаркылдап көлеп җибәрә. Үзе кул куйган бер актны исенә төшерә. Русча язганнар иде. Нәкъ язылганча хәтерли.

«Акыт. ,

Ыфтаруй май, 1933 гут.

Нижнеподписавшы нисколька приставитил колхозәртил «Маяк» Қамско-Устинский район Татарской области заффирмыәртил Тата, учитчик птичкофирма Хәнә Галяутдинуа, члин колхозәртил Габидулла Тухуатуллин, присидатил рифкамиссия әртила «Маяк» Сәлимулла Фахиуллин, сиклитар артилный камсамула Магиҗамал Шайхаразиуа, присутстуал нисколько члин калхуз биз нимания составил настаяшшига акыта тум шта чарашный динь ыфтаруй май 1933 гут вся диривна нарут бла выпомша, а начальствуа артила был на туржиствинный абид праблиние калхузартила. Иты бримя один артилный гус сама крупный и дба кулхузный утка бижал суая помишшиния и стали гуляйт на агарут усадба активный члины калхуза тауаришши Ибраһим Ибатуллину.

Патум ани пычамута прасунил суая галова ыскыбуз забур дира. Ита брима какрас бижал ызлуй сабакы и кусил вси три галаба. А биз галаба калхузный гус разы мислима, утка тужы. Зря ысказайт ни нада. Хыйт габари ни габари жибуй ни будит. За ту мы написали настояшшего акыта шта адин калхозный гус и два калхузный утка ат злува субака умырла. Их нада ыс калхузный чут склучит. Ризалутси.

... Ладна ишша ита брима ни был нискалка артилный питух. Скулкы готна магла их тужы кусат. Мый ужы тышша раз габариль ита сабакы убивай, патамушты учин злуйни, такуй тумаша, бида струит мужыт, ыспаси бух.

**Присидәтил рифкум (имза).**
**Зав птичкефирма (имза)**
**Члинны артила (танымаслык сызыклар)».**

Менә шушы шыр надан актка кул куеп янды Тата абзагыз.

Ревкомиссия председателе авыл активы оештырган тантаналы мәҗлескә чакырылмавының кайгысын бәйрәмгә әверелдермәк булып куптарган иде бу әвәрәне. Зыяны бүтәннәргә дә эләкте. Ярый, гаепне аңа гына аудармыйк, беркемне дә көчләп куйдырмады имзасын — булды инде булды. Узган эшкә салават диик тә нокта куйыйк һәм ягъни дип әйтик, шушы хәл аркасында бөтен авылны ду китергән гауга җиле «птичкефирма мөдире» булган Тата кесәсеннән шактый акчаны штраф атамасы белән чыгарып туздырды, ә ревкомиссия председателен урыныннан ук куптарып атты.

Шул җәһәттән Татага акчаның бик тә кирәк чагы иде. Манара төшерсәң — сиксән сум... Бик кирәк булса да ризалашмады: «Соңгы сыерымны сатып үзем түлим, тик манарага кулым күтәрелмәс», — диде.

* * *

Мәчет янына халык җыелган.

Халыкны аралап, арканнар, балталар, багурлар һәм кадак суыргычлар тоткан биш әзмәвер уза башлады. Исәнлек-саулык сорау юк, әйтерсең кемнә дә күрмиләр. Мәчет капкасына тикле килеп җиткәнче, илаһи тынлыкны бозарга беркемнең дә йөрәге җитмәде. Биш әзмәвер мәчет капкасын ачмакчы һәм... Юк, мәчет капкасының нәкъ элгечле турында Тата пәйда булды. Биш әзмәвернең берсе — дөресен әйткәндә, әзмәвер генә түгел, усал гыйфрит — шушында басып торган бәләкәй генә, өтек кенә гәүдәле гади бер яшь крестьянга гаҗәпләнеп карады. Ә соңрак нигәдер көлде:

— Я, я, җүләрләнмә. Минем артта кемнәр тора — күрәсеңме?

— Аркаң олы вә киң... ярты ил киңлеге бардыр, — дип, күз дә йоммыйча җавап бирде Тата.

— Шулай булгач? Ходай сиңа ярдәмгә килмәс.

— Нишләп килмәсен, килер. Көт әзрәк.

Биш әзмәвернең бөтенесе берьюлы телгә килде:

— Безгә нәрсә, бәхәс кузгатырга кушылдымы әллә?

— Безгә бәреп төшерергә кушылды.

Артында аны яклап кузгалырга әзер торган халык барын тойгангамы, Тата баягыдан да кыюрак, олырак сүзләр ташлады:

— Кирәген без үзебез бәреп төшердек инде. Хәзер патша юк. Кемне сөреп төшермәкче буласыз? Мәчет башындагы әләмнеме? Кулыгыз кыска, җитмәс!

Әмма куллар озынайды һәм алдагы әзмәвер Татаның сырма изүеннән эләктереп, бала-чаганы алып аткан кебек кенә атып та бәрде. Егылган җирдә ята торган кешеме Тата — җәнлек кебек сикереп кенә, тагын алларына ыргылды, капка бавын эләктерде. Гыйфрит ачуланып ук җилтерәтмәкче иде, бу юлы халык телгә килде — гауга купты. Үкерү, улау, акыру, җикерү, ялыну — бөтенесе бергә, ләкин бер кешене дә беркем тыңламый. Беркемнең күзенә бер нәрсә күренми. Татаның күзләре күккә баккан, ә күктә, әзмәвер кулында — балта...

Күпме вакытка сузылгандыр бу хәл, әйтүе кыен. Әмма шунысын шәп хәтерли: балта кинәт калтыранды, ә Тата кыймшанмады да. Ул балта кетә, төшсен балта! Төшсен! Бетсен бөтенесе! Ләкин — юк, балта үзе калтыранды. Калтыранды да түбән төште. Түбән төште дә... гыйфрит кыяфәтле кеше капканы ачарга азапланмас булды. Буш кулы белән нигәдер җилкәсен тотып, китәр якка борылды. Аңа юл бирделәр. Калган дүрт әзмәвер аның артыннан иярде һәм... киттеләр. Бөтенләйгәме? Белүче юк. Белмәсәләр дә, хәл тәмам ачыкланганны көтеп калдылар, таралмадылар. Койма буендагы утыргычларга, бүрәнә өсләренә утырып, кыямәт хакында гәп корырга вакытлары җитте. Ләкин туфрак эшкәртү уе җилгә очты.

Дингә каршы көрәш дигәннәренә дә каршы түгел Тата, бүтән авылларда мәчет дингә рухландырадыр да. Ләкин Җәмәкидә хәл күптән икенче төрле бит! Юк, Татаның энесе һәм аның иптәшләре нәрсәнедер аера, аңлый алмыйлар. Күмәк тормыш төзеделәр үзләре... Ә күмәк көч белән төзелгән нәрсәне юк итмәкчеләр! Ник?.. Нинди максат? Нинди ният? Татаның хәле авыр, Тата моны аңлый алмый һәм интегә. Ә хатирәләр, матур хатирәләр бал кортлары шикелле безелди. Бер елны җәйнең ямь-яшел бер көнендә урам яклап корт гөжләгән тавыш ишетеп, тыңлый-тыңлый урамга чыкса, чынлап та корт күче... Уйламаганнитмәгән, гомер буе уйга килмәслек җирдә — корт күче манарага сарылып ята!

Шуны гына күргән иде Тата, тотты да йөгерде төп йортка, энесе янына. Битлек һәм күрек сорап алды. Энесе дә чәй эчеп утырган җирдән урамга чыгып карады. Күчне күрде дә:

— Артык биек икән, абый, ничек җыярсың? — дип куйды.

Йөгерә-атлый урамнан узганда шул ук сорауны бүтәннәр дә кабатлагач, энесе дә ишетсен диптер инде, каты итеп кычкырып җибәрде Тата:

— Әйдә булсын, безнең бәхет югарыда ул!

Бу сүзне чынлап та бөтен авыл ишетте һәм җай чыккан саен кабатлый торган булды.

Тата өскә, башкалар уйлаганча, тышкы яклап үрмәләмәде, биек күтәрелүнең җайлы ысулын сайлады — эчке яклап менде дә, манараның ике кечкенә тактасын куптарып, күчне шул ачыклыктан җыйды. Соңыннан тактаны, мәзин утыра торган җирдән бауга бәйләнеп, янадан кагып куйды — анысын да уйлап-нитеп тормастан дигәндәй эшләде — барысы да тиз һәм кирәгенчә килеп чыкты...

Шуннан бирле Тата бакчасында умарта унар баштан ким булмас. Хәзер дә гөжләп утыралар — Татаның югарыдан төшкән бәхете ялындырмыйча ишәйде, кортлары умарталарга изге ризыкны, татлы балны армый-талмый ташып торалар.

Тата болай уйлый: «Җимерергә килгән биш әзмәвер, сез шушы манарадан матурракны үзегезнең төзи алмасыгызны чамалыйсызмы? Сезнең кулдан килми ул. Шулай булгач, халыкка рөхсәт итегез — нинди генә манаралар ясап куймас ул! Әллә ышанмыйсыз? Халык кодрәтенә ышанмыйсызмы? Халыктан аерылганны аю ашаган. Шулай, бетерү җиңел. Син аны соңыннан торгызып кара...»

Муллаларның комсызлыгы, бүгенге белән генә, бүксә тутырыр өчен генә яшәве һәм күбесенең надан булуы Татаның дингә ышанычын тәмам какшаткан инде. Кемнәр генә мулла булмады бу мәчеттә. Шыр диваналарны да күрде халык. Шәкүр карак белән бер компаниядә йөргән адәм дә берничә ел мулла булып кешеләрне күңел сафлыгына, гаделлеккә өндәде...

Татага биш-алты гына яшь булгандыр. Мәчет салырга кайтарылган нарат бүрәнәләрне ат итеп атланып уйнадылар малайлар. Халыктан кабат-кабат акча җыйды картлар. Эшкә яраклы ирләр Тәмте урманында агач кисте, агач ташыды. Дин чәчәк атсын дигән сүзне хәтерләми Тата, авылыбыз башкаларныкыннан ямьсезрәк булмасын, дигән сүзләр исә колак төбендә әле һаман да ишетелә. Осталарга хакны да бергәләп түләделәр. Бу эшне башлап йөрүчеләрнең берсе Татаның әтисе иде.

Әтиләр инде гүрдә ята. Аларны яман нәрсә ясаганнар дип рәнҗетергәме? Әтисе хатирәсенә ничек салкын карый алсын Тата? Әйе шул, Җәмәки мәчете үзенә бер төсле ул.

Авыл уртасындагы манара Җәмәки халкына сәгать ролен дә, маяк ролен дә үти. Манарада беренче кояш нурлары балкыгач, сукачы иртәнгелекне ашый. Манара күләгәсе мәчет кыегына җиткәч, сукачының хатыны төшкелекне әзерләргә керешә, кырдагы ире яки малае бу вакытта атларына хәл алдыра. Манара күләгәсенең иң кыска чагында ризык өстәлгә куела — тиздән сукачы кайтырга тиеш.

Менә авыл Советы председателе, юк, ул гына түгел, авылның партия оешмасы җитәкчесе, Татаның туган энесе килә! Татаның әллә нинди каршылыклы тойгыларын алар аңламыйлармы? Баягы биш әзмәверне тагын да ник иярткәннәр? Кыргый көчкә таянмакчылармы? Безгә каршы? Үз аталары, үз абыйлары теләгенә каршы?

— Абый, нишләвегез бу? — Энесе туп-туры абыйсы янына килде.— Ач капканы.

Энесе капкага үрелгән иде — абыйсының шактый олы кулы үзелгеннән шул минутта күккә күтәрелде. Йодрыкка төйнәлеп...

— Ягылма! — дип акырды Тата, әйтерсең ки җан әчесе белән. Эне кеше коелды да төште. Әле председательгә карый, әле баягы әзмәверләргә, әле үзләрен чолгап алган халыкка. Халык тыныч, әмма кырыс — әйтерсең кемнедер әсир итмәкче. Чырайларда — чатнамас тәвәккәллек. Эне кеше, мөгаен, шуны күреп, нишләргә белмичә карап торды-торды да башын иде һәм шул килеш, иелгән башын күтәрмичә, килгән юлыннан ашыга-ашыга атлап та китте. Председатель дә, баягы әзмәверләр дә, эшкә тотына алмыйча, тезелешеп аның артыннан иярделәр.

Кулларына колга-таяклар тоткан бер төркем ир көн-төн мәчетне саклады. Басу онытылды. Киләсе ел уңышы... кечкенә нәрсә булып калды. Язның бер көне елны туйдыра дигән үз мәкален исенә дә кертмәгән шикелле тынды халык. Шушы көннәрдә Нурулла дигән мулла каяндыр кайтып, Татага бик зур рәхмәтләр укырга, догалар кылырга, алай гына да түгел, үзенең бер өтек мөритенә кызыл әләмле манарага менеп азан ук әйтергә боерык биргәч исә, Тата телдән язды. «Нишләдең син, Тата, нишләдең? Кемнәр ихтыярына буйсынып, кемнәр белән берләштең?! Кем хәзер сиңа ярдәм итә алыр? Югарыдагы иптәшләр безне ишетмәсәләр?»

Дингә һәм идәнгә баш орып хезмәт итүчеләрне берәм-берәм уеннан кичерде: күбесе дивана, күбесе шарлатан...

Малай чагында Тата сабак алырга шушы мәчеткә йөрде. Укырга-язарга тиз өйрәнде. Кем белә, укып, бәлкем берәр һөнәргә өйрәнерлек хәлгә дә барып җитәр иде, тик... Нурулла — ул чакта әле яшь мулла — Тата исәнлегенә дога кылудан ерак иде. Бер көнне, борын астыннан мыгырдап, нәрсә хакындадыр сорады да җавап бирергә кушты. «Сүзләрегезне ачыграк итеп әйтсәгезие, хәзрәт!» дип, чын күңелдән сораган шәкертнең «ә» дигәнче якасыннан эләктереп алды да:

— Әле син мине өйрәтәсеңме, чучка танау! — дип чыелдап та җибәрде мулла.

Якадан тарта-селки торгач, малайның бишмәт төймәләре коелып төште. Малай мулланың үзеннән дә кызурак канлы иде. Идәндәге китапларын тиз генә җыйды да бөтенесен хәзрәтнең битенә шапылдатып орды. Сабакка мәңгегә йөрмәс булды һәм надан калды. Ярый әле, революция булып, соңгы елларда наданлыкны бетерү мәктәпләре оештырылды, һәм Тата авыл хәтерендә озакка калачак актларны үзе дә яза, кеше язганга кул куя да белә башлады.

Дингә нәфрәт тәрбияләүдә файдасы онытылмаслык зур булды мулланың, ә нияте бөтенләй икенче — дингә уйсыз ышанучы кеше тәрбияләү иде. Менә бит ничек! Мондый хәлләрне фикер һәм хис әһелләре белергә, гыйбрәтне хәтерләрендә тотарга тиештер.

Уразаның кызу урак өстенә туры килгән чагында баш әчендәге ми казандагы төсле кайный. Ә син, авызыңа су әсәре капмыйча, урак ур. Тамаклар чатнап кибә, кырдан кайтканда аяклар өстерәлә.

Үзалдыңа сөйрәлеп, күләгәле җиргә кайтып егыласың. Күләгә дә хәл кертмәгәч, Тата кар базына ук төшеп утыра иде. Ләкин озак утыра алмый — аны кырга, кояш астында янарга, ач килеш янарга чакыралар. Яну бер хәл, дөрләп янган килеш һаман ур, һаман көлтә бәйлә, чүмәлә күтәр. Эш тәмен эшкә нәфрәт алмаштыра. Шулай да эшләргә, эшләргә кирәк — югыйсә, бер айга түзмәсәң, озын кыш буе «ураза тотарга» туры килә.

Бер көнне өйгә кайткач, күрше егете белән яшерен генә чәй кайнатып, чормага менеп эчтеләр һәм үзләренең хилаф эшләренә «теоре-

тик» нигез дә таптылар. Һәр чакны шулай эшләнә... «Кеше күрмәсә, авыз ачсаң да гөнаһ саналмый дип әйтелгән, имеш, Корьәндә».

Һәр адәм баласын яшертен эшкә мәҗбүр иткән дин үзе тәмуг кисәве булырга тиеш. Тата йола бозганнан беркемгә дә зыян килмәде, ә файда булды. Ул көнне иген чагыштыргысыз күп урылды, чүмәләләр биегрәк өелде. Кылган гөнаһларны, дингә барлы-юклы ышаныч һәм ихтирамны рәхәтләнеп аккан салкынча тир юып ташлады һәм, ничектер, күңел иркенәеп, яктырып китте, акыл мөстәкыйльлек алды! Әй, ireккә ул күптән талпына иде, бик күптән — әтисе дөньядан киткән чакта беренче кабат тойды ул акылның канат җилпегәнен.

Татаның әтисе үләр алдыннан хатынын һәм балаларын үз янына чакырды да васыятьләрен әйтә башлады. Васыятьләрнең берсе шул: гүр сәдакасы итеп карт муллага камалы тун, ә яшенә көзге тәкәне бирергә. Шулай эшләнде дә: мәрхүмне җирләгәч тә, тунны карт муллага илтеп бирделәр, ә көтү кайткач, тәкәне, мөгезенә бау салып, яшь муллага Тата алып барды. Ләкин яшь мулла Нурулла бәрәнне кабул итмәү генә түгел, юньсез сүзләр белән сүгә-сүгә, малайны ишегалдыннан куып чыгарды да шалт итеп капкасын бикләде. Аннан соң да әллә нинди яман сүзләр белән йодрык төя-төя каргый калды. Бер бәрәнгә генә риза түгел, янәсе. Әтисе үлгән баланы кызгану, юату кайда, мәрхүмнең рухын рәнҗетмәү дигән хис кайда? «Карт муллага камалы тун биргәч, ничек оялмыйча сөйрәп килдең миңа бу мәче баласын, ахмак!» — диде Нурулла.

Бәрән көзгә кадәр көтүдә йөрде дә, көтү кергәч, аны суеп, итен авылдагы бөтен ятимнәргә һәм картларга өләштеләр. Бу хәбәрне ишеткәч, яшь мулла өйгә инде үзе килеп бәрәнне дәгъвалады.

— Минем бәрәнне суярга ни хакыгыз бар иде, имансызлар! — диде.

Ахыр чиктә бәрәннең киртәгә эленгән тиресен күтәреп китте.

— Карак мулла, карак, карак! — дип кычкырып үч алды Тата.

Шуннан Тата «хәзрәт» дигән сүзне онытты. Алар борын астыннан тәкърарлаган «алла»ны артык зур ихтирам белән искә алмаска күнекте.

Бер заман авылга гомерен зимагурлыкта уздырган бер адәм кайтып төште. Авылдашлары: «Нинди җил картаймыш көнеңдә генә туган якка кайтарып ташлады?» — дип, кабат-кабат сорагач та бер генә җавап ишеттеләр: «Үзем — монда ялгалган туфрак... шуны читтә калдырасым килмәде». Ә гомерен нинди юлда уздыруын ничек тә сөйләтә алмадылар. Авыл өчен аның гомере табышмак булып калды. Озак та үтмичә, дөнья куйды бу кеше. Кәфенлекләре арасыннан ун таңка акча килеп чыккан. Биш таңкасе — җирләүчеләргә хәер, ә калганы — гүр сәдакасы. «Бу мәрхүм узган гомерен безгә сөйләмәсә дә, фәрештәләр җавап алганда серләрен барыбер яшереп кала алмаячак бит. Фәрештәләр телен белгән кеше халык киткәч кабер саклап калса, барын да ишетәчәк», дип, гүр сәдакасына да беренче булып Нурулла кул сузды.

Җәй уртасы — арыш бөртекләрен катырыр өчен генә килә торган чалт аяз чиллә. Кыл өйлә вакыты. Зиратта ышыкланырлык агач заты булмаганга бугай, күмүне тиз тоттылар. Җитмәсә, мулланың гүр өстендә калачагын бөтен авыл ишетеп өлгергән иде. Өйлә вакытындагы тынлыкта гүр хәлләре бигрәк тә ачык ишетелә, имеш. Өф иткән җил юк. Бөтен тереклек, кызудан әлсерәп, телен салындырган да хәлсезләнеп ята кебек. Анда-санда арыш арасында чикерткәләрнең уклар чүкегәне генә ишетелгәли. Ләкин алар хәзрәткә комачау итәрлек түгел, рәхәтләнеп тыңласын һәм эләктерсен биш таңкәне дә күрсен игелеген. Иншалла, җәмәгатьчелек авылга юл тоткач, мулла тирәсен-

дә зиратны әйләнеп алган ур өсләрендә күзләрен чекерәйтеп җиргә ябышкан кәлтәләрдән башка җан иясе калмады.

Тата соңгы кабат караганда, мулланың чырае гаять тә җитди — мәңгелек белән, ходай һәм аның фәрештәләре белән очрашырга чыннан да әзер кебек иде, хәтта бүтән чакта уйнаклап торган йолтыр күзләре дә тоныкланып калган иде. «Теге дөнья белән бәйләнешкә кереп тә алды!» дип уйлады Тата.

Тата үзен куркаклар рәтенә кертми. Ләкин бер ялгызы кыл өйлә өстендә каберлектә шулай кала алыр идеме, юкмы, әйтә алмый. Йөрәге җитмәс иде шикелле. Ә менә малай чакта аны чикмән сәдәпләре коелганчы селкегән мулла абзагыз батыррак, ахрысы. Көнләшерлек тә.

Күмүчеләрнең бүтәннәре нәрсә уйлый кайткандыр, Тата исә әнә шундый соклану хисләренә бирелеп кайтты. Авылга кергәч тә, кешеләр, нигәдер таралмыйча, авыл башындагы каравылчы йорты янына туктадылар. Кайсысы шундагы агач күләгәсенә барып ятты, ә кайберләре өй артындагы бүрәнәләр өстенә утырышты. Урак өстендә хәвеф-хәтәр булмаса, әйбәт кенә уңыш җыелачагы хакында гәпләшергә керештеләр. Тик шулай да һәркем ара-тирә зират юлына күз салгалый иде.

Күпмедер вакыт узгач... чүгәләп утырган бер адәм сикереп торды. Әкрен-әкрен генә турая башлады. Кулсыз Ибрай дигән кеше иде бу. Турая язган хәлдә бердәнбер кулын алга таба сузып нидер әйтмәкче иде, аңлаешсыз ымлыклар гына чыгара алды. Шуңа гаҗәпләнеп кинәт дәррәү сикереп торгач, Ибрай кулы сузылган якка карасалар, анда, зират юлында — мулла чаба иде! Чатыр-чотыр чаба. Гомер буе кешеләрне түземлек, чыдамлыкка үгетләгән адәм үзе котырган шикелле чаба иде.

Бөтен халыкның күз алдында чапкан мулланың җилпенгән чалмасы башыннан төшеп калды, иелеп алырга вакыты җитмәде — никадәр саран кеше дә кызганмады бит шундый байлыгын!

Менә инде ахылдаган-ухылдаган, деп-деп баскан тавыш ишетелә һәм тора-бара җир селкенә башлады шикелле. Менә мулла ахылдапухылдап халык белән тигезләште. Ә күзләре! Теге дөньядан кайтып өлгермәгән күзләренең уйнаулары! Шашкан күзләр! Яна гына!

Мулла, халык арасына кергәч беразга туктап, кулындагы галошларын киде дә тагын чатыр-чотыр чабып китте. Үз өйләренә җиткәч, капка ачып кергәч кенә беркадәр тынычланды шикелле. Ләкин анда да әле ачык капка арасыннан гына кулын бутады:

— Кайда акча? Акчаны китерегез! Акчаны! — диде, аннары өенә кереп шылды. Әлеге хикмәтне белү теләге һәм акча китерү сылтавы белән кереп сорашсалар да, адәм аңларлык җөмлә ишетә алмадылар. «Харап, харап... харап, алла ярлыкасын үзен»,— дип кабатлавын гына белде мулла.

Өч көн өеннән чыкмыйча түшәктә ятты. Дүртенче көнне генә иртәнге намазга киткәнен күреп калды авыл халкы: чырае агарып, суырылып калган. Берәрсе күзенә чалындымы, сорау да көтмичә, һаман шул сүзен туглый иде:

— Алла ярлыкасын үзен, алла ярлыкасын...

Бер табышмак икенчесен китереп чыгарды. Гүргә усал фәрештәләр килеп гауга куптарганмы, әллә мулла-мокыт куркуыннан шашканмы? Тата, әлбәттә, соңгы фикерне куәтли.

Тфү, шайтан, манара хакында уйлаганда ничек килеп керде соң әле зиһенгә алама мулла?..

Шулай, муллаларга кул селтәде Тата, күптән кул селтәде. Тик динне бөтенләй үк ташлый алмады. Дөресрәге, дин дигәне, ата-бабадан

гореф-гадәт буларак, көндәлек булмаса да, сүзләрдә калды. Кайбер елларны хәтта гает яки гарәфә кичендә намаз да укыштыргалый. Кешеләр күрсенгә, тәүфыйксыз кеше дип уйламасынга укый Тата. Кем әйткәндәй, дине өчен түгел, көне өчен. Һәм анысы да житеп арткан дип фараз итә.

Бервакыт Тата иртәнге гает намазын укый башлады. Ә биш-алты яшьлек малае аның артындагы сәкедә әле маэмай кебек шыңшып утыра, әле мич алдында бәйрәм ашлары пешерүче әнисенә берөзлексез бәйләнеп йөри. Бервакыт, җай килеп, сәҗдәгә киткән жиреннән аягын сузып, малаена каты гына тибеп җибәрде Тата. Җилтерәтеп күтәрде дә шуның белән тагын да катырак елый башлаган баланың арт ягына суккалый башлады. Белгәннәрен укый-укый гает коймагы пешереп ятучы хатыны, өйдәге барлык кешеләр шаркылдап көлешергә керешкәч һәм ходайны алдавы фаш ителгәч, Тата үзе дә көләргә тотынды.

— Намазымны бүлдердегез — гөнаһысы үзегезгә! — дип, юри генә җикеренгән дә булды.

Тфү, шайтан, бу хатирә тагын манара хакында булып чыкмады бит әле. Нишләп соң әле бу алама хәтер балта сораганга шөшле китереп тоттыра?

Инде килеп, үзе куралмаган Нурулла мулла түбәнлегенә төшкәч, дөньяның тәме дә бетте, яме дә кимеде. Җайсыз хәлдән кем чыгарыр? Бармы андый кеше?

Койма ярыгыннан карап, Тата ул кешене күрә: мәчет катына җигүле ат килеп туктады.

Арбадан төшкән кеше үзенә күтәрелеп карарга да теләмәгән халык белән исәнләште, ләкин җавап алмады. Килгән кешенең үз энесе икәнен белгән Тата тиз генә аның янына ашыкты һәм энесенең сүзләрен килгәндә үк ишетә килде:

— Ярый, абзыйлар, уттай эш өстендә бик матур утырасыз, күңелегез булгандыр.

Тата килешли үк ярып салырга тиеш тапты:

— Җәмәгать, житте, гаугалашу — файдасыз,— диде һәм, кешеләрнең аңламавын чамалап, өстәде:— Без хаталандык.

— Ягъни, сез кемнәр?

— Без, Җәмәки дигән тиле авыл кешеләре.

Билгеле, мәҗлес халкы аптыраштa — инде партячейка секретарена ярдәм көткәндәй карыйлар. Абыйсы башлаганны секретарь тагын да катгыйрак тавыш белән дәвам итте:

— Әйе, хатагыз зур, бик зур. Шул ук вакытта безнеке дә бәләкәй түгел. Без... шулай, мәчетегезгә кагылмыйбыз.

Иң гөнаһсыз исәпләнгән Нәбиулла исемле картның гына аваз бирергә кыюлыгы житте:

— Һы... мәчеткә кагылмыйлар. Манарасын төшергәч, нигә кирәк ул мәчет?

Секретарь куеныннан газета чыгарды.

— Менә монда минем сүзләрне ташка басканнар. Мәчетләрне тулаем җимереп бару дөрес түгел, кайбер авылларда исән калдырсак та, революциягә зыян килмәячәк дип язылган монда. Мисалларның беренчесе — сезнең мәчет. Чөнки бу авыл халкы кызыл байракны беренче тапкыр шушы мәчет башында күрде. Хәтерлисездер, минем абый кадап куйган иде аны. Хәтерлисезме?

— Хәтерләмичә...— Ниһаять, халык телгә килде.— Бик яхшы хәтерлибез.

— Мин үз күзем белән күрдем, намаз укып утырган Нурулла хәзрәтнең аркасына Тата сугыштан алып кайткан мылтык сөңгесен

тэрэгэч, тегенең күзләре урыныннан купты.— Шул сүзләрне әйткәч, Нәбиулла күрше шаркылдап көлде.

— Шулай шул, аркасына сөңге терәп, Тата мулланы өенә хәтле озатты.

— Тата гражданнар сугышына киткәч кенә мәчеткә керергә җөрьәт итте Нурулла хәзрәтебез. Мәчетебез мәдрәсә булып кына калды.

Үзе хакында сөйләшкән халыкка күз төбәп карарга кыймый торган Тата энесеннән дә ояла иде. Шуңа күрә сорый куйдылар:

— Синең энең, Тата, акыллы кеше икән. Теләсә кем аңлый алмый ул мондыйны. Язу хакында әйтәсе дә юк. Тик менә гәзите чынмы икән?

Шуннан соң эне кеше газетаны кычкырып укып чыкты. Аннары янә шуны кабатлады:

— Килештек, эшкә керешик, җәй җитә.

— Син, коммун иптәш, безне алдамакчы буласың, бу былтыргы гәзиттер әле.

— Ант итәргәме әллә?

— Ант ит, ант ит!

— Валлаһи газим, Себер китим. Әгәр сүземне бозсам, аллагыз мине баскан төшемдә суксын.

Шуннан соң халык таралды һәм ашыга-ашыга басуга юнәлде. «Менә бит ул Әлмөхәммәт каны,— дип уйлый Тата,— нинди катлаулы хәлдән абыйсын да, үзен дә, халыкны да җайлы гына чыгара белде. Энекәшне берничә елдан соң эшкә район үзегенә үк чакырып алулары да бер дә юкка булмагандыр, әлбәттә. Көз саен ударник булып чыга торгач (Җиһан белән бергәләп алган бүләкләр һаман истә!), шушы егерме алты өйлек колхозга Тата абыйсын председатель итеп сайлаганда, шулай ук энесенә булган ышаныч һәм хөрмәт тә йогынты ясамый калмагандыр.

Җиһан белән бергәләп, байтак еллар көйле генә, матур гына гомер кичерделәр. Әмма бәхетле кыска еллар әллә ничек озын, салкын еллар белән чиратлашты. Еллар үзегендә — Җиһан.

*
* *

Җиһан, Җиһан! Нигәдер ул озын гомер юлының ахырына кадәр озата килмәде, кайдадыр еракта калды, ярты юлда икенче иптәш табарга туры килде. Нишләптер, һәр ике исемнең мәгънәсенә Тата хәзер генә төшенде шикелле.

Җиһан белән узган көннәр үкенечле кыенлыклар белән бәйләнгән булса да, бүгенгенең иң матур көннәреннән дә яктырак һәм җылырак сымак. Кабатланмас бәхетләр, күктәге йолдызлар шикелле, күңелне һаман да иркәли. Ә Кояш... Кояш көзге һәм кышкы аязларда сөякләрне җылыта, елмая. Ләкин җәйге кебек түгел инде ул, көзге кояш яктысын сипсә, җылысын сипмәс.

Җиһан күп вакыт бизәкле зәңгәр яулык һәм шуның ишеннән үк тегелгән алъяпкыч бәйли иде. Зәңгәр яулык ышыгыннан елмайган зәңгәр күзләр... болытлы көннәрдә дә дөньяда зәңгәр сафлык һәм изгелекнең җиңелмәячәге хакында сөйли. Йөрәгендә ерактан, ата-бабалардан, бөтен нәсел-нәсәптән күчә килгән миһербан — чиста, зәңгәр кан акканны аңлата торган караш... Тата үз балаларында һәм оныкларында шул карашны күрә дә сискәнгәндәй итә. Сискәнү белән бергә, күңелдә иң татлы истәлекләр яңара. Иген кырына чыкса, зәңгәр чәчәкләрдә Җиһан төсе җемелди, аның сүзләре ишетелә.

Үзе кебек үк матур балалар калдырды Җиһан.

Быел яз, мартның хәтәр дә буранлы, адашып үләрлек көннәрендә,

этиләренең хәле начарайгач, җыйнаулашып кайттылар. Күрми калам, бәхиллек бирергә өлгерми калам дип куркудан, телеграмма суктырган иде Тата. Менә үләм, менә җан бирәм дип сулыш ала алмыйча интеккән җирдән, мин сиңа әйтим, балаларын ишетү шатлыгыннан әллә — күзләрен ачты. Күкрәкне ничәмә көннәр басып торган албастыны бәреп төшерде дә Тата, караватында гына булса да, торып ук утырды. Күзләреннән елтыр-елтыр сөенеч сирпелә иде. Янда тезелешеп утырган балалары, бигрәк тә кызлары, бигрәк тә Кырлы курай, башта шәп кенә елмая, аннары чыш-пыш көлешә үк башладылар. Ник көлгәннәрен әйтмәсәләр дә, аталары шуны гына аңламаслык түгел,. балаларының зәп-зәңгәр һәм кап-кара зур күзләрендә: «Сагынудан гына, күрәсең килеп кенә чакыргансың бит, эти, хәйләләгәнсең бит!» дигән шук мәгънәләр ялтырый иде. Я булмаса үлемнән артык шүрләгәнгә күрә, ярдәм өмет итеп чакырган дип уйлыйлармы? Ләкин Тата чынлап та үләм дип уйлаган иде. Кем белгән шатлыкның кинәт терелтеп җибәрәсен. Балаларын үз гомерендә бер генә кабат булса да алдаганын тоеп, оялудан кызарып утырды ата.

— Гафу итегез инде, балалар... үлеп булмады...

Елмаерга тырышып, шаяртыбрак әйтмәкче иде дә, чын килеп чыкты, ахрысы. Балалар, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, этиләрен юатырга керештеләр. Кырлы курай сумкасын ачып, бүләк тә тоттырды:

— Менә, эти, үлемне җиңгәнең өчен сиңа бүләк.

Бүләк дигәне музейларда тора торган таш курчак, аяксыз-кулсыз малай иде.

— Нишләптер гарип,— дип куйды этисе, бүләкне кулына алгач.

Сәбәбе «Легенда» дигән экияттә аңлатылган икән.

Борын-борын заманда безнең бабаларыбыз исәпләнгән кабиләне исеме бу көнгә килеп җитмәгән дошманнар кырып ташлаган, имеш. Исән калган бердәнбер җан иясе — шушы бала. Тата күреп тора, аякларын-кулларын кискәннәр дә аны да сазга ыргытканнар — бетәчәк дип уйлаганнар, әлбәттә. Бәлки чынлап та әлеге кабилә дөньядан бөтенләйгә киткән дә булыр иде. Ләкин үзенең балаларын җуйган бер яшь бүре бу баланы күтәреп үз оясына алып киткән һәм җәрәхәтләренә төрле үләннәр ябып, сөт имезгән, терелткән һәм карап үстергән. Бераздан соң бүреләр тормышы белән яшәргә өйрәнгән ул бала. Үсеп җиткәч, аңа бүре интәшкә балалар алып кайткан. Гарип түгел, сау-сәламәт һәм иң мөһиме — адәм балалары. Алар, үсә төшкәч, тагын үрчи башлыйлар. Шул рәвешле, бетәсе кабилә яңадан тернәкләнгән һәм чыгышы ягыннан бүре ыруы булып киткән. Тата — шул ыру дәвамы... Бүреләр — аның бабалары...

Тата экиятне, чын дип, бәхәссез кабул итте. Көн саен диярлек кулында гарип бала курчагын уйнята торган булды. Тикшерә китсәң, дип уйлый Тата, һәр кешенең эчендә ерткыч җәнлек ята... Әгәр ул җәнлеккә ирек куйсаң, тиз арада үзеңнең ерткычка әйләнүеңне көт тә тор. Дөрес, тышкы охшашлык юк диярлек. Ләкин, бик тырышсаң, анысын да табарга мөмкин. Менә Тата дигән кеше. Аның тамырларында — сүнеп, үзгәреп, алмашынып бара торган булса да, тәрек морзалары каны ага. Үз илләрендә бәхетсезлеккә очрагач, бөлгәч, азат һәм иркен җирләрнең берсенә, шушы якларга килеп җиткәннәр дә төпләнеп исән калганнар. Тата һәм аның төпчек кызы төсендә һаман яшәп яталар. Бөкрерәк зур борын. Дөрес, бу җирләрдә андый борынның бәясе әллә ни зур түгел, кәкре борын дип мыскыллаучылар да очрамый түгел. Әмма зәвыгыңа туры килсә, матур борын бу. Борын бәхәсле дисәң, күзләр бар. Зур кара күзләр. Аларны халык та бик яратып җырлый. «Карлыгандай кара, һай, күзләрең», ди. «Шомырт төсле» дип тә мактыйлар. Калганнарында зәңгәр күзләр, Җиһан күз-

ләре. Матурлык — үлемсез. Шундый матур кешеләрне бүре бабайлар белән бәйләү бик үк табигый түгел дә, нишлисең — әкият дигәнең бер дә юктан бар булмый ул. Димәк ки, дөньяга бүреләр аркасында килгәнбез һәм шулар аркасында гына исән калганбыз. Шуңа да карамастан, һәркем үз эчендәге бабасы белән көрәшергә, җиңәргә тиеш.

Җиһанга алай көрәшергә туры килмәгәндер, чөнки аның күңеле дә, яшәве дә гел сафлык хакында гына сөйли иде. Матур кешенең чиста яшәве бәхәсле. Ә Җиһанга шик ташлау мөмкин булмаган әхлаксызлык иде. Бәлки шуңа күрә дә ул бу дөньяга ат һәм бары тик тәге дөньяга гына китеп сафлыгын саклый алгандыр. Тик бичараның гомере артык та кыска булды шул, артык кыска.

Җәмәкинең сугыштан алты аты һәм шул чама сыеры исән чыкты. Бүтәннәре батырларча һәлак булдылар: кайсылары сугыш кырларына китте, дошманнан чистарган җирләрне сөрергә һәм башкага. Исәннәренең дә хәлләре хөрт буласы — ашарларына бетте, булган печәннең беразы болында калды. Тата шул хакта аһ ора, ә Җиһан зарланмыйча гына ат җигә дә болынга юл тота. Болыннан печән ташу хәтта матур эшкә әйләнде һәм авылның хөсетле дип даны чыккан Хәтимә атлы бер гайбәтчесе үзенең чираттагы сүзен авыл буйлата очырды: «Председатель хатыны дигәч тә, авылның нәсел атын җигеп кенә печән ташырга аңа кем права биргән?» Шуны ишеткәч, Җиһан үзе җиккән атны Хәтимәгә биреп, үзе арык бер ат җигеп, Тата бармаска кушса да, барыбер тыңламады, ерак болынга китте.

Җәмәкинең төп печәнлегенә Кама тамагы тирәсеннән Идел аръягына чыгасы. Район үзәгендә куналар да аннары көнозын кайталар. Бу юлы да шулай: өч хатын, өч малай, булган печәннең бөртеген дә калдырмыйча төяп, кайтырга чыктылар.

Хөсетле Хәтимәдә атның иң рәтлесе иде. Ул артына борылып та карамыйча элдерде генә. Җиһан аты арыганнан-арый барып, артта калды һәм, ниһаять, юлдашлары күздән югалгач, борыны белән җиргә төртелде. Печән ашатып карады Җиһан, сөеп-сыйпап карады — файдасы тимәде, Җиһан аны туарырга мәҗбүр булды. Тик ат туарылгач та аягына басмады. Шул рәвешле Җиһан ялгызы ялан уртасында калды.

Мондый җил оясында җылы каян табасың? Җитмәсә, көн инде кичкә авышкан. Тешләре тешкә тимәслек калтырый башлагач, кырда берүзе төн үткәрергә йөрәге җитмичә, өйгә кайтырга мәҗбүр булды. Өйдәгеләр аны ут сүндермичә көткәннәр иде. Ләкин хәзер Тата ник каршы барып алмадым икән дип үкенә. Бүтән ат юк иде шул. Ләкин җәяүләп барса?

Җиһан, үпкәләгәндәй дәшмичә, кайтты да егылды.

Кырда калган печәнне алырга ат атланып Тата таң белән үзе китте. Барса ни күрә?! Егылган ат өстендә бүре утыра... Тата булып Тата күзләрен кулы белән каплады.

Кеше күренгәч, бүре, әлбәттә, теләмичә, әкрен генә булса да кузгалды һәм ашыкмыйча ике-өч йөз сажин җир узгач, тагы утырды. Анда да авызын ялмавын белә...

Тата печәнне кайтаргач, үлгән атны алырга дип яңадан килсә, бүре тагын аның өстендә утыра иде. Тагын көч-хәл белән куып җибәрде. Ат гәүдәсен чанага сала алмыйча интекте. Ярый әле, бер хәерле адәм узып бара иде — ярдәмгә килде. Һәм Тата, ат зиратына, Чилче дигән коры елга буена кайтып, шунда, үләксә янына, атның үз башы хәтле капкын корып куйды. Җиде килолы тимер капкын. Ул аны шушы тирәдә аучы булып йөргән Чулак Албак дигән кешедән былтыр ук алган иде. Күренмәсен дип, капкын өстенә бераз гына салам, аннары йомшак кар салды. Ат, әлбәттә, кешегә үлгәннән соң да хезмәт итәчәк — үз янына бүрене «чакырып» китерәчәк...

Ап-ак, тыныч таң. Бер көпшәле мылтыгын алып, ат янына җәяүләп китте кеше.

Рәхмәттән башка ни әйтерсең — ат чынлап үзенекен эшләгән — аның янында бүре утыра. Ул, куркырга вакыт җиткәнен һаман аңламыйча, нәкъ маэмай шикелле, берни булмагандай, кешегә карап тын калды. Әйтерсең үз гомерендә бер тапкыр да җинаять эшләмәгән һәм җәза да көтми. Ләкин артык оятсызлыктан гына тыныч ул ерткыч. Кеше аңа инде җәза бирүче, гаделлекне тормышка ашыручы буларак килде. Хөкемме, көрәшме — ничек дисәң дә дөрес. Кем әйткәндәй, бергә — бер. Җинаятьче белән мондый тигезлекне саклау мәҗбүри булмаса да, әйдә, зыян юк.

Тата мылтык көпшәсен бүренең оятсыз маңгаена төбәп, чакманы тартмакчы гына иде — явыз торып чапты. Чапты дигәч тә, ул хәтле тиз кача алмас — капкынга эләккән бит бүре! Капкынны өстерәп, өч аяклап чаба. Яңа яуган мамык карда чабата хәтле өч эз ята.

Кеше бүре артыннан иярде. Ашыкмый гына барды да барды. Бер арада бүре Татага таныш, хәтта үзенә охшагандай да тоелды. Әйтерсең, бүре, усаллыкка тамчы да урын юклыктан чыдый алмыйча, көчле кеше күңеленнән чыгып качкан һәм хуҗасы аны куа киткән...

Күпмедер вакыттан соң, ерткыч юкка чыкты. Бәлки кайда булса да посып ял итә торгандыр. Ләкин инде, бүре әфәнде, сиңа ял бетте. Алгы тәпиеңдәге корыч йозак синең хәлне әкертен-әкертен кысып чыгарачак. Күпме тырышсаң да, туймас тамагың кертте сине тәмугка.

Чилче чокыры буйлап ике-өч чакрым баргач, бүре яр астына поскан — мөгаен, шунда үзен эзәрлекләгән кешене аңдып ята. Үзен кешедән акыллырак дип исәпли ерткыч. Әйдә, исәплә, исәплә. Шуның аркасында мөшкәгә туры да килерсең әле...

Чокырның сөзәк ягына чыкты Тата. Ике-өч йөз метр ара калдырып, тагын төзәде. Ә төзәлгән мылтыкны җанлы нәрсә яратмый инде ул. Кеше үз максатына иреште — бүрене тәки чыгарды ачык кырга. Ары китте ерткыч. Шулай, дөрес — хәлдән тайсын. Аннары аны хәтта коры кул белән дә тотып булачак.

Ярты көн чамасы кыр әйләнгәч, кеше бүренең хәле ничек икәнне чамалады: үзе хәтта капкынсыз да шактый талчыкты. Шуңа күрә, ахрысы, күзгә-күз очрашуны бераз гына ашыктыру өчен, адымнарын тизләтте. Ара ике-өч йөз метрлап калгач, атып та караган иде, ләкин тимәде. Шулай да бүре, куркып, юлын тагын үзгәртте. Ачык һәм тигез яланда куркынычны күреп торганчы, янадан чокырга төшмәкче булып, уңга борылды. Мәгәр кеше аның ниятен сизде һәм, бүредән дә кинәтрәк борылып, Чилчегә таба атлады. Тигезлектән котылыр өчен хәзер бүрегә иң җайлы юл авылга чабу иде. Һәм шул якка юнәлде дә! Авылда нәрсәгә өметләнүен, нәрсәгә исәп тотуын ул үзе дә белми, әлбәттә. Ирексездән, мәҗбүри бара... Ә исәпсез йөрелгән мәҗбүри юлның беркайчан да максатка алып килгәне юк. Кеше моны аңлый, ә бүре...

Кеше акылы бүредә булса?

Кеше акылы бүредә булса, аны фашист дип атыйлар бугай... Кайбер бәндәләр үз эчләрендәге ерткычлыкны үтерү түгел, аны хәтта иркәләп үстергәнгә күрә, бүрегә әйләнгәннәр...

Кар яумый. Көн җылы, аяз. Шундый яп-якты көндә бүре авыл урамыннан атлап китте. Аны күргән кешеләр, мөгаен, курыкмагандыр — эт дип уйлаганнардыр. Капкын өстерәп барганын абайлагач, хәтта җәлләп тә куйганнардыр әле.

Ләкин бүре, үз хәлен белеп, ерак китмәгән иде. Авыл башындагы өйнең хуҗалары чабышып урамга чыккан сарыкларын һәм сыерларын кабат ихатага кертергә тырышсалар да, һич кертә алмыйча хәлдән

тайган һәм тәмам аптырашта калганнар иде. Аларны күргәч, Тата бөтенесен аңлады.

— Кумагыз сарыкларыгызны, интектермәгез сыерны! — дип кул селтәде ул.

Мылтыклы кешенең кем икәнен авылда беләләр. Бу авылның элекке кияве ул. Гөлҗиһанны урлап чапканда үзе эләксә... хәле әлеге бүренекеннән һич җиңел булмаячак иде.

— Сезнең абзарга бүре кереп качты,— диде Тата аптырабрак калган кешеләрне тынычландыру нияте белән.

Ләкин кайда ул тынычлану — авылның бөтен бала-чагасы, бөтен карт-корысы — кай арада диген — шушы тирәгә җыелды. Аларга илтифат итмәстән, аучы башта өй тирәләрен, күтәрмә асларын, аннары утар-бакчаларны айкады, аннары килеп абзарга керде. Тик анда да күзгә берни чалынмады.

— Юктыр ла,— диешә башлады кешеләр,— көпә-көндез каян килсен ди бүре.

Әйе, ышанган тауда — киек бар. Бу абзарда да шулай. Абзарның инде соңгы бүлеме, бозаулыйсы сыер, бәрәнлисе сарык яки яшь мал ябыла торган караңгы бүлеме. Шушында... Ишек ачык... Чак кына ялгышсаң, юлында торсаң, бәрелеп, егып качачак. Мылтыкны ашыкмыйча гына коргач, ягъни яңа патрон куеп, чакманы күтәргәч, ун-унбиш минут сагалап торды Тата. Ләкин бүре чыкмады. Әллә чынлап та монда юкмы, әллә бүтән җиргә качканмы?

Көн кичкә авышкан — ашыгырга кирәк. Төнгә калдыңмы — синә җайсыз. Караңгылык — ерткычның юлдашы.

Ни булса да шул дип, Тата караңгы бүлемнең ишек катына ук терәлде. Тагын бераздан... Юк, бүре кыштырдамады да хәтта... Димәк, түземлек — аның бердәнбер коралы. Аучы ачык ишектән караңгы бүлемнең эченә үк керергә мәҗбүр булды һәм... Коточкыч ырлаган тавышка борылып караса, бүре дөм-кара почмакта тешләрен ыржайткан, кеше кебек, ике аягына баскан иде. Бүре кеше өстенә ташланырга тора. Бер секунд... Аннары соң булачак. Кем кемне...

— Стой!

Шулай дип кычкырды Тата — әйтерсең аның каршында кеше басып тора иде. Һәм, ходайның хикмәте, бүре әйтерсең шуны аңлады — өскә ташланмыйча, тагын ике аяклап басып калды. «Кыюлыгы качкан!» — ул арада капкын да күзгә чалынды. Әйе, ниһаять, алар күзгә-күз очраштылар. Ике дошман, дүрт күз бер-берсенә текәлеп калган. Монда инде килешү юк. Кем кемне үтерә ала, шул — җиңүче, шул гомерен дәвам итәчәк. Ә җиңелүче... Уйларга вакыт юк, җитте вакыт — ат! Югыйсә...

Ләкин Тата тагын атмады. Ник икәнен аңлый — ерткыч булса да, җинаятьче булса да, дошманның үз тешләреннән гайре коралы юк, ә кешенең ул тешләргә каршы куллары бар. Бүренең кулларга каршы күтәрелергә тиешле тырнаклары капкынга кысылган... Бер генә тәпи... Аңа каршы — мылтык... Тешләргә каршы — мылтык... Бердәнбер гадел ысулны сайлады Тата — мылтык көпшәсен бүренең баш сыярлык авызына, бугазына тыгып җибәрергә талпынды һәм... ялгышты. Тимерне капмыйча, Татаның үз өстенә ыргылды бүре. Тик Тата «ә» дигәнче хатасын төзәтеп өлгерде һәм ерткычның маңгае шакылдап мылтык түтәсенә бәрелде. Дошманының чак кына исе җуела калудан файдаланып, Көчле кеше бүре башына мылтык белән тагын китереп орды һәм мылтык шартлап сынып та чыкты. Сынык мылтык белән булса да тагын бәрмәкче иде, бүренең кинәт башы кыйгайды, һәм шул арада Тата мылтыкның теткәләнгән түтәсен хәлсез дошманының авызына каптырды. Агачны кабул күрде ерткыч һәм үлем әчесен җыеп чәйни

калды. Кеше ни өчендер тиз генә чыгып чапты. Күзләренә ак-кара күренмәде.

— Кайда сәнәк, кайда балта? — дип акырды ул.

Бүтәннәр балтамы, сәнәкме эзли торганда, аучының башына икенче төрле фикер төшеп, ул тиз генә чалбар каешын ычкындырды да бүре янына яңадан кереп китте һәм, ничәдер минут үтүгә, кулына сынык мылтыгын тоткан килеш, бүрене көч-хәл белән өстерәп кешеләр арасына алып чыкты. Тана хәтле бүре тере килеш халык аягы астында аунап ята иде.

Тата үтенече белән авыл картлары бүрегә борынчак әмәлләгәч һәм ерткычны салам ташый торган зур гына кул чанасына яткырып бәйләгәч, авылны чыкканчы озата килделәр. Ике малай ярты юлга чаклы тартыша килде. Биек тау башыннан үз авылы күренә башлагач, ничек тә кайтып җитәрмен, адаша күрмәгез, дип, Тата малайларны да кайтарып җибәрде һәм чанага җигелеп үзе генә тартып китте.

Юл инде югарыдан, бая бүре качкан чокырлар өстеннән уза. Анда, билгеле, җәнлекләргә качарга, яшеренеп яшәргә, оя корырга мөмкин. Куркыныч урыннар. Бая курыкмыйча узганы хәтергә төшеп, шуңа үзе дә гаҗәпләнеп куйды. Хәзер чокырларны сөзәгрәк төшеннән узасы итте.

Чана җиңелрәк шуа башласа, Тата артка, бүрегә борылып карый. Ауса да ычкыныплык түгел болай, каты бәйләнгән. Әмма тана хәтле бүре шактый авыр — ауса, яңадан чанасы-ние белән әйләндерүе җиңел булмаячак.

Утырып ял итәсе килә. Көч-хәл белән өстерәлә. Тән манма су. Бая бүре өч аяклап чапканда Тата, ике генә аяк белән булса да, барыбер куып җитте. Куып та җитте, бергә бер булган гадел көрәштә егетләрчә җиңеп тә чыкты — ачыктан-ачык, күзгә карап. Почмак артыннан сагаламады. Туп-туры барды һәм чынлап җиңде. Ләкин шунысы сәер — җиңгән зат, менә ат булып җигелгән дә җиңелгәнне тартып кайта. Бүре шуны сизгәнгә күрә тыныч кына, горур гына ята шикелле. Кинәт... сәер тавыш:

— Стой! — Бая бүрегә Тата үзе шулай дип акырган иде.

Тупас тавыштан катты да калды Тата. Каршында мылтык тоткан яшь кенә бер егет басып тора. Таныш егет — күрше Черныш авылыннан Петруха малае. Әтисе сугышта каһарманнарча һәлак булгач, авылдашы аның геройлык йолдызын алып кайткан һәм әнисенә тапшырган дип сөйләделәр. Ә менә улы...

Ике-өч ел элек алар үзләренең сыерларын Татага саткан иде. Сыерын сагынып иза чикте Полина түтәй. Шушы кечкенә малаен нәртте дә килде, нәртте дә килде. Килде дә кадерле сыерын кочаклап үкседе. Килгән саен малаен да, анасын да куе, тәмле катык белән сыйлый иде Гөлҗиһан. Сыйлангач, Полина түти чукына-чукына зур-зур бәхетләр тели, ә малай борынын тартып сүзсез генә карап утыра иде.

Малай егет булып җиткән. Армия хезмәте исәбеннән ФЗОга алып киткәннәр иде шикелле. Ләкин нишләп кире кайтты икән? Шул хакта сорагач, егет:

— Артык күп белсәң, башың авыртыр,— дип кенә куйды һәм:— Давай, кирәк нәрсәне биреп котыл,— дип җикерде.

Сүзләре, билгеле, үзенеке түгел, Тата моны шунда ук аңлады. Тавышында да ясалма кыюлык. Менә синең борын тартып, мышкылдап торган малай. Сүз әйтергә дә курка торган мокый нинди тупас адәмгә әйләнгән! Малайларның начары булмый. Нишләп әле матур һәм саф күңелле малайлар алама ирләргә әвереләләр?

— Бирмәскә уйладыңмыни, Тата абый?

— Нәрсә кирәк соң сиңа, балам? Бүреме?

— Мин үзем бүре. Син миңа дары бир.— Шулай дигәч, чанадагы

затык мылтыкка сузылды. Караса, бердәнбер патрон, анысы да атылган. Шуны кесәсенә салгач, бүрегә соклана калды.— Эх, нинди дәвен каптыргансың бит, ә? — Хәзер ул тагын элекке матур малайга әверелде.

— Зыяны күп тиде, балам. Шуңа күрә авыл хөкеменә алып кайтам.

— Ә мине тотам димә, башың ике булмаса.— Тагын чит сүзләр.

Тата абыйсы аның күзләренә карап менә ни күрде: усал булып кыланыр өчен малайга нык тырышырга туры килә, шуңа күрә каушый. Кем кулына эләккән, кем йомышын үти һәм кем сүзләрен сөйли?

— Сине ФЗОга җибәргәннәр иде түгелме, балакаем?

— ФЗОга түгел... Армиягә.

Монысы да аңлашыла. Бәләкәй чагында арбага тапталып аягы имгәнгән иде егетнең һәм хәзер дә сизелер-сизелмәс кенә аксаклый. Егет кеше шул кечкенә гариплегеннән армия урынына ФЗОга алынуыннан гарьләнә. Һәм... мөгаен, качкан.

— Әйе, армиягә. Ә нишләп, алайса, монда буталасың?

— Анысы синең эш түгел.

— Балам, акылыңа кил, болай качып йөрмә.

— Бирәсеңме дары, юкмы? Бирмәсәң, җаныңны бездә калдырасың.

«Әһә, «бездә!» Димәк, үзе генә түгел».

— Ничә кеше сез?

— Мин... берүзем. Әгәр тоттырасы булсаң, таныш кеше дип тормам.

— Миңа мылтык төзи алырсыңмы?

— Мин булмасам, башкалар табылыр.

— Чуже үзең генә түгел. Кем анда качып ята? Ник сине котырта?

Тата абыйсының нияте һич тә егетне рәнҗетү түгел, бары тик үзе яраткан чибәр ак малайны коткарып калу иде, ләкин, үзе дә сизмәстән, катырак бәрелде бугай. Егетнең кинәт агарынып китүеннән күренде саксызлык. Аны кызганырга гына кирәк иде бу минутта һәм Тата кызганды да. Үзен, ничектер, гаеплерәк санап, башын түбән иде. Ләкин егет, әллә инде моны курку билгесе дип уйлады, тагын батырая төште һәм усал тешләрен күрсәтеп ырҗайды:

— Дары бирмәсәң, башың бетә.

— Ышанмасаң тенте.

— Ышанам. Барыбер миңа дары кирәк.

— Каян алыйм юкны?

— Өеңдә бар?

Өйдә чынлап та бар иде. Ялган Тата абыйсының кыяфәтеннән үк сизелгәнгә, малай тагын да кискенрәк боерды.

— Алып кил, смотри.

— Кайчан?

— Бүген үк.

— Күреп торасың — арылды. Бүре куып кара син.

— Алайса, иртәгә Чернышевкага минем әнигә илт.

— Ярый, илтермен.

Татаның ни уйлавын чамалап, егет кисәтергә тиеш тапты:

— Бу арада район үзәгенә бармыйсың. Авыл Советына да сугылмыйсың. Әгәр андый-мондыйны уйласаң, башың бетә. Безнеке бетсә, башта синеке...

Тагын «безнеке...» «Карап карарбыз, кем икән ул сезнекеләр?»

— Кемгә дә булса әйткәнеңне сизсәм, өеңә үзем кереп җаныңны алып чыгам. Шаярмыйм. Сөйләнмисеңме? Ант итеп әйтсәң генә җибәрәм хәзер... Синең мылтык әтмый бит. Ә минеке — төзек.— Шулай дигәч, егет читкәрәк тайпылды. Бу минутта аңардан усаллыкны, кыланудан чынга әйләнәчәк ерткычлыкны көтәргә дә мөмкин иде. Тата вәгъдә бирергә тиеш.

— Мин бит — колхоз председателе, районга теләсә кайчан чакыралар. Бармый калырга ярамый. Тагын чакырсалар, берни сөйләмәсәм дә сез мине харап итәрсезме?

— Безгә һөҗүм итүче булмаса, әйтмәвең шул булыр. Синнән башка белүче юк.

— Ә чуже сизсәләр?

— Сизмәсләр. Дарыны минем әнигә бирерсең.

— Ярый, бирермен.

Шул рәвешле, Тата абыегыз җинаятьчел бәйләнешкә керде. Тынычлыгын югалту бәясенә генә авылына кайта алды.

Бүре тоту, тана хәтле ерткычны күзгә-күз бәрелештә җиңү горурлыгы үзенең ләззәтле көчен тиз җуйды.

*

* *

Вәгъдә — иман. Ходай да, адәм дә шундый гадел закон чыгарган. Әгәр бу дөньяда иман бозсаң, тегесендә җәдәченне икегә аералар, имеш. Анысы — киләчәк эше, күз күрер иде әле, бәлки Тата үлгәнче андагы тәртипләр үзгәрә дә төшәр. Үзгәрмәгән очракта, Тата, аллага шөкер, беркайчан да аптырап кала торганнардан түгел, күз тимәсә, тиешле затлар белән анда да уртак тел табар — җәдәчен саклый алыр чарасын күрер. Әмма хәзергесе бик тә хәерсез — адәмнең үз әхлакый законы якадан эләктерде. Икенең берсе — я вәгъдә бозасың да районга чабасың, яки исә Чернышка дары илтә китәсең. Аннары инде чанада яткан карт бүре яңадан күңелгә кайтып ырлый башламас димә.

Районга китсәң, кайда сагалап ятуларын белмәссең, ә эшнең ничек бетәсе аермачык — запаста бер генә кешене (гәрчә ул Тата булса да) теге дөньяга җибәрерлек дары бар аларда. Юкка гына кыю сөйләштемени малай актыгы. Кемгә булса да әйтсәң? Авылда малай-шалай, хатын-кыз. Кызык итеп бер-берсенә пышылдаша торгач, ике-өч сәгатьтә ул сүз, саескан шикелле, авылдан авылга сәяхәт итәчәк. Аннан мылтыклы егет (ул булмаса, әзмәвер кебек бүтән кеше!) алдыңа килер дә чыгар. Анысын егет каты карганып әйтте. Сүзен үтәр. Төрмәгә кереп ятасы килмәсә.

Чернышка дары илтә китсәң? Бусы, әлбәттә, бернинди ант, вәгъдә белән беркетелмәгән. Үпкәсеннән эләктергән тимер бармаклар җибәрмәгәнгә, Тата сугышта булмаган, присяга дигәннәрен бирмәгән. Шулай да илгә, законга, халыкка хыянәт инде бу. Җинаятькә тоташкан хыянәт. Әгәр яшереп калса, халыкка, вөҗданга хилаф эш була монысы. Көчле кеше алай эшли алмаячак. Әлбәттә, эшли алмаячак. Хәбәр итәчәк — җай чыккач та. Ләкин менә җай... Ничек чыгар. Мылтык тоткан кеше кайчан каршыга чыгып басар?

Арттан килеп юлны бастылар да түгелме?

Тфү, үләт ялаган, чанада бүре тартыша. Әллә җан бирергә чамалый инде хәсис — чалган мал төсле чәбәләнә. Юк, җан бирергә ниятләнми. «Ычкынып чабарга вакыт» дигән уй башына килгәндер. Нигә дисәң, күзләре мут карый башлаган. Үләргә исәбе юк мәлгуньнең. Эт җан икән бүре дә — шул хәтле тукмалуга һәм... Әле генә игътибар итте Тата — күпме кан аккан. Аклы-каралы язгы карда кан таплары чуарланып калган.

Канлы сукмакны тагын озынайта төшеп, ары атлый Көчле кеше. Көчле кешене сораулар хәлсезләндерә.

Ишек төбендә борын тартып торган юаш малай... Помшак күцелле, кыюсыз малай... Нишләгән ул? Тагын нишләр? Дарыны юкка гына сорыймы? Җәнлек атаргамы? Җәнлек кенәме? Әгәр үзенә куркыныч була башласа, куркуын һәм ачуын патронга тутырып очырмас дип

кем вәгъдә бирә? Әйе, егет каты җинаять алдында, әле үзе үрмәләп менгән Чилче базыннан да тирән һәм шомлырак упкын каршында тора. Башы әйләнеп киттеме, сөякләрен бүреләр җыячак. Үз-үзенә шундый баз казырга керешкән малай. Саклап калырга кирәк. Ничек итеп сакларга мөмкин диваналы? Акыллыны мөмкин әле, ә диванны ничек? Үз гомере бәясенә коткарсынмы Тата аны? Дөнья матур. Тормышның хәзергесе алама һәм авыр булса да, инде киләчәк гүзәллеге якында гына. Шуны күрмичә, балаларның башлы-күзле чакларына, матур тормышларына сокланмыйча, балаларның балаларын тез өстенә утыртып сөймичә, ничек китәсең бу дөньядан кайчандыр борын тартып, мышкылдап утырган малайны коткару бәясенә? Җитмәсә, тагын шунысы бик ихтимал: коткара да алмассың, үз гомереңне дә бирерсең. Менә сиңа булыр мәгънәсезлекнең аръягы. Юк, Татаның яше шактыйга җиткән булса да, андый мәгънәсез әҗәлгә баш бирәчәк түгел ул, бирмәячәк. Ләкин нишли ала?

Күпме тырышсаң да, уйның очына чыгармын димә. Авыл.

Канлы сукмак шушында тукталыр, ләкин уй... Авыл капкасын узуга, әллә бүре исен, әллә Татаның авыр уйларын һәм афәтле хәлен сизеп, авыл бетереп этләр һауларга кереште.

*

* *

Бүтән чакта капка төбенә чыгып каршылый торган хатыны бүген күренмәде. Балалар да каядыр киткән, ахрысы. Каратал тавында, кардан арынган чирәмдә — «җәй»дә ауныйлардыр. Балалар гел шулай җәйгә ашыга, ә Җиһан? Иренең нинди авыр хәлдә икәнен сизми, мөгаен.

Бүрене чанада калдырып, өйгә керде. Ләкин өйдә дә шомлы тынлыктан башка нәрсә юк иде.

— Җиһан, Җиһан!

Ак өй түреннән ыңгырашкан тавыш ишетелде.

— Нишләп чыкмыйсың, ни булды?

Шулай дип сорады Тата. Хатынының төнлә хәлдән таеп кайтканын һәм төн буе пошыргаланып чыкканын ул, ничектер, онытkан икән. Хәтеренә төшкәч, тиз генә түргә атылып керсә, Гөлҗиһан түшәктә ята иде.

— Хәлең авырмы әллә, сиңайтәм?

Җавап урынына хатыны елап җибәрде. Әллә каян сизелеп тора: бөтен тәне ут шикелле, сулышын көчкә ала. Печән артыннан йөреп һәм бүре белән мавыгып, Тата нинди авыр хәлдәге хатынын көнозын ялгыз калдырган.

— Уфф... Туңам, салкын. Тагын бер кат юрган яп әле.

— Шулаймы? Ярый, тынычлан, сиңайтәм. Салкын тими тормый ул. Менә хәзер баллап чәй эчертәм, мәтрүшкә кайнатам.

Хатынын әйбәтләп яткырды, өсләрен рәтләп япты да иң әүвәл самавар куйды, утын кертеп мичкә якты — кара өйнекенә дә, ак өйнекенә дә. Ишегалдына бер чыгуында утардагы малларының куркып чабышуын шәйләде. Урам як койма буенда чанада бәйле яткан бүре һаман селкенә икән — үлем белән тарткалаша, мөгаен. Шул кирәк ләгыйньгә. Ә менә Гөлҗиһан... изге җан — аның ни гөнаһысы бар да, ник аны җәфалый бу дөнья?

Татаны күргәч, бүре тынычлангандай булды. Хәлдән тайган, янәсе. «Күп кылдың җинаять, җәзасын күр». Ләкин үз яныннан чак кына ераклашкач та, җинаятьче, ырлый-ырлый, аякларын кыскан тимерне чәйнәргә кереште. Җаны чыкса да, явызлыгы чыкмас, каһәрнең. Дөмегергә исәбе юк күпме каны аккан килеш! Булса да булыр икән!

Бүрене алып кайтты кайтуын, әмма, дөресен генә әйткәндә, кая куярга, нишләтергә икәнен белми аучы. Соңыннан, дистәләп ел узганнан соң, анда да балалары аңлаткач кына төшенде: ерткычның тунын район үзәгенә илтергә һәм күпмедер акча алырга тиеш булган икән ул. Кайсы колхоз җирендә тотылган, шул колхоз бер сарык бирергә тиеш булган. Шулай да әйтү кыен, әгәр белгән булса да, бүре тиресе сатып акча сорап йөрер идеме икән ул? Бу эшне акча өчен эшләдеме Тата? Юк, юк, һич тә акча өчен түгел, бүтәнчә булдыра алмаганга, атны җәлләп, исән терлекләрне саклау теләге белән һәм шул ук вакытта, ниндидер җилкенүгә охшашлы бер хис кушуы буенча эшләде. Көчле белән күзгә-күз күрәшү әллә нинди куркыныч ләззәт бит ул. Моны бары тик аучы, аның да сирәге, Тата булганы гына тоя һәм аңлый торгандыр. Бүре тоту күңелне иркәли, ә төлке тоту — рәнҗетә. Үз гомерендә бер генә төлке тотты Тата һәм анысын да үтермәде.

— Ничек? Тукта әле, тукта, бая мылтык тотып юл баскан малай да бар иде түгелме соң төлке тоткан чакта? Нәкъ шул малай, шаян, җор малай — әле аягының да исән чагы иде. Черныш сыерлары туплавында, кечкенә буа тирәсендә уйнап йөргән җиреннән, Татаның кулбашында мылтык, кулында көрәк барын — җәнлек тотарга баруын белгәч, уйлап та тормыйча иярде дә китте.

Төлкенең кайчан, кай тирәләрдә йөргәнен, яшәү рәвешен Тата яхшы белә иде, ул ялгышмады. Чикләвек куаклары бетүгә, төлке чокырның аргы башыннан чабып та чыкты. Ләкин кәтелгәннән тизрәк качты. Мылтыкны җилкәдән алырга да өлгереп булмады. Әмма шулай хәерлерәк иде, чөнки малайның сөенүен күрсәң! Өтне өстерә-өстерә, төлке артыннан чабарга кереште. Татаны бер басу арасы ераклыгында калдырып киттеләр һәм ахырда (әгәр күзгә чалынуы дөрес булса) нигәдер туктадылар. Бер тирәдә әйләнгәләп йөрделәр-йөрделәр дә күздән югалдылар. Тата шул тирәгә барып җиткәч кенә төшенде: төлке җир тишегенә кереп киткән, ә маэмай белән малай, янадан чыкмасмы дип, аны сагалап куак төбендә яталар иде. Чыгарырсың!

— Качтымы? — дип, малайның башыннан сыйпады Тата.

— Менә, Тата абый, шушы тишеккә керде, — диде малай сулышын көчкә тыеп. — Нишлибез инде, ә?

— Нишлибез дип... чыгар әле, җир астында мәңге ятмас.

— Көтәбезме?

— Көтәбез.

— Ә ул кайчан чыга?

— Кыш җиткәнче чыга да чыга инде.

— Шуңынчы саклыйбызмы?

— Сакламыйни. Кая ашыгасың? Ят та ят.

— Ашыйсы килә бит, Тата абый.

— Төлкенең дә тамагы синекеннән ким ачыкмый ул.

— Алайса, тиз чыга.

— Көтеп карыйк соң.

Әлбәттә, оясы өстендә кешеләр йөргәндә төлкенең үлсә дә чыкмасын аучы белә. Хәл алыр өчен генә шаяртты ул малайны. Бераз сулышы тынычлангач, көрәкне малайга тоттырды һәм чиратлап казырга керештеләр.

Октябрь башлары, көзге көннең холкы билгеле. Кинәт кенә килде дә яңгыр коярга кереште. Тата:

— Әллә кайтыйкмы, иртәгә яңадан килербез, — дисә дә, малай күнмәде:

— Что син, Тата абый, ярыймыни шулай?! — диде хәтта бераз рәнҗеп. — Иртәгә бу чокырга якын да килми ул.

Тирдән һәм яңгырдан манма суга батса да, бертуктаусыз казыды малай. Хәтта, ничектер, бераз кызганыч та сыман тоелды. Ләкин кеч-

кенәрәк соры күзләрнең очкынланып януын күргәч, кызгануны сокла-ну, ярату хисе җиңде. Үз сүзле, нык холыклы малай икән, болай гына басынкы күренә. Һәм... Шул мәлне төлке ырлавы ишетелгәч, малай эче катып көләргә кереште.

— Төлкенең өенә барып җиттек бит, җиттек!

— Шулай бугай шул, балакай. Тик шаулама, бераз тыңлап карыйк.

Тыңласалар, искиткеч хәл: казылган җирдән шактый еракта, җир астында ырлашкан, сугышкан тавышлар ишетелде. Төлкеләр, димәк, берәү генә түгел. Тавыш килгән урыннан чамаласаң, яннарына барып җитәр өчен тагын бер көн казырга кирәк.

— Бүгенгә булмады, улым, әйдә, иртәгә килербез.

— Мин кайтмыйм.

— Төн буе шушында утырырсыңмы?

— Утырмыйча!

Менә сиңа!

— Иртәгә иртүк килербез.

— Кайтасың бик килсә, син кайт, Тата абый.

Хәл катлауланды. Бүтән чара тапмыйча булмас. Әйе, оя казу бер-дәнбер ысул түгел бит.

— Синдә шырпы юкмы, балам?

Малай Татага шырпы сузды. Эшнең нәрсәдә икәнен аңлагач, чы-бык-чабык җыярга кереште, ике-өч кабат барып, коры салам китерде. Тата исә саламны бераз читкәрәк, икенче өн өстенә өйде дә ут төртте. Чыгып чапмасын дип, казылган тишек янында малайны калдырды. Ут-ныклап үрләгәч кенә аның янына килде.

— Ни рәвешле эләктерербез икән, бияләй юк бит?!

— Эт тотар әле.

Малай шул сүзне әйтеп тә бетерде, чокыр эченнән әллә нинди кара бер җәнлек чыгып та чапты.

— Өсс, Пальма! — Әлбәттә, җәнлек артыннан эт тә атылды.

Шул минутта... ярый әле күреп калдылар: төлке дә ыргылмакчы иде, малай аннан алдарак өлгереп, төлкенең өстенә капланды. Җәнлек ырлый, тешли, малай ухылдый, ләкин ычкындырмый. Шул арада Тата фуфайкасын салып төлкегә каплады да тиз генә аны күтәреп алды. Малай аның тирәсендә бөтерчектән дә тизрәк бөтерелә: битләре кап-кара, кулларыннан кан ага, ә үзе көлә, күзләре, соргылт-яшел күзләре, бәхетле күзләре, әйтерсең очкын чәчә.

Ялкындай җитез хәрәкәтләр белән малай озын бил каешын (мөгаен, атасыннан калган) кай арада ычкындырган да кай арада төен ясап, Тата кулындагы пинжәккә, юк, пинжәк эчендәге төлкегә үрелә. Икәү-ләп күпмедер азаплангач, төлкегә менә дигән шәп борынчак әзер дә иде инде.

— Молодец, балакай, әтиеңә охшагансың икән, кеше чыга икән болай булгач синнән, шәп кеше чыга!

Малайның күзләреннән яшел сөенеч сирпелә иде. Әйе, бу аның ялангач куллар белән төлке тоткан көне, гомер буе онытылмас бәхете булгандыр. Үсә төшкәч, нәкъ төлке кебек җир тишегенә кереп качар да үзен шулай чокып һәм төтен белән тончыктырып чыгарырга туры ки-лер дип ул чакта кем уйлаган!

Ул чакта Тата абыйсы малайның үзеннән һич тә ким әсәрләнмә-гәндер. Бәләкәй баланы кочаклагандай кочаклап, җәнлекне (җәнлек-нең дә ниндиен — әкиятләрдә атаклысын, хәйләкәрен һәм иң чибә-рен!) күтәреп кайт әле син!

Шатлыктанмы, аска таба рәтләп карый алмагангамы, абына-сөрте-нә уздылар басуны. Тауга җиткәч, карама төбендә бераз ял иттеләр. Телдән бигрәк, күзләр аңлата иде бөтен сөенечне. Малайның бәхетле

күзләре, яшел ут очкыннары күңелгә мәңге ялкынланыр өчен керделәр бугай.

Чакрымнарга сузылган уҗым басуын узгач, саргайган чирәмле җирдән тау төшкәч һәм Черныш юлына чыккач, яраткан этен кочаклагандай, төлкене кочаклап тоткан малайга Тата карап торды-торды да, аның моннан да матур чаклары әллә булыр, әллә юк дигән уйга килеп, уртак төлкене бүлешмәскә, малайга бүләк итәргә булды. Шулай да, сынамак өчен, болай дип сүз кушты:

— Кулың талгандыр, бир инде хәзер үземә.

— Юк, юк, мин сине өеңә хәтле озатам.

Аңлашылды.

Малайның аркасыннан яратып какты аучы.

— Ярый, улым, төлке — синеке.

— Чынлапмы?

— Менә инде, чынлап булмыйча. Икенче юлы миңа тотарбыз.

Малай күзләреннән көләч очкыннар бу мәлдә бермә-бер артык чәчелде. Кешене, бигрәк тә гөнаһсыз сабыйны, бигрәк тә шатлык сирәк була торган елларда сөендерә алу үзе бер бәхет иде бит. Олы кеше малайдан да бәхетлерәк түгел идеме икән әле? Кешене сөендерә алу дөньяда иң олы һәм изге хис. Ул үз бәхетеннән чамасыз канәгатьлек белән малайны, аннары төлкене тагын бер кабат сыйпады да:

— Ярый, улым, алып кит өеңә,— диде һәм үз юлы белән атлады.

Малай башта, үз бәхетенә үзе ышанмыйча, хәтта кузгала алмыйча торды. Аннары кыюсыз гына, әкрен генә атлап китте, шуннан соң инде Татаның шаяртмавына тәмам төшенгәч, син күр дә мин күр — йөгерде генә.

Хәзер шунысы бераз үкендерә: ник сорамады икән соңрак, нишләтте икән малай төлкене? Үтердеме, бәйләп булса да саклыдымы, күтәреп киткәндәге кебек үк яраттымы икән?

Шик интектерә хәзер: үтермәдеме икән? Үз куллары белән? Кыйнап? Малайның мылтыгы юк иде ул чакта... Әллә нилэр күз алдына килә — теп-тере төлкене буып үтергәндер һәм тиресен тыныч кына тунап саткандыр төсле...

Бәлки болай ук уйлап Тата үзенә гөнаһ арттыра торгандыр, әмма әйләнә дә килә, әйләнә дә килә бәйләнчек уйлар. Ник кызыксынмады, ник сорамады икән шул чакта?! Ник хәзер мылтык тотып юл баскан чагында сорарга башына килмәде? Мөгаен, үтергәндер, мөгаен, теп-тере, кып-кызыл шул чибәр төлкене, үзенең яраткан төлкесен, кечкенә куллары белән буып үтергәндер...

*

* *

Ул чакта аучы кеше үзенең сөекле хатыны янына кош тоткандай канатланып кайтты.

— Төлке тоттым бит, сиңайтәм.

— Әйбәт булган. Кайда соң төлкең? — Гөлҗиһанның зур һәм матур күзләреннән нәкъ баягы малайныкы төсле очкыннар сирпелде.

Иргә ничектер уңайсыз булып китте.

— Кайда дип, ни... Теге Петруха малае ияргән иде — шуңа биреп җибәрдем.

— Ә-ә... Миңа да күрсәтсәң, әйбәтрәк буласы икән.

Дөрес сүзгә җавап юк. Бераүне шатландыру икенче кеше бәхетен киметүгә охшады. Җайсызрак килеп чыкты, каһәр, бөтен нәрсәнең дә ахырына чаклы уйлап бетерү мөмкин түгел икән. Ярый әле, карчык шәп — якага кирәк иде бит дип тирги башласа һәм якадан алса, нишләтер идең. Бераүнең хатыны булса... Акыллы, дәгъвасыз, сугылып-

бәрелми — табигате белән үк әдәпле хатын. Аслы һи, нәсле һи — затлы ырудан шул, затлы. Ни генә дисәң дә, кан белән үк бирелә әдәп. Чулак Албак дигән аучының әнә балалары да аучы. Чулак дип, аны сугышка алмадылар, ә монда шул кулы мылтыктан һич аерылмый — штатный аучы. План дигәннәрен бирәләр, шуңа күрә башкалар тотканны да үзенә сорап ала. Ул чакта да: «Әй, әрәм итеп, төлкене әллә нинди малайга биргәнсең!» дип рәнҗегән иде. «Сиңа бирүдән ни файда, син ул малай кебек шатлана белмисең, акча гына каерасың бит!» дигәч, рәнҗемәгән шикелле иде. Сиздермәгән генә, ахрысы.

Нигә дисәң, менә хәзер, бүре тикле бүре тотып кайтса һәм хәбәр җибәрсә дә, килми Албак чулак — ялындыра, мәгънәсез. Җир кануны, гаделлек сүзе: капкын Албакныкы булгач, ярты бүре — аныкы. Мәгәр Тата ваклана торган кеше түгел — алсын чулак бөтенләе белән. Әерткыч исә койма буенда ике көн шыңшып, бөтен авылның барлы-юклы тәрлеген һәм этләрен акылдан диярлек яздыргач кына җан бирде. Ләкин Албак күренмәде. Өенә хет үзең илт. Анысын да эшләр иде, иренмәс һәм горурлык та сакламас иде, әмма Петруха малае моны авыл Советына үзе хакында хәбәр итәргә бару дип уйламасмы? Соңгы патронын кайчандыр яраткан Тата абыйсына сәлам итеп җибәрмәс дип ышану мөмкинме? Мәгънәсез эшләнгән эшне Тата гомер буе яратмады. Мәгънәсез кешеләрне тозсыз дип мыскыллады. Шул рәвешле бер көн көтте Албакны, ике көн. Ә өченче көнне... Албак килсә дә, фәлән сум акча бирсәң, хатыныңа фәлән төрле дару табарга була дип, нидер сөйләсә дә, Тата аны күрмәде дә, ишетмәде дә. «Дөмек бүрең белән» дип әйткәндәй генә тоелды.

*
* *

...Тата бакчасы турына җиткәч, Үләмә кырт борыла. Шунда, эз алмаштырган куян кебек, Үләмә кырт борылган җирдә, ике кеше бер юлы кочакласа да кул җитмәс юан, кайбер кошлар да бик тырышып кына күтәрелә алган биек куш өянке шаулап утыра. Җилле, давыллы көннәрне әйткән кая, бүтән агачлар яфрак селкенүнең нәрсә икәнен оныткан тымызык көннәрдә дә жуылдап нәрсәдер сөйли бу өянкеләр. Алар — Татаның күңеле төсле... Аларда Тата якын һәм ерак бабаларының мәңгелек сулышын тоя. Теләсә кайчан тыңласаң да әллә нинди тирән мәгънәләр аңлатып шаулый шул өянкеләр — үткәннәрдән васыятьләр, теләкләр, риваятьләр, хатирәләр — барысы да, барысы да бар сыман шул өянкеләр шавында. Алар — Татаның гомере буена изге дип исәпләгән өянкеләре — тере һәйкәлләр.

Өянкеләр белән бергә, Тата кайбер кешеләрне хәтерли: алар, 1921 елда ачлыктан качып, үз ояларын калдырып, Себер янсә Ташкент якларына киттеләр дә кире кайтмадылар. Тата кайтты — үлсәм дә шушы җирдә, өянкеләрем янында туфрак булсын гәүдәм, диде.

Кайберәүләр Донбасс якларына китеп төпләнделәр. Тата да барды, күмер базларында тимер кәйлә белән ташлар актарды. Ләкин чак кына хәле авырайса, гәүдәм читтә күмелеп калмасын дип, туган туфрагына җилкенде һәм кайткан саен туган җир үләннәре белән бергә тернәкләнә торды.

Татаның нәсел-нәсәбе кайчандыр Иделнең нәкъ яр буенда Шелангада гомер иткән һәм ерак яулар, су юлына үзләре урнашып, аларны әчкәре кугач, менә шушында төпләнгән. Социалистик революция җиңгәч һәм халыклар арасындагы дошманлык тар-мар ителгәч, тарихи гаделлекне яңарту, иске җәрәхәтләрне төзәтү кебек изге максат белән мондагы халыкка яңадан Идел буена күчәргә рөхсәт бирелсә дә, Тата ул иректән файдаланмый: «Өянкеләремне хәзер инде алыштыра алмый

Идел имәннәре», — дип кенә куя. «Үз күзем белән күргән нәселем — бабам, атам, әниләрем, туганнарым шушында — шушы өянкеләрне тыңлап яшәгәннәр, аларны ничек ташлап китим? Алар күчә аламыни? Әгәр күчә калса да, истәлекләре шушында калачак бит — аларны ничек ташлап китим».

Үләмәнең иң тирән җире — кешенең муеныннан, киңлеге — буасыз җирдә алты-җиде метр. Ә яз җиттеме, каян чыга торгандыр, һич арттырмый әйткәндә дә, үз өстендә өй хәтле бозларны йомычкадай уйната, чөя. Уйната-уйната аларны Зөя суларына алып ыргыта. Ә бер көнне салмак кына килгән шәпкә боз өянкеләргә килеп орылды да яр өстенә, бакча буена атылып чыкты — комда калган кораб кебек... сәбәнче — өянкеләр, өянкеләр...

Бакчага боз килеп туктаган көнне Җиһан, тәнем әзрәк җылынмасмы дип, мунча ягасы итте. Тата исә: «Болай булгач хәлең әйбәтләнде», дип, мунчага утынны сөенә-сөенә кисеп үзе китерде. Суны Җиһан ташыды. Әмма сукранганы бик хәтердә:

— Сукмак буена әллә нинди боз утырган, суык өрә, яныннан узар хәл юк...

Күзләренең зәңгәр ялкыны кими, сүрелә төшкән кебек иде. Шуңа күрә Тата аңа өйгә кайтырга кушты һәм мунчаны үзе томалады. Җиһанның бик тә хәле киткәнгә, Тата аны мунча керергә күтәреп кенә алып барды. Ындыр сукмагыннан атлаганда, кулдагы килеш сөйләнә килде Җиһан:

— Бакчада ямьсез боз... Зәхмәтледер ул, югыйсә, хәлем болай ук начар түгел иде.

Үкенечкә каршы, Тата ул чакта бу сүзләргә әллә ни әһәмият итмәде шул. Чирле кеше ни сөйләмәс дип кенә уйлады.

Ләүкәгә яткырып каен миллек белән әйбәтләп чапкач:

— Ничек, сиңайтәм, җылындыңмы? — дигән сорауга:

— Юк, юк, тәнемдә боз,— дигән җавап ишетте.— Әйдә, тизрәк өйгә кайтыйк. Зәхмәтле боз... Сиңайтәм, тизрәк ваткалап ташла шуны. Өрә бит салкынын, өрә генә. — Өйгә кайтканда да, кайткач та гел шушы сүзләрен кабатлады.

Ишек ачар хәл юк, зарланырга керешә:

— Зинһар өчен ачмагыз ишекне, салкын бит, ябыгыз, ишектән теге боз зәхмәте керә, — ди.

Төн буе саташып, сөйләнеп чыкты.

Иртән матур булып, яктырып кояш чыкса да, гөрләвекләр акса да, тавыклар кыткакласа да, казлар каңгылдашса да, яз шатлыгы, кояш җылысы Җиһанга тәэсир итмәде.

— Уфф, боз, туңам, өшим, боз...

Ә үзенең бөтен тәне һаман уттай яна иде.

Кичке караңгылык белән бергә мыштым гына Полина түтәй килеп кергәч исә, Татаның үз тәне дә чымырдап, өшеп куйды. Кайчан гына җир җимертеп дигәндәй йөргән хатын хәзер кичке көн төсле чырайсыз, шәүлә төсле генә калган, хәтта кайгысыннан хәлсезләнеп, пышылдап кына сөйләшә. Яман сүзләр болай да авыру Җиһанны борчымасын ди бугай. Кара якка чыккач та хәтсез вакыт сөйләшә алмый тордылар.

— Аптырагач, үзем килдем инде... ул кетә.

Карчык күз яшьләрен сөртеп алды.

— Утыр, Полина түтәй, утыр, елап нәрсә кыласың?

— Нишләргә дә белмим, харап була бит балам.

Тата үзе дә нинди дә булса киңәш бирерлек хәлдә түгел, ул үзе дә борчыла, хәтта каушый. Нигә дисәң, шушы минутларда, ничектер, бернич кешенең язмышы берьюлы хәл ителер төсле. Әйтерсең аны Тата үзе хәл кыла — бөтенесе хәзер аның нәрсә әйтерено һәм ни эшләвенә бәйле.

һәм ул, үзе дә сизмәстән, көндез җавап таба алмаган соравын Полина түтәйгә житкерде.

— Синең хәтереңдә юкмы — мин синең малаеңа бәләкәй чагында бер төлке биргән идем.

— Төлке дисеңме? Төлке... Төлке... Ә, төлке! Бераз гына хәтеремдә, исемә төште.

— Менә шул төлкене нишләтте малаең?

— Нишләтте? Ничек инде анысы?

— Үтердеме, кешегә бирдеме?

— Үтер, хәтерләмим — бөтенләй онытылган, гаепләмә инде мине.

— Гаепләп ни...

Полина түтәй, кайчандыр үзе саткан сыерын кочаклап туйганчы яшь түгәргә килә торган «елак түтәй», сөт һәм каймактан күңеле хушлангач чукына-чукына рәхмәтләр укый, бәхетләр тели-тели китә торган изге түтәй, хәзер икенче кешегә — шомлы, астыртын төн пәриенә, тәнсез-сөяксез шәүләгә әверелгән. Бер карасаң, юри, икенче карасаң, чынлап та үзәккә үтәрлек итеп, әйтерсең хәлсезлектән генә пышылдый.

— Тата, улым дары сорый бит тәки. Җәлмени — бир инде.

— Син ана кеше — уйлап кара. Ул дары ни өчен кирәк аңа?

— Җәнлек атар өчен генә ди ул, атакаем, бүтән ни эшкә булсын. Ул бит андый-мондыйдан түгел инде.

— Каян беләсең?

— Менә инде үз баламны белмәскә.

Ак өйдә, түр почмакта Җиһан ыңгырашып ята. Тынын көчкә ала — сулаганы әллә каян ишетелеп тора. Белмәссең, җанга кайсы ныграк чәнчидер — хатынының интегүеме, әллә Полина түтәйнең ялынып текәлгән очлы күзләреме?

— Сиңайтәм, уффф, үләм, туңам. Бозны ватчы әле, зинһар ваткалап кер, үтерә бит, үтерә, уфф...

Бу якта Полина да әллә нинди ачу һәм кызгану кузгатып аһ-зарын дәвам итә:

— Җәлмени сиңа, бир син аны, җан кисәгем, бер уч дарыдан дөнья җимереләмени?! Тата!

Татаның хәтерендә бер нәрсә мәңгелеккә калды: нәкъ менә шушы вакытта күкрәгенең нәкъ үзәгеннән кемдер тимер куллары белән эләктереп алды да әкрен-әкрен бармакларын батырып, кысарга керешә. Бермәлне ул шундый дәрәҗәгә житте ки, Полина кыяфәтендәге төнге шәүләне дә, сөекле хатынын да куркытмас өчен генә «аһ» дип кычкырып җибәрүдән чак тыелып калды. Ләкин кемгә икәнен үзе дә белмәстән, барыбер акырды:

— Бәдбәхет, егылып үлгере!..

Ир кешегә өмет җую, хәлгә буйсыну — гарьлек. Төлкегә генә түгел, кайчак йөрәккә дә борынчак кидерә белергә кирәк. Татаның нияте — тынычланырга тырышу. Шуңа күрә ул сәкегә утырды. Берара күкрәген, муеннарын угалап утыргач, ахрысы, тынычланды да.

— Утыр, Полина түтәй.

Тегесе аның каршынарак, мич буендагы кечкенә эскәмиягә утыргач, дәвам итте:

— Әйт әле, Полина түтәй, малаең качып кайткач, син аны ник кире военкоматка җибәрмәдең?

— Бердәнбер малаемнымы? Аннан да аерылсам... Аннан да аерылсам, миңа дөньяда ни кала инде?

— Сукыр мәхәббәт юньлегә илтми, Полина түтәй. Петруха сиңа рәхмәт әйтмәс иде.

— Петруха... Кайда соң ул Петруха? Менә минем кесәмдә бит ул, менә шушы йолдызга әйләнде ул, менә ул.

— Йолдызга теләсә кем әйләнә алмый, Полина түтәй.
— Әйләнмәсә соң? Мин нишлим ул йолдыз белән? Нигә кирәк ул миңа салкын тимер? Миңа ирем кирәк, аның тән җылысы, аның күкрәк сулышы кирәк миңа, йөрәк тибеше кирәк. Ә бу салкын тимер. Хәзер баламны тартып алмакчы буласыз.
— Сугыш бетте бит, бетте!
— Барыбер бирмим улымны, бирмим бирдәнберемне, китмәгез! — Җиһанның ак өйдәге авыр сулышын, ыңгырашуын Полина түтәйнең күксегән тавышы күмде. — Җитмәдемени инде миннән? Бердәнберем бит, бердәнберем!
— Уфф, боз, боз, боз... туңам, үләм! Сиңайтәм!..
Татаның күкрәк турыннан нәрсәдер умырылып чыккан кебек булды. Һәм ул, авыртуга чыдый алмыйча, инде бөтен тавышына кычкырып җибәрде:
— Уфф!..
Күкрәктән бая әләктергән, күзгә күренмичә генә әйтерсең якадан ук селкергә керешкән кодрәткә түзә алмыйча, сандык капкачын күтәрде дә төрелгән чүпрәкләре-ниләре белән алып, Полина әбинең аяк астына ыргытты:
— Мә, егылып үлгере, күргәне-күрмәгәне шул булсын. — Түтәй идәнгә чүгәләгән арада, Тата дәвам итте: — Шуны да белеп торсын, әгәр дә берәр кешегә төзәп атарга кыюлыгы җитсә, теге үзе күргән бүрене хәтеренә төшерсен. Шул бүре хәлендә мин аны бәләкәй чанага салып, НКВДга илтеп тапшырачакмын. Карт бүрене бугазлаган бу куллар ул аксак төлкене генә теләсә нинди хәлдә дә буып үтерерлек. Качып котылырга чамаламасын.
Татаның дары шикелле кабыну гадәте бар һәм моны бөтен тирә-күрше белә иде. Полина түтәй дә гаҗәпләнмәде. Төенчекне култыгына кысып тоткан көе, ишек бавына үрелгәч, тынычлангандай, сүзен иплә генә әйтте:
— Атакаем, син алай итмә инде. Минем сөекле улыма синең изге кулларың күтәрелмәс, алла бирсә. Улыма әйтермен, җәнлектән башкага мылтык төзәмәс. Мин улымны яхшы беләм, бер дә хафаланма.
— Берсекөнгә мине районга чакырдылар. Мине генә түгел, бөтен колхоз председательләрен. Хатын авырый, аңа дару да алырга кирәк. Юл басып азапланмасын.
— Әйтермен, атакай, әйтермен.
— Районга минем белән барасы килсә, сәгать иртәнге биштә тәрәзә каксын.
— Ул да барырга тиешмени?
— Анысын ул, исән каласы килсә, үзе аңлар. Бар, тизрәк, тизрәк!
— Әйтермен, әгәр дә бүген очрашсак, берсүзсез әйтермен.
Елак түтәй китте. Ләкин өйдә тынычлыкның әсәре дә юк һәм булырга да чамаламый иде. Хатынның авыр сулышы... Шундый авыр — хәтта ирнең үз сулышы куырыла. Баягы тимер бармаклар үпкәләргә үк батып кергәндер, ахрысы. Җибәрми бит, җибәрми генә бит албасты. Аптырагач, тагын хатынның башын тотып караган иде, януы — кулларны пешерерлек. Кайчандыр күк яктылыгыдай балкыган зәңгәр күзләргә томан төшкән — яшькә чыланган... Ахрысы, авыртудан, үлем әчесенә түзә алмыйча елый, бичара. Тата үзе дә аннан һич ким үрсәләнми. Чулак Албакны куып диярлек җибәрүе искә төшкәч исә, аһылдап ук куя һәм терсәгеп тешли алмый интеккәндәй җәфалана. Нишләп ул хәтле каты бәрелде соң әле ул Албакка? Бүрене алырга ялындырып килгәне өчен генәме? Юк, алай гына түгел, ахрысы. Колакка сәер сүз кереп калган... Әйе, аңга вакытында килеп җитмәгән «пинсәлин» дигән сүз инде сыер хәтле зур мәгънә булып күз алдына килеп баса. Ни дигән иде Албак? Салкын тию зәхмәтен мәче ялагандай тиз арада бетерә торган «пинсә-

лин» атлы дару чыккан, әмма сатуда юк икән әле, дигән иде. Сыер бәясе акча кирәк булачак дип, Татаның бүресен өстерәү белән бергә, аның сыерын да житәкләп китмәкче булып кинаялап маташканга күрә, Тата күкерттән тиз кабынып киткән иде. Хәзер исә хатынын коткару хакына сыерын корбан итә алмаган өчен үзен каһәрли. Гомерлек үкенечтән курқып, артык кыйбатлы булса да, шул даруны әллә алыйкмы дип киңәш иткәч, Жиһан:

— Балаларны сөттән мәхрүм итеп үтерергәме? Уфф... Юкны сөйләмә, — дип, андый ниятне якын да китермәде.

— Яңа дару икән. Бик тиз терелтә ди.

— Тереләсем дә килми — барыбер... икенче кабат мондыйны күрәсем килми. Тизрәк кенә тотсын, уфф...

— Хәзер, мәтрүшкә кайнатам.

— Үләм, бар, йокла, иртәгә торасың бар, иртүк... бар... Уффф... Бозны ват, тизрәк, бар!

Сыерны, ярый, балалар хакына кызгансын да, уйланып та калсын ди. Әмма хатынының бердәнбер теләген үтәргә, бозны шунда ук жимереп ташларга көчле-куәтле иргә нәрсә комачау итте икән? Инде менә ничәмә еллардан соң да Жиһанның мең аһлы сүзләре, ялварулары аермачык ишетелә һәм Тата кайчандыр булган хатасын төзәтү өчен, кайчандыр Жиһанын газаплаган салкынлыкны әйтерсең юк итәр өчен, аңлашылмас дәрәҗәдәге ачы бер ашкыну белән кәйләгә тотынды бит.

*
* *

Боз тавы тыныч.

Ләкин эче-тышы усаллык сыман.

Кара пычракка буялган гади боз. Ләкин тора-бара ул хәтта тере сыман тоела башлады.

Әйе, Жиһанга гына түгел, Татаның инде үзенә дә салкынлык сизелеп сирпелә. Куыш артының кояшлы ышыгын калдырып, боз янына житкәч, Татаның ютәл өянәге кузгалды. Хәле китеп, калку жиргә утырды һәм, күкрәген тота-тота, ким дигәндә ун-унбиш минут йөткереп интекте. Күзләрдән яшь ага. Тезләр калтырый. Буыпмы-буа күзгә күренми торган кул: бармаклары әле кайнар, әле боз сыман. Әлбәттә, шушы зәхмәтле бозның күзгә күренми торган куллары кыса...

Күпмедер вакыт узып, каһәрле бармаклар бераз ычкындыргач, Тата чыланган күзләрен кул аркасы белән сөртте дә бозга якын ук килде. Өянәк тагын кузгалмакчы булып күкрәкне кытыкласа да, бу юлы Тата бар көчен куеп, аны жиңде. Һәм шунда бер нәрсәгә илтифат итте: бозның үткен почмаклары иртәгедән дә ныграк чәрдәкләнгән.

Жир астында дөнья җылысы буларак җыелган ташкүмерне кайчандыр оста ваткан кеше хәзер, һөнәр яңартып... бозга китереп сукты. Йодрык-йодрык бозлар ташкүмердәй тәгәрәргә тотындылар. Кайчандыр булган үкенечле хәлләрне, ямьсезлек һәм усаллыкны Көчле кеше боз кисәкләре рәвешендә таптый һәм изә торды, тантана итте. Уйлый торгач, ачыкланды: салкынлык үзенең төрле хәлләрендә җанга һәм тәнгә гомер буе үтеп кергән икән...

Тау ягына еш килә торган иген кытлыгы борын-борыннан күпме кешеләрне кышкы эче көннәрдә чит жирләрдә тилмерергә, сукбай тормышы белән яшәргә, тукталыр ышык таба алмыйча ят кырларда адашып йөрергә мәжбүр иткән. Тау ягында, иген кытлыгы белән кочаклашып, бурандай ажгырып, ярым жимерек өйләрне калтырата-калтырата, утын кытлыгы жил шикелле йөргән. Ул афәтләргә кешеләрнең үз жаннарындагы салкынлык өстәлгән: ил-көн тормышының, дәвер һәм язмышларның өшеткеч бураннары...

Уйлый китсәң, күз ачкысыз...

Менә шуларның бөтенесе җыелып килгән инде шушы боз гыйфрит кыяфәтендә. Ләкин хәзер Тата аның холкын белә: хатынын үз кулы белән дигәндәй биреп җибәрсә, үзе тиз генә ияреп китмәс. Китмәс һәм элекке ялгышы, югалтуы өчен үч тә алмый калмас.

Хатынының исеме юкка гына Җиһан булмаган — аның белән бергә Тата өчен бөтен дөнья яме очты... Суык язмышка үпкә хисләре күңелгә тулды һәм алар, бозлар белән бергә, кәйлә ярдәмендә кителә төшә:

— Чылдырт, чылдырт, чылдырт...

Матур көннәр һәм бәхетле очрашуларны ватык бозлар белән ничек тә җибәрмәскә, беренче бәхетләр җылысын ничек тә яңадан җанга кучерергә, сакларга кирәк. Тиешле вакытында Тата аларны саклый белмәде, моның өчен ул үзен гомер буе каһәрләде, ләкин йөрәгенә ничек тә тынгылык таба алмады.

— Чылдырт, чылдырт...

Төшкелек ашар чак җитте дип өйгә чакыра килгән Кояш апагызның үзен һәм сүзен күрсәттермичә һәм ишеттермичә, узганнардан тавыш һаман килә: «Җимер тизрәк, ват шул бозны, туңам, уфф, туңам!..»

Бу сүзләрне Тата Тәмтегә барып, авыруны врачларга күрсәтергә кирәк дигән мәгънәдә генә кабул иткән иде. Анысы да җиңел эш түгел: вакыты нинди иде бит — юл өзеге. «Хәерле булсын».

Тата ашык-пошык ат җигеп, арбага былтырдан калган, сагышка охшашлы сары салам түшәде. Аның өстенә җәймә ябып мендәр салгач һәм Җиһанны чыгарып яткыргач, бер генә чакрымлы Караталга чыгар өчен (Үләмәнең ташыган чагы!) Черныш аркылы, өч чакрым җир артык урадылар. Шулай да Караталга чаклы әйбәт кенә барылды. Әмма аның тавын менгән чакта! Ни дисез? Дөрес, камыт бавы... Менә шунда хәтерләде дә инде Тата егет чакта җырланган җырларның иң чынын:

> Камыт бавын ялгый-ялгый,
> Сызыла йөрәк майлары.

Шуның аркасында булса кирәк, гомер буе Татаның йөрәгенә май кунмады...

Начармы, яманмы — ничәмә ел инде кечкенә генә булса да бөтен бер колхозның председателе бит әле ул. Ләкин Тата үз гомерендә башка председательләр кебек, район үзәгенә шәп айгыр һәм кара тарантаска утырып, арка терәп бер генә тапкыр булса да барса икән. Юк. Колхозның иң рядовой дигән бер әгъзасыннан өстен булуны, әйбәтрәк яшәүне дә вөҗданы кабул итә алмады. Халык нинди хәлдә булса, аның җитәкчесе дә шундый булырга тиеш дип исәпли иде. Җитәкче кеше халыкның үз тормышы белән яшәмәсә, аңарда мин-минлек, үзен югары тоту, һавалану дигән яман чир кузгала. Шуңа күрә дә андый җитәкчеләр: «Мин халыктан чыктым, түбәннән күтәрелдем!» дип мактаналар. Халыктан чыккан яман ботак. Халыктан чыкмагыз сез, иң олы зирәклек — халыкта. Тормышы гади тоелса да, хәл-әхвәле начаррак, ямьсезрәк күренсә дә, беркемне дә кимсетергә, беркемнән дә үзенең өстенлеген урнаштырырга тырышмый ул. Аның Тата, икенче төрле әйткәндә, Көчле дигән кушамат алуының сере дә шунда иде, мөгаен. Халык биргән исемне акламау — көчсезлек, юньсезлек, тәрбиясезлек. Шуңа күрә менә нинди ашыгыч, хәтәр чакта да колхозның каеш баулы камытын сайламаган һәм юкә бауны яңадан бәйләп азаплана. Каушый, ашыга. Җитмәсә, Җиһан сызлана:

— Сиңайтәм, хәерсез юлга чыктык, кире кайтыйк. Помшак түшәктә үлим, йөртмә болай.

— Нинди үлү ди әле ул! Сөйләнә тагы...

Шулай дип җикерде сөекле ир.

Камыт бавын ярыйсы гына нык бәйләгәч, ары киттеләр. Ләкин артык кызулый алмадылар. Арба чак кына кыштырдый башласа, Җиһан елый:

— Уф, башым, бетерәсең башымны... миләрем чайкала, туктат. Кайтыйк, сиңайтәм, өйгә...

Өйгә таба борылмаса да, хатынының ярты үтенечен үтәмичә булдыра алмады — Тәмтегә хәтле атын үз көенә генә куйды. Пычрак юлда әллә ни тизләү болай да мөмкин түгел иде. Унике-унбиш чакрымны узганда кояш кичкегә авышкан иде инде.

Врач бүлмәсенә хатынның үзен генә чакырсалар да, ун-унбиш минуттан соң ирне дә дәштеләр һәм хатынын култыклап бүтән бүлмәгә алып керергә куштылар. Больницада ятарга калдыралар икән. Дару гына бирегез, өйдә дәваланырбыз, дип карасалар да, врач ишетергә дә теләмичә: «Болай да соңга калгансыз, элегрәк килергә иде»,— дип, кырт кисте. Ир кеше, хәлнең шул хәтле читен икәнлеген сизенсә дә, бәхәсләшмәкче, янәсе:

— Алай ук куркытмагыз әле сез, духтыр иптәш.

— Мин түгел, чире шундый.

— Нәрсә соң чире?

Врач ниндидер аңлаешсыз, тел әйтеп карамаган һәм әйтә дә алмаячак сүзләр белән берни төшендерә алмады. Аннары өстәлгән сүзләреннән генә аңлашылды: салкын тигән, үпкәсенең ике ягы да бик хәтәр шешкән. Сулыш ала алмый интегүе менә нәрсәдән икән. Дөресен әйткәндә, моны Тата врачка килмичә дә белә иде бит — юл өзегендә шушы чаклы җир узмыйча да.

Әмма хатынына бу хакта тел тибрәтмәде. Хатынының болай да хәле юк, болай да чырайсыз — кайчан гына алсуланып янган кеше — инде акшар төсле. Сулышы һаман шул — кыска-кыска, үзәккә үтә, йөрәкне чәнчи. Иренә бу хәтле кыен булгач, үзе ничек түзә торгандыр.

Хатын ятачак бүлмә — бер генә тәрәзәле, баз сыман караңгы. Ике караватның икесе дә буш. Димәк, хатын берүзе генә ятасы — тереләйкабергә кемнең кирәсе килсен. Билгеле инде, хатын караватка утырса да, ятарга кушкач, карышты. Ярый әле, авыл больницасы булгангамы, киемнәрне алыштырып өлгермәгәннәр иде һәм шунлыктан җайлы килеп чыкты. Ире хушлаша башлагач, караватбашына ике куллап таянган Җиһан күз яшьләре коярга керешә.

— Сиңайтәм, калдырма мине, мин монда барыбер син киткәч тәүләм, калдырма, җаным...

Иренең үзенең дә күңеле тулган иде, бусагадан кире борылды да хатынының кулларын тотып, аны урыныннан күтәреп дигәндәй кузгатты. Урамга чыккач, күтәреп, җайлап арбага яткырды:

— Әйдә, язганы булыр.

Юл буе ир кеше үз-үзе белән, ә хатыны чир белән бәхәсләшеп, сүзсез генә кайттылар.

Петруха малае килергә тиешле көнне Тата сәгать дүртләрдә үк уянды. Тәрәзә кагучы юк, җил генә шыңшый иде. Җил сөекле хатынының элекке җиңел сулышын урлаган да, рәхәтләнеп оча, тилерә, сикерә — Петруха малае кулына эләккән төлке сыман. Гөлҗиһан яшь чакта да алай ирекле булмады, басынкы, тыйнак булды. Күзләре генә җиһандай чиксез иде. Күңелдә шул сүзләр, колакта авыру сүзләр: «Юк инде, тереләсем килми, яңадан чирлисе була...»

Нишләп, нишләп син аны бәхетле итә алмадың, Тата, нишләп син аны еллар салкыныннан саклый алмадың?

Сәгать бишләр җиткән иде бугай — Тата сөт һәм мәтрүшкә кайнатып эскәмиягә куйды да атлар утарына юл тотты.

Бүтән чакта, бүтән председательләрдән аермалы буларак, ул районга (бер ат булса да колхозга эшли торсын дип) җәяү генә китә һәм

юлда очраган председательләргә утырып кына йөри торган иде. Әгәр туры килмәсә, киңәшмәләргә шактый соңга кала һәм шелтә ала. Икенче юлы җәяү йөрмәскә вәгъдә бирсә дә, вакыты житкәч, үзеннән ат кызганып, тагын тәпи-тәпи атлый. Бу юлы алай эшләмәде. Сәбәпләре житди. Беренчедән, юл өзеге. Икенчедән, Петруха малае куып житмәсен — ул качып ятарлык жирләрне урабрак һәм чаптырыбрак узу хәерле.

Атка иярсез-нисез генә (каян аласың бу елларда ияр) атланып китте. Караныбрак барса да, андый-мондый шомлы шәүлә күренмәде һәм ул район үзәгенә исән-сау гына, гадәттәгедән иртәрәк барып житте. Милиция идарәсенә сугылыргамы дип тә уйлаган иде, ләкин берәрсе күреп, Петруха малаена әләкләмәсен, бәладән башаяк дип, туп-туры райкомга килде.

Райкомның беренче секретаре Иван Дмитриевич Чаган — базык һәм нык гәүдәле, кырыс кыяфәтле кеше. Татаны күргәч, ул да ничектер йомшара, елмаеп сөйләшә һәм ничектер үз итә шикелле. Кешеләр арасында ул аны барлы-юклы уңышлары өчен дә мактый, үрнәк итеп күрсәтә, ә тиргәргә кирәк булганда, жыелышлардан соң калдырып, кызганып кына тирги. Ник болай якын итә торгандыр — аңлап бетерми Тата. Кечкенә колхоз председателе булуын, озакламый бүтән колхозга берләшәчәген истә тота бугай. Ничек кенә булмасын, Тата секретарьны үзе дә хөрмәт итә, бүтән районда секретарь булып эшләгән туган энесед әй күреп ярата һәм гөнаһ тоелган гаепләрен дә яшерми, өрекми сөйләшә.

Секретарь тагын аягүрә басып каршылады.

— Ә, хөрмәтле Тата! Әйдә, түргә уз. Нишләп әле иртәләдең болай?

— Хатын авырый,— диде председатель, кинәт тыны бетеп. Ә үзе бөтенләй башка нәрсә әйтмәкче иде.

— Хатын? Нәрсә булды?

— Ут кебек яна — сулышын көчкә ала.

— Врач ни карый?

— Ник пылау ашамый ул халык дип әйтте ди Бохар әмире, халык ачыкканны ишеткәч.

Сүзләрнең мәгънәсенә төшенмәсә дә, кабатлап сорамыйча, секретарь телефон трубкасын күтәрде һәм, больницаны сорап, тиз арада Җәмәкигә врач жибәрергә кушты.

— Үзең кайтуга хатының терелгән булыр. Тагын нәрсә бар? — Күңелдә тагын нидер барлыгын әллә күреп торамы бу?

— Бар шул, Дмитрыч, бар.— Тата шулай диде дә Чилче чокырында булган хәлне сөйләп бирде.

Секретарь тагын телефон аша гына милиция начальнигына хәбәр итте һәм тегене тиргәргә кереште:

— Оят, иптәш Биктимеров, оят!.. Борын тишегегездә уголовниклар оясы... Ә сез әллә кем булган булып, шул борынны күккә чөеп йөрмәкче. Дәрәжәң төште, бөтенләй төште, иптәш Биктимеров. Чара! Чара күрмәгез сез — жинаятьчене тотып кайтыгыз. Менә монда бик шәп бер кеше утыра — өч-дүрт көн элек кенә азау ярган карт бүрене үз кулы белән тотып, шушы баткак юлда өстерәп алып кайткан. Булдымы? Моннан да шәп үрнәк каян табасың? Тоткач та миңа хәбәр итегез. Хәерле юл...

Эшнең уңышлы хәл ителәчәген алдан ук белгән төсле, секретарь Татага елмаеп карады. Тата үзе дә жилкәсеннән тау төшкәндәй жиңеләеп китте. Хәтта бакча буенда калган, Жиһан каргап яткан боз тавы да онытылды. Менә бит, ә, ничек жиңел генә хәл ителде — ничә көн интектергән уйлар күпмедер минут эчендә секретарь өргән тәмәке төтенедәй очып таралды. Райком секретаре, милиция, врачлар дөньяда булган өчен тәкъдиргә һәм илгә чын күңелдән рәхмәт укып, хәтта сулышының да иркенәюен, әле күптән түгел генә күкрәккә баткан тимер

бармакларның ычкынуын тоеп, бик тә бәләкәй колхоз председателе икәнен онытып, башкаларга тиң рәвештә көлә-көлә сөйләшә башлады. Киңәшмәдә үз колхозына куелган бурычларны, сугыштан соңгы бу икенче язда җир сөреп чәчү кебек олы һәм авыр йөкне җилкәсенә салсалар да, зарланмый гына күтәреп алды һәм хатынын терелгән кыяфәттә, Петруха малаен милиция машинасында утырган итеп күз алдына китерә-китерә, юл буе елмаеп кайтты. Юл пычрак булганга, атын ашыктырмады — үз көенә генә атлатты. Әмма җиңел генә куелган бурыч алай ук җиңел үтәлмәгән иде. Терелеп капка төбенә чыгып каршылавы да ихтимал дип фараз ителгән хатыны капка төбендә түгел, ишек төбендә дә күренмәде. Ак өй ишеген нигәдер каушый-каушый ачса, врач һәм сестраның хәрәкәтсез басып торуыннан тагын әчтә ниндидер салкынлык жуылдап куйды. Күзгә күренми торган тимер кул тагын бармакларын күкрәккә батырды, пычрак боз тавы җанга үзенең үлем төсле өшеткеч сулышын ажгырып өргәндәй тоелды.

Хатыны — сөекле Җиһаны хәрәкәтсез иде...

Бакча янындагы боз тавы... Менә кем өчен килгән ул!

Кешенең иң олы дошманы — салкынлык... Шул алып китте Гөлҗиһанны... астыртын гына. Бәлки бөтенесен билгесезлек йоткан булыр иде, Җиһанның ничек җан бирүе табышмак булып калыр иде. Ләкин ана билгесезлеккә китмәде — караватта үз янында мәче шикелле генә яткан биш яшьлек кызчыгының кап-кара зур күзләренә күчеп, еллар буйлата сәяхәткә китте.

*

* *

Әтисе баланың шул чактагы кыяфәтен күз алдына китерергә тырыша. Кыз бала — сынарга торган коры үлән сабагы, ләкин эчендә җаны бар. Сындырып кара — чыелдап кычкыруыннан бөтен авыл колагын каплар. Тавышыннан бигрәк, күзләре кычкырыр. Инде дә! Бәләкәй һәм нечкә генә Курайга каян килгән шундый зур кара күзләр? Аяклы-куллы кыз түгел, аяклы-куллы күзләр йөри дисәң, дөресрәктер. Кыш булса, олы киез катадан һәм ак йон шәл ябынган килеш шул тавыш, шул күзләр карга чума-чума авыл бетереп йөрер — өй артында әтисе өеп биргән тауга ризалашмыйча, әллә кайдагы Каратал тавына китәр һәм караңгы капканда гына чанасын өстерәп кайтыр да, әнисе ашаргаэчәргә биргәнче, өстен чишенеп яки чишенгәнче үк сәкегә ятып кына торган җиреннән йоклап та китәр. Аннан соң үнде уятып кара син аны!

Җәй дисәң, чыпчык шикелле, кая карасаң да ул пырылдап очар, кая барсаң, ул чыркылдап каршылар. Кайчан чемченеп җим чүпләгәнен белмәссең — өстәл янында тыныч кына утырып торганын күрмәссең. Бәйрәм көннәрендә, тәмле ризык пешкәч кенә, бар кешедән күбрәк итеп ул сорар.

Җәйге чилләдә ул, комда кызынган төслерәк, ялан аяк йөри. Ураза бәйрәме. Әнисе Җиһан мич авызыннан алып кына кайнар пәрәмәч ташый. Табында — әтисе һәм сукадан әле генә кайткан унөч яшьлек абыйсы. Билгеле, сукачының ашау дәрте пәрәмәчнең үзеннән дә кайнаррак — әнисе китереп өлгерә алмый, сыпырта гына. Аңа булган шундый аерым хөрмәтне аяклы күзләр бик җәһәт күреп ала һәм утырган җирендә бөтерчектәй бөтерелә, үзенә дә шундый игътибар-хөрмәт сорый:

— Ник аңа күп, миңа нишләп аз! Ник аңа гел дә гел, миңа бер дә юк. Миңа да күп кирәк, миңа да!

Тавыштан туйгандырмы, үз дәрәҗәсенә тел тидергәнгә кабыныпмы, абыйсы үз тәлинкәсенә әле генә салынган кайнар пәрәмәчләрне сеңелесенә атып та бәрә:

— Мә, сиңа булсын, ал!

— Ай, ай-й-ай!..

Бала чырылдап та җибәрә, күкрәгеннән уа-уа идәнгә егыла, бөтерелә-бөтерелә ауный. Ачыргалануы колакны яра. Аның исән калмаячагы беркемдә дә шик тудырмый шикелле. Абыйсы үзе дә каккан баганадай катты — күм-күк төскә керде, бичара. Әнисе телдән язды. Ярый әле, этисе югалып калмады — баланы кулга алды да юатырга кереште.

— Бетте, бетте... Әй, минем кызымны... Минем кызым елак түгел ул, минем кыз бит ул. Кайнар пәрәмәчтән үзе кайнаррак бит ул — бар дип тә белми ул аны. Хәзер без аңа күп итеп пәрәмәч пирәбез. Әнә бит, зур үскән ул, еламый ул. Елаган кешеләрдән көлә генә ул минем кызым. Әйе, шул, көлә. Шулай бит, кызым, көләсең бит елак-мылаклардан?

— Көлмим!— дип җикерде бала каршы әйтер өчен генә.

Ләкин елаудан туктады һәм аскы иренен кабартып, абыйсын үчекләргә тотынды:

— Мырау, мырау песи!

Әйбәт кенә, тыныч кына торган җирдән көтмәгәндә һөҗүм итү гадәте булганга күрә, этисе атна-ун көн элек: «Безнең малай песи ыруыннандыр ул!»— дип куйган иде. Кыз, бөтенләй ишетмәгәндәй, курчаклары белән булашса да, колагына салып куйган бит әнә. Менә син сөйлә инде, бала ишетми, аңламый, дип.

— Мырау, мырау песи.

Карасалар, баланың тәнендә, күкрәк турысында, борчак хәтле куык барлыкка килгән икән. Хәзер инде, буй үскәч тә, декольте кия алмыйм дип, абыйсын җай килгән саен тирги...

Әнисенең вафатын үз күзе белән күргән бердәнбер кеше — шул бала. Үпкәсе шешүнең нәрсәдән икәнен белсәләр дә, авыруы йогышлы булмагае дип, балаларын ана үз бүлмәсенә кертми. Олыраклары тыңлый, ә менә төпчек кыз барыбер үзенекен итә — мәче баласы кебек мыштым гына керә дә, әнисенең аяк очына, юрган астына поса. Әнисе барлык көчен сарыфлап үгетләргә, куркытырга тырышса да — файдасыз... Сүз көрәштермәс өчен, йоклаганга сабыша да куя. Соңгы кабат әнисе хәтта үгетләп тә тормады... Әнисенең авыр сулышын тыңлап ятканда, бермәлне шыгырдап капка ачылганга, әти кайтмадымы дип караса, анда ниндидер мылтыклы абый күренде. Ул кешенең күзләре үк шашкан кешенеке төсле иде. Куркуыннан бала тиз генә тагын әнисенең аяк очына үрмәләде һәм юрган астына чумды. Өйдә бүтән кеше юк иде. Ят кешенең ишекләрне кинәт ачуыннан һәм шакылдатып ябуыннан хәерле нәрсә көтелмәгәнгә, бер генә күзен ачып, тын алырга да куркып, бала селкенми дә ятты. Менә түр ишекне дә җимерердәй ачып яптылар. Мылтыклы абый, пычрак һәм иске итекләре белән лап-лоп басып, карават янына, ана каршына үтте дә акырып җибәрде:

— Кайда Тата абый, кая качты?

Хаста бер секундта баш калкытырга, нәрсәнедер аңларга тырышып азапланса, икенче секундта үзәк өзгеч тавыш белән:

— Ай!..— дип кенә әйтә алды.

Бөтен булганы шул. Аннары инде ана бөтенләй селкенмәс булды. Мылтыклы кеше үзе дә гаҗәпләнеп, бер-ике минут шашкан күзләрен анага терәрдәй карап торгач, атылган ядрә тизлеге белән чыгып та чапты. Аяк тавышлары, итек шапылдауларына караганда, ни өчендер абзар-кураларга кереп чыкты һәм, үзенә кирәкле кешене таба алмыйча, нигәдер бакча ягына йөгерде.

Аяк тавышлары тынып күп тә үтмәде, тагын берничә абый капкадан, аннары ишектән баягы мылтыклы абый кебек ашыгып керделәр дә, баланың үзен күрмичә, аның хәрәкәтсез анасына гына бераз карап тордылар, һәм алар да башта абзар-кура тирәсендә әйләнгәч, тагын бакча ягына чаптылар. Озакламый, шул яклап ике-өч тапкыр мылтык

шартлаганы ишетелде. Бала, һични аңламыйча, куркудан энисенең кинәт катыланып калган аякларын кочып ятты һәм соңыннан тынычкына йоклап китте. Күпме яткандыр, анысын ул хәтерләми. Уянып күзләрен ачса, энисе каршында ягымлы гына ике апа басып тора иде. Алар, әлбәттә, баланы күрделәр һәм берсе, олырак яшьтәгесе, аны күтәреп алды, нигәдер кочып сөйде, нигәдер тынычландырырга тырышты. Ә чынлыкта бала болай да тыныч иде. Апаның кулыннан үз теләге белән төшеп, янә энисе янына менеп ятты.

— И бала, бала, берни аңламый шул, — дип кенә куйды нигәдер гаҗәпләнгән апа.

Юк, бала бөтенесен аңлый: энисенә нәрсәдер булганын, ниндидер шомлы үзгәреш барын тоя, ләкин кабул гына итми, ышанмый һәм тынычлыгы, еламавы да бары шуннан гына иде.

Озакламый әтисе кайтып керде. Әтисе кулына бала үзе сорап менде. Аны тоткан килеш, ата күпмедер вакыт хәрәкәтсез торды-торды да баланы күршеләргә чыгарды:

— Әниегезне юган арада син көйсезләнми генә шушында тор, яме? Акыллы бит син.

— Әнине ник юасыз? Ул чиста бит.

— Чиста шул, тагын да чистарак булсын дип. Үзем кереп алганчы беркая да китмә, яме!

— Я.

Әтисе ул көнне кызын нигәдер тиз генә кереп алмады. Кыз шомланып тагын үзе чыкты һәм гадәтләнгән урынына менеп ятмакчы иде, анда юрган-ястык юк — караватны урта бер җиргә күчергәннәр дә энисен шунда салганнар...

. Баланы кемдер бераү, бөтенләй чит кеше, яңадан күршеләргә чыгарып йокларга яткыргач кына, ул, чәбәләнүдән туктап, ниндидер борчулы йокыга талды. Төнлә уянып, шактый озак караңгылыкка карап ятты, аннары сәбәбен үзе дә белмәстән кычкырып елап җибәрде. Беренче тапкыр аны юатучы булмады. Арыганчы сулкылдады-сулкылдады да тагын борчусыз тирән йокыга талды. Уянган чагында көн яп-якты, кояшлы иде инде. Ишегалдында күренгәч тә аны юындырдылар-ашаттылар һәм:

— Әйдә, әниеңне күреп кал, балакаем,— дип, үз өйләренә алып кереп киттеләр.

Бу юлы энисе элеккеге кебек үк чибәр, ак йөзле иде. Ләкин хәрәкәтсез. Бала аның нигәдер маңгаен тотып карады. Салкын иде. Ләкин кыз еламады һәм шуңа күрә бугай аның барын-югын тиз оныттылар. Олыларның аяк астында тыныч кына чуалып йөрде һәм авыл капкасын чыкканчы энисе артыннан иярә барды. Соңыннан апалар һәм барлык кыз-кыркын тукталгач, әллә кеше әйтеп, әллә үзе тоеп, бала да шунда калды һәм аннары өй артында күрше кызлары белән сикерә-сикерә сызыклы уйнарга керешле.

*
* *

Гомерлеккә хәтеренә уелып калган бу күренешләрне кызы әтисенә соңыннан, зур ускәч, кабат-кабат сөйли торган булды. Ә мылтык тоткан кешенең кем булуы, ни өчен керүе судта тиз ачыкланды. Чилчедәге бүреләр оясына милиционерлар чабышып барганны каршы тау арасыннан күреп калган егет, эшнең нәрсәдә икәнен абайлап һәм аларга Тата хәбәр иткәнен чамалып, үзе вәгъдә иткәнчә — атып үтерергә дип тиз генә Тата авылына килсә, бәхете — ул өйдә юк. Авыру хатыны гына караватта ята. Авыру хатын иренә атылырга тиешле ядрәләрнең барын-югын белмәсә дә, куркуыннан... Бәлки соңыннан барыбер җан биргән

булыр иде, бәлки врачлар дәвалый башлагач, терелгән дә булыр иде — хәзер әйтүе кыен. Әмма шунысы хак, дөньядан китәргә ашыктыручы — мылтык төзәп каршына баскан кеше... Аны ул Газраил дип, мөгаен, артыннан ирде дә китте. Әйе, мылтык тоткан кеше... ашыктырды, ашыктырды, врачлар соңга калды...

Нишләргә тиеш иде Тата мондый чакта?

Дөрес, малайның качып ятканын ул беркемгә дә әйтмәскә ант итте, ләкин антында тора алмады. Ант бозу — имансызлык. Ләкин Тата үзен иманга хыянәт иткән дип исәпләмәде. Гомер буе вөҗданы сыкранмады — мөмкин булганча һәм вөҗданы кушканча эшләде ул. Беренчедән, Петруха малаеның үзе өчен, аны булачак җинаятьләрдән саклау-коткару өчен шулай эшләү фарыз иде. Дөрестән дә, малай ниндидер куркыныч җинаять эшләгән егет коткысына эләккән булып чыкты. Ул, армия хезмәте исәбенә төзүчелеккә өйрәтә торган ниндидер мәктәптән риза булмыйча, чынлап та качып кайткан. Шәһәрдә теләсә кайда бәреләсугыла йөри торгач, төрмәдән качкан бер уголовник йомышчысына әверелгән — иясез маэмай төсле ияргән. Әгәр Тата абыйсы, биргән антны бозмыйм дип, хәбәр итмәсә, малайны ул җинаятьче егет үзе төсле кешегә — ерткычка әвереддермәс идеме? Ике сүз булу мөмкин түгел. Менә сиңа ант, менә сиңа иман.

Куып баручы милиционерлардан ул никтер әлеге төсле үк шомлы, атаклы боз артына качкан — шунда эләккән иде.

Тата гаделлеккә, хаклыкка һәм, ниһаять, туган туфракка телдән әйтелми торган олы антка тугры булып калды. Ләкин нәрсә хакына...

Хакы адәм ышанмаслык кыйбат булып чыкты. Ул бер кешене җинаятьтән саклап калыр өчен үзенең иң сөекле кешесен — хатынын, Җиһанын бирде... Ә Җиһан, татарча әйткәндә — дөнья!

Аның хатыны чынлап та дөнья бәясе кеше иде. Кыйбатрак, кыйбатрак түләтте Петруха дус малае — кайчандыр үзенә биргән төлке өчен рәхмәтен рәхимсезрәк итеп кайтарды. Әлбәттә, аның белән кайчан да булса күзгә-күз карап сөйләшергә, очрашырга кирәк булачак. Ләкин ничә ел инде туры килгәне юк. Үзенең вөҗданын тынычландыру өчен генә булса да килеп гафу сорамасмы икәнни юньсез малай?

Хөкем вакытында аңардан туп-туры сорадылар:

— Армия хезмәтен үтәү йөзеннән җибәрелгән эштән ник качтың?

— Авылны сагындым, әнине.

Тата аның бу сүзләрен ялгызы калганда еш кабатлый торган булды. Әнине, туган җирне ярату хисе дә җинаятькә әйләнә икән!

— Юлдашыңны кайда очраттың?

— Казанда.

— Үзенең кем икәнен, җинаятьче икәнен әйттеме?

— Каян килеп ул җинаятьче булсын?

— Белмәгәч, ник ирдең?

— Ул үзе дә минем хәлдә иде. Бүтән кем белән дә сөйләшә, сер чишә алмый. Аптырагач, «Пароходта Саратов ягына китик»,— диде... Мин анда бармыйм дигәч, бераз вакытка дип үзе безгә килде.

— Кунаккамы?

— Шулайрак.

— Күпме кунак булдыгыз?

— Бер елга якын.

— Ничек тукландыгыз?

— Терлек урлап... әнигә дә китердек. Ул пешерде... Кайчак билгеләнгән урынга үзе китерә иде.

— Ә мылтыкны ник йөрттегез?

— Саклану чарасы итеп.

— Каян алдыгыз аны?

— Мылтыкны Тата абый табып бирде, дарыны да гел аннан алдык.— Малайларга хас беркатлы ачу белән түгел, Татаның күзләренә карап, олыларча явызлашып, иреннәре белән чәйнәп чыгарды тагын бер сүзне: — Хыянәтче!

Төлке күтәреп барган, акыллы елмайган бәхетле малай! Кайда ул? Кем алыштырды? Менә аның чын җинаяте кайда икән! Ярый, тилелеге аркасында иярсен дә ди алама юлдашка, тилелеге аркасында кылсын да ди җанварлык. Әгәр күңеле кешенекечә миһербанлы калса, бөтенесен төзәтергә мөмкин. Ләкин күңел көзгесе пычрактай туңып катса? Кояшның гына көче җитми аңа... аны эретү сирәк очрый торган хәл. Шулай итеп, егет үзенең чын күңелдән яраткан абыйсына чын күңеленнән яла якты — бу инде җинаять, җан гарипләге! Аяк гарипләген төзәтә алмаган чакта, җан гарипләген ничек төзәтергә мөмкин?

«Хыянәтче!»

Кем? Ник? Ничек?

Хыянәт төрлечә була икән.

Үзенә хыянәт итте дип, малай Татага җәза бирмәкче. Ләкин юк. Тата абыйсын үз артыннан иярттә алмады ул — судья кемнең кем икәнен яхшы белеп эш итте. Бер кабат дары биргәнен, мылтыкка катнашы юклыгын әйткәч, ышанды, бүтәнчә төпченмәде. Ә закон каршындагы ышаныч — горурлык.

Җиһанны атмыйча үтерҮән җинаятьче шунда үч кайтара алса, аңсыз усаллыгы аңлы рәхимсезлеккә әйләнмәс идеме? Юлдашы оста өйрәтүче булган, күрәсең — яхшылык гомер буе тәрбияләгән хисләрен әшәкелек ярты елда канлы пычрак булып бутап ташлаган. Гаҗәп һәм кызганыч.

Улы өч елга төрмәгә киткәч, Полина түтәй кайгысыннан өч ай да яши алмыйча дөнья куйды һәм малаеннан Татага усаллык, салкынлык бөркелеп торган хат килеп төште: «Әгәр син мине тоттырмасаң, минем әни исән йөриячәк иде. Бел, аны үтерүче — син! Миңа гомер телә — исән кайтсам, син аны миңа табып бирергә мәҗбүр булырсың. Белеп тор».

Хатны Тата ак өй түренә, түшәм белән бүрәнә арасындагы ярыкка кыстырып куйды. Хәзер дә көтә хуҗасын...

«Ярый, ул әнисен таптырып якага ябышса, мин аңа Җиһанымны табарга кушармын. Ул таба алса, әҗәтемне мин дә теге дөньяга алып китмәскә тырышырмын. Шулай.»

Авыр сүзләр ишетсә ишетте, вөҗданы кушканны курыкмыйча үтәде Тата. Гомергә үкенмәс. Ләкин хатыны... мәңгелек үкенеч...

*
* *

Петруха малае — йомшаклык корбаны, туган авылын ратканга, әнисен ташлап китәсе килмәгәнгә күрә качып кайткан. Тата да үз исемемә шулайрак хилафлык китерде — артык көчле яратуы аркасында иң кадерле кешесен югалтты... Җинаять шәфкатьсезлектән генә түгел, аумакайлык, куркаклыктан да ярала...

Армия хезмәтенә тиң эштән качып кайту һәм кыз урлау — ник бутала бу хәлләр? Кәләш урлап кайтканда ат тугарылу, ашыгу, каушау ник өстәлә шуларга? Ничек кенә әйтсәң дә, Тата үзе дә оешып бетмәгән булган, кулга эләккән бәхетен саклау хакында кайгыртмаган, кайгыртса, сәләте җитмәгән. Бәхетне кулда тотканда ярату гына җитми, катылык, усаллык та кирәк бугай. Егет чакта башланган йомшаклык гомер уртасына чабып кергәндә дә үч алды: арбаны шалтырата-шалтырата каядыр чапкан чакта, тугарылды да төште бәхет чаптары. Көчле дигән

исемен аклый алмады Тата — үзе гаепле һәм Петруха малае. Тагын менә шушы боз тавы.

Узган хаталарның бөтен әчесе күңелдә нәкъ менә шушы боз тавы шикелле укмашкандыр. Югыйсә, бу хәтле авыр һәм кыен булмас иде. Бусы әйтерсең күңелдәгесенең сурәте генә. Әшәке салкынлыкны бер минутта юк итәсе иде. Бүре булып кимерәсе иде, ләкин инде тешләр шактый какшаган. Нәфрәткә көчсезлек әчесе юлдаш. Шул әчелекне җегәренә кушып бер кизәнгән иде дә, кәйләсе һавада асылынып калды.

— Сиңайтәм!— Кояш апа тавышы иде бу.

Тата кәйләгә таянды. Ул үзенең кызганыч хәлгә җитеп арыганын тезләре калтыраудан гына түгел, һәр вакыт диярлек якты чырайлы Кояш апагызның телсез калуыннан да чамалады. Менә ничек тә шуны сиздермәскә кирәк — катырак басып атларга, менә шушылай. Ләкин куыш янына килеп җиттем дигәндә, тигез җирдә абынып егылуы бик үк егетләрчә булмады, әлбәттә.

— Чакырып-чакырып та кайтмагач, үзем килдем менә. Ашавыңны да оныттың син.

— Күрәсең бит, вакыт юк.

— Я, кайнар чагында ашап кал.— Кояш ашъяулыкка төрелгән чүлмәкне чишеп, икмәк куйды.— Котырган, күзләре үк шашкан, алмашынган. Иртәгә көн беткән диярсең.

— Көннәр күп анысы, тик алар безнеке микән соң?— Тата кашык белән чүлмәккә үрелде.

Матур эш түгеллеген сизсә дә, Кояш кашыкның чүлмәктә ничә кат булуын санып торды: бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде. «Болай булгач, боз ватуның файдасы бар, соңгы көннәрдә өч-дүрт кашыктан артмый торган иде. Сүз әйтәсе түгел болай булгач. Вата бирсен».

— Озаклама, сиңайтәм, көч китерә күрмә үзеңә, ишетсен колагың.

— Рәхмәт, әйбәт ишетә әле колак.

Чүлмәкне ашъяулыкка төреп китеп барганда, Тата елмаеп карап калды. «Кайчандыр Җиһан ашны шушылай кырга китерә торган иде».

Озакламый бозлар тагын тәгәри башлады.

— Чылдырт, чылдырт, чылдырт...

Җиһанны җирләгәч, Тата матәмне артык озакка сузмады. Дөресрәге, аны сузмаска мәҗбүр иттеләр. Сәбәп — тагын шул йомшаклык.

Дүрт ай узгач та, күрше Миңлебикә абыстай Татаның үзеннән ун яшь чамасы яшьрәк, ак кына чырайлы, бәрәңге алмасы кебек түгәрәк кечкенә борынлы, яшькелт күзле бер хатынны ияртә керде. Икәүләп өй җыештырдылар, су ташыдылар, чәй куеп, яңа гына алган бәрәңгене әрчеп пешергәч, парлары күтәрелеп торган хәлендә өстәлгә куйдылар.

Ачык чырай белән такта чәйне ир кеше үзе дә кызганмады. Ә хатыннар — сизгер, тиз арада үзләрен хуҗаларча тота, елмая, чышык-пышык көлешә үк башладылар. «Хатын-кызга син йомшаклыгыңны сиздер генә, аннары алар синнән менә дигән аркан ишә беләләр!» дип уйлый Көчле кеше, ләкин ихтыярсызлыктан үзе тәм таба... Аумакай!

Көлешү дигәннәрен, ярый әле, балалардан, дөресрәге, төпчек кыздан — Кырлы курайдан башладылар. Ят хатын (исеме Кояш — бик тә мәгънәле), табында иң беренче эш итеп, бөтен кешегә чәй ясады — кыюлыгын кара! Аннары ипи алып май якты да Кырлы курайга тоттырды. Тегесе тартыныбрак торса да, әз генә үгетләгәч, бүтәннәр күз ачып-йомган арада ипине кечкенә ябык куллары белән әләктереп тә алды. Башта нигәдер капмыйча, кулында гына әйләнатса, соңыннан игътибар итүче югын күргәч, иреннәрен чапылдата-чапылдата ашарга ук керешә. Әх, үз әнисе күрсә!

Өйләдән соң җыйнаулашып бәрәңге алдылар. Олы малай һәм ата кеше сука белән җир ярдыра, хатын-кыз бәрәңге җыя, җир өстенә җилләргә тарата. Кечкырын, шулай ук күмәкләшеп, капчык-капчык бәрәң-

ге ташыдылар. Кояш апа бигрәк тә Кырлы курай белән ачык сөйләшә. Соңынтын бала аның артыннан адым да калмыйча, маэмай кебек иярә башлады. Тик олы малай гына аска карап, күзләренә чыккан ачуын көчкә тыеп, ят апага һәм сеңелесенә читтән генә каһ атты шикелле.

Кояш апа кичке ашны Миңлебикә ападан башка гына әзерләде һәм, төенчегеннән нәрсәдер чыгарып, эссе суда югач:

— Иң тәмлесен кызыма бирим әле, — дип, ят җимешне беренче булып тагын Кырлы курай чынаягына салды.

Нәрсәдер дигәнебез өрек икән. Кыз моны белә — үз әнисе дә бик ярата иде — тансык күчтәнәч.

Кырлы курай шул хәтле ияләште ки, инде кич нигәдер Кояш апа белән Миңлебикәттәй үзебезгә чыгып йоклыйбыз, дигәннәр иде, кыз аларга чат ябышты:

— Китмәгез, бездә генә куныгыз, — дип кыстады.

Ата кешегә күз сирпегәч, мөгаен, аннан каршылык сизмичә, Миңлебикә апа төпчекне сөяргә керешге:

— И әйбәт тә кыз инде син, үскәч кем булырсың икән? — дигән булып, үзләренә һәм төпчеккә идән түренә урын җәйде.

Икенче көнне дә шулай, өченче көнне дә...

Бәрәңге алынып беткәч тә китәргә ашыкмады ягымлы апа. Дөресрәге, Миңлебикәттәй үз өенә чыгып кунса, Кояш апа әүвәлгечә Кырлы курайны үз янына ала да кочаклап кына йоклата. Тик сабый бәхете бик үк озакка сузылмады. Күп дисәң, бер атнадыр. Атна узгач, күрше авылдан мулла бабай дигән бер кеше килеп, әллә нинди аңлашылмаган сүзләр белән бер тавышка көйләде-көйләде дә аңлаешлы телдә этисе белән Кояш апасына бәхет һәм тәүфыйк, озын, матур гомер теләде:

— Амин.

Кичкелеккә яшь этәчләрнең икесен берьюлы суеп, тәмләп аш ашадылар. Әлбәттә, этәчнең иң әйбәт боты тагын Курайга тиде. Әмма бу юлы урынны төпчек кызга да кара өй сәкесенә, абыйлары-апалары янына җәйделәр. Әниләре ята торган караватка ата белән Кояш апа яткач, балалар нәрсә уйлады икән?

Тата үзе бер генә нәрсә хәтерли: ат тугарылып диңкетмәде.

Көйсезлек шул — ике-өч көннән соң ук олы малай район үзәгенә күчте. Аннары ике кыз бала Казанга ук киттеләр: берсе — укырга, икенчесе — эшкә.

Кырлы курай өйдә бердәнбер һәм иркә бала булып калды. Дөрес, иркәлек тагын күпкә җитмәде. Нигә дисәң... Монысында инде сарык бәрәне гаепле.

Кыш узган, март урталары җиткән иде. Һәммәбезгә мәгълүм — кыш буе бәрәңгене өй базыннан алып ашыйсың. Бу өйдә дә шулай. Бермәлне баз капкачын ябарга кул җитмичә, бәрән имезергә дип өйгә сарыклар керткәч, бутала-бутала имгәндә, бер бәрән ачык базга төште китте. Баз авызы тирәсендә, әй, бөтерелә сарык, әй, бөтерелә, әй, кычкыра-өзгәләнә генә, сикереп төшәргә чамалый. Сизелеп тора инде — йөрәге ярылыр дәрәҗәдә үрсәләнә. Бәлки сикереп тә төшкән булыр иде, әмма Тата үзе тиз генә базга чумып, бәрәнне алып чыкты һәм сарык булып сарык шунда биегәндәй итте, «бә-бә!», «бәә-э!» дип шатланды.

Шул көнне ата кеше телдән калгандай уйланып йөрде-йөрде дә Кояш әнигә ягымлы һәм җылы бер тавыш белән менә нинди сүз әйтте:

— Синайтәм, сизәм, сизмим түгел, сагынасыңдыр кызыңны. Алып кил инде син аны. Үзең сыйган җиргә бер генә бөртек кызың да сыяр.

Шуннан соң өйдә Кырлы курайның үз яшендәге тагын бер кыз бала пәйда булды. Ә тагын да берздан... менә нәрсә ачылды: Кояш ананың өч кызы бар икән — башта берәү генә дип, анысын да алып килмәскә вәгъдә биргән, тайчанмыйча әйткәндә, яшергән...

Җиһан, әлбәттә, мондый эшне һичнинди хәлдә дә эшли алмаган булыр иде һәм шуңа күрә, хәйләсез яшәгәнгә күрә, бәхетен дә тапмыйча, тоймыйча дигәндәй, вафат булды. Бәхет өчен дә кайчак агрессив булырга, бәхет өчен дә бераз катылык, хәйлә кирәк икән ләбаса...

Татаның үз балалары китеп беткәч, алардан калган биш бәхеткә ят сабыйлар ия булды. Дүрт кыз матур гына үстеләр. Авылда җиде классны мәктәп бетергәч, Кырлы курай да калага укырга элдерде.

Тата бөтенләй ят тормышта ят кешеләр белән калды.

Бәхетле, тәүфыйклы булсыннар.

*

* *

Хатирәләр, хатирәләр... Боз кисәкләре рәвешендә һаман тәгәриләр, мәңге кире кайтмас өчен китеп югалалар, гөрләвекләргә кушылалар. Ләкин Көчле кеше үз күңелендә яктылык булып калган көннәрнең берсен дә боз суларына агызып җибәрмәс. Көчле кеше шушы кәйлә белән боз тавын ваткалап, үзенең иң ак көннәрен аннан аерып ала да хәтеренә яңадан салып куя — аннары балалары, оныклары күңеленә тапшырачак. Бу инде — кешенең җиңүе, мәңгелек салкынлыкның җиңелүе булыр. Кешенең гомер бурычы — салкынлыкны җиңә бару... Усаллык, гамьсезлек ничаклы гына каты һәм куркыныч тоелмасын, бер заман барыбер тәкәббер горурлыгын югалта.

— Чылдырт, чылдырт...

Ә ямьсез көннәр, кайгылар, йөрәкне һаман да сызлаткан үкенү, ялгышулар пычрак боз сулары булып аксын.

— Чылдырт, чылдырт.

Шулай да Кояш дөрес әйтә — иртәгә тагы көн бар. Һәм ул — безнеке. Һәм ул килер. Һәм ул...

Килде. Боз кисәкләре тагын тәгәрәргә керештеләр.

*

* *

Әйтергә кирәк, Кояш атлы яшь бикә яман холыклы булмады. Кояш кояшлыгын итте. Ләкин, ни генә дисәң дә, чит кояш чит икән инде ул. Күнегелгән тормыш, көйле көн шактый үзгәрде, бозылды. Тегесе җитми, бусын тап. Тапмый түгел Тата, элеккедән күбрәк булмаса, һич тә аз түгел. Әмма бүген тапканы иртәгәгә калмый. Калса, күрше-күләнгә таратыла. Өф-өф итеп җыештырып кына торган икән Җиһан, бичара. Өйдә аңлатып булмаслык хәл — әллә иркенлек, әллә таркаулык. Чит оланнарны кочаклап яши ата кеше, үзенекеләр — күзге кош балалары шикелле...

Өйдә ямь кимегәнгә күрә, Тата баштанаяк дигәндәй колхоз эшенә чумды. Егерме генә өйлек булса да колхоз — катлаулы хуҗалык. Өйдә тәртип урнаштыра алмасаң да, колхозда урнаштыру мәҗбүри. Бигрәк тә сугыштан соңгы беренче елларда. Егерме беренче елны күргән Тата өчен дә хәтәр һәм афәтле чаклар... Атлар пошкыруы, машиналар гөрелтесе тансык. Каладан ярдәмгә бер машина җибәргәннәр иде, бер көнгә генә килгән икән — заводтан шулай кушканнар. Бер көнне дүрт рейс ясады ясавын — уңган егет булып чыкты кала шоферы. Ләкин илтәсе ашлыкның яртысы түбәсез амбарда кала — аны черетсәң, башыңнан сине беркем сыйпамас. Житен төсе бизәгән баш әйтерсең якты фикер әйтә: әгәр тагын бер көнгә калып, дүрт-биш рейсны ясаса, шоферга бер капчык бодай түләргә мөмкин...

Вәгъдә — иман. Председатель кеше дәүләт алдындагы бурычын үтәвенә чын күңелдән куанып, тиешле бодайны автомашина әрҗәсенә үзе

карап, хәтта күтәреп салыша, хәерле юл тели. Әмма да хәерсез булып чыга шул. Икенче көннә таң белән авыл Советыннан килгән йомышчы Көчле кешенең райком секретаре булмәсенә иртәнге сәгать тугызга «как штык» барып җитәргә тиешлеген әйтә.

Председатель нәрсәдер сизенеп, атның шәбен җигеп, беренче һәм соңгы тапкыр тарантаска утырып барды. Әйе, күңел алдамады...

Бүтән вакытта аягүрә каршылый, ике куллап күрешә, елмаеп, дусларча гына сөйләшә торган секретарь бу юлы, Тата кергәч, башын күтәреп тә карамады. Сулуы соңгы көннәрдә тагын кыса башлаганга һәм хәзерге билгесезлек борчуыннан ешая да төшкәнгә, Тата хәл җуйды — утырды, урын тәкъдим иткәнне дә көтмәде. Үзе башлап сүз әйтергә дә кыймады. Чакырткан икән, сталы быть, кирәгем чыккандыр, үзе башласын. Ә Татага аңардан бер нәрсә дә кирәкми.

Ниһаять, секретарь башын күтәрде. Салкын гына караш белән хәлнең хәерсез икәнлеген аңлаткач, телефон аша кем беләндер, нәрсә хакындадыр сөйләште — Тата анысына колак та салмады. Әлсерәгән маэмай шикелле сулыш алып, тынычлана алмыйча интекте — секретарь үзе дә шуны көтә иде бугай. Ләкин хәл тиз генә кермәсен чамаладылар. Ниһаять, секретарь аягүрә торды да ишекле-түрле йөренде һәм, өстәлнең икенче, кергән кешеләр утыра торган төшенә утырып, мөмкин кадәр йомшак, ләкин интекмичә генә кирәген ярып салды:

— Чәчләр чалармыш көндә җинаять эшләргә тотындыгызмы?

Татаның иреннәре калтырап китте. Күз кабагы тартып тагын да ныграк үртәде, тимер кул сулышны буды, шунлыктан вакытыннан элек ачуы купты. Секретарьның моңарчы игле һәм яклап сөйләшүеннән иркәгә әверелгән әллә... Әллә шуңа күрә серкәсе су күтәрмәде, әллә Петруха малаеның дивана сүзе кинәт икеләтә мәгънә алды... Малай актыгы: «Хыянәтче!» дисә, ил олысы: «Җинаятьче!» диде. Беренчесен онытырга азаплана иде, ул сүзне әйткәндәге җимерек каш, кысылган теш һәм югарып чалшайган иреннәр күз алдыннан киткән дә кебек иде. Ләкин онытылмаган, йөрәгенең нәкъ үзәгенә үткән икән. Һәм иске җәрәхәтне күзгатырга бер сүз җитте: «Җинаять!» Юк, искесе яңару гына түгел, ике җәрәхәт хәзер бер йөрәктә.

Петруха малаена түгел, Чаган фамилияле олпат кешегә дә түгел, үзенә ачулана Тата, ләкин сүзләре башкаларга бәрелә.

— Сезгә дә җитәр әле ул көн, Чаган иптәш, үзегез дә ишетерсез.

— Нәрсә-ә?

Нәрсә әйтсен Тата — ык-мык итте. Чөнки сүзе юк, ачуы гына бар — мәгънәсез ачу. Ә секретарь ачыклау сорый.

— Әллә син мине дә шундый җинаять эшләр дип уйлыйсыңмы?

— Мин кылган эш җинаять булгач, сезнеке күбрәктер дә. Сез бит күбрәк эш кыйратасыз.

— Син нәрсә кыйраттың?

— Кешегә хезмәте өчен түләдем. — Сүзнең нәрсә хакында баруын председатель, әлбәттә, башта ук төшенгән иде.

— Нинди нигездә? Гомум җыелыш җыйдыңмы? Я булмаса, ташка басылган кодексларны үзгәртүгә ирештеңме? Әллә законны үзең чыгара башладыңмы?

— Җирнең үз законнары бар, иптәш секретарь. Шулар белән яшәмәсә, бүтән законнар корый. Шуны белеп яшә, иптәш секретарь. Мин менә бер дә корымыйм, минем закон — табигать дигәнегезнең үз гаделлеге. — Тата бу сүзләрнең хаклы түгеллеген чамалый, ләкин бүтәнчә әйтә алмый.

— Менә син хәзер шушы чал чәчләрең белән матур гына итеп караңгы төрмәгә барып керсәң, шул булырмы гаделлек? Гаделме шул?

— Алай бик куркытмагыз, иптәш секретарь.

— Син биргән бер капчык бодай милиция кулында һәм акт төзеп

тиешле урынга җибәрелгән. Менә сиңа гаделлек! Шулмы синең гаделлегең?

Ни хикмәттер, Тата бу сүзләргә гаҗәпләнмәде һәм курку тиешлеген башына да китермәде. Аңа ни өчендер бу минутта бөтенесе барыбер иде. Сәбәбен аңламады, ләкин бернәрсәдән дә курыкмавын, каушамавын тойды. Бары тик шунысы гына гаҗәп иде.

— Теләсә нәрсә булсын, мин — җир кешесе, крестьян. Кайда да, кайчан да ике кулыма бер эш — туфрак чоку, җир айкау. Ә менә сине эштән алсалар, син нишләрсең? Кая барырсың? — Татаның күз алдыннан кайчандыр үзенең энесенә күтәрелгән йодрыгы чагылып китте.

Аптырады да калды секретарь — өнемме, төшемме, янәсе. Үзенең дистәләрчә еллар буе җитәкчелек итү тәҗрибәсендә мондый мисалны белми иде ул. Шуны хәтерләргә тырышып азапланса да, зиһен шартлап өзелердәй булып тартылса да, юк, исенә төшерә алмады. Бигрәк тә шушы оста сүзле мөлаем кешедән көтмәгән иде ул мондый усаллыкны. Инде бердәнбер чара: балаларча җиңел уйлаган кешегә тиешле җәзасын бирү — атасыз-анасыз сүзләр белән сүгеп чыгару. Ләкин үзен тыя алды секретарь. Татаның инде олы эшкә һәм борчуларга көче беткәнен чамалап, үз урынына ашыкмыйча гына барып утырды да хәрәкәтләре төсле үк салмак сүзләр әйтте:

— Бөтенесе ачыкланды. Яхшы әйттең. Сугышның буеннан-буена кечкенә колхозны булса да әйбәт тартып бардың. Рәхмәт сиңа моның өчен. Халык та онытмас, һаман хөрмәт итәр, яратыр дип уйлыйм. Синең энең дә райком секретаре. Минем урында булса, ул да шушы сүзләрне әйтер иде дип ышанам. Аңа булган хөрмәтемне дә кушып әйтүем: эшеңне судка җиткермәс өчен, сине карак хәлендә калдырмас өчен бөтен көчебезне куярбыз. Әгәр булдыра алсак. Бар, кайт та гомум җыелыш җыятор.

Тата озак кына йөткерде дә урыныннан торды:

— Рәхмәт яхшы сүзеңә, иптәш секретарь.

— Хуш, рәнҗемә.

Бая тиргәлгәндә шәп иде хәл — ә болай җылы сүзләр ишеткәч, күңеле тулды. Көчле кешегә елау килешәме инде? Бүреген батырып киеп, тиз генә чыгып шылды Тата.

Җайсыз, бик тә җайсыз бугай — хезмәт, бер гомерлек хезмәт күңелле тәгәлләнмәде, ахрысы.

Кеше олы тормыштан каядыр китеп бара — тынлык иленә бугай, теге дөньяга үк түгелме икән?

Гомум җыелышны җыйды ул җыюын, ләкин үзе, авырыйм дигән булып, анда бармады. Иртәгесен председатель итеп кемне куйганнарын сораган иде, бөтенләй көтелмәгән хәбәр әйттеләр: авылны бүтән колхозга кушканнар. Заман үзгәргәне, ул заманга Тата дигән кешенең инде ярамавы көн кебек аңлаешлы иде. Ләкин бу да мәгънәләрнең әле иң тирән ачылышы булмаган һәм алар, тора-бара, артык тәүфыйксыз чишелеш көткән булып чыкты. Анысы соңрак. Әмма Тата бер вакытта да күңел төшермәде, өметсезлеккә бирелмәде. Арыслан тота алам дисә, бүре үтерә алам дисә, инде арттыру булыр, ялганлау булыр. Әмма да үзенне төлке тотарлык хәлдә түгел дип исәпләү — үлемнән дә ачырак мескенлек. Ә Татага кушаматны ялгыш кушканнармы? Юк, халык ялгышмый ул. Беркайчан да.

*
* *

Балалар үстеләр. Әтиләре аларны җәйге каникулга кайткач кунак итүен, алма һәм бал җибәргәләвен исәпләмәсәң, әллә ни зур файда эшли алмагандыр. Шулай да күз тимәсен, үз дөньяларын матур гына корды бала-чага. Олы малай сугышлардан исән-сау кайткач, Казанның

мех комбинатында кара эшче сыйфатында ярты ел эшләгәч тә мастер ярдәмчесе, аннары мастер ук булып китте. Олы кыз — галимлеккә үрләде, ә Кырлы курай, Ленин укыган университетта укыгач, музей дигәннәрендә фән әһелеме шунда — эшләп йөри. Иң сөенечлесе — үзе төсле бер кыз белән нәкъ әнисе Җиһан шикелле зәңгәр күзле малай алып кайтты.

Бабай юк йомышын бар итеп оныгын күрергә калага элдерә.

Өч яшькә житте малай. Балалар бакчасына йөрмәгәнгә күрә, әнисе кибеткә-мазарга чыкса, өйдә ялгызы гына кала икән. Шәһәргә килгәч, Тата бер көнне ишек яңагындагы звонокка баскан иде, ишеккә шул оныгы килде.

— Му-ул?! — «Кем ул» дигәне шул инде аның.

— Мин бу, улым, дәү әтиең.

— Качер, дәү әти. — «Хәзер» дигәнен аңлау кыен түгел.

Сизеп тора Тата — оныгы эчтәге йозакка үрелә һәм ахрысы буе житми. Мыш-мыш килеп шактый азаплангач, нәрсәдер өстерәп китерә. Соңыннан билгеле булганча — чана икән. Шуны ишеккә терәп куя да йозакны бора һәм ишекне тартып карый. Ә ишек ачылмый. Йозакны бер бикләп, бер ачып ишекне күпме тартса да, ул селкенми дә. Хәлдән тайганчы интеккәч һәм барыбер ача алмагач, өметсезлеккә бирелми нишләсен.

— Бар инде, дәү әти, үз өеңә кайтып тор, әни кайткач килерсең.

Алтмыш чакрым пароход белән, аңа хәтле ат белән күпме килеп интеккән жиргә кайт та яңадан кил. Бала жиңел хәл итә. Әмма дәү әтисе дә оныгыннан бик үк ерак китмәгән булып чыкты.

Бишенче каттан төшеп, бакча эскәмиясеннән өскә, фатир тәрәзәсенә карап уйга калды. «Чынлап та, нишләп безнең бәхет гел югарыда икән ул?»

Бишенче кат, мөгаен, Татаның Үләмә буендагы өянкеләреннән дә биегрәктер. Җәмәкинең теге манарасы да шушы чама гына түгелме икән?

Күпме тавыш кузгатып, хәтта әнесе белән ямьсезләнешә язып, теге чакта саклап калсалар да, манара барыбер озын гомерле булмады. Бабаларыбыз матурлык хисләрен күк зәңгәрлегенә һәм киләчәк гүзәллегенә илтеп житкерергә теләсәләр дә, кодрәтләре, байлыклары житмәгән — тарихи бәхетсезлек. Моның өчен аларны тиргәү ансат, әлбәттә. Бәлки шулай кирәктер дә. Ләкин аларның фараздагы сүзен туп-туры үзебезгә кайтару фарыз түгелме? «Ярый, без ныклыкка ирешә алмадык, сәнгать көчебезне биналар, сарайлар рәвешендә жиргә мәңгелеккә бастырып, күккә күтәреп куя алмадык. Нигезләре нык булмагач, жимерелделәр. Әллә хатабыз, әллә бәлабез. Ә хәзер? Ә сез? Сезнең бит бөтен мөмкинлегегез бар. Сез нәрсә карыйсыз? Бүгенге көн дә тарих булып калмас һәм үзегезгә ерак балаларыгыз өйне бөлдереп үлгән әчкече атага карагандай карамаслар дип уйлыйсызмы?»

Саклап калганнан соң Җәмәки манарасы күп дигәндә егерме-утыз ел тыныч утыра алгандыр. Аннары калтырый, селкенә башлады. Жил генә түгел, вакыт селкетте һәм давыл чакларында аңа якынрак өйләрдә яшәү куркынычка әйләнде. Шулай, рәхим итеп, авыл советына халык үзе килде һәм манараны төшерү өчен акчаны да үзе түләде. Ә теге чакта Тата нәрсә өчен кычкырышкан булып чыкты соң? Әгәр ул шунда киләчәк биеклекләр хакында кайгырткан булса, болай кемнәрдер салган матурлыкка карап кызыгып утырыр идеме?

Бәби дигән авылдан бер тимерчене чакырдылар. Тимерче манараны төшерде төшерүен, тик шуннан соң ук сәер казага тарыды: көнендә үк аның биш сарыгын бүре буган. Теге заманда аллаһы тагалә каргышы дип азмы шаулашырлар иде?! Беркемнең дә диярлек исе китмәде. Үзгәрсә дә үзгәрә икән кеше дигәнең!

Сәгать чамасы ишек төбе саклагач, кыз үзе кайтып килде. Шатлыклары эченә сыймады.

Аталы-кызлы әкрен генә менделәр. Атасы бер-ике баскыч күтәрелгән саен каты-каты сулап ял итте. Бәхете һаман югарыда булган кеше өчен дә җайлы хәл түгел бу. Шулай да... Менеп ишек ачсалар, ишек янында гына чана тора. Оныгы шуны терәп куйганга һәм үзе шуның өстенә басканга күрә ачылмаган икән ишек. Йозакны ача белгән... әмма чанадан төшү башына килмәгән. Бәхеткә дә шулай күп вакыт чак кына нәрсәдер җитми кала бит. Өч яшәгән бала һәм җитмеш яшәгән карт акылы өчен дә шулай икән.

Өч яшәгәннең куллары дәү этисенең мыегы тирәсендә уйнаса, җитмеш яшәгәннең уйлары авылга юл ала. Бигрәк тә тын ваннада тыныч су чылтыраганда күңел тар бүлмәдән кыр киңлегенә кайтып китми нишләсен. Бүтән чишмәләр бар бит, ирекле чишмәләр. Оныкның үзе төсле шаян тормыш. Ләкин ул кайдадыр еракта, еракта — чакрымнар һәм еллар артында.

Авылны яшәртим, тормышны яңадан башлыйм дисәң, оныкны авылга кайтарып, авылны ул яратырлык һәм ташлап китә алмаслык хәлгә китерү, мавыктырып яшәтерлек мәгънәләр һәм кызыклар булдыру фарыз. Мөгаен, оныкларга әтәчләр һәм төлкеләр генә җитмәс, мөгаен, алар бабаларыннан күбрәкне сорарлар. Ә нәрсә? Нәрсә кирәк аларга?

Тата монысын әйтә алмый. Ләкин оныгын авылга алып кайтырга һәм шунда гомерлеккә калдырырга хыяллана. Югыйсә, авылны саклап калу җайсызга китәчәк. Ләкин дәү ата үзен бер мәзәк фикердә фаш итә: душ дигәннәренең чишмәдән өстен яклары бар түгелме соң? Оныкны алып кайту урынына, Тата менә үзе бәйрәм-фәлән җиттеме ник калага элдертә? Ник? Авылда бәйрәмнәр инде бәйрәм түгелмени?

Җавап таба алмый интеккәндә, дөбердәп тышкы ишектән кияү кайтып керде дә ванна ишеген какты — хәл сораша...

Кичкелектә зур итеп өстәл әзерләделәр һәм, билгеле инде, хәмерсез генә буламы дәү этине күрү бәйрәме! Елдан-ел сирәгрәк килә башлады бит. Ләкин бәйрәмнең ахыры — тәмуг. Иртән сәгать бишләр чамасында уянып китсә, баш әйләнә, күкрәкне тимер кул тагын да рәхимсезрәк кыса. Башкалар йоклый иде әле. Тата үзе генә газга тотынырга курыкты, кичтән калган чәйнектән генә чәй агызды. Әмма файдасы тимәде. Хәлсезлек яңадан яткырды. Үзенең яткан килеш ясый торган гимнастикасын кабатлау да ярдәм итмәде. Тик кая барасың, мунчадан гына чыккандай еш-еш сулап ята бирде. Кызы чәйләр кайнаткач, кияү белән онык та йокы бүлмәсеннән залга чыктылар. Шул вакыт бабаларының әлеге дә баягы әлсерәгәндәй мышкылдап, хәтта гыжылдап чалбар кияргә азапланганын күргәч, сәерсенеп карадылар. Ап-ак урынга кап-кара чалбарны сузган да ике аягын яткан килеш кенә чалбар эченә сузмак булып азаплана кунак.

— Ничек, бабай, әллә баш авыртамы?

— Юк, кияү, ул хәтле зыянлы түгел.

— Дөрес, нинди бүреләрне җиңә торган көчле кеше ярты аракыны гына аудара инде ул. Үзе нык тора.

Кулына чәйнеген тоткан килеш кызы да чыгып сүзгә кушылды:

— И эти, эти, күпме аучы булып йөргән булдың, күпме бүре тоттың. Төпчек кызыңа төлке якалы бер пальто да кидерә алмадың.

— Төлке яка хәзер кимиләр түгелме соң, кызым? — Ә чалбар тәки буйсынмый гына бит — керми мәгънәсез аякларга.

— Кияләр, эти, кияләр. Затлы әйбернең модасы чыкмый аның, беркайчан да.

— Төлке яка киясең киләме? — Чалбарның бер балагы буйсынды!

— Килә шул, эти, бик тә килә. Тотып бирәсеңме әллә?

Икенче балак та артык карышмагач, чалбарын төймәләп бетергәч, әти кеше күкрәген тотып диванга утырды һәм ун минутлык ютәлдән соң үз сүзен әйтте:

— Ярый, кызым, төлке тоту кыен түгел ул.

Кычкырып көләргә тиешле кияү, үзе дә сәер ымлыклар гына чыгарып, әчен тотып идәнгә утырды. Кызы да бер мәлгә телен йотты. Тик оныгы гына, бер дә гаҗәпләнмичә, бабасын кочаклап, аучының киләчәк уңышларына чиксез ышаныч белдерде:

— Дәү әти, дәү әти, төлке тотканда мине дә ияртерсең, яме, дәү әти?

— Кайтсаң ияртермен. Кайтырсыңмы соң?

— Кайтам, дәү әти. Тшш, тш-ш-ш. — Үзенең зәңгәр кавырсын автоматыннан, төлкеләргә бугай, атарга да кереште бала.

Ләкин бабасы төзәтмә кертергә тиеш тапты:

— Чуже, матур җәнлек ул төлке, атмаска тырыш син аларны. Төлке белән сугышу егетлек түгел.

Ниһаять, кияү телгә килде:

— Ә тотарга ышаныч зурмы, бабай?

— Өметсез кеше — шайтан ул, куркыныч адәм.

— Этсез дә тота аласыңмы?

— Этсез дә була.

— Бер минут, бер метр да йөгерә алмаган чакта дамы?

— Үләренә бер минут калганда да ир кеше теләсә нинди җәнлекне тота ала. Чуже, мин гомеремдә бер генә төлке тоттым, анысын да хата санадым.

Бу сүзләргә хәзер игътибар итмәгән төсле тоелса да, кем белә, бәлки оныгы аларны кайчан да булса хәтеренә төшерер һәм кемнәргәдер яңадан кабатлар?

— Ярый, кызым, бик сорагач алай, төлке — миннән.

*
* *

Каланы Тата ике-өч көн генә мактый. Җәй көне балалары, оныклары кунакка кайтканны артыграк күрә. Ләкин көн җиткәнне дә көтмичә, кошлардан алда алар китә. Аннан соң, көзге яңгырларның тигез шыбырдавын көннәр һәм төннәр буе тыңлап, ят уйланып: «Кошларның жылы якка, онықларның калага китмәүләрен теләү гакыллы эшме?»

Мондый чакларда күкрәкне тимер бармаклар рәхимсезлекнең ахыр чигенә җитеп кыса. Түзсәң түз, түзмәсәң аяк суз. Ә дөнья бит үзе һаман кин, болытсыз көннәрдә күкләр биек, теләкләр чиксез. Шундый иркен дөнья һәм күкрәктәге кысанлык — һич ярашмас нәрсәләр генә түгел, табигатькә, кешеләргә үк каршы. Уфф, булмый болай, урамга чыгып әйләнергә кирәк.

Күпне күргән кирза итеген, шактый таушалган бүреген кигәч, тун киярга азапланган чакта, колхоз председателе Рамазан килеп керде. Ничек сөйләштеләр, нәрсә хакында? Юк, Тата моны хәтерләргә дә тиеш түгел. Тәгәрә, боз, тәгәрә, менә шулай.

— Чылдырт, чылдырт.

Ләкин ындыр яклап ишетелгән ниндидер сүзләргә күтәрелеп караса... Җилкәсенә лом салган Дәвеш күрше, аның артыннан Палҗан күрше килә, аның артыннан... Юк, анысын хәзергә булса да танымый тору хәерлерәк. Күршеләр белән кичәге очрашу күңеллерәктер.

Тау ягы теле әйтә алганча Палҗан, мулла кушканча — Фазылҗан — нечкә, озын гәүдәле чал карт, күкне аркасы белән күтәргән бер кыяфәт белән атлый. Кичә иртән аның ишегалдына Тата кергәндә, бәләкәй арбасына тәгәрмәч кидерә алмыйча интегә иде. Куллары калтырый иде.

Тата кергәнне сизмәде. Тата арбаның күчәр ягыннан күтәргәч, Палҗан тәгәрмәчне ыңгыраша-ыңгыраша булса да кидерде. Әзмәвердәй батырны да нинди хәлгә куйды бу дөнья.

Тәгәрмәчләрне кидергәч, күчәргә чөй кактылар һәм эшне төгәлләнгән санап, икесе дә мөмкин кадәр тураеп бастылар. Палҗан ким дигәндә ике башка озын иде. Әйтерсең ки, шуңа күрә аның колагына сүз менеп җитми.

— Күрше, минем бакчага боз кергән бит әле.

Рәтләбрәк сөйлә әле, дигәндәй, күршесе авызын ачып куйды. Тата катырак кычкырырга тиеш.

— Боз, боз кергән, тау хәтле боз.

— Без дип, сез генә түгел, безнең дә баз карсыз калды быел. Картайдык, күрше, өлгерә алмадык.

— Мин әйтәм, бакчага өй хәтле боз кереп утырган. Шуны җимереп ташларга кирәк иде. Нәрсә белән дигәндә менә баш җитми тора. — Тата кулы белән башын тотып аңлатырга тырышты.

— Әһә, баш. Беләм, беләм, минеке дә бик каты авырта баш. Катырак итеп чәй эч син. Мин үзем дә шул чәй белән генә кеше.

Тата кулын селтәде дә чыгып китте. Күршесе «ник үпкәләдең тагы» дип сөйләнә-сөйләнә баш чайкап калды.

Дөньялар!

Икенче күрше — авылдагы иң яшь кешеләрнең берсе — Дәвеш. Анысы хатыны белән гөжләп торган самавар каршында, рәхәтләнеп пар чыгара-чыгара, бәрәңге бәлеше ашап утыра иде.

— Исәннәрмесез.

— Әйдүк, Тата абый, мактап йөрисең икән. Утыр, чәй эчик бергәләп.

— Дәвеш туган, чәйләп торырга вакыт юк, эш ашыгыч.

— Син гомер буе каядыр гел ашыктың, Тата абый.

— Шуңа күрә гел соңга калдым.

— Нәрсә бар ул хәтле?

— Нәрсә дип, ни. Бакчага өй хәтле боз кереп утырган бит әле.

Дәвеш, үзе итле бәрәңгене авызга ныклап тутырса да, күршесен җавапсыз калдырмады.

— Керсә соң? Яз ул бозлары белән матур. Керсен, алай бик керәсе килгәч. — Олы ир кеше шундый мәгънәсез сүз сөйләгәч, бүтәнгә ни сан!

Тата аңлатып торуны да кирәк тапмады.

— Шуны ваткаларга иде. Ничегрәк дигәндәй, нинди киңәш бирерсең икән?

— Киңәш дип. Киңәш кирәкми монда, лом кирәк.

— Күтәреп карадым да бит.

— Әлсә, бер ярты куярсың да үзем юк итәрмен.— Тата сүзсез калганга күрә, өстәде: — Нәрсә, ярты кызганасыңмы әллә?

Татаның хәтере калды.

— Их, Дәвеш, Дәвеш, яртыдамыни эш, — дип баш чайкады да чыгып та китте.

Һәм әнә Дәвеш килә лом белән! Ә председатель? Анысына ни җитмәгән? Тата монысын да чамалый, әлбәттә. Имештер, авылда өч-дүрт өй генә калган, анда кешеләргә тиешле хөрмәтне күрсәтү кыен. Имештер, якында гына кибет юк, ипи алырга да күрше авылга йөрергә туры килә. Электр чыбыгы сузудан мәгънә юк — караңгыда утырасыз... Дөрес түгел, председатель иптәш, крестьян беркайчан да ипине кибеттән сатып алмады һәм алырга тиеш тә түгел. Өендә җылы ипи кебек аңкыган бәхеттән үзен мәхрүм иткән крестьянны әйбәт һәм акыллы кеше дип булмый аны. Тоздыр, шырпыдыр, алырга гына күрше авылга барып килү — үзе бер ирек ачу, үзе бер кызык. Ә электр дигәндә, төн ул караңгы булсын өчен килә, яктылыкның кадерен белдермәк өчен.

Имештер, хәзер бүтән авылларда су өйгә ук керә. Ләкин хатын-кызның иң күркәм вә бәхетле чагы — көянтә-чиләк күтәргән мәле. Шундый хатын-кызы булмаган авыл — айсыз күк.

Тата боздан бераз читкәрәк китеп утырды. Бүтән чакта булса, каршы барып исәнләшер иде. Бу юлы хәле калмаган икән — кунакларга утырган килеш кенә кул бирде.

Председатель боз ватуның нигә кирәге бар дип бераз гаҗәпләнгәч, монысына бик матур гына итеп Палҗан карт җавап бирде:

— Безнең икебезнең сүзебез бер инде, иптәш пресидәтель, без авылыбызны ташлап беркая да китмибез, — диде.

Рамазан энеләре елмаеп кына куйды:

— Синең колак, Фазылҗан бабай, гел үзеңә кирәген генә ишетә икән. Раз шул хакта сүз чыккач, дәвам итик. — Һәм ул ютәлен көчкә тыйган Татага таба борылды. — Кичә идарә утырышында шундый карар кабул иттек, Тата абый, сезгә бик әйбәт өй салабыз. — Тик Тата тиз генә эндәшергә җыенмаганны күргәч, тагын өстәде: — Ничек карыйсың син шуңа?

Тата нәрсәдер әйтмәкче иде, ләкин шул минутта ютәл өянәге кузгалды. Ким дигәндә биш минут чамасы интеккәч, үзенә кызганычлы күзләр белән караган кешеләрне тынычландырыр өчен, мөмкин кадәр ачыграк, яктырак чырай алырга, хәтта елмаерга тырышты һәм шул сәбәпле тагын да кызганычрак кыяфәткә керде.

— Яңа өегезне газга көйләрбез, Тата абый, җылыда гына утырырсың.

— Җылылык миңа гына түгел, башкаларга да кирәк бит.

Татаның сөйләшә бишлавына сөенеп, Рамазан аның янына ук күчте:

— Ә без беренче чиратта сезнең хакта борчылабыз. Күпме еллар колхоз җитәкләгән кеше...

— Колхозга башлап керүче, оештыручыларның да берсе ул булган, — дип, Дәвеш тә сүз кыстырды.

— Беләбез, бик яхшы беләбез. Шуңа күрә дә өйнең иң шәбен салачакбыз, Тата абый, риза гына бул.

— Мин үрмәкүч түгел бит, балалар.

— Беләм, Тата абый, үрмәкүч кебек, теләсә кая күчәргә димләмим, олырак авыл тирәсенә җыелсак, тормышны көйләү җиңелрәк булганга күрә, тагын да зуррак коллектив тупларга тырышабыз. Дөнья гел шуңа бара — күбрәк кешеләр берләшүгә.

— Без шушы авылны хуҗалыкка туплаган кеше, балам.

— Ләкин хәзер таркаулыкны яклыйсыз. Бик мәзәк килеп чыга бит, Тата абый.

— Шулай шул.

— Алайса, күчәсең инде, риза?

Тагын ютәле кузгалганга күрә, Тата баш кына чайкады, ә председатель, бәхәснең файдасыз икәнен төшенеп, урыныннан кузгалды һәм ютәл юашлана язган бер арада Татаны кулбашыннан кочаклап хушлашты:

— Уйла әле, Тата абый, ныклабрак уйла.

Тата тагын баш чайкады.

Председатель белән Фазылҗан киткәч, Дәвеш лом күтәреп боз янына килгән иде, Тата сагая калды. Күршесе аны-моны сорамыйнитми генә, бозга лом белән сугарга җыенгач исә, бар көчен җыеп, кычкыра алды:

— Әй, нишлисең?

— Җимерәм. — Күршесе ломны җиргә төшерде.

— Җимермә тор.

— Нишләп?

— Үзеңә тиешне җимер.
— Минем — юк.
— Булыр, көт бераз гына. Һәркемнең үз бозы, үз язмышы.
Дәвеш, Тата сүзләрен ахрысы бик үк аңлап бетермичә, үзенекен тукыды:
— Курыкма, мин синнән ярты сорамам.
Шулай дип тагын ломны күтәргән иде, Тата тагын ыңгырашып кычкырды:
— Әй! — Дәвеш тынычланмагач, бөтен усаллыгын күзләре белән чәчеп аңлатты һәм тагын шуны өстәде: — Бәхиллегем юк.
Билгеле, Дәвеш алыштырып куйгандай кинәт үзгәрде һәм, күршесенә бик җитди күзләр белән озак кына карап торганнан соң, ломны кулбашына салды да лап-лоп атлап китеп тә барды.
— Ярый, үзеңчә эшлә, Тата абый, җаның теләгәнчә эшлә,— диде ул китешли.
Авылны ташлап китү — Тата өчен дөньяны ташлап китү белән бер. Билгеле, бу хакта ни өчендер беркемгә дә сөйли алмый. Кышлар үтә дә җәйләр килә. Күпме генә еллар килсә дә, хәтта кысанга әйләнгән дөнья да, таралып бетә язган шушы авыл да һич туйдырмый. Белеп тор, иптәш председатель, туйдырачак та түгел.
Шулай да бер көнне Кояш апагызга әйтә куйды:
— Сиңайтәм, хәлем авыр булса да, үлмичә балаларны чакырмасың. Теге юлы исән калуыма бик тә уңайсызландым.
Кояш апагыз, билгеле, андыйга риза түгел.
— Үлмисең әле, алла бирсә, үлмисең. Чыраең бик әйбәт әле.— Үзенең йөзе әз генә булса да караңгылана.
Чынлап та, шушы тынгысыз кешене күз алдына ничек инде үлгән итеп китерәсең? Әмма сулышлары көннәр кыскарган кебек кыскара бара шул.
Янына хатыны килеп утырса, сулыш кысанлыгын җиңәргә тырыша, бераз тынычлангандай тоела һәм дөнья яратылганнан бирле кабатлана торган бәхилләшү кебегрәк нәрсә килеп чыга.
— Сиңайтәм, уйласаң, синең белән дә бик әйбәт гомер кичердек. Әйтеп булмый начар дип. Инде килеп, шунысын да беләсең — теге дөньяда Җиһан апаң бар, көптән мине көтә. Сине дә көтәләр, үзең беләсең...
— Әйе шул, Мөхәммәтгалием мине дә көтә торгандыр.
— Аларны ятим итү килешмәс диюем.
— Әйе шул, сиңайтәм.
— Мин теге дөньяда Җиһан апаң белән булырмын инде, син — Мөхәммәтгалиең белән.
— Әйе шул, — дип куя Кояш апа һәм нигәдер күзләрен сөртә.
Дөньялар!..

*
* *

Алмагачлар чәчәк ата майның унбишләрендә.
Быел алар соңрак бөреләнделәр, чәчәкләр әле ачыла гына башлады. Соңгару — җылы җитмәүдән. Ә җылының ни өчен җитмәве күренеп тора, салкынлык чыганагы — боз албасты, дип уйлый Тата. Әгәр бозны шушы көннәрдә Көчле кеше җимереп бетерә алмаса, алмагач тамырларына боз салкыны тиеп, чәчәкләр кара көячәк. Теге елны, Җиһан вафат елны, нәкъ шулай булды бит. Ул чакта әтиегездә тәҗрибә җитмәгән, ватып-җимереп ташламаган шул кара суыкны. Тәҗрибәсезлек, хәрәкәтсезлек нәтиҗәсе күп көттермәде — алмагачларның кайберсен чәчәксез-алмасыз гына түгел, әтиегезне ялгыз да калдырды.

Җиһанны җирләп кайткач бакчага төшеп караса, ни күрсен, хәшәрәт тау да җан бирә, эреп бетеп килә, өстен кара-кучкыл ләм, пычрак каплаган иде...

Ярый, бүгенгә җитәр, кояш баеп бара...

*

* *

Кай арада байый да, кай арада яңадан чыга кояш. Ә Тата, билгеле, гел аның белән бергә кузгала. Бүген албасты белән очрашуның соңгы көне булачак. Соңгы көрәш алдыннан кәеф һәм көч сафландыру өчен Тата авыл урамнарын әйләнергә тиеш тапты.

Үз өеннән чокыр аша — ике өй: Фазылҗан карт һәм ир уртасы Дәвеш. Берсе һаман эштә, икенчесе һаман абзар тирәсендә кыштырдый. Әнә ул бәләкәй арба тарткан да каядыр китеп бара. Күршесен күргәч, туктады. Елмаерга кирәген белә, тик тиле кеше сыман авыз ачып тормаска икәнен генә хәтереннән чыгара, күрәсең. Тата эндәшмәсә, шулай торасы да торасы.

— Палҗан күрше, хәлең әйбәтме?

— Менә, карчыкка ярдәмем тисен дип, берчама кизәк җыеп кайтыйм дидем ие.

— Ә-ә. Алайса, эшләрең шәп синең.

— Юк инде, кая хәзер безгә утын ташу. Монысына көч җиткәч тә тә ходайга шөкер.

— Хуш, Палҗан.

— Ярый, бик әйбәт, бик...

Нинди егет кеше иде күрше: озын буйлы, зәңгәр күзле чибәр әзмәвер. Көчле кеше аның янында бала-чага кебек кенә күренә иде. Ә хәзер... Тигезли дөнья, бөтенләй тигезли.

Дәвешләргә чаклы бергә атлаулары мөмкин иде, ләкин Палҗан артык тәкәббер булганга күрә, артыннан күршесе ияргәнен бар дип тә белмичә, шыгырдый бирде. Дәвеш бу юлы өйдә юк иде. Тата авылның икенче башына, кирегә таба борылды. Бүтән вакытлардагы хәл белү бүген ничектер саубуллашу төслерәк килеп чыкты.

Якындагы ике-өч көн эчендә үлән урманы шаулаячак урында, соры искелекне тишкәләп, яшел кыяклар баш тертә. Нәбиулла абзый нигезе. Әле дә исәннәр шикелле. Әйтерсең бәхеткә ирешкән шөпшә һәм башка бөҗәкләр бәйрәме — кайчандыр еракта калган туйларның дәвамы.

Туй булгач туй. Кияү бер генә булса да җыр җырлап бирергә тиеш. Кыз яныннан килгән кодалар: «Егетнең үзен күрдек, тавышын да ишетик инде»,— дип җыр сорый башлагач, Нәбиулланың гел генә алланып һәм янып торган түгәрәк йөзе кәл төсле күгәрә дә, аннары каен тузы шикелле агара. Ләкин бер хәл дә кыла алмыйсың. Ходай көй бирмәгән һәм гомерендә бер җырлап карамаган кеше дә бите белән пычракка үзе теләп егылмас. Тырышып карарга тиеш адәм. Кияү, тирән сулыш алып, кычкырып та җибәрә:

Сикереп төштем, боз тиштем,
Боз тиштем дә су эчтем.
Бу хәсрәтне күрмәк өчен
Ник тудым да ник үстем.

Җыр тынгач, күңелсез бер тынлык урнаша, пырхылдап куйган тавышлар, көлүне томаларга тырышып йөткерүләр ишетелеп тора...

Шулай да, хәерсез сыман башланса да, гомерләре ямьсез үтмәде. Нәбиулла карт үзен бик әллә кемгә куймыйча, тыйнак яшәде — карчыгына тавыш күтәреп бер сүз әйтмәде. Гомерендә бер тапкыр микән инде, Бәки базарына баргач, йөз грамм чамасы зәмзәм суы эчеп

алгандыр. Тишек-тошыклы арбасын яман да калтырата-калтырата, юл тузанын куптара-куптара, кайтып килә бу. Атын һаман да ашыктыра, куа, дилбегәсен болгый-болгый кыйный.

— Кая бу хәтле ашыгасың, Нәбиулла абзый? Ник шул чаклы кыйныйсың атны?

Абзый җавабын бөтен иркен яланга ярып сала:

— Айныганчы хатынны кыйнап калырга кирәк. На, на!...

Кеше үз гомерендә тереләрнең күңелен күтәрә алырлык бер генә мәзәк калдырса да, бушка яшәмәгән дигән сүз буладыр. Мәзәк тирәякка таралды — аны бу заманда да сөйлиләр. Димәк ки, Нәбиулла абзыйны исән диярга кирәк.

— Ярый, оҗмахлы бул, картлач.

Тата урам буйлап атлый һәм бераздан тагы туктала.

Монда исә бөтенләй нигез дә, өй дә булмагандыр шикелле. Үтүчесүтүче өчен шулай, әмма Тата өчен алай түгел. Гөлбану исемле карчык, әйтерсең Татаны түргә чакыра. Чакыра һәм якты чырай күрсәтә. Атаклы егерме беренче елда син шулай якты йөзле булып кара! Ләкин такта чәй пешереп сыйлый алмый әби. Шул елны, бөтен авыл халкы шешенгән вакытта, Гөлбануга Тата дигән малай чыпчык тотып, күчтәнәчкә кертә. Нишләсен әби, чыпчыкның үзеннән зуррак савытка салып пешерә. Пешерә дә өстәлгә куя. Куя да кызын кыстый-кыстый ашатмакчы була. Кызы: «Ник син үзең ашамыйсың?» дип сорагач, әби:

— Мин ашамыйм, кызым, син аша, мин ашасам әрәм була, — ди.

Кызын шулай ачлык елның ахырына хәтле озата барды да үзе чынлап та дөнья куйды бичара...

— Изге карчык идең. Оҗмах дигәннәре чын булса, очрашырбыз әле. Теге чакта әйтә белмәгән җылы сүзләрне анда инде һич әйтмичә калмабыз.

Карт ары атлады һәм тагын туктады. Монда бергә үскән яшьтәше Гарифулла яши иде. Бик тә ярлы иде. Егет булып җиткәч, кызлар янына, аулак өйгә кергәндә, Гарифулла чалбарны гел Татадан алып тора иде. Бер кичне үзе дә сизмәстән, аны Тата бик каты рәнҗетте. Хәзер дә үкенеп бетә алмый, теге чакта сорый алмаган гафуны хәзер күңеленнән мең тапкыр кабатлый Тата дусты.

Алабута, кычыткан арасыннан яшьтәш егет мәңге чыкмаячак. Уйласаң, исләрең китәрлек — шушы хәтле дә озак яши ала икән кеше. Сезне калдырып бик тә ерак һәм ерак китте яшьтәшегез — сездән башка яшәү хәтта бераз оят та шикелле.

Әйе, хәтердә: сәкегә егетләр, кызлар утырышкан. Гарифулла янда гына. Акча салыш уенына җитә чират, тик бөркемнең дә акчасы юк икән, таба алмыйлар. Шул вакыт кылт итеп исенә төшә Татаның: Гарифулла киеп кергән чалбарында йөрми торган булса да бер тишек тәңкә бар лабаса. Аны-моны уйламыйча гына:

— Минем кесәдә булырга тиеш, алып бир әле, — дип Гарифулладан тәңкәне сорый.

Кычкырып та түгел, пышылдап кына сорый. Гарифулла да сиздермәскә тырышып кына, җилкәсе аша гына суза акчаны. Ләкин алдарсың кызларны — шарык-шырык күләргә дә керешәләр. Ник көлгәннәрен әйтмәсәләр дә, Тата егет сизә, аннан бигрәк — Гарифулла үзе сизә. Шул кичтән соң ул аулак өйләргә йөрмәс булды һәм озакламый чалбар юнәтеп булмасмы дип читкә киткән иде, шул килеш хәбәрсез югалды...

Һай, һай, узган гомерләр, калган хәтерләр сатып алыйм дисәң табылмас.

Урамның каршы ягына чыкты Тата кеше.

Монда кордаш карчык хәзер дә исән. Исеме хөсетле Хәтимә булса да, хәл белеп чыгу фарыз. Мескен җан. Нишләп ул гомер буе Җиһан-

нан көнләште икән? Шул дәрәҗәгә җитте ки, Җиһанның чирләгәнен ишеткәч: «Үлсә, ярар иде, Татага үзем кияүгә чыгар идем»,— дип әйткән, имеш. Юравының бер өлеше, бәхетсезлеккә каршы, юш килде, мәгәр икенчесе — юк. Тата Кояшка өйләнгәч, ул өен сатып кызы белән кияве янына, Казанга күчте. Тик бер-ике елдан соң күз башында кияве аны авыл уртасына кайтарып ташлаган да үзе беркемгә сүз кушмыйча китеп тә барган. Сандыгына утырып, урамда күпме яшь түккәндер хөсетле бичара. Үзе соңыннан: «Авылны бик сагынуга чыдамыйча бик йөдәткәч, кайтарып куйдылар инде», дип сөйләнде. Гөнаһларына кермик. Ярый. Тик ел чамасы Хәтимә үзе, кем кертсә шунда кунып, чиратта йөрде. Әле дә колхоз юмарт — матур гына өй юнәтеп бирде.

Хөсетле Хәтимә булса да, Тата аның да хәлен белергә гел килә торган булды.

Узган кыш урамнан шушылай узып барышлый тукталса, хөсетләнең бәхетсез чагы иде — сарыгы бәрәннән үлгән. Өйдә кечкенә генә ике бәрән ята. Тата: «Исән булмас болары да!» — дип эчтән уйлап кына өлгергән иде, карчык бәрәннең берсен бәби күтәргәндәй күтәреп алдына утыртты да имезлектән сөт имезә башлады. Бәрән артык ялындырмыйча гына имә бит. Берсе туйгач, икенчесен шулай сыйлады.

— Әгәр ходай кушып исән үссәләр, берсен корбанга чалырга булыр, — дип куйды карчык соңыннан.

Бәрәннәр чынлап та бик тә тиз тернәкләнделәр һәм яз көне чабачаба чыгып көтүгә кушылдылар. Җылы булгач, үсә икән, бик тиз үсә хайван баласы. Кешенеке алай ук түгел.

Әмма юктан бар булып күпме генә адәм баласы үсеп кеше булмады. Мәгәр үскәне берсе каядыр китеп югала торды. Менә шушы дөньядан, шушы авылдан туеп, кемнәрдер үз теләге белән китә. Нинди кешеләр икән алар? Бәгырьләре ташмы икән әллә? Рентгеннан караганда, кайберләренең бәгырьләрендә чынлап та таш күренеп тора, имеш...

Ишегалдында кеше күренмәгәч, өйгә кермәкче иде, Тата сискәнеп китеп ава язды. Ниндидер ят карчык бәрелә-сугыла чабып чыкты һәм, чоланнан ниндидер чиләк алып, янадан өйгә кереп китте. Тата ачык ишектән караса, өйдә ут шары тәгәрәп йөри. Әйе, бер ялгансыз, ут шары тәгәри. Ят карчык шул утка нидер сипкән иде, ут шары икеләтә зураеп дөрләргә кереште.

— Нәрсә ул, нәрсә? — дип кенә кычкыра алды Тата.

Карчык исә, һаман шашкан кеше кебек, телдән калган. Тата аяк астында утның күккә талпынуын, әгәр дә хәзер бер-бер хәл кылмасаң, бөтен өй эчен тутырачагын, өй белән бергә шашкан карчыкны һәм Татаның үзен дә күккә очырачагын чамалады. Ирек куярга ярамый. Шартлап үзе очса очар, әмма Тата күрәләтә күрше карчыкның колхоз салып биргән өен җилгә очырта алмас. Чөйдә нидер эленеп тора иде. Ут өстенә шуны япты да шарны алып чыгып та китте. Тфу, шайтан, пешерә, ялкын теле каплап бетерелмәгән төштән үрелеп кулны ялый, беләкне ялый, биткә-күзгә үрелә. Шулай да шайтанны чирәмгә чыгарып ыргытты Тата. Ят әби дә өйалдыннан чиләк белән нәрсәдер алып чыгып тагын ут өстенә сипкән иде, сибеп тә бетерде, шар тагын икеләтә кабарып, баягыдан да куәтлерәк дөрләргә тотынды һәм өстәге туңны да чолгап алды. Тата туңны алып читкә атарга мәҗбүр булды.

— Җен карчыгы, нәрсә сибәсең? — дип, бөтен көченә акырмый түзә алмады Тата ят карчыкка.

Акырды акыруын, тик күк гөмбәзе калтырамады, өй селкенмәде — ят әби хәтта кымшанмады да. Шуңа күрә Тата рәтләбрәк сорады:

— Нәрсә сиптең?

— Нәрсә дип, ни... су сиптем... су... суңми ходай кушмагач.

— Су! Су! Шулай дөрләп янамыни су!..

— Ходай кушкач яна икән бит, үзең күреп торасың лабаса.

— Ходай! Ходаеңны җен орган! — дип, үзе дә кефер сүз ычкындырганын сизми калды Тата.

Шул арада өйдән тәтен исе килгәндәй тоелгач, яңадан бар хәленчә ашыгып керсә, ут сәке йөзлеген ялмап маташа иде. Баягыча ук түгел, калдык ялкыннар гына, ләкин сүндермәсәң...

Фикерен очлап бетермәстән, Тата яңадан өйалдына чыкты. Теге әби «су» алган кисмәкне иснәп караса, аннан керосин аңкый. «Су кайда икән соң, су?» Бүтән кисмәк күренмәгәч, яңадан өйгә керде һәм мич янына, казан катына килде. Бәхеткә каршы, ярты казан чамасы су бар иде. Буш чиләк табып, шуңа су тутырды һәм ялкын өстенә койды. Ут җиңелмәслек түгел иде, ләкин ярты чиләк судан ук тончыкмады — тагын су сорый иде сәке. Ә су аз... инде чүмечләп кенә түгә Тата. Шулай да дөрләп яну кадәресе басылды, тик су да бетте. Тата тагын чөйгә үрелеп, андагы соңгы тунны тыш ягы белән сәкегә капланды һәм үзе дә капланды. Бераздан тагын торды. Торды да, сәкегә үк менеп, тунны таптарга керешге. Ниһаять, ялкын сүнеп, өйгә әллә нинди ямьсез көек исләре таралгач, тунны күтәреп караган иде, бөтенләй үк эштән чыкмаган — тишекләрен рәтләп ямасаң, тагын берничә дистә кышыңа җитәрлек әле.

Казандагы соңгы тамчылар идәндә һәм сәкедә калган соңгы кызыл тапларга җитте. Шуннан соң гына Тата сәкенең исән төшенә утырып сулу алды. Еш-еш алды сулышын. Болай да кысыла торган үпкәгә җитә калды. Һәм өй дә бик кысан кебек — чыдарлык та түгел иде. Көч-хәл белән стенага тотына-тотына (бая ничек кызу атлаган иде!) өйалдына, аннан күтәрмәгә үк чыгып, баскычка маэмай төсле башын салды. Ничә минутлап яткандыр, бераз хәл кергәндәй тоелгач, башын күтәрим дип тырышып ятканда гына, ах-ух килеп хөсетле карчык үзе кайтып керде:

— Ни булды, күрше, нәрсә бар?

Үз өендә ни булганын күршесеннән сорый торган карчыкка ни дисең инде? Шулай да башын күтәреп, әйбәтләп утырды Тата. Хөсетле карчык өйгә кереп чыккач, шуны гаҗәпсенеп тыңлады ир кеше:

— Менә сиңа... алланың бирмеш көне... Гает көнне китерде ходай үзенең казасын. Үзең дә күрдең ие бит, күрше, кыш бер сарыгым бәрәннән үлде, адәм баласын карагандай карап кеше иттем. Исән-сау үссәләр, корбан чалырга адарындым ие. Менә шуның берсен чалдык ие бүген. Үзем авылдашларны ашка чакырырга киттем ие. Әле сезгә дә кердем ие... Гает укытмакчы ием. Пешеренергә дип менә шушы кодагый карчыкны чакырдым ие. Корьән укыласы көн дип, иртүк торып кулдан килгәнчә пешерендек. Үзем ашка өндәргә киткәндә кунагыма, кеше килгәнче кайнап торсын дип, самавар кайнатырга куштым ие. Чәй эчәр вакыт җиткәч җылытып кына алырга булсын дидем ие.

Кунак карчыкның да энә очы хәтле дә гаебе юк икән:

— Самаварга мин ни, өйалдыннан алып су салдым да, учактан күп итеп алып кызу күмер тутырдым да шул, кеше-әхрәт килгәнче дип, тәһарәт алырга утырдым ие. Берзаман шартлаган тавышка сискәнеп карасам — самаварның эче-тышы гел ут. Яна, дөрләп яна. Өйалдыннан су алып сиптем ие, яңадан да котырыбрак яна башлады... Менә үземнең дә куркудан җаным шушында төште, шушында! — Кодагый карчык, җан төшкән җир дип, нигәдер телгә алырга ярамаган төшен күрсәтә — җаны шунда качкан, янәсе! — Менә, ходай әмер иткәч, дөрләпме дөрли салкын су!

— Кирәчинне судан аера белмәгән башка ходай ни кушмас! — Тата усаллыктан бигрәк, аңгыралыкка, көчсезлеккә үртәлә.— Су! Икегезгә бер баш бирмәгән, менә шул ходагызның хатасы!

— Сүзең хак, күрше, ярый әле, ул хатаны син төзәткән. Рәхмәт инде, мең рәхмәт.

Вакыйганың, әлбәттә, шушы төштә төгәлләнү җае бар иде, тик, әлеге дә баягы, кодагый карчык керосин сипте бит.— Ишегалды уртасында самавар өстендә җәелеп яткан тунны күтәреп караса, адәм көлкесе икән.

— Карале, кодагый, нинди хәлгә килгән бит, ә? Ничек моны тун дияргә телең барсын инде, ә?

Чебешләре тирәсендә әйләнгән тавык шикелле, хуҗабикә тун тирәсендә озак бөтерелмичә чарылдап җибәрмәс диген:

— Харап иткән, харап кына иткән! Мөхәммәтшәрифемнең бердәнбер хатирәсен корама иткән! Ансыз дөньяда ни калды инде, ни?

— Өең калды, өең, әзмени шул?!

— Өй калып ни файда, тун көеп өтәләнгәч. Мөхәммәтшәрифем...

— Пужарны сүндермәскә идеме, тун әрәм булмасын дип, ә? — дип алагаем җикеренде Тата.

— Пужарны ник сүндердең димим лә... Анысына рәхмәт укыдым бит инде, мин сиңа ник тунны яндырдың димен ләбаса. Шушы изге гает көнне...

Хатыннар фикер сөрешен Тата гомер буе аңламады. Бу елларда аңларга тырышканы да юк. Аларның мәгънәсез бәйләнүе — иркәлектән. Алар шул рәвештә ирләргә, ягъни көчле кешеләргә иркәләнәләр, көчсезләргә иркәләнмиләр. Ирләргә хатын-кыз иркәләнергә, алардан бер сәбәпсез дә гаеп табарга тиештер, күрәсең. Озак еллар бер көйләүчесе булмаса, хатын-кыз иркәлеге усаллыкка, үт әчелегенә әверелә... Нишләтәсең, ярый, ачы булса да рәхмәт үзенә — бер гаепсез килеш бәйләнә икән, димәк, әле Тата чынлап та көчле кеше булып кала. Көчлене күрәш көтә.

Тыныч нәтиҗә белән Тата урыныннан кузгалган иде, карчыклар баягыча ук сукрана-сукрана, аны ашка калырга үгетли, ялына, ялвара башладылар. Ризалашмады. Ходайга бернинди корбан бирергә нияте юк иде Татаның.

«Вакланды ходай, вакчылланды. Әлеге теге бозны әйт... Минем белән, күкрәген ютәл кыскан чирле кеше белән, көрәшер өчен җибәргән бит ул сап-салкын бозны, әлеге ятимәләр өстенә ут шары ташлаган шикелле. Әгәр мин туры килмәсәм, өйләрен күккә очырасы иде. Менә сиңа ходай. Ходай дигәнне хәзергеләр Табигать дип атый. Ярый, шулай да булсын. Табигать дигәне дә барыбер кешене сыный, юри сыный шикелле. Җанлымы, җансыз көчме — адәм баласы барыбер көрәшергә тиеш аның белән. Көрәшмәсәң, ут шары бөтен авылны чорнап аласы иде. Әгәр ваткалап ташламасаң, бакчадагы албасты авылны бозга катырып куя алмаса да, агач тамырларын җәй буе өшетеп торачак...

Уйлый китсәң, кешенең бөтен гомере, бөтен тарихы салкынлык белән көрәштән гыйбарәт!

Дөньялар!..

Кара син, кара, бая гына Тата карап узган җирләрне трактор изә ләбаса, трактор! Кай арада! Бәрәңге бакчаларын әйткән дә юк, элек өйләр, нигезләр торган изге җирләрне актара. Нәбиулла абзыйның да өй урынын айкап ташлаган. Урамнарга шаулап басу керә...

Адәм баласына җир җитми, җир, җир, җир! Патшалар күпме сугышкан шушы җир өчен, бер-берсеннән күпме җир талап алганнар — һаман җитмәгән. Яшел урам кечкә таба кара басуга әверелер. Биш-алты гына өй калган, алар да өметсез утраудай кысылган. Капкара бу буразналар, чиксез дәрья чак кына катырак дулкынланса, калган утрауны да юып алып китәр, күмәр шикелле. Бүген булмаса, иртәгә...

Ашыктылар, бик тә, бик тә ашыктырдылар. Зур авылга, рәхәткә күчсеннәр дип... Ә күчү дигән сүз Тата нәселенә мәңге ят, канда бер-

кайчан да булмаган ул. Шушы җир — безнең Ватан, без аны шушында тапкан, без аннан беркая күчмәгән, күчмәячәк тә. Үрмәкүчләр оя кора торган тыныч өебез — тыныч көнебез. Пәрәвезләр пәрдә булып безнең тынычлыгыбызны саклый. Безнең пәрәвезләрне тупас куллар белән умырып ташларга кемнең ояты җитәр? Рамазан энекәш, синеңме? Синең куллармы?

Әгәр күченә торган булсак, ерак һәселебез яшәгән төп өебезгә, Шелангага, нәселебез телендә тын сөйләшә торган Иделебез буена, элекке авылыбызга кайткан булыр идек. Анда яшьләр кайтса, сүзебез юк, әмма без фәлән гасырлык хатирәләребезне ташлап беркая да китә алмыйбыз — гореф-гадәтебез бүтән, һәркайсыбызның үз Җиһаны — аңа, аның хатирәсенә хыянәт итү — тәмуглык гөнаһ.

Үләмәнең арьягыннан пытырдап матай килеп чыкты. Яшел чирәм аша сузылган тар юлдан, күз иярмәслек дигәндәй тизлек белән авылның нәкъ уртасына — Тата өенә килде. Кызык, элек авыл башында булган өй хәзер үзәктә калды.

Тата үзенә күрә ашыгыч адымнар белән кайтты. Капка төбендәге яшел матайны сыйпагандай иткән иде, кулы тимер катылыгын ошатмады. «Без җигә торган атлар мең мәртәбә матуррак һәм мәхәббәтлерәк иде. Чаптарлар, юргалар, юртаклар. Кайда алар?»

Ишегалдыннан узышлый, тәрәзәдән аңа ниндидер ягымлы күзләр елмайды да тиз арада юкка чыкты. Ят кеше аны каршыларга ашыккан икән — өйалдында очраштылар.

— Исәнме, Тата абый! — Авазлары русчарак яңгырый.

— Исән әле, аллага шөкер.

— Бик яхшы. Вот сине күрасы килде.

Тата кунакны ятсынды, ләкин ул аның бөтенләй үк чит кеше түгеллеген дә чамалый иде.

— Сине кем дип белик соң?

— Может танырсын?

Өйгә уздылар. Егет Татага урындыкны өстәл янына, үзенә тәрәзә янынарак куйды. Утыргач, кабат сорады:

— Инде таныйсыңмы?

Егетнең чиста йөзен, хәйләкәррәк яшел күзләрен, сарылы-каралы галстугын, кара күн курткасын, куртка эченнән күренгән саргылт ак күлмәген — ыспай һәм таза килеш-килбәтен эчәсеннән җебенә кадәр дигәндәй тикшереп чыккач, Тата аны, әлбәттә, таныды һәм телсез калгандай булды. Йөзе җитдиләнде. Егетнең дә каушавын чамалагач, аның ни уйлавын белмичә, нияте усаллыкта түгеллегенә ышана алмыйча, урыннан торды.

— Әниеңне таптырырга килсәң, ялгышасың. Ул минем кесәмдә түгел.

— Ни сиписен, Тата абый?!

— Син — Петруха малае! Шулай булгач...

Тата тагын урыныннан торды, мөмкин кадәр җәһәт булырга тырышып, ишек башы өстендәге бүрәнә ярыгына үрелде һәм аннан саргаеп беткән хат чыгарды.

— Синеке бу хат. Мә, мә!..

Егет теләр-теләмәс кенә хатны алды да, нишләргә икәнен бик тиз хәл кылып, ертып ташлады. Ләкин, идәнне чүпләргә ярамаганын хәтерләп, яңадан җыеп алды.

— Синең хат.

— Шунга күрә ертырга правам бар.

— Әниеңне таптырырга килгән булсаң...— Гомер буе диярлек күңелдә йөргән каты һәм салкын сүз ниндер кинәт эреп юкка чыкты. Сәбәп — егетнең күз карашы. Усал сүзнең әйтелмәскә тиешлеген, гөнаһлы баланың гаебе өчен олы кешедән җавап алынмаска тиешле-

ген әллә нинди рәнҗү һәм курку белән аңлатырга тырыша иде бу күзләр. Тата, бер секундта коточкыч ялгышлык эшли язуын сизеп, яңадан урынына килде һәм, рәтлерәген таба алмыйча, мәгънәсез сыман тоелган сүзләр пышылдады, ләкин искиткеч зур мәгънәле иде ул сүзләр.

— Син үч алырга кайтмадыңмыни?

— Рахмат әйтергә кайттым.

— Мин сине бик озак көттем.

— Прости. Ани булмагач, кайтылмады.

Барысы да аңлашылды, күпме еллар җилкәдә йөргән авыр йөк төште һәм сүз дә бетте шикелле. Күпмедер шулай утыргач, ярый әле, егет үзе башлады:

— Тата абый, хатирлисен, син минга төлкы бирден, а? — Татарчасын егет шактый оныткан икән, Тата моны шушында гына абайлады.

— Хәтерләмәскә. Хәтерлим.

— Мин синга рәхмәт әйтәм лисица ычен да. Мин малай чакта не догадался, извини.

— Онытмаган өчен үзеңә рәхмәт.— Һәм бераз гына йөткереп алгач, гомер буе дигәндәй йончыткан икенче соравын бирергә ашыкты.— Төлкене син тере килеш алып киткән идең. Син аны нишләттең? Аттыңмы, кыйнап үтердеңме?

— Что син, Тата абый, что син!

— Чуже, нишләттең? Ничек үтердең?

— Үтермәдем, не смог.

— Тырышып карадың?

— Тырышып та карамадым. Җибардем, потому что ул ашамады. Улмасен ычен җибардем.

— Чынлапмы?

— Вот син, Тата абый, чынлап, валлаһи.

Шуннан соң инде Тата абыйсының да чырае чынлап яктырып китте һәм ул кунагына елмаеп ук эндәште:

— Рәхмәт, балам, югыйсә, гомер буе шуны беләсем килеп интектем ие.— Шуннан соң егетнең язмышын сорашырга кереште.

Егетне төрмәдә озак тотмаганнар, яңадан ФЗУга җибәргәннәр икән.

— Анда уж добровольно киттем.

— Хәзер кайда, ничек яшәү?

— Севастопольне төзедек. Инде семья, бала-чага. Сине күрергә кайттым и авылны.

— Авылыгыз инде юк шул, безнеке дә.

— Да, печально.

— Яшәргә кирәк, пичәлдән файда юк.

— Дөрес.

Кояш апаның яңарткан чәе кабат өлгергәч, кунак алып килгән кала сые белән тәмләп чәй эчтеләр. Тата бакчага яман ният белән килеп чыккан зәхмәтле боз хакында, экертен-экертен аны җиңә баруы хакында сөйләгәч, егет кайнарланып:

— Әйдә, мин аны бик тиз юк итәм,— дигән иде, Тата абыйсы, билгеле, риза булмады.

— Яхшы сүзеңә рәхмәт. Үзеңә атап килгән язмышны бүтәнгә калдырып та булмый, калдырырга тырышу вөҗданга хилафлы көчсезлек, җинаятькә тоташа,— диде ул нәтиҗә ясап.

— Простой тоелсаң да, бик гордый син,— дип елмайды кунагы.

Хушлаштылар. Егет әле киткәнче тагын килеп чыгарга вәгъдә бирде. Ял вакытын Варварино авылында, туганнарында уздыра икән. Хатыны һәм балалары белән кайтканнар.

Ай бу дөньялар!..

*
* *

Петруха малае авылын, әнисен, туган җирен, ихтимал, инде мәңгелеккә югалткандыр. Ни өчен бу хәтле каты җәза? Артык яратканга күрә. Артык та нык яратырга ярамый, аны җиңә дә белергә кирәк. Мәхәббәт белән җинаять тә юлдаш була ала... Авылдан китмичә, тарих хәрәкәтенә иярмичә, Тата үзе дә хәзер җинаять кылмыймы? — Күпме генә баш авырттырып уйласа да, җавап табылмый.

Әйе, яратуны җиңә ала торган тәвәккәллек Көчле дигән кешегә җитми һәм җитмәде: бакчадагы сөекле өянкесен ул кисә алмады һәм... бөтенесе шуннан башланды.

...Кәйләсен алып Тата боз янына килсә, албасты, ничектер, уфылдап куйган кебек тоелды. Әллә гомер буе, әллә көн саен әкренләп вата торгач, инде яртысы гына калган. Ләкин һаман горур утыра бәдбәхет, бакча өстенә салкын афәтен өрә, сулышы кырау чакыра кебек дошманның.

Эшкә керешкәнче, кеше яшел чирәмгә ятып бераз сулу алды. Сулу алып утырганда, өянке гадәти җуылдавын яңартты. Ерак еллар хакында шушы хәтле ямансу итеп башка берни, беркем дә сөйли алмый. Ата-ана тавышын, аларның мәңгелек моңнарын шушы хәтле дә җилкендергеч итеп берни, беркем көйли алмый. Ничек итеп кисәсең ди аны?

Җил уңаенда үзенең бозлы сулышын өреп, албасты Көчле кешене калтырата алды. Кеше гарьләнүдән кәйләсенә тотынды да көндәгечә дошманы каршына килеп басты, көндәгечә кирза итеге белән бозның челтәрләнгән почмакларына типкәләде. Кояш караган яктан, челтерәп боз кисәкләре коелгач, кешенең чырае тагын яктыра төште: «Болай бер көе эш әйбәт бара безнең, һич тә күңел суынырлык түгел, Кояш белән икәүләп, без бу галәм җибәргән мәңгелек салкынлыкны әлбәттә җиңәчәкбез!»

Тагын эшкә тотынды — кәйлә батып ук кермәсә дә бозны вак-вак кимерә, бозны «чорт, чорт» дип мыскыллап тетә. Тетелгәннәре белән нишләргә кирәген кояш шәп белә — аларны күз яшьләре рәвешендәге тамчыларга әйләндереп, җир чиксезлегенә, мәңгелек хәрәкәткә кушаозата тора, аксыл пар итеп күккә очыра. Ул парлар ак матурлыкка, болытка, яңгырга, шифага әйләнеп, шушы ук бакчага, алмагач чәчәкләренә, игеннәргә, урманнарга яшәү көче булып сибеләчәк. Әллә бүген шулай, әллә мәңге...

Кеше белән көрәшү албастыга җиңел түгел — өстеннән кара тир, юеш пычрак ага бәдбәхетнең. Тата маңгаеннан да бөрчек-бөрчек тамчылар тәгәрәп төшә. Шулай да анысы артык борчымый, тын кысылу борчый. Дөнья иркенлегеннән тагын мәгънә азая, һаман кечерәк Галәм мәгънәсе...

— Чорт, чорт, чорт! — дип тәкрарлый Тата сөекле дусы кәйлә белән бергә.— Суык шайтан, бетәсең барыбер.

Ачыкланды шушы мәлдә: боз тавы чынлап та кечерәя, ләкин салкынлыгы Татаның күкрәгенә тула бара. Күкрәгенә генә түгел, аркасына да күчә. Бу ике-өч көндә аркада салкынлык, чамадан тыш күп җыелу сәбәпле, хәлне бермә-бер киметергә кереште.

— Чорт, әшәке чорт!

Нигәдер, тезләр калтырый. Арка котып бозы шикелле туңып ката, күкрәк өшүдән ашып яна. Адәм тагын утырып ял итәргә мәҗбүр.

Тау ягының Атабай, Җәмәки тирәсендә, нишләптер, бакча үстерергә халык бик үк маһир түгел. Бәгъзеләр өй артына агач тертергә дә ирена. Адәм көлкесе. Андыйлар тамырында күчмәләр каны тәки ага торгандыр, бу якка соңрак килгәнгә, нәсел-нәсәпләренең тирмәләрдә

озаграк яшәгән булуы бик ихтимал. Тата үзен андый ыругларга кертми. Нигә дисәң, галим булып җиткән кызлары да шул фикерне куәтли. Татаның төрекләрдән килмәгән чаты — мәңге-бакый дигәндәй, шушы җирнең төп халкы. Алар дөньяда еллар санын исәпли башлаганчы ук монда яшәгәннәр. Акыл белән генә түгел, Тата моны хисләре, гадәтләре буенча да белә. Аның өен һәр вакыт яшеллек, агачлар күмгән булыр. Гәрчә бәгъзеләр: «Өй тирәсенә чыршы-нарат утыртсаң, йорт башлыгы башына була ул», дисәләр дә, нарат-чыршы утыртудан да курыкмас. Күчмәлек ырымы дип саный моны Тата. Тата — чын бакчачы. Әгәренки боз зәхмәтен юкка чыгара алса, матур-матур алмалар, грушалар, кара җимеш, карлыганнар гөрләп үсәр иде — алар да тоя дөнья рәхәтен, алар да җанлы. Аларны да рәнҗетергә ярамый. Өянкене дә. Кисәм дип ничә тапкыр пычкы-балта күтәреп килсә дә, кулы бармады, ничәмә кат иптәшләрен чакырды — ялварып кире җибәрде. Кайчакта, духтырлар шикелле, авыртудан курыкмаска, кызгануны олы миһербан белән бутамаска кирәк, диючеләр булды. Юк, кисә алмады Тата һәм сөекле өянкеләр боз албастыга бакчага ыргылырга, басып керергә ике кабат инде ярдәм иттеләр, хуҗага хыянәт иттеләр. Тәмте больницасында да хатынының аһ оруыннан каушамаса, артык та нык кызганмаса, ихтимал, духтырлар аны терелтә алган да булырлар иде.

Әнә чак кына ирлекле сыйфат күрсәткәч, Петруха малаен коткара алган булып чыкты һәм рәхмәт ишетте. Ә сөекле Җиһан рәхмәт әйтмәячәк.

Үзенең булган һәм булмаган барлык хаталарын, үч һәм үҗәтлекләрен кәйләгә туплап, бозны тагын ах-ух килеп кыйратырга керешге: «Чылдырт, чылдырт, чылдырт...»

— Уфф...

Ютәл буганлыктан, чирәмгә таянды. Ким дигәндә ярты сәгать йөткергәндер. Бөтен тәне калтыраганны тоеп, кәйләсен ташлады да куышка барып сөялде. Яңа һөҗүм өчен күкрәгенә әллә хәл, әллә һава җыярга азапланды.

Дөресен әйткәндә, тау хәзер тау да түгел инде, ул әйбәт чүмәлә хәтле генә калды. Ләкин салкынны исән чагындагыдан бер дә ким өрми торгандыр, чөнки Көчле кешенең сулышы тәмам кыскарды, тимер бармаклар кысудан азып, тарткалый, селки үк башлады. Калтырау дигәне шулайга әйләнде. Болай барса... Юк, Тата кеше бер-ике минут кына ял итәчәк тә... Аннары — соңгы талпыныш!

Бөтен яну-туңуларын тыеп, Тата тыныч утыра. Күзләре — кара пычрагы эреп ага торган тауда... Тфу, егылып үлгере, тагын ялгыш уй керде — зәхмәте бетеп җитмәгән чүмәләдә. Хәзер аны карашы белән дә эретә бугай Көчле кеше — әкренләп-әкренләп тамчылар тәгәриләр. Билгеле, Кояш ярдәме белән. Кояш кебек эшлекле ярдәмчесе булган кешене кем җиңә алсын? Үзе исәндә боз тавын... боз чүмәләне мескен күлдәвеккә әверелдереп ташлаячак ул. Тик менә вакыт аз кала шикелле тоела, ашыга төшү зыян итмәс кебек. Ә чүмәлә артында Җиһан ышыкланган, чүмәләне айкап аткач, Җиһан килеп чыгачак.

«Җаен балыгы үрдәкне йоткандай, минем Җиһанымны талап алган җинаятьче синме? Менә җәзаңны алдың инде...» Тамчылар кечкенә гөрләвеккә әверелә, Тата ваткан бозлар Үләмә дулкыннарына кушыла.

— Җиһан хакы, аның үче...

Татаның бу хисенә каршы килүчеләр элегрәк тә булмады түгел, булды. Берише адәмнәр: «Яз айларында, бозлар актарылганда, үпкәсе авырткан кеше күпчелек очракта зәхмәтле тау килмәсә дә агып китә, имеш», дигәләсә дә, бу сүзләр белән Тата килешмәде һәм килешмәс.

Татын шундый да тозсыз сүзләр ишеткәләде Тата: өянке һәм язгы су куәте бакчага аткан боз тауларының саны ике генә түгел, ә бәлки күбрәк имештер дә, бүтәннәрен Тата оныткан, янәсе. Боз тукталган

кайбер елларда, имештер, хәтта ки бәхет килгән чаклар булган. Ә бәхетләр онытыла... Шундый бер елны олы малае сугыштан исән-сау кайтып төшкән. Күптән түгел Кырлы курае үзеннән дә гыйлемлерәк бер егетне кияве итеп кунакка алып кайткан да җыйнаулашып, өй сырасы коеп бәйрәм иткәннәр.

Тата бәхәсләшми, дөрес, аның озын гомер юлында зәңгәр һәм ал бәхетләр күп тезелеп калдылар. Әмма боз албастының монда һич катнашы юк. Андый бәхетле елларда тукталмады боз тавы.

Боз өстеннән аккан тамчылар белән бергә йөгереп торган фикерләре кинәт тукталды, һәм Тата үзе дә янә бөгелеп төште, пычракка ялгыш таяну аркасында таеп китте дә җиргә ауды. Боз зәхмәте, ютәл өянәге бу юлы бугаздан ук буа икән. Күңел болгана, баш әйләнә. Ояты — бетеп барган чагында булса да боз янында егылуы... Татаның хәлдән таюын тәки белеп, сизеп бетә бит дошман!

Ютәл белән якалаша торгач, Көчле кешебез әллә инде елап җибәргән, әллә күзләренә боз суы чәчрәгән — тамчылар, тамчылар тәгәриләр, әйтерсең ки — фикерләр...

Көчле кеше бераз гына шуышып чирәмгә утыргач, бозга караган иде, ни күрсен: салкынлык Көчле кешенең нәкъ үзе шикелле яшь коя лабаса! Ул инде һич албасты да, чүмәлә дә түгел, ә мескен җицелүче. Хәлсезлек җәһәтеннән Тата тесле. Әйтерсең ки Татаның теге дөньядан килгән шәүләсе! Бер җанның ике кыяфәт белән яшәвен Табигать тә, тормыш та хуп күрми. Имеш, икенең бары тик берсе яшәргә хаклы — мәҗбүри рәвештә алар бер-берсен юк итәргә тырыша һәм, берсе һәлакәткә дучар булмыйча, канлы көрәш тукталмый. Дөрестер дә. Әнә боз гәүдә селкенеп куйды, тешләрен ыржайтты сыман, тик Тата өстенә ыргылырга... өлгерә алмады, бу дөнья кешесе үзенең кара һәм боз рәвешендәге ямьсез карачкысына аннан да элегрәк ташланды. Соңгы кисәккә кәйлә белән бәрде...

...Әйе, каһәрле боз инде юк. Ләкин ул изеп чәрдәкләгән алмагач та турая, тора алмаячак. Алмагач пычрак йомычкаларга, чыбык-чабыкка әйләнгән...

Әллә көрәш шулай максатсыз, мәгънәсез булып чыктымы?

Кояш ярдәмендә ирешелгән бу беренче җиңүдән соң, икенчесе алдыннан иркенләп хәл алырга кирәк икән. Бакча ышыгында һава җитми, тын буыла, тизрәк, мөмкин кадәр тизрәк сахра, кыр чиксезлегенә чыгарга, үпкәләрне киереп бер суларга кирәк! Монда калу мөмкин түгел, кысыла, бигрәк тә каты кысыла күкрәк. Әх, каһәр төшкән тимер бармаклар! Бер генә мизгелгә ычкындырсалар! Аһ, аркада җыйналган салкынлык! Калды? Боз тавы җимерелгәч тә калдымыни? Зәһәр салкынлык? Салкынлык тезләрне калтырата, каяндыр бозлыкарлы тавыш үкерә: «Боз тавының бөтен салкынлыгы синә күчте, үзеңә күчте! Кагылмаска кирәк иде, ялгыштың, адәм, ялгыштың!»

Ләкин Көчле кешенең иманы кара сүзләрдән инде каушамаячак. Ялгышмады бәндәгез, иң дөресен — вөҗданы кушканны эшләде.

Ләкин тын бетүе бер дә шәп түгел. Тизрәк яланга, кырга чыгарга кирәк — җил тулсын күкрәккә.

Бөкрәеп, кәйләсенә таяна-таяна гына булса да, Тата Үләмә ярына таба атлады. Узышлый өянкесен кочаклап бераз ял итте. Яфракларның ниндидер сер әйтергә теләвен аңлап, таепле, ләкин һаман да сөеклә кәүсәне сыйпаганда күңеле тулыпмы, күзләреннән тагын яшь коелды. Шулардан оялгандай, хисләрдән качкандай, булдыра алган дәрәҗәдә тиз атлап, җиңү шатлыгыннан, әйе, авырудан түгел, шәрабтан исергәндәй чайкала-чайкала булса да, инеш аркылы исән генә чыга алды һәм каршы як ярга капланды. Ике-өч адым узса — анда инде басу, кыр, җил...

ӘХСӘН БАЯНОВ ◆ ТӨЛКЕ ТОТУ КЫЕН ТҮГЕЛ

*
* *

Көчле кеше җил белән кочаклашачак.

Җил, җил, җил!..

Моңарчы ничек аңлашылмыйча йөрелде икән — дөньяда җил иң олы бәхет лабаса. Күкрәгенә җил тутыра алу — шундый бер минут мәңгелекне алмаштыра торган гаҗәеп бер җиңеллек икән бит. Тата шул бәхетенә таба китте һәм... кавыштым дигәндә, кинәт һушын җуя, егыла язды. Артык та нык сөенүдәнме, әллә җилгә артык та нык сусаганлыктан комсызрак кыландымы, һава дулкыны авыз-борынга, күкрәккә кермичә генә булыктырды. Ярый әле, читкә борыла алды. Мәгәр хәл бермә-бер кимеде һәм ул яр буеннан әллә ни ары китә алмады. Монда Тата теләгән үк иркенлек түгел, монда, ни дисәң дә, кыр түгел әле. Тата кыр чиксезлегенә чыгарга тиеш. Эше төгәлләнгән кешедәй ялкауланып ятарга тиеш түгел. Һәм ул торып басмакчы иде, гәүдәсе нишләптер күтәрелмәде. Шулай да беренче уңышка иреште — тезләнә алды. Бу инде аз да түгел — тезләре белән атлады. Тик әллә нигә таянырга мәҗбүр булды да дүрт аяклап китте һәм алай да күпсенде язмыш — кеше җиргә капланды. Ул хәл җитмәүдән бигрәк ояттан, үзенең бүре бабалары кыяфәтенә кайтуыннан гарьләнде. Терсәкләре, иякләре, тезләре белән җирне тырный-тырный шуышырга кереште. Болай җайлырак, кулга былтыргы камыл һәм корган әрем кадалмаудан бигрәк, гарьлеге кимрәк.

Тата, еллар буе төпченеп, кушаматының мәгънәсенә тәмам төшенде һәм Тата булуына күнегүдән, ахрысы, үз исемен бөтенләй онытты диярлек. «Кеше» борынгы телдә — «ар». Нишләптер кайберәүләрнең ар дигәннән хәтерләре кала. Нишләптер, Татага да авылдашларының «Тата ар», яисә бер хәрефне йотып «татар» дигәннәренә караганда, «Тата кеше», «Тата абый» дигәннәре күркәмрәк яңгырый. Ни өчен шулай икән? Югыйсә, мәгънә барыбер үзгәрми, мәгънә барыбер матур лабаса, ә?

Күпме шуышкандыр, Көчле кеше үзенең җилкәсенә җил кагылганны сизде. Җирдә аунамаска, күтәрелергә куша җил. Җил, җил, җил! Бер генә йотым, күп түгел, бер генә йотым җил кирәк Татага. Бер йотым! Һай, нинди бәхет ул — бер йотым җил! Белмибез икән лә кадерен аның! Җил!..

Бер мизгелдә кеше коры җиргә чыгарып ташланган балыкның ничек сулыш алырга тырышып чәбәләнүен бөтен әчелеге белән аңлады. Бу мизгелдә Көчле кеше нәкъ шул балыктай иреннәрен кыймылдатты, башын сузды, нидер йотты, ләкин җилне йота алмады, булыкты һәм тагын җиргә капланды. Ләкин җиргә капланган хәлдә дә, сулыш алмаган килеш тә тагын бар көченә алга, алга талпынды — шушы секунд эчендә кырга чыгып җитәргә, тизрәк, тизрәк, югыйсә... һәм... тагын җиңү — ул үзенең җилкәсендә, хәтта бөтен аркасында җилнең яңача, ялангагыча, яшь хисләрдәй көчле тибергәнүен сизде. Чыкты, чыгып җитте Көчле кеше кырга, чыгып җитте кыр дигән чиксезлеккә! «Ана карынында бала шушы җил шикелле тиберчәнә торгандыр»,— дип уйлады Тата. Фикер бар җирдә яшәү бар.

Тата кайчандыр, ерак елларда кар суларын инешкә агызмас өчен өелгән, инде авыру, яки карт адәм төсле таушалган, тәбәнәкләнгән дамбага башын куйды. Максатка ирешкәч, бераз ял итү гөнаһ түгел ул... Дамба — йомшак мендәр. Моннан да шәп мендәрнең булганы юктыр гомер. Бигрәк тә ир кеше өчен.

Тата йөзтүбән яткан хәлдә җир дымын эчте. Җир дымы белән тәнгә әзрәк дәрман да керде шикелле — йөткерү өянәге биш минут чамасы гына интектерде. Ләкин күкрәк җир белән тоташып катмасын

дип, чалкан әйләнде Тата. Чалкан әйләнгәч тә күккә бакты һәм... Күк йөзе! Менә ул нинди! Күптән, бик тә, бик тә күптән инде, Татаның болай чалкан ятып күккә караганы булмаган икән. Дөнья мәшәкате артыннан чаба-чаба, гүзәллеккә, биеклеккә карарга вакыт тапмаган җир кешесе.

Югарыда, адәм хыялыдай биектә — җилкендергеч зәңгәр иркенлек. Җем-җем, җем-җем итә. Җиһан күзләрендәге зәңгәр ялкыннар! Менә каян төшкән икән алар! Бүген үлсә, шуны белми үләсе булган икән! Күк җилкенү... Ир кеше, салкын кодрәтне җиңмәсә, мәңге күрмәгән булыр иде аны! Бәлки моңарчы Җиһан күзләре сүнгәнгә күрә тоныкбулгандыр... Гөмбәз соңгы елларда алтынсу, чия-көрәнрәк төскә кергән иде. Чынлап. Ә бүген сабый чактагыча, яшьлек елларындагыча, Җиһан белән бергә яшәгән чактагыча ачык зәңгәр терелек сирпи күк йөзе. Узган еллар әйтерсең яңадан кайтты. Истәлекләр тургай шикелле, җанлы кыңгырау шикелле чыңлый башлады киң, чиксез дөньяда! Тәндәге сырхау да бер минутта каядыр китеп югалды. Тата рәхәт җиңеллектән нәкъ бала чактагыча йөгереп каядыр еракка, бик тә, бик тә еракларга китмәкче булып, күзләре башка матурлыкка төште. Күкләр генә түгел, басулар, таулар да яңача балкый. Күптән онытылган сөенечләр, әткәй-әнкәй белән бергә яшәгән еллар, аннары Җиһан хакында уйлап талпынган хисләр, бәхетләр якында гына бал кортлары төсле, күбәләкләр төсле җилпенә! Әйе, Тата үзендә гаҗәеп үзгәреш сизә: аның хисләре әкрен-әкрен дөнья күренешләренә әверелә бара икән!

Миһербанлы көчне мактап, тургайга — көмеш кыңгырауга әйләнгән дә, Кояш белән бергәләп башкарылган олы хезмәт нәтиҗәсе, көчсезлекне җиңү шатлыгы канат кага. Аның йөрәк тавышы кырларга, бакчаларга булачак уңышлар, моңарчы күрелмәгән байлыклар төсе сыман ява. Кырлар, бакчалар үзләре дә Татаның күңел иркенлегенә кушылган. Инешләр өстенә, ераклардагы таулар өстенә ап-ак чәчәкләр төсле булып ул кичергән еллар ява.

Еллар кешене генә түгел, тауларны да үзгәртте. Малай чакларда чаңгы белән, чана белән бу таулардан очып төшкәндә, җил сызгыруыннан күкрәк турысында ниндидер нечкә бер җеп өзелгәндәй була да күзләрдән яшь килә һәм мәтәлеп очасың гына... Мәтәлмәсәң дә очасың — авырлык җуеп, нәкъ хәзергечә... Тау шуган кешеләр — авылның иң кыю егетләре. Тата гомер буе шундый башсыз кешеләрнең берсе булды. Биеклектән курка белмәү сәерлеге бар иде аңарда. Кош кебек очам дип, бәләкәй чакта кулларына фанер такта бәйләп, өй түбәсеннән сикергән һәм хур булган малай хәзер әнә теләгенә ирешә — күңеленең бер почмагы тау өсләрендә кошлардай, бөркетләрдәй җилпенә.

Еллар тауларны кечерәйтте. Тауларның элекке биеклеген күрсәтә торган җайсыз хәлләрнең сан-исәбе юк иде. Тау төшкәндә арбаларның тәгәрмәчләрен бәйлисең. Югыйсә, хуш, җаным, бәхил бул. Менгән чакта шартлап өзелгән камыт баулары, хәлдән таеп егылган атлар һәм Татаның сулыш ала алмыйча, тимер куллар белән көрәшүен, үз тәненнән ычкынырга тырышып үрсәләнүен киләчәктән хәбәр иткән газаплары... инде онытылдылар. Хәзер җиңел, хәзер таудан атларны чаптырып кына төшерәләр, менгәндә дә шома гына узалар. Түбәнәйде таулар, кечерәйде. Тата да шактый чүкте. Ләкин фикерләре...

Тау булып тау картайгач, адәм баласы нишләп картаймасын. Ләкин Көчле кеше... аның фикерләре яшь чактагыча саф һәм мәһабәт. Ул үзенең матур, көчле чагына яңадан кайтты һәм, сөекле таулар, кинәт сез дә яңадан зурайдыгыз. Фикерләр — таулар... Кеше сезне аркагыздан сыйпау нияте белән аягүрә басты һәм... шунда кинәт әллә нәрсә булды — таныш җиңеллек белән ул җиргә ауды.

Бу халәтнең нәрсә икәнен, җегәренең кинәт кенә ник бетүен әйтү мөмкин түгел иде. Кеше яңадан тормакчы, таулары белән кочаклашмакчы иде, ни сәбәптәндер, тора алмады. Дамба өстенә чалкан ятты. Караса, әле кайчан гына зәңгәрләнеп янган күк йөзе — кап-кара! Ә таулар бөтенләй юкка чыккан. Ләкин гәүдә барыбер җиңел, күкрәктәге тимер кул инде кысмый, күкрәк кайнарлыгы тимер кулларны эреткән һәм аның белән бергә, тәнне калдырып, чир дә теге дөньяга очкан. Эсселек үзе калган — яна күкрәк, яна. Димәк, әле кешенең тәне дә исән. Нигә дисәң, җылылык көче тәндә генә яши ала бит. Шулай ук салкынлык та. Шунысы гына гаҗәп, нишләп әле эссесе-салкыны бер үк тәндә яши? Кайнарлык — күкрәктә, суыклык — аркада... Һәм авырлык...

Тата капланып ятты. Әйтерсең бая үзе җимергән боз тавы аның аркасына килеп өелде. Кояш, бу юлы да адәмгә Кояш ярдәм итәргә тиеш. Кеше аркасын кояшка, күкрәген җиргә куйган. Ләкин күпме ятса да, бу юлы Кояш аңа ярдәм итә алмады. Кояш кинәт каралып калган күк йөзенең үзеннән дә кара. Әллә аңа бер-бер хәл булдымы? Бәлки аңа хәзер кеше ярдәмгә ашыгырга тиеш? Кояш һәлак булмасын өчен, кеше күзләрен нык ачарга тиеш, акыллы күзләр караса, дөнья яктырыр. Әйе, шулай... Әмма күзләр ачылдымы, юкмы — аны да тоеп булмый икән. Моның белән килешү мөмкин түгел, кеше күзләрне ачу кебек олы батырлыкны да эшләргә тиеш. Йомылган хәлдә дә күзләр күрергә тиеш һәм алар әкрен-әкрен нәрсәләрнедер шәйли дә башлады. Кара канатлар җилпенә һәм колакка ниндидер тавышлар ишетелә:

— Коң, коң, коң...

Әкренләп дөнья яктыра, киңәя башлады, ерактан таулар күренде, фикерләр... һәм кеше хисләре тагын үзгәрешләр кичерә инде — тере әйберләргә әверелеп китә.

Әнә якыннан гына кызыл төлке йөгереп узды, кып-кызыл төлке. Ниятең явыз булса, мылтык төзә, эт өстер. Бөтен гомерегездә күп дигәндә бер-ике тавык-казыгызны урлаган өчен, саранлашып, нинди матурлыктан колак кагуыгыз ихтимал! Басуда курыкмыйча койрыгын сузып йөгереп йөргән кызыл җәнлекне бер генә күрү дә гомерлек бәхеткә охшаш лабаса!

Төлке артыннан көлә-көлә Петруха малае чаба. Петруха малае көлә-көлә, йөгерә-йөгерә Тата абыйсы янына килә:

— Рәхмәт сиңа күңелдәге усал ерткычны алмаштыра торган матурлык өчен. Шаян төлке өчен рәхмәт!..

Петруха малае гына түгел, Җиһан да килгән. Елмая сөекле күзләр. Аның белән бергә шук оның килгән:

— Дәү эти, дәү эти, кайда ул безнең ат? — Нинди саф тавыш!

Дәү этисенең күңелендә, кем әйткәндәй, иярле атлар да ята. Дәү этисе күңеленнән әнә берсе чабып та чыкты. Оныгы аңа тиз генә атланды да тургайлар якты көй чәчкән язгы кырлар буйлап чабып китте — тояк тавышлары... Инде тояк тавышлары ерактан, бик тә, бик тә ерактан ишетелә. Тояк тавышлары ишетелмәгән кыр — тол хатын. Ә Тата күңеленнән яралган кырлар — бәхетле! Бәхетле кырлардан төпчек кызы, Кырлы курае килеп чыга:

— Әти, күпме аучы булдың, бер төлке яка да бүләк итә алмадың.— Шаярта гына, чынлап әйтә алмый ул аны.

Ә этисе ихлас:

— Кичер, кызым, андый эшне киләчәктә дә эшли алмам, ахрысы. Ә син елыйсың. Ник елыйсың әле син? Үпкәләдеңме? Син генә түгел, абыйларың, апаларың да монда икән. Алар да яшь коя. Ник? Әтиегез

сезгә кара боз калдырмады. Бәлки бүтән чакларда борчуларыгызга, кайгыларыгызга да сәбәпче булгандыр. Ләкин ул үзенә тиешле салкынлыкны сезгә калдырмады — ничек итсә итте... Ә шулай булгач, нигә сез әле елыйсыз? Мин сезне түгел, җәнлекләрне дә рәнҗетмәдем.

Шул сүзгә протест шикелле, Тата кеше каршына, тешләрен яман да шакылдатып, бүре килеп басты. Бүре? Ә! Сине рәнҗеттем шул. Нигә дисәң, син безгә зыян китердең — үлемебезгә хезмәт иттең...

— Синең ыруг башың мин идем. Син мине түгел... авылыңны корыттың, нәселеңне.

— Кеше күңелендә борыннан килә торган ерткычлыкны, үз күңелемә хәтле килеп җиткән усаллыкны үтердем.

— Үз тәнеңне дә юкка чыгардың, минем белән бергә. Үлдең.

— Юк, үзгәрдем генә!

Җавап эзләп таба алмыйча, бүре баскан җирендә юк булды. Ә балалар калды. Ләкин алар елыйлар.

— Балалар, нигә елыйсыз? Мин сезнең яныгызда мәңгелеккә калдым!

Балалар, ахрысы, шатлыктан елыйлар.

Якында гына Үләмә чылтырый. Үләмә буеннан Җиһан елмаеп уза. Әй, Җиһан! Адымнарың шундый җиңел, шундый матур! Менә ни өчен дөньядан яшьләй китеп баргансың икән — мәңге яшь, мәңге чибәр булып калыр өчен!

Тата үзендә тагын яңа үзгәреш һәм яңарышлар сизә башлады: күңелендәге нindидер тойгылар кызыллы-сарылы канатлар булып укмаша шикелле. Пар канатлар икенче мизгелдә — канатлы кош. Сөекле кош!

Сөекле кош читән башына очып менә дә канатларын шапылдата. Канатларын шапылдатып алгач, мәңгелеккә калган канлы кылычны җанлы кикриккә алмаштырып, башын Кояшка таба суза:

— Ки-ке-ри-кү-үк!..

Әтәчләр, тавыклар, мәңге чыр-чу киләчәк кошлар — Көчле кеше күңелендәге тере мәгънәләр. Тойгылар күңелдә чиксез — барысы да үсә, үсә һәм үзгәрә бара. Тойгылар дөньяның чиксез күп төрле рәвешләренә әйләнә. Җир өстен шулар бизәгән: бакчада алмагачлар, кырда сабакларын сузган игеннәр, урманнар, елгалар, таулар. Болай булгач, Көчле кеше шушы дөньяның үзенә әверелеп шаулап кала түгелме соң?

Көчле кеше күңеле — дөньяның үзе.

Көчле кеше Җиһанга сүз куша:

— Әйдә, киттек, мәңгелек буйлап сәяхәткә! Дөнья — үлемсез, ул барлык башка минутлардан матуррак, мәгънәлерәк. Нигә дисәң, анда син бар, яшьлек бар!

Җиһан елмая. Җиһан сөекле кешесенең битләренә үзенең пешкән алмадай татлы битләрен куя, кочаклый. Онытыла язган йомшак куллары белән Көчле кешенең күзләрен сыйпый. Әллә... Әллә күзләрен йомдыра инде?

Кош канатыдай җиңел һәм йомшак куллар кагылудан, ничектер, салкынлык та, җылылык та көчен җуя. Канат-куллардан да җиңелрәк сүзләр әйтә Җиһан:

— Мин инде бер дә аерылмаска килдем. Син ризамы шуңа?

Җиһан сүзләрен җөпләр өчен Көчле кеше баш кага. Ризалашып баш кагуы соң мәртәбәме?

Ышанмагыз.

*
* *

Кешенең төсе киеменә дә күчә. Бигрәк тә баш киеменә. Аңа иясенең күз карашы, килеш-килбәте, хәтта хәрәкәт-гадәтләре йогып кала. Вафатларның һәм аерылганнарның киемнәренә карыйлар, саклыйлар. Югалганнарның төсләре өй түрләрендәге сурәтләрдә генә түгел, чөйләрдәге киемнәрдә дә саклана. Һәм киемнәрдә генә дә түгел.

Көчле кеше башын дамбага салды.

Ул баш салып йокыга талган дамба өстен ямь-яшел, яшь-яшь үләннәр каплаган. Палас шикелле. Ул баш салып йокыга талган дамба өстендә былтырдан калган саргылт һәм кара-кучкыл сабаклар да артык түгел. Тата кешенең баш киеме, өс киеме — шул төстә. Дамбада — аның төсе, чырае. Бу калкулыкка тоташ күз салсаң, Татаның кайда ятканлыгын белү, табу мөмкин булмаган хәл. Чакрымнарга сузылган шушы дамбаларда, шушы тирәдәге барлык кырларда, барлык тауларда — аның төсе, аның күз карашы. Тауларның һәркайсы көчле кешегә охшаган.

Бакчада — яңгырдан чыланган алмагачлар, шомыртлар, сиреньнәр. Ә күктә — тургайлар.

Бакчада боз тавы калган булса, мөгаен, кара көяр, агачлар, кемгәдер рәнҗеп, боегып утырырлар иде. Көчле кеше бакчага чәчәкләр бүләк итте, туган җиренә үз чыраен, үз төсен, үзенең тыныч сыман дәулы холкын, тургайларга үзенең җырын, җир өстенә сибәргә сөенечле тойгыларын бирде.

Авыл буенда яңа уңышлар өчен трактор мәйдан киңәйтә — урамнарга озакламый яшел дулкыннар, яшел ташкыннар керер...

Ә күктә тургайлар...

Басуларның, тауларның, тургайларның төсенә, киңлегенә, анда яңгыраган моңнарга колак салып, кырдан кырга, таудан тауга, тугайдан тугайга таба табигать күрке — кызыл төлке чаба...

1974—1975.

Фәннур Сафин

# АК КАНАТЛЫ ЕГЕТ

ПОЭМА

Безнең буын, безнең токым тиеш
бөек хыял-уйда янарга.
Сүнмәс йолдыз бүләк итсәң икән
җил-давыллы шушы заманга!

Узган буын утка кергән чакта
якты җиңү җырын җырлады,—
без очарга тиеш чорны узып,
алга өйдәп гаҗәп дөньяны!..

●

Җилпенде дә очты
ак канатлы егет —
очты хыялларда.
(Балавыз канат түгел бу,
кояшта эреп,
диңгезгә егарга!)
Уй канатларында
җилпенде дә очты,
карап
бик якын һәм ерак
кояшка,
язларга...
Гүя акыллы ат —
алып кайтты канат
аны
туган якка —
таныш ярга!..

●

Туган якка моңнар сирпеп,
кыр казлары киткән мәлдә,
ялгыз ана калды өйдә,
яулыгына яшен сөртеп.

Кыр казлары китте иртән.
Ана, карап шул якка,
кул болгый һаман шәфәкъкә...
Әллә ана үз улын шул
кыр казы дип уйлый микән? —
Кыр казлары китте иртән...

Җилпенде дә очты алар.
Язын урман тагын шаулар!
Кычкырсаң — яңгырап торыр,
тавыш бирер таулар!
Ләкин алар аңламас күк безнең хәлне —
таулар биек.
...Ак канатлы егет!
Син дә җавап бирмәссеңдер хәзер
карурманнан «әү-ү» диеп...

●

Юл читендә — абага,
орынды ул
урман буйлап шыгыр-шыгыр узган
иске арбага.
Ә анда...
бала
тәүге тапкыр тавыш бирде
ак дөньяга!
Җирнең икенче читендә,
үтерергә теләгәндәй карурманны,
мылтык тавышы яңгырады,
ярь-яшь тынлыкны өзеп.

Җилпенде дә очты
ак канатлы егет!..

●

Мин туганчы, миңа туган тиеш абый
яу кырында
соңгы минутында күккә карап
күргәндер ак канат!
Аның өчен бу мизгелдә
ай сызыгы,
күк, болыт-юрган,
җилкән, кораб —
барысы да канат булган...
Һәм ул очкан шул канатта
туган якка,
үсмер чакка.
Соңгы сәяхәткә...

●

...Туган якның якты яланнары
ак чәчәктә!
(Ерак синең барыр юлың...)
Үсмер чакта
ак чәчәкләр кушып үзең үргән

ак такыялы
күрше кызы йөгерә һаман
сиңа табан!..
Ялан буйлап
ялан аяк...
Килеп җиталмый тик
ауган җиреңә...
Бөрлегәндәй иреннәрен
тидералмый иренеңә.
Ак күлмәген ертып,
яраңны бәйли алмый.
Тыштан тыныч-сабыр калып,
эчтән ярсып-янып,
«терелерсең» диеп, назлый-назлый,
яшерен елап, юата алмый —
маңгаеңа куеп кулын...

Әйди ул сине, абый,
әйди
урмандагы якты аланга —
баланга.
Ә баланнар өлгермәгән.
Ык буенда пешкән бөрлегәннән
авыз итмәк булып
сез алга йөгерәсез.
Сез бергә йөгерәсез!
...Кинәт син
ак канатларны чөясең
ак хыяллар давылына!

●

Үзең калдың...
Канлы яу кырын кичеп,
синең хыял канатларың
кайтты туган авылыңа!

Ил күгендә алар
гүя
яңа туган ай булып балкый.
(Әйтерсең төн карасында була торган
афәтләрдән саклый.)
Бу минутта
ак буран булып та,
уралып болытка,
авыл уртасында бөтерелә канат,
талпына
һәйкәл каршында...
Һәйкәлгә уелган
исемнәрне укымакчы, ахры, —
ачуланып улый буран...
Ай да,
кемгә киңәш бирергә белми аптырап,
чөйдә эленеп
хуҗасыз калган бүрек кебек...

Ул бары тик
тулып җиткәнче яна.
Аннан тагын дугалана.
Ә безгә —
карап аңа —
сагынырга кала,
уйланырга кала:
«Уздырмыйбызмы бу гомерне
без заяга?!»

●

Зая гомер?!
Шуның өченме без килдек җиргә?
Уйласаң бер,
ни алдык та әле,
ни бирдек без илгә?
Канатлымы без күгебездә?
Хыянәт итмибезме үзебезгә?..
Күп вакытны шәһитләргә
дан урынына
матәм җырламыйбызмы?
Нәкъ безгә тиң мәйданнарны
читләп узмыйбызмы?

●

Ничәнче кат
канатлы ат
күрәм тешемдә.

«Без юлга чыгарга тиеш!»

Хыялны чын итеп,
тормышны җыр итеп
гел бергә барырга,
авырлыкны җиңәргә —
егарга тиеш!
Көчсезлек — ялган!
Бездән көтә заман:
без мәйданга чыгарга тиеш!
Ә нинди ул мәйдан?
Йөзмибезме сайдан?..
Пакьме безнең йөз,
кылган эш?..

Бушка үткән минут —
зая гомер...
Уйласаң бер,
героем —
шул ак канатлы егет —
шул унсигез яшьлек егет —
күптән инде минем энем
яше белән...

Ул күзәтеп тора
безнең кылганнарны.
Юк!
Төн-караңгылык
сукырайтмаган аны!
Ул барын да күрә!
Безгә авыр булса,
килеп иңен куя.
Төшенкелеккә бирелсәк,
бармак яный, тыя.
Ул барын да күрә!
Алар күтәргән авырлык
җиңелрәктер бәлки безгә
безнең иңгә
төшмәгәнгә күрә...

●

Юллар алтын-сары,
көзләр шундый якты!
...Бер пуля эзеннән
якты хыял акты...—
Гомерләр язмышын
мизгел хәл иткән чакта,
давыллана уй-хыял —
чәбәләнгән кебек иген
без туган якта...

●

Дөрли мәңгелек ут
мәңгелек бурыч булып!
Гомер кебек яна
синең утың, замана!..

Җанга якты өсти,
кояш белән ярышып.
Кояш инде бара
көзгә таба авышып...

Көзге парк яна
кызгылт-сары утларда.
(Бу — аның сагышымы,
килер шатлык тавышымы?)

Утлы көзгә карыйм,
уйга талып тәкрарлыйм:
— Гомер кебек яна
синең утың, замана...

Яшьлек утын өстим аңа —
сүнмәсен, сүрелмәсен
Заман уты!

1975

# Әсгать Мохтар

*Күренекле үзбәк язучысы Әсгать Мохтар — «Апа-сеңелләр», «Туу», «Дәвер минем тәкъдиремдә», «Чинар» романнары, күп-ләгән повесть һәм хикәяләр, поэмалар, шигырьләр, сәхнә әсәрләре авторы. Ул 1920 елда тимер юлда эшләүче татар гаиләсендә туа. Югары белем алгач, Әндиҗан педагогия институтында үзбәк әдәбияты кафедрасы мөдире, республика газеталарының әдәби хезмәткәре, үзбәк әдәби журналы «Шарк юлдузи» редакторы, Үзбәкстан Язучылар союзының секретаре булып эшли. Хәзер ул әдәби «Гулистон» журналын редакцияли. Быел аның «Чинар» дигән романы Лирон Хәмидуллин тәрҗемәсендә Казанда чыгачак.*

*Әсгать Мохтарның бер хикәясен укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.*

## Тап

«Күккә төкермә, йөзеңә төшәр»
(Мәкаль.)



Белгечләр тора торган дүрт катлы коммуналь йортның ишегалды ягындагы балконнарына көн кичкә авышу белән күләгә төшә. Җәй көне кичкә таба шунда яшәүче гаиләләрнең һәммәсе диярлек шул балконнарга күчеп бетә: берсендә чүкердәшеп чәй эчәләр, икенчесендә кемдер үргән кәнәфигә җайлап кына утырган да газета укый... Кыскасы, монда яшәүчеләрнең «гаилә серләре», кичкырын ни белән мәшгуль булулары бер-берсенең күз алдында.

Өченче каттагы бер балконда урта яшьләрдәге сылу гына бер хатын әледән-әле пәйда булып, тынычсыз кыяфәттә уңлы-суллы карап ала да тагын эчкә кереп югала иде. Бу кеше хикәябез каһарманнарыннан берсе, доктор Шадиевның иптәше Салтанатбикә ханым. Моннан ике айлар чамасы гына элек бу балкон һәр вакыт ямь белән тулы, кичке якта ир белән хатынның монда наз-нигъмәткә кәефләнеп чәйләп утырулары күпләрнең дикъкатен тарта иде. Гаҗәеп нәфис кытай ефәгеннән тегелгән халат кигән Салтанатбикә бу тирәләрдәгеләргә, гүя, «менә без!» дигәндәй, һавалы һәм горур караш ташлар. Ул чакта Салтанатбикә тирә-якка хәзергедәй сынап бакмас, башкаларның нишләгәнен әллә ни күзәтмәс. Киресенчә, бүтәннәрнең аны тамаша итүе табигыйрак иде...

Менә ике ай инде, һәрберсенең кызыксынуын кузгата торган күркәм тамаша юкка чыкты, балкондагы кыйммәтле нәрсәләр җыешты-

рып алынды. Салтанатбикә дә хәзер анда сирәк чыга, җете күзләрен тегендә-монда йөгертеп ала да кереп китә.

— Мөслимевләр кайтты, — диде бер көнне Салтанатбикә, балконнан кереп.

Ул моны күптән көтелгән бер вакыйга кебек хәбәр итте. Ләкин өстәле янында эшләп утырган Шадиев өчен бу гадәти бер хәбәр иде.

Чыннан да, күршеләре эштән кайткан икән, аның нәрсәсе гаҗәп?

— Үз бусагаларыннан ук култыклашып чыкмасалар ни була икән?..

— Яшьләр ич әле, — диде Шадиев, башын күтәрми генә.

— Алай йөрергә булса, яшьлегем корысын... — Салтанатбикә әйләнеп-тулганып алды да көзгедәге килешле тәүдәсенә күз салды. Аның озын кара керфекләре каймактай ак йөзенә күләгә төшереп тора, сөйкемле туры борыны янындагы нәфис миңе дә йөзенә ямь өсти иде. Аның матурлыгы нинди дә, күршесе Нәфисәнең гомердә иннек-кершән күрмәгән җәлпәк йөзе нинди!

— Кыяфәте шундый булса да, кая гына бармасын — иренең итәгенә чытырдап ябышуы ябышу. Кулымнан леп итеп очып чыгып китмәгәе дип курка. Ире район-фәләнгә очса, җанын учына салып утыра. — Шулай дигәч, Салтанатбикә хихылдап көлеп җибәрде.

Хатынының сөйләгәннәре бер колагыннан кереп икенчесеннән чыгып торса да, бу көлү Шадиевның эчен пошырды. Аның ачуы чыга башлады.

— Ни дип шулар белән авыз чайкыйсың, җаным? Көне-төне һаман бер сүз. Җитәр...

— Син әйбәт инде, бик, башыңа менеп атлансалар да, өнең чыкмый. Кичә генә институт бетергән бер чебеш урыныңны алды. Унбиш ел эшләгән тәҗрибәле врач бит син, мәнә кем. Кичә генә янында бөтерелеп йөргән бала — бүген баш врач. Иртәгә больницадан ук сөреп чыгарып җибәрер әле үзеңне. Шунда да рәхмәт дип торырсыңмы?..

Салтанатбикә, иренең әле бер, әле икенче ягына чыгып, һаман чәчәләнә бирде. Доктор Шадиевның җәнҗал ясап торырга вакыты юк, гадәтенчә, мөмкин кадәр сабырлык һәм җай белән кирәксез гәпне туктатырга тырышты.

— Җаным, аңларга кирәк: яшьләр һәр яктан шундый. Доктор Мөслимев яшь булса да, ике ел эчендә зур гына ачыш ясап, диссертация яклады. Хәзер институтлар да без укыган дәвердәге кебек түгел. Яшьләр зур кыюлык, олы белем белән чыга. Аларның йөгереклеген күреп, башың әйләнеп китәр. Мөслимевнең соңгы операцияләре Ленинград галимнәрен дә кызыксындырган. Мин аңа юл куйдым. Аннан соң... Ул баш врачлыкны үзе әрсезләнеп алмады, киңәш-табыш итеп тәгаенләдек. Минем ризалыгымны сорады. Инде кайчаннан бирле бер урында таптанып торуымны икърар иттем. Бер урында тору — артка тәгәрәү дигән сүз ул. Урынымны үземә караганда гайрәтлерәк, өметле, тиз үсеп бара торган яшь врачка бирүем табигый. Яшьләрнең безне алыштыруы, гомумән, табигый...

Иренең саллы, басынкы тавышы Салтанатбикәне бераз тынычландыра төште, тик шулай да ул аның сөйләгәннәрен тыңламый, үз уйларына чумган иде. Әле кичә генә килде-киттенеке түгел, баш врач хатыны иде, урамда берәрсе очрап, аңа күз салса, «бу — фәләннең хатыны» дип кызыгып карап торадыр сыман тоела, шуның белән күңеленә канәгатьлек һәм горурлык хисе тула иде. Салтанатбикә доктор Шадиевка хөрмәт белдереп, аның саулыгын сораучыларның һәммәсенә бер генә баш селкеп җавап бирә һәм горур гына үтеп китә иде. Хәзер исә бу тирәдә бердәнбер булган зәңгәр панбәрхет күлмәген киеп чыкса да, үзенә берәү дә игътибар итмидер төсле тоела. Әүвәле чиратсыз гына итне симез җиреннән кисеп бирә торган кибетче дә кичә бер кило иткә өч йөз грамм сөяк кушып рәхәтләндерде. Нәфисәнең исә

һәйбәт түш итен күтәреп кайтып килүен Салтанатбикә үз күзе белән күрде.

Әллә нинди баш врачның хатыны булса да, машинистка гына инде ул. Чыпчык симереп бер батман була алмый.

— Тагын шул сүз! Аның ни гаебе бар, ташлачы, җаным. Үз эшен белеп, машинисткалыгында йөри бирсен, — диде Шадиев, ачуын басарга тырышып.

— Шушы хәлеңә сөенеп торыйммыни?!

Шадиев, аның сүзен кискен генә бүлеп:

— Кыскасы, сүз күбәебрәк китте, — диде. — Эшсезлектән булса кирәк. Үзеңә дә берәр җиргә урнашырга кирәк булыр, җаным.

— Нинди эшкә? Мин дә машинистка булыймммы? — диде Салтанатбикә, — автобуста кондуктор бул, диярсең бәлки?.. — Ул машинистка, кондуктор дигән сүзләрне йөзен чытып әйтте. — Инде көнем шуңа калдымыни? Инженерлык, врачлык белгечлегем булса икән, эшкә кергәндә. Институтның беренче курсын үзең ташлаттың ич!..

Шадиев сүзсез калды. Бу хакта бәхәс элек тә күп булды. Салтанатбикә мондый бәхәсләрдә һәр вакыт шушы соңгы сылтавы белән җиңә иде. Шадиев моннан унөч ел элек кылган хатасы аркасында аның менә шушы дәлилен юкка чыгара алмый, күп вакыт дәшми калырга мәҗбүр иде. Шулай да бу юлы ул бөтенләй җавапсыз калмады:

— Яңадан укырга кер булмаса.

— Шул гына калды инде. Оп-олы башым белән кичә генә мәктәп эскәмиясеннән торган кызлар белән бер өстәл артына утырыйммы?

Шадиев сүзнең кычкырышка әйләнүеннән курка иде. Ул, ачуын басар өчен, өстәленә иелеп тагын эшенә керешге.

Салтанатбикә, балконга чыгып, кулына китап алган булды, әмма аның күзе күрше балконда иде. Анда Нәфисә Мөслимева өй эшләре белән мәйханә килә икән. Ул чүлмәккә утыртылган гөлен балконга алып чыкты. Моны күргән Салтанатбикә аяк очына гына басып бүлмәсенә керде дә кисмәккә утырткан зур гөлен күтәреп чыкты. Күршесенә игътибар итмәгән Нәфисә инде ул арада кыймматле кып-кызыл төркмән келәмен җилләтергә чыгарып элгән иде. Салтанатбикә тагын ашыга-ашыга бүлмәсенә йөгерде. Идәндәге искерәк келәмгә нәфрәт белән дөп-дөп басып үтте. Гардероб янына барды, йокы бүлмәсеннән әйләнде. Йөрәгендә нәрсәдер ташырга тотынгандай, үзен-үзе кая куярга белми башлады. Иренә карады: ул хатыны хәлен ни дип тә белмичә бирелеп эшләп утыра иде. Салтанатбикәнең кычкырып җибәрәсе килде, әмма үзен тыеп калды, бүлмәсенә кереп караватына ауды.

Иртәгесен Шадиев больницадан кайтканда аның эш өстәле өстендә өр-яңа кызгылт келәм ята иде.

— Бу кайдан килде?

— Кайдан дип, кибетләр корып бетмәгән әле. Нәрсәгә шул хәтле исең китте?

— Бик каты кирәк идемени соң ул?..

Салтанатбикә аңа сүзен әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде:

— Нәрсәгә шулкадәр исең китте? Кешедә бар әйбер нишләп миңа кирәкмәсен икән?!

— Тагын кычытмаган җирне кашыгансың ич син, җаным! Хупламыйм. Диссертация яклаганда кирәк булыр дип җыеп куйган акчам иде...

Шадиев диссертациясен озакка сузганы өчен җыелышта сүз ишетеп, шуның өстенә хәйран ачыгып та кайткан иде. Өйдәге яңалык аны тәмам чыгырыннан чыгарды. Чишенеп тә тормастан, кәнәфигә килеп утырды. Хатыны сөйләгәннәр колагына кермәде, фәкать өзек-өзек гыйбарәләрен генә ишетте: «Тегенди-мондый гына кеше түгел, доктор хатыны...», «Инде көнем шуңа калдымыни?..», «Минем кай җирем ким?..»

Шадиевның ихтыяр көче бу күңелсезлекне дә җиңәргә ярдәм итте. Ашап-эчеп алгач, тагын эшенә утырды.

Ул эш белән генә онытыла иде. Каршы сүз әйтсә, бәхәсләшергә, аннан килеп ызгышырга кирәк. Моның белән генә кителгәнне төзәтеп булмаса да, сабырлыкны хуп күрә иде. Салтанатбикәгә исә, киресенчә, иренең салкын канлылыгыннан начары юк, давыллап-дулап алырга җае табылмый. Балконда Нәфисәсе дә күренми бит. Нишли икән? Эштән ул һәр вакыттагыча җиденче ун минутта кайтты. Кулында газетага төрелгән бер нәрсәсе бар иде шикелле. Нәрсә булды икән?

Салтанатбикә, чыккач, коридорда Нәфисәне очратты.

— Салтанатбикә апа, нихәл? Безгә бер дә кермисез, кергәләгез, — диде Нәфисә, кулындагы себеркене ишек артына сөяп, яңак сөякләре киңрәк, әмма күзләрә үтә эчкерсез елмаеп торган яшь кенә хатын иде ул. Сызганган җиңнәрен төшереп, Салтанатбикәгә ишек ачты.

— Исән-имин торасызмы, иптәшкәйләр? — диде Салтанатбикә, «сенелем» урынына әйтелгән «иптәшкәй»гә басым ясап.— Керәм дип җыенам үзе, бер сөйләшеп утырасым килә, һаман форсаты табылмый, күр инде, иптәш.

Бу җиде ят кына сөйләшә торган сүзләр иде. Чит телдә аңлашкан кебек. Акылы зәгыйфь булмаса, Нәфисә бу гәпнең асылын аңларга тиеш иде. Асылы исә болай: «Әҗәлең килгере, юха тагарак. Күзем күрмәсен, синең белән мин тиңмени?!»

— Доктор Мөслимев исән-саумы?.. Чирләп йөргән сыман, эше авыр, ахры, яшь кешегә... Бер көнне күрдем — шундый ябыккан...

Моның мәгънәсе шундый иде: «Эшләгән эше чуалып бетсен бәдбәхетнең. Берәүнең урынын алып тапканы бугазына аркылы килсен...»

Нәфисә ире хакындагы сүзләргә җаны эреп елмайды. Өстәл янындагы чемоданны читкә алып куеп, кунакка урын әзерләде.

— Тагын берәр якка киттеме? — дип сорады кунак, түргә узганда чемоданга ымлап. — Бер көн өйдә, ике көн сәфәрдәдер инде?

— Үзегез дә беләсез инде, хирург бит ул. Кай кичләрдә самолет белән чыгып китәргә дә туры килә. Бүген дә менә районга...

— Ай-һай, хәрәкәтчән Мөслимевегез. Яшь нәрсә... Үзегез дә беләсездер...

Нәфисә төшенеп бетмәде, ахры, күзләрен йомгалап, аптырабрак калды.

— Сездән дә яшьрәкме әле ул?

— Бер тиң без, — диде Нәфисә, тагы да гаҗәпләнә төшеп.

— Яшь икән...

— Әйе, яшь.

Сүзсез калдылар. Салтанатбикә, бу тынлыкка мөмкин кадәр серлерәк мәгънә бирмәкче булып, үзенчә башын селкеде.

— Кәнфитеннән җитешегез, апа. Әллә нигә бер кердегез, күр инде, вареньем да юк икән.

— Бәхетегез зурдан икән, иптәшкәй. Шундый ир! Яшь. Белемен генә алыгыз! Хәзер сылу, чибәр кызлар күп, әмма күбесе ирдән сезнең кебек уңмый.

— Уңган дип инде... — Нәфисә каршы төшмәкче иде дә сүз таба алмады. Җитмәсә, күршесе дә сүз әйтергә ирек бирмәде.

— Инде уңу гынамы соң! Якын күргәнгә күрә әйтәм — юлдан табылган алтынга ия чыга, диләр. Бәгырькәегезне җуймагыз... Бизәнмисез дә икән тагын, иптәшкәй...

— Мин Мөслимев хакында алай уйлый алмыйм.

— Шул шул менә. Ир затының әнә шундыйлары алдый да инде, әйтсәм әйтим мин сезгә. Башымнан үтмәгән булса, авыз да ачмас идем. Мөслимев яшь икән шул...— Салтанатбикә тавышын әкренәйтте.— Менә минем иремне дә бер дә уйламассын! Шушы яшькә җиткәндә...

— Юк, юк, апа, сөйли күрмә! — Нәфисә кунакка чын йөрәктән ачынып төбәлде, — мин доктор Шадиевны бик пакь кеше дип беләм.

— Ир кеше бит ул, җаныем, ир кеше, беләсезме? Сыйлап-сыйпап йөрде дә, бер заман ишетәм — районда күз атып йөри торган врач хатыны бар икән. Юу-у-ук! Мин ябышсам, каты ябышам. Әлегрәк ачык авыз булуыма да гел үкенәм әле.

— Кайчан булды соң ул хәл?

— Кичә генә. — Салтанатбикә, келәм алып кайткан көнне сүзгә килүнең сәбәбен үзгәртеп, ызгышны бөтенләй шуңа нигезләп тасвирлады.

— Якын күргәнгә генә серемне ачтым, берәүгә дә ычкындыра күрмә,— дип бетерде ул сүзен, ул-бу чыкмасын дигән ният белән.

— Ярар... — диде Нәфисә битараф төстә. Бу хатыннан аның беренче мәртәбә ихласы кайтты.

— Мин шулай дигәнгә карап хафаланма тагын. Мөслимев хакында берни дә әйтә алмыйм. Яхшы егет. Әмма артык яхшы ул. Фәкать шуны гына әйтәсем килә, матурым. Ирең булгач, бөтенләй үзе дә, фикере-зикере дә, һәрбер адымы да үзеңнеке булу кирәк икән. Булмаса... кайсыдыр адымы билгесез калса, соңрак сөреме тия икән. Һай, лыкылдап утырып оедым, ахры, кайтыйм, докторым нишләп утыра икән?

— Утырыгыз әле, — диде кәефе бозылган Нәфисә.

— Рәхмәт. Киңәшемне күңелегезгә авыр алмагыз, якын күреп кенә сөйләштем, иптәшкәй.

Ишек ябылганда Нәфисә урыныннан кузгалмады, чемоданга озак кына төбәлеп торды. Бердән, озак вакыт күрмәгән кебек, ирен бик сагынгандай булып китте. Моннан бер ел элек, әле яңа гына тормыш корып җибәргәндә ул иренең эштән кайтып җитүен шундый зарыгып көтә иде...

Доктор Мөслимев эштән кайтты. Нәфисә аның аяк тавышын шунда ук таныды: Мөслимев һәр вакыт каты-каты басып, өс-башына кунган урам тузанын ишегалдында ук кагып, сөенечле һәм дәртле бер төс белән өйгә килеп керә иде.

Ул, кергәч ук Нәфисәгә карап, «яхшы әле, өйдә икәнсең» дигән кебек ягымлы елмайды да костюмын салып җиңнәрен сызганды. Тыштан керү белән җиңен сызганырга больницада гадәтләнгән иде. Көчле беләкләрен ялангачландырганда, «яле, эш бармы, «ә» дигәнче эшләп ташлыйм», дигән сыман бер кыяфәткә керә. Хәзер дә җиңен сызганып,— әйтерсең Нәфисәне күтәреп алып күкрәгенә кысмакчы, — салмак кына атлап килде дә мич янында шаулап кайнап торган самаварны җиңел генә күтәреп өстәлгә куйды.

— Юлга һәммә нәрсәңне әзерләп куйдым, — диде Нәфисә, иренең күзләреннән берәр сер эзләгән шикелле карап. Күрше хатынының сүзләре әле һаман колагында әрсез чебен кебек безелди иде.

— Рәхмәт, Нәфисә. Бик әйбәт булган. Ярты сәгатьтән очам.— Мөслимев ванна ягына чыгып күлмәген салды да салкын су чәчрәтә-чәчрәтә юына башлады. Аның вакыты һәркайчан тыгыз. Әмма бер генә эшне дә ашыгып эшләргә яратмый. «Ярты сәгать» яки «биш минут» дип әйтә дә ул арада гына һич тә бетерә алмаслык эшкә керешә. Бетереп тә куя. Нәфисә моны белә, шуңа күрә аны беркайчан да ашыктырмый. Юынганда аны ашыктыру исә бөтенләй бушка гына хафалану иде.

— Ай-һай, күп йөрисез,— диде Нәфисә, чәй эчәргә утырганда. Аның тавышында ризасызлыкка охшаш ят төсмерләр ишетелгәндәй булды. Мөслимев хатынының тавыш төсмереннән бигрәк, сүзенең мәгънәсенә игътибар итте.

— Ничек инде «күп»?

— Гел районга очасың, гел...

— Әйе, әйе, шулай,— диде Мөслимев уйланып,— шулай. Мин бу хакта уйламаган да икәнмен. Читтән караганда чыннан да шулай күре-

нүе мөмкин. Врачларның тормышы шундый мәшәкатьле инде, үзебезгә сизелми дә, күнегелгән. Син читтән карап күреп тә алган мена.

— Читтән карап түгел. Мин бөтен эшләренә синең караштан чыгып бәя бирмәкче булам.

— Рәхмәт, Нәфисә.— Мөслимев аның кулы өстенә үзенекен куйды.— Күз алдына китерик әле: таулар арасындагы бер кышлакта синең белән минем шикелле үк бер кеше түшәктә ята. Кызышудан башы чатный. Азаплы чир белән уздырган һәр минуты, һәр сулышы күпме көч, күпме чыдамлык сорый. Хәле торган саен авырая. Ул әле бик аз яшәгән, бөтен киләчәге алда. Бәхете, иҗаты, хезмәте, дуслары, хыяллары күз алдыннан китмидер. Тормышы исә куркыныч астында. Менә шул кеше берәүне көтә. Кояш чыгуын көткәндәй көтә. Бөтен өмете шуңарда. Шул «берәү» аңа бәхет тә, иҗатын, хезмәтен, дусларын, хыялларын да кайтарып бирә ала. Әгәр шул «берәү» син генә булсаң, нишләр идең?

Нәфисә иренең җитди күзләренә миһербанлы карашын салды. Салтанатбикә дә, аның сүзләре дә онытылган иде.

— Абау, сине ни дип аптыратып утырам соң әле мин!

Нәфисә иренең костюмын алып килеп, аның иңенә салды, аннары арттан иренең киң җилкәсен кочып алды да беравыкка гына аңа сыенды. Мөслимев, урыныннан торып, хатынының көлеп торган күзләренә төбәлде.

— Кайткач шул кеше турында сөйләп бирермен, яме?

Нәфисәнең шәфкать белән тулы күзләре ярар дигән мәгънәне аңлатты.

— Нәсим абый, операцияме? — диде ул.

— Әйе, — диде доктор, көр күңеллелек күрсәтергә тырышып.

— Сак булыгыз.

Ире җавап урынына аны кочагына алып үпте. Нәфисә ишек төбеннән озак кына карап калды. Иреннәрендә Нәсимҗанның кайнар орыну эзләре калган иде...

Мөслимев иртәгесен үк кайтып җитәргә тиеш иде — кайтмады. Нәфисә тагын бер көнне шулай көтеп уздырды.

— Докторның ымы-шымы ишетелми шикелле? — диде Салтанатбикә, икенче көнне Нәфисәне очраткач.

— Доктор кайттымы? — диде ул өченче көнне, Мөслимевнең әле һаман кайтып җитмәвен белә торып. Нәфисәгә аның соравыннан бигрәк хәлен уртаклашкан сыман карап торуын күтәрүе авыр иде.

— Доктор Мөслимев күзгә-башка чалынмый. Исән-сау йөриме? Әле һаман шул китүеннән кайтканы юкмы? Китүе китү инде, хат-фәлән дә юк диген, ә?

Мөслимев алтынчы көнне дә кайтмады. Нәфисә хәзер Салтанатбикә белән очрашудан тайчана башлады. Көненә өчәр мәртәбә сораша. Ниһаять, ул кайсыдыр бер шәһәргә туганнарына кунакка киткәч, Нәфисә җиңел сулап куйды.

Мөслимев кайтып төшкәч, боларның барысы да онытылды: доктор, яңадан туган кебек яшәреп, дәртләнеп кайткан иде. Тау һавасы хакында, авыр чиреннән котылган яшь агроном хакында ике көн буе кат-кат сөйләде. Агроном Нәфисәне дә сорашкан, сәлам әйткән, адресларын алып калган икән.

— Гаҗәеп егет! Чире җитди булган, ярдәм кичексә, зур бәхетсезлек килүе мөмкин иде. Гомерен саклап калган кешегә рәхмәт кенә әйтү буш сүз кебек кенә күренә икән, ди. Сунарга килергә чакырды. Бер карасаң — философ, бер карасаң — сабый бала...

— Бүләк алып кайттым! — диде Мөслимев бер көнне эштән кайткач. Кәгазьгә төрелгән бер нәрсәне югары күтәрде. — Буең җитсә, ал.

Нәфисә Нәсимҗанга «кәтүк» дип, Нәсимҗан исә Нәфисәгә «багана» дип кушамат таккан иде. Нәфисә аның җилкәсенә асылынып кулын суздьι. Нәсимҗан, кулын тагы да югарырак күтәреп, «багана-багана» дип көлә иде. Алар байтак шаярышып көлештеләр, аннары Нәфисә җитез генә сикереп бүләкне кулга төшерде. Бу — Нәфисә әллә кайчаннан бирле таба алмый йөргән китап — «Стенография дәреслеге» иде.

Менә шушы күңелле көн узып киткәч үк Мөслимев тагын китәргә җыена башлады.

— Кая?

— Сәхибәне күреп килим әле.

— Нинди Сәхибә?

Нәфисә шулай дип сорауга, үзенең дә исенә төште: үткән ел Мөслимев Сәхибә дигән кызны дәвалады. Бу операция хакында, Сәхибәнең үзе хакында Мөслимев шул вакыт шактый күп сөйләгән иде. Ире сөйләгәннәрдән Нәфисә шуларны белде: Сәхибә унтугыз яшьләрдәге кыз. Матур гына. Бик түзем, акыллы. Өлкә шәһәрләренең берсендә шәфкать туташы булып эшли, ата-анасы юк.

— Аның авыр операциядән соң саулыгы мине генә түгел, профессорыбызны да кызыксындыра.

— Саулыгы әйбәт диләрме соң?

— Барып күрүгә җитми инде. Андый операция бик сирәк ясала. Күп кешеләр башкача күрәзәлек иткән иде, әмма, күрәсең ич, бер ел узды инде, саулыгы әйбәт дигән булалар. Гаҗәп кызык очрак. Барыйм әле. Иртәгә китәрмен.

— Берәүне дәваладым дип, гел шуның артыннан гына йөрересеңмени?.. — диде Нәфисә үпкәләгән төстә. Әллә ни зарур булмаса да, китеп барырга гына атлыга, дип уйлый иде ул. Мөслимев тә моны сизеп алды.

— Беләсеңме, Нәфисә, бер үлемнән калып, синең кулыңнан төзәлеп, савыгып чыккан кеше туганың кебек якын була икән. Минемчә, дөньяда иң күп дусты булган кешеләр врачлардыр. Адәм баласы үзен коткарган кешене онып аламыни? Аларны врач та оныта алмый, һәрберсе бөтен кыяфәте белән күз алдында тора. Нәрсә булды икән, йөри микән дип уйлыйсың, күрәсе килә башлый. Кыскасы, кардәшең кебек...

— Хәрендәшең, алайса? Сәхибә хәрендәшең булгач, кем була инде ул? — Нәфисә шулай төрттереп әйткәч, Мөслимев көлеп җибәрде.

— Сәхибә — әйбәт кыз. Булдыклы кыз.

— Кайчан китәсез... хәрендәшегезгә?

— Хәзер үк түгел әле, Нәфисә... Иртәнге якка чемоданны әзерләп куй. Машина бара икән, шуңардан калмыйм.

Нәфисә бу җитдилектән боегып калды, тик кисәтүдән ары китәргә нигез юк иде. Иртәгәсен ирен озаткач, күңеле тәшвишләнә башлады. «Әйбәт кыз», «кардәш» дигән сүзләр янә күңеленә килде. Көне дә әллә ничек күңелсез тоелды. Әллә кайдан күз алдында Салтанатбикәнең караңгы күләгәсе калыкты, шомлы тавышы ишетелгән сыман булды.

Бу вакытта Салтанатбикә өлкә үзәгендәге бер туганының бәйрәмчә җыелган өендә кунак иде. Өй хуҗасы өч бүлмәсенә фатирчылар кертеп, шулар хисабына көн күрә, беркайда да эшләми торган ханым. Очрашкан көнне сүзләре мәңге бетмәс төсле тоелды. Ләкин өстәл янында ефәк белән тышланган көрпәгә утырып ике көн туктаусыз гәпләшкәннән соң, әңгәмәләре саекты. Сүзләре бетмәс иде дә, исемнәре кайта-кайта телгә алынган, болар таный торган хатыннар бетте. Ул хатыннарның беришесе иреннән аерылган, яисә берәрсенең гаиләсендә низаг булган булса да, бу хакта тагын күпме сүз озайтырга мөмкин соң? Салтанатбикә мондый гәптән туюын гомерендә беренче мәртәбә тойды. Яхшы әле, бер фатирчы кыз бар икән, кичкырын ул кайтып, мәҗлескә

ямь өстәде. Икенче көнне менә шушы кыз хакындагы гәп иртәдән кичкә кадәр ике туганга җим бирде.

Өч көннән соң бу кыз тагын керде. Сәхибә бу арада ут кебек янып йөри иде. Ул туфлиен салып, тездән югары күлмәк итәген төзәткәләде дә Салтанатбикә янына килеп утырды. Ул нигәдер дәртле күренә, күзләрендә ниндидер сер, йөрәгендә әйтәсе нәрсәсе бар кеше сыман, кызарып торган иреннәре менә-менә ачылып китәм дип тора иде. Йорт хуҗасы чыгып киткәч, Сәхибә сак кына сорады:

— Салтанат апа, шәһәрдәшегез доктор Мөслимевне танымыйсызмы?

Салтанатбикәнең йөрәге, нәрсәдер буласын сизеп, сикерә башлады. Күңеле кытыкланып китте. Ләкин ул, гамьсез һәм ваемсыз кеше кебек, һәвәсләнүен белдермәскә тырышты.

— Мөслимев?.. Һе-е-е, доктор дисенме әле... белмим. Әйе-әйе, тукта әле, доктор Мөслимев, ә? Беләм. Нәрсә булган аңа?

— Яхшы беләсезме?

— Әйе... күрешкәләп торабыз, — диде Салтанатбикә саклык күрсәтеп. — Шуннан нәрсә?

— Ул кеше бервакыт мине дәвалаган иде. Кичә шәһәребезгә килгән.

— Килгән? Нәрсәгә?

— ...Мине күрергә...— диде Сәхибә кызарып.— Операциядән соң сәламәтлегемнең ничеклеген беләсе килә икән...

Шул чак йорт хуҗасы керде. Сәхибә чыгарга кузгалды. Кыздан аерылгач, Салтанатбикә уйга калды. Инде аны бүтән нәрсә кызыксындырмый иде. Ул Сәхибә белән өзек-өзек алышкан сүзләрдән байтак нәтиҗә чыгарырга өлгерде. Эч пошулары бердән юкка чыкты.

Уйларсың монда. Кыз йөрәгендәге гыйшкын кемгә ачарга белми аптыраган икән. Шулай сизелә. Кешесен таптым дип сөенгән, имеш!

Салтанатбикә мондый уйлардан соң кычкырып көлеп җибәрергә әзер иде. Әмма үзен тыеп калды. Доктор ник килсә дә, барыбер. Гәпнең төбе кызда. Кызның дулкынлануына караганда, монда берәр кызык чыгар, ахры.

Салтанатбикә иртәгесен көнозын фатирчы кыз ишегеннән күзен алмады. Сәхибә эштән кайту белән, Салтанатбикә үзе барып керде. Кызның тыныч урын табуыннан, фатир хуҗасының ятим, шәфкатьле булуыннан сүзне башлап, ул әкрен-әкрен максатын тормышка ашырырга кереште. Бүтән сөйләшер кешесе булмаганга, Сәхибә дә йөрәгендәген тышка чыгарды.

— Хатын кеше, әнием шикелле берәү сез, яшерер хәлем юк, Салтанат апа. Мин... аны онытмаган идем. Хәзер барысы да яңадан исемә төште. Больницада ятканда миңа шундый илтифат, шундый миһербанлык күрсәтте. Мин ул вакытта моны доктор булганга күрә шундыйдыр, дип уйласам да, йөрәгем кай арада әллә ни сизенгәндәй була иде. Соңрак исәнлегемне сорашып хат язды. Менә хәзер... үзе дә килгән. Бүген врач кабинетына чакырып алып, сорамаган нәрсәсен калдырмады. Йөрәгем дөрләгәнгә, кеше төсле җавап та бирә алмадым. Әллә нәрсә булды миңа, Салтанат апа, елыйсыларым килде...

— Юрәрләнмә! Шуннан хәтле күрергә килгәч... яшь бала түгел ич син... Яшь бала да чамалый инде моны. Үзеңнән соң, үзеңнең күңелең ятамы?

Сәхибә аның күкрәгенә капланды. Күзләрен челт-челт йомгалап телгә килде:

— Ул мине үлемнән коткарган. Бер сүз кушса, аның белән үләргә дә риза. Салтанат апа, ул миңа тәкъдим ясамас шул... Андый якка кагылганы да юк.

— Мәхәббәт сүз боткасы ясау түгел ул. Ул эш-хәрәкәттән тора. Бәхетең ачылган. Шундый егет диген, әй!

Сәхибә, бәхетенә ышаныр-ышанмас, Салтанатбикәне кочаклап елап җибәрде.

Мөслимев өлкәнең тагын кайбер районнарындагы элекке авыруларының хәлен белешеп, сигез көн тулганда гына кайтып керде. Өендә «кардәш»ләре турында шатлыклы да, күңелсез дә хәбәрләрен сөйләп бетергәч, Нәфисә иренә нигәдер кызганычрак кыяфәт белән карады.

— Нәсим абый, бернәрсә әйтимме?

— Нәрсә, Нәфисә? — Мөслимев урыныннан ук сикереп торды.— Әйт.

Нәфисә, күзен яшереп, эскәтер чукларын бөтергәләде.

— Үзең белмисеңме?

— Нәрсәне, Нәфисә? — Мөслимев, аның маңгаена кулын куеп, дымлы күзләренә карады.

— Врач башыгыз белән дә... белмисез, имеш...

Мөслимев, кинәт үзгәреп, аны күкрәгенә кысты.

— Нәфисәм! Җаным! Нигә элегрәк әйтмәдең! — дип кычкыра салды. Нәфисәнең йөзеннән, күзләреннән үпте.— Шәп! Менә шатлык! Кичер, уйламаганмын, игътибар итмәгәнмен, утыр, утыр...— Мөслимев ни дияргә, нәрсә эшләргә белмичә аптырап калды. Алар иңгә-иң терәлеп янәшә утырдылар. Беренче бала турындагы татлы хыяллар икесен дә җанландырган иде.— Инде нишлик икән, Нәфисә? Белештермәвемне күр инде, хәзер нәрсә...

— Нәрсә шул кадәр кабаланасың?..

— Иртәгә ялга чыгармын! Нәрсә кирәк, Нәфисә, әйт, сора...

— Чираттагы ялыңны соңрак алырсың, тагын өч-дүрт айдан. Хәзергә берни кирәкми.

— Кирәк, кирәк, Нәфисә! Нәрсә кирәген әйт кенә...

— Кызык син, нәрсә кирәк булсын соң? Һич ни...

Мөслимев ары барып, бире килеп, нишләргә дә белмәде. Соңыннан өй эшләрендә ярдәм итәргә уйлап, кешелеккә кия торган киемнәрен салды, пижамасын киеп алды. Сызгырына-сызгырына баскычтан аска, астан өскә малайлар кебек йөгереп йөрде...

Нәфисә Нәсимҗаны хакында уйлап, ирен шулай куандыра алганы өчен сөенде, аның белән танышканнан бирле бергә үткән татлы, күңелле көннәрне күз алдына китерде, киләчәктәге шатлыкларны хыялга урап башыннан кичерде. Нәсимҗан хакында күңелендә туа башлаган шомнары өчен үзен битәрләргә әзер иде. Ул Нәсимҗан өйдә юк чакларда хыялларына аеруча ирек бирә, кыз чагындагы җырларын көйләп өй җыештыра, үзен коштай җиңел хис итеп, күз ачып йомганчы дөнья кадәр эш башкарып өлгерә иде.

Бүген кичкырын Нәсимҗаны эштән кайтыр инде дип көтеп утырганда ишек кактылар. Салтанатбикә керер я дип, теләмичә генә барып ишекне ачса, бусага төбендә тездән генә кыска күлмәк кигән сылу бер кыз күренде.

— Гафу итегез...— диде кыз, нигәдер уңайсызланып. Ул керергә дә, кермәскә дә белмичә, әле ишектәге квартир номерына, әле Нәфисәгә карап, телдән язды.

— Керегез, кер,— диде Нәфисә, күзенә мөлаем күренгән кызны кыстап. — Әйдә, әйдә, керегез.

Кыз ихтыярсыздан эчкә атлады.

— 51 нче фатир шушымы, әллә саташтырдым инде?..

— Нәкъ шушы, керегез, кер. Исән-саулыкмы? — Нәфисә исемен әйтеп күрешергә кулын сузды.

— Сәхибә... — диде кыз, үз исеменнән үзе сискәнеп.

Нәфисәнең йөзенә дөрләп торган ялкын орылгандай булды, йөрәге жу итеп китте. Сәхибәгә карагач, башына беренче килгән уй шул булды: ул бу кызны нәкъ менә шушындый итеп — аграк йөзле, очлырак иякле, юка борынлы, сылу, күркәм кыз дип күз алдына китергән иде.

— Нәрсә карашып торабыз, әйдә, түргә узыгыз. Сумкагызны да монда куйыйк... Мин сезне яхшы беләм... Киләүегез яхшы булган, бик әйбәт, әйдә...

Сәхибә, кая килеп эләккәнен төшенмичә, тәкъдим ителгән йомшак кәнәфигә утырды. Утырмый нишләсен? Уйлары чуалып, телләре көрмәкләнде, үзенең уңайсыз хәлгә төшүен генә аңлый иде ич ул.

— Мине беләм дисезме? — дип сорады ул, ниһаять, җөрьәт итеп.

— Доктор Мөслимевне эзләп килгәнсездер ич, — диде Нәфисә, кызның соравына җавап катмастан. Чәй әзерләп йөрүендә дәвам итте: — Хәзер кайтып җитәр. Ул миңа сезнең турыда исе китеп сөйләде. Мин сезне менә шушындыйдыр дип уйлаган идем инде. Күптән түгел барып сәламәтлегегезне белеп кайткач сөенгән идем. Бик әйбәт...

Нәфисә чынаякларны крахмалдай ак тастымал белән сөртә-сөртә сөйләшкәндә, Сәхибәнең йөзе агарынуын, маңгаена салкын тир бәреп чыгуын күрми иде. Сәхибә хәлсезләнеп китүен сизде, күз алдында тоныкк күләгәләр бии сыман тоелды. Уена әллә нинди сүзләр килеп миен тундерде — аларның берсен дә менә хәзер телгә алырга ярамый иде. Ул һаман баш ватуында дәвам итте. «Моннан хәзер ничек чыгып китәр инде ул?»

Хәзер инде ул кемнең эчкерсез кунакчыллыгын күрүен, кемнең табынына килеп утыруын чамалый иде. «Ә ул үзе бу сүзләрне кемгә сөйләп торганын белә микән?»

Нәфисәнең кешелекле мөнәсәбәте Сәхибәгә исен җыярга ярдәм итте. Мондый хатын алдында үзенне гаепле итеп тою да читен. Сәхибәнең хыялында доктор Мөслимев җанлана башлады. Йөрәгендә аңа нәфрәт хисләре укмашып килә иде. Шундый әйбәт, акыллы кешенең икейөзле ялганы... юк, бу уй, бу ачу дәррәү юкка чыкты. Сәхибә үзенең нинди хәлдә калуын белдермәс өчен:

— Сез... — дип авыз ачты да туктап калды.

— Мин доктор Мөслимевнең хатыны,— диде Нәфисә. Сәхибәнең йөзенә күз төшергәч, ул да барын да аңлап алды. Сүзсез сораулы карашлар бер-берсе белән очрашты. Беренче булып Сәхибә карашын аска күчерде.

— Миңа хәзер җавап бирегез инде, — диде ул кыюсыз рәвештә.

Нәфисә каушап калмады:

— Тукта әле, Сәхибә... сеңелем... Икебез дә яшь бала түгел. Әле күнелгә тулганны ачмадык.

— Мин сезгә хәйран калдым: ничек сез шулай миңа якты чырай күрсәтәсез? — Сәхибә уйлап торды да өстәде: — Нигә мине куып чыгармыйсыз?..

Нәфисә аның янына килеп, кулына орынды, эчкерсез итеп карап торгач, китәргә кузгалган Сәхибә тагын утырды. Нәфисә дә, кулын аның җилкәсенә салып, янәшә урнашты.

— Мин сезнең күңелдәгене аңлыйм, Сәхибә. Сез дә мине аңларга тырышыгыз. Башта әйтегез әле... Мөслимев сезгә нәрсә диде?

— Нәрсәме?.. Миңа ул кеше... менә, — Сәхибә ихтыярсыз кискен бер хәрәкәт белән куеныннан телеграмма чыгарды.

Нәфисә телеграмманы укыды. Анда Мөслимев Сәхибәнең тиз генә килеп җитүен үтенгән, ансыз тора алмаячагын белдергән иде. Нәфисә иренең фамилиясен, үз өенең адресын кабат-кабат укыгач тынып калды.

— Мөслимев шундый начар кешемени? — диде Сәхибә. Тагын урыныннан кузгалды. Нәфисә әле һаман телеграмманы тотып сүзсез утыра иде. — Миңа рәнҗемәгез, гафу итегез, Нәфисә апа, минем гаебем юк. Юләрлегем генә булса инде, сезне һич тә онытмам... — Сәхибә, ашыга-ашыга шушы сүзләрне әйтеп, ишеккә таба китте.

— Туктагыз! Туктагыз әле!..

— Мин сезне бер дә онытмам...

— Сәхибә!..

— Хушыгыз!

Нәфисә йөгереп чыкса да, куып җитә алмады. Сәхибә баскычтан төшеп, күздән югалган иде. Кайгысын кочкә тыеп торган кыз коридорга чыгу белән елап җибәрде. Нәкъ шул вакыт каршысына килеп чыккан Салтанатбикәне Сәхибә күрмичә үтеп китте. Аның күрмәве, елап чыгып баруы аркасында иде, күңеленә сөенеч тулган Салтанатбикә, бармагын тешләп, аның артыннан серле караш белән карап калды.

Нәфисә, телеграмманың числосына карап, аның Мөслимев районда чакта ук сугылуын аныклады. Ул моны абайлагач, тагын йөгереп урамга чыкты — Сәхибәдән җилләр искән иде. Инде аны кайдан табасың? Тапса, кочаклап алыр да кире өйгә җитәкләп алып керер иде. Әмма эзе дә калмаган иде...

Нәфисә телеграммага Мөслимевнең катнашы юклыгына ышанды. Тик аны, дөнья эшен белеп булмый, дип, яшереп куйды, иренә күрсәтмәде.

Ул шушы арада Мөслимевнең йөзендә берәр үзгәреш булмасмы икән дип күзәтеп йөрде. Сәхибәне көткән булса, аның килмәвенә хафаланырга, бу кәефсезлек йөзенә чыгарга тиеш иде...

Өченче көн дигәндә Мөслимев эштән чырае сытылып кайтты. Аның әле бер дә мондый хәлгә кергәне юк иде. Кайту белән эш бүлмәсенә кереп китте дә, берни эндәшмәстән, башын ике учы белән тотып өстәл янына утырды.

Нәфисәнең йөрәге сикерә башлады. Менә бит ул... Әгәр Нәфисә көткән үзгәреш шул булса...

Кич җитеп килә иде. Ишегалдындагы сәрби агачының башы җиңелчә чайкалып куюы, балконның ачык ишеге аша яңгыр шыбырдавы ишетелде.

— Нәрсә булды? — диде Нәфисә, тәрәзәләрне ябарга да онытып.

— Гадәттән тыш вакыйга булды, Нәфисә.

Мөслимев, тәрәзәләрне үзе ябып, Нәфисәне үзе янына чакырып кертте дә аңлатып бирде.

Доктор Мөслимев өстеннән шикаять килгән икән. Больницада бүген партбюро утырышы чакырылып, мәсьәлә тикшерелгән. Мөслимев шикаятьнең күп урыннарын хатынына сүзгә-сүз әйтеп бирде: «Күпләр тора торган коммуналь йортта иҗтимагый әхлак кагыйдәләренең бозылуына җәмәгатьчелек дикъкатен җәлеп итүегезне үтенәм. Доктор Мөслимевнең төрле яктан килә торган уйнашчылары аның хатыны белән әрләшеп, әхлаксыз шау-шу, ай-вай, елаш-талаш, чәч йолкулар, бер-берсенең йөзләрен тырнашуларын тамаша итә-итә гыйффәтле хатын-кызларның тәкате корыды».

— Кем язган? — дип сорады күзләре зур булып ачылган, үз колакларына үзе ышанмый утырган Нәфисә.

— «Сәлам белән әчкерсез дустыгыз».

— Исеме юкмы?

— Исеме юк. Әйт әле, Нәфисә, берәрсе килдеме?

Нәфисә гөнаһлы тавыш белән Сәхибә вакыйгасын сөйләп бирде. Телеграмманы күрсәтте.

— Моны әйтми йөрүең яхшы булмады. Мәкер, шөбһә менә шун-

дый нәрсәләрдән башлана. Ярар, соңрак сөйләшербез бу хакта. Әле тагы шунысы бар...

— Тагын нәрсә булды? — дип сорады Нәфисә, «нинди гаебем булса да үз өстемә алам» дигән мәгънә белән карап.

— Өебездәге хәлләрне белешергә комиссия җибәрергә булдылар.

— Абау, ояты...

— Соңыннан, бюрода шикаять хаты кулдан-кулга кереп, доктор Шадиевка килеп керде. «Туктагыз әле! Бу шәхси дошманлык аркасында язылган! Бу минем хатынымның хаты», диде. Хатынымның кулын таныйм, дип ышандырды. Мәсьәлә хәл ителмәде, чөнки шушы хәл аркасында доктор Шадиевның сәламәтлеге кинәт начарланып китте.

Шул вакыт балконның ачык ишегеннән әче итеп кычкырган аваз ишетелде. Нәрсәдер дөбер-шатыр килеп ауды. Аннары елаган тавыш та ишетелде.

Мөслимев, урыныннан торып, костюмын җилкәсенә элде.

— Карыйм әле...

— Нишләмәкче буласың?

— Кереп чыкмый ярамас.

Ире күршеләренә кереп киткәч, Нәфисә елау тавышына колак салып торды. «Мин үземне-үзем буып үтерәм! Гаебе үзегезгә булыр! Үкенерсез әле!» дип чырылдый иде Салтанатбикә. Бераздан тавышы басылды. Ялварган сүзләре ишетелә башлады.

Нәфисә нигәдер Сәхибәне уйлады... Аны алдаган Салтанатбикәнең тавышы колагын ертып, кыргый аваз шикелле керә иде.

Мөслимев алардан чыккач, өметсезлек белән кул селтәде.

— Доктор Шадиев җыелыштан кайткач: «Бергә тора алмыйбыз» дигән икән. Салтанатбикә каравыл кычкыра башлаган.

— Син ни дидең?

— Татулаштырырга көчем җитмәде. Ташлыйм ди, вәссәлам.

— Шадиев өчен борчылам...

— Моңа кадәрге тормышы өченме, киләчәге өченме?

— Үткәне өчен...

Үзбәкчәдән ТӘУФИКЪ ӘЙДИ тәрҗемәсе.

---

Илгиз Кәлимуллин

# ДАН ОРДЕНЫ

ПОЭМАДАН ӨЗЕКЛӘР

●

Һәр тарафта апрель зәңгәрлеге,
Яз кояшы яна яктырып.
...Хәким Айдаровка Дан ордены
Тапшырдылар махсус чакырып.

Котладылар:— Рәхмәт! Яу кырында
Илнең тугры улы булгансың.
Зур бүләге аның сине эзләп
Тапты менә ничә елдан соң?!

...Асфальт юлда уйный якты нурлар,
Атлый Хәким хискә бирелеп.
Офыкларның җылы-йомшаклыгын
Тойды микән шулай ул элек?!

Күпме гомер узгач... Мондый хөрмәт
Куандырмас ничек, җилкетмәс.
Күңеле тулды аның, ил бүләген
Күкрәгенә ипләп беркеткәч.

...Истәлекләр кимер димә икән
Тынгы белми типкән йөрәктә.
«Полкташларымнан ике дусны
Мин ярата идем бигрәк тә.

Әрмән егете Тигран иде берсе,
Икенчесе — Петр, Байкалдан.
Сугыш давыллары эчендә без
Өчәү бергә азмы айкалган?!

Ничек онытылсын бергәләшеп
Юк итүләр дошман сакларын,
Көзге төндә күккә очыртулар
Аэродромда бензин бакларын.

Күзләреннән мәхрүм калды Тигран
Одер өчен сугыш барганда.
Күңел күзе белән ныграк күреп
Көрәшә ул ләкин һаман да.

Ә Петрдай лачын югалырмы?
Тайгада ул совхоз хуҗасы...
Шатлык алып килгән шушы көндә,
Эх, ничек соң бергә буласы!»

●

Йолдызлардан тонык нур сибелә,
Шәһәр инде талган йокыга.
Тәрәзәләр генә ара-тирә
Балкып куя фара утында.

Карт әнкәсе, хатыны һәм кызлары
Күптән йоклый инде төш күреп.
Мең газаплы авыр сугыш юлын
Ята Хәким исенә төшереп:

Яндырылган шәһәр һәм авыллар,
Җимерелгән йортлар, күперләр...
Әсирләрнең сулган, ябык йөзе...
Күз алдыннан китми ул көннәр.

Күпме сагыш-хәсрәт! Кешеләрнең
Башларыннан ниләр кичмәде!
Әле һаман дөрләп торадыр күк
Бухенвальдның газлы мичләре.

Солдат Хәким түзем пехотаның
Авыр йөген салып иңенә,
Утлар-сулар кичеп атлый-атлый
Барып җитте дошман өненә.

Ничә елга шунда беренче кат
Яз җылысын тойды битендә.
Тап төшермәс егет һичбер кайчан
«Без — җиңүче!» дигән исемгә.

Туплар дулап аткан мәхшәр аша
Килде бит ул тыныч көненә...
Күз текәде — әле пыскып яткан
Окопларның кайнар көленә.

Поход кухнялары тирәсендә
Сабыйларның хәлсез тавышы...
Фашизмга хөкем булып яңгырый
Кешелекнең ачы каргышы.

Ап-ак чәчле немец коммунисты
Бар көченә тели дәшәргә:
«Ирек алдык сезнең кулыгыздан
Кабат туып җирдә яшәргә!»

●

Империя канцеляриясенең
Җимерек стенасы алдында
Бии Хәким... Медсестра белән
Ярсып бии Җиңү таңында.

Күрсен дөнья — оста икәнлеген
Сугышырга да аның, җырга да...
Кыз шаярта: имеш, мөмкин синнән
Менә дигән артист чыгарга!

Шәфкать туташының йомшак тавышы
Сихри бер көч бирә егеткә:
Җирдә түгел, кызны әйтерсең ул
Кулларында үзенең биетә.

«Сылукайның якын сердәше бар,
Әй, егетем, шуны онытма!..»
Җир-әнкәне — кояш, йөрәкләрне
Шаян сүзле дуслар җылыта.

●

Тормыш җиңә һәм тантана итә,
Кем соң тоймас аның сулышын!
Ил алдында бурычын үтәп, солдат
Кынысына тыга кылычын.

Һәм әйтә ул: «Җиргә гөнаһсызга
Беркемнең дә каны таммасын...»
Идел буендагы туган йортын
Сагынып искә ала аннан соң.

Искә ала сагынып карт әнкәсен,
Аның яуга озатып калганын.
Тын бакчада үскән чияләрне
Язлар саен чәчәк сарганын.

Искә ала туган-үскән җирен,
Чыгармас ул аны уеннан:
Ил кичергән яра-җәрәхәтләр
Үз тәненә аның уелган.

Халкы түккән кан-яшь аның да бит
Йөрәгенә күчеп саркыды.
Ә соңыннан болар бөтенесе
Җиңүле Май булып балкыды.

Шуңа да ул әнә горурланып
Басып тора рейхстаг кырында.
Зур һөҗүмгә барган чакта алган
Партбилеты йөрәк турында.

Сөенеп күзәтә ул ак каурыйдай
Болытларның күктә гизгәнен.
Солдатның да бүген, маршалның да
Бер үк комач үбә йөзләрен.

Уйлап алды Хәким маршал белән
Бергә төшкән рәсем хакында.
Әнә ич ул, әнә, үзе тора:
Дусларының тыгыз сафында.

...Дан ордены эзләп тапты аны,
Ил онытмый үзенең улларын.
Ир егетнең эзен суытырга
Көч-кодрәте җитми елларның!

**РӘШИТ ГӘРӘЙ** тәрҗемәсе.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**МАЙ, 1975 ЕЛ**

Старый Сокол автотрактор электр җиһазлары заводы коллективы фашистик Германияне җиңү көненә утыз ел тулу уңае белән алынган йөкләмәләрне вакытыннан элек үтәп, хезмәт темпын үстергәннән-үстерә бара.

Ярышка катнашучылар Кама автогиганты заказларын үтәүне аерым контроль астына алдылар. Күптән түгел, алдан билгеләнгән сроктан ун көн элек, җыю цехы коллективы «РС-335» маркалы электр магнитларының беренче промышленность партиясен әзерләп бетерде. Приборлар КамАЗга озатылды.

ТАСС, Старый Сокол, Белгород өлкәсе.

Кама автомобиль комплексын төзүчеләр алтынчы тапкыр тантаналы Беренче май демонстрациясенә чыктылар. Төзүчеләр, монтажчылар, эксплуатациячеләр апрель аенда социалистик ярышта яулап алган байраклар күтәргәннәр. Бишьеллыкның бу зур төзелешенә катнашучыларның исеме хәзер бөтен илебезгә билгеле. Социалистик Хезмәт Герое А. Новолодский, Н. Абдуллин, Н. Шемякин, Л. Кольпов, К. Аличиков исемнәрен кемнәр генә белми! КамАЗның беренче карлыгачы — ремонт-инструменталь завод сафка басты һәм уңышлы эшли. Шәһәр яңы зонасының индустриаль нигезе көннән-көн ныгый. Кама елгасы буенда гүзәл шәһәр барлыкка килде, анда ике йөз меңнән артык кеше яши.

Беренче май бәйрәме һәм совет халкының фашистик Германияне җиңүенә утыз ел тулу уңае белән хезмәт вахтасына басып, төзелештәге яшьләр, сугыш һәм хезмәт ветераннары белән берлектә, беренче квартал заданиеләрен уңышлы үтәделәр. КамАЗның төп корпусларында 174 мең квадрат метр производство мәйданнары төзелде. Хәзер биредә технологик җиһазларны монтажлау эшләре киң җәелде.

Ал байраклар белән бизәлгән Чаллының үзәк урамында — Гидротөзүчеләр проспектында — бәйрәм демонстрациясе өч сәгатьтән артык дәвам итте. Ул КамАЗ кешеләренең хезмәттәге зур уңышларын, партиянең XXV съездын яңа казанышлар белән каршыларга омтылышын тагын бер кабат раслады.

«Советская Татария», Казан.

— Мин үземнең полкташ дусларым белән Ленин шәһәреннән Эльба ярларына кадәр авыр сугыш юлы үттем. Сугыш бөек җиңү белән тәмамланганнан соң, Чиләбе өлкәсендәге Нязепетровск шәһәренә кайттым. Аннан КамАЗга килдем.

Ел башында Бөек Ватан сугышы ветераннары барлык төзүчеләрне Бөек Җиңүнең 30 еллыгы хөрмәтенә гвардия хезмәте вахтасына басарга чакырганнар иде.

Бер мең ярым егетләр һәм кызлар «Үзем өчен һәм сугышта һәлак булган егет өчен» девизы белән эшләргә керешә.

Зиятдин Арсланов, Дан орденнарының тулы кавалеры, «Камэнергострой» автомобиль транспорты идарәсенең электр һәм газ белән эретеп ябыштыру остасы.

«Труд», Мәскәү.

Балта остасы-бетончылар бригадиры П. Дорошенко белән прораб Р. Гайнуллин нигездәге анкер коелары әзерләү өчен гади генә кондуктор ясады. Бу кондукторны куллану нәтиҗәсендә җыю заводында балта остасы-бетончылар эшне элеккегә караганда 3—4 мәртәбә тизрәк һәм яхшы сыйфатлы итеп башкаралар.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

Беренче июньнән башлап Бигеш аэропортыннан Харьковка, Симферопольгә, Минеральное Воды, Сочи, Омск һәм Новосибирск шәһәрләренә самолетларның регуляр рейслары башланачак. Мәскәү, Казан, Волгоград, Пенза, Воронеж, Тула шәһәрләре маршрутлары буенча самолетларның очышы ешаячак.

Аэрофлотның шәһәр агентствосында яңа касса ачылу пассажирларга хезмәт күрсәтүне тагы да уңайлаштыра.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

Чаллы шәһәренең үзәк магистрале — патриот шагыйрь, Советлар Союзы Герое Муса Җәлил исемендәге проспектта Бөек Ватан сугышында һәлак булган батырларга һәйкәл ачылды. Монумент Чаллы яшьләренең өмәләрдә эшләгән акчалары хисабына салынды.

«Труд», Мәскәү.

«Энергетик» культура сараенда сайлаучылар РСФСР Верховный Советына депутатлыкка кандидат, КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Рәис Кыям улы Беляев белән очраштылар.

Беренче булып сүзне кандидатның доверенные — «Камгэсэнергострой»ның шәһәр төзү идарәсе начальнигы урынбасары И. И. Зубченко алды. Ул Р. Беляевнең җитәкче буларак хезмәте һәм җәмәгать эшчәнлеге турында сөйләде, сайлаулар көнендә барлык сайлаучыларны Чаллы шәһәренең 860 нчы сайлау округы буенча Рәис Кыям улы Беляевкә тавыш бирергә чакырды.

Җыелышта «Теплоэлектромонтаж» идарәсе монтажчысы Ю. А. Цыганков, бишенче магазин сатучысы Г. Гарипова, РИЗ слесаре А. С. Скрементов һ. б. лар чыгыш ясады. Җыелышка катнашучылар депутатлыкка кандидатка наказлар бирделәр.

Р. Беляев ышаныч күрсәтүләре өчен җыелышка катнашучыларга рәхмәт белдерде.

«Советская Татария», Казан.

**Барлас Камалов**

# ФЕРМА — ЛАУРЕАТ



Беренче кар октябрьның егерме өчендә төште ул елны. Таңнан ява башлаган иде, көне буе туктамады. Җепшек кар, яңгыр катыш. Куаклар, акка төренеп, сыгылып калды. Иртәгесен синоптикларның күрәзәлек сүзләрендә «урыны белән буран» дигәне дә ишетелеп китте. Дөрес, буранлап ук җибәрмәде, мәгәр табигать ике ай чамасы сузылган шыр корылыктан соң явымны кызганмаска булды. Вакыт-вакыт җан өшетердәй салкын җил исте. Тын, тыныч иртәләрне куе томан төтенләп, пыскып торды.

Авыл тынып, күшегеп-боегып калгандай булды. Бары тик юл буйларына җыелган сулардагы каз-үрдәк кенә хафаланмады. Су кошларына ни?! Дөньяны дингез басып китсә дә, гамьнәрендә дә юк, бәйрәм иткәндәй, кыйгаклый-бакылдый бирәләр...

Кырда эшнең инде түгәрәкләнгән чагы. Иң соңыннан җыела торган культура — шикәр чөгендере уңышы да казып алынган, чистартылган, татлы тамыр эшкәртү заводына озатылып беткән иде инде. Ә менә терлекчелек фермаларында мондый көннәр, ни генә дисәң дә, эшне катлауландыра. Сыерлар юешне аерата авыр кичерә. Чиләклэп койган яңгыр яки йөзгә бәреп яуган кар астында эшкә килүчеләргә дә бик ансат түгел. Иң борчыганы — сөт алу кимеп кала. Монысы инде сыер савучы операторларның кәефен кыра да кыра. Алда елның санаулы көннәре калып бара, социалистик йөкләмә дигән сүз белән аңлатыла торган изге бурыч бар, ул һичшиксез үтәлергә тиеш, ә сөт кимеп йөдәтә...

Кинәт көчле җил купты. Ачулы, гайрәтле җил. Ул болыт юрганын ерткалап ташлады, өер-өер болытларны куып таратты. Аннары, минем вазифам шуның белән тәмам дигән кебек, тынып калды. Кешеләр тансыклап өлгергән кояш елмайды. Күк гөмбәзенең зәңгәр киңлегендә нур балкыды. Көн җылынды. Күлләвекләр, бинһая зур көзге кыйпылчыкларыдай ялтырашып, күзне чагылдырды. Күңелгә рәхәт, җанга сихәт булып китә. Нишә сөйләсәң дә бер хакыйкать: кеше җаны яктыга, нурга, җылыга, елмаюга тартыла. Тормышның нигезе балкышта, таңнар алсулыгында, күкләрнең аязлыгында, суларның тоныклыгында!

«Ватан» колхозы үзәге — Күл-Черкен авылына килеп ирешкән куанычлы хәбәр дә көннәр бозылып торганнан соң кояш балкый башлаган сөенечтәй тәэсир итте.

Иртәнге чәйдән әйләнеп килгән председатель Әгъзам Хәсәнов белән партком секретаре Мансур Исмәгыйлов, идарә йорты бусагасында кабат очрашкач, берсе икенчесенә бер үк сорауны бирделәр.

— Ишеттеңме, Әгъзам абый?

— Син ишеттеңме димәкче идем, Мансур...

Татарстан радиосының иртәнге тапшыруында әйтелгән яңалыкны икесе дә ишеткәннәр иде. Яхшы хәбәр канатлы дигәннәр бит.

Колхоз житәкчеләре партком бүлмәсенә керделәр. Председатель стена буендагы урындыкка эшләпәсен, күн перчаткаларын салып куйды да кабинет түрендәге өстәл буена килеп утырды. Урындык, авырлык тоеп, шыгырдап куйгандай булды. Зур, таза кулларын угалаштырып, пальто төймәләрен чишеп җибәрде, пәке белән кырдырганнан соң үсеп килә торган чал чәчләрен сыпырып алды, тамак кырды.

— Егет тә соң безнең кызлар, мәйтәм...— Әгъзам шатлыгын яшерә алмый, яшерергә теләми дә иде. Аның тулы түгәрәк йөзендә елмаю балкый, күзләрендә сөенеч чаткылары биешә. Хәрәкәтләре дә гадәттәгедән житезрәк сыман, бер дә тулы, авыр гәүдәле кешенекенә охшамаган. Шатлыкның яшәртеп җибәрүе шулай була торгандыр, күрәсең.— Булдырдылар яшьләр! Колхозның арка таянычлары дими ни дисең аларны?! Чын уңганнар, тормыш тоткалары, төпкә җигелеп тартучылар!..

Партком секретаре, урта буйлы, саргылт-көрән чәчле, зәңгәр күзле, терекөмештәй хәрәкәтчән Мансур урындыгына утырырга ашыкмады, арлы-бирле йөренеп торды. Сүзгә болай да саран түгел ул, бу көнне исә тагын да җанлана төшкән иде.

— Ферма — лауреат!— Мансур уң кулын өскә күтәрде, гүя үз дикъкатен үзе тупларга теләп иде.— Шәп яңгырый, шәп, Әгъзам абый! Комсомол-яшьләр фермасы дисәң дә җирендә. Фермада тыңладылар микән, әй? Шылтыратыйк әле үзләренә...

Терлекчелек шәһәрчегендә генә түгел, колхозның һәммә бригадаларында да беләләр иде инде яхшы хәбәрне. Төш авышкач, почта кайтып житте. Иң беренче эш итеп республика газеталарын кулга алдылар.

Газеталарда фән, техника, производство өлкәсендә алдынгыларга Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе бирелү турында хәбәр басылган иде. Лауреатлар арасында Буа районы, «Ватан» колхозының комсомол-яшьләр фермасы коллективы да бар!

Ноябрь башында булып узган ВЛКСМ өлкә комитеты пленумында фермага диплом һәм лауреат билгеләре тапшырылды. Кул-Черкен товарлыклы-сөтчелек фермасында эшләүче яшь терлекчеләрнең хезмәт фидакарьлеге фәнни казанышлар һәм КамАЗ төзелеше батырлары уңганлыгы белән янәшә куеп ихтирам ителде.

Комсомол премиясенең дипломы һәм медале терлекчеләр йортының үзәк бүлмәсендә — зур залда — түр урынга куелган. Алар — коллективның горурлыгы да, яңа үрләргә өндәп торучысы да, алмашка киләчәк яшьләргә кыйммәтле үрнәк-өлге дә. Уныньчы, унберенче бишьеллыкларда һәм аннан соң да тормыш юлларын һәм эшчәнлекләрен туган колхозлары белән ныгытып бәйләячәк яшьләр үзләренең өлкән иптәшләре белән — тугызынчы бишьеллык гвардиячеләре белән хаклы горурлана алырлар. Чөнки бу олы бүләк халык җырларына бизәк булып кергән ямьле Зөя елгасы бормаларына сыенып утырган колхозның әйбәт данына яңа мактаныч өстәде.

«Ватан» колхозында булган кеше зирәк фикерле өлкәннәргә дә, сылу-чибәр, уңган-житез һәм белемле-булдыклы яшьләргә дә сокланмый калмый. Ферма коллективындагы кызлар һәм егетләр дә шундый. Сөйләсәләр — сүзләре үтә, эшләсәләр — хезмәтләре җырга тиң.

Ферманы лауреат иткән һәм аннан соңгы уңышларга ирешкән бишьеллык гвардиячеләре кемнәр? Бу сорауга җавап рәвешендә, барыннан да элек, сыер савучыларны, дөресрәге, машина белән саву операторларын санарга туры килә. Алар — Сәрия Хаттапова, Рузия Гыймадиева, Кәүсәрия Насыйбуллина, Рузинә Гайнетдинова, Гүзәл Хәбибуллина, Рушания Камалова, Флүзә Хәбибуллина, Гөлфия Гайнетдинова, Нази-

мә Нигъмәтҗанова, Рәхилә Хәмидуллина. Аннары терлекчелек ветераннары — «Почет билгесе» орденына ия Һаҗәр Хәлиуллинаны, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Фәрханә Насретдинованы да ихтирамлап телгә алу зарур. Көтүчеләрдән Җиһангәрәй Сабирҗанов белән Таһир Шакировның да уртак казанышта өлешләре зур.

Фермадагы күтәрелешнең ни рәвешле барганын колхоз председателе — Октябрь Революциясе һәм «Почет билгесе» орденнары кавалеры, күмәк хуҗалыкка унтугызынчы ел җитәкчелек итүче Әгъзам ага Хәсәнов шактый тәфсилләп сөйләгән иде, аның мәгълүматларын фермада кат-кат булганда Сария Хаттапова һәм Рәшит Сәләхетдинов тулыландырдылар. Савучы-оператор һәм ферма мөдире, яшь булуларына карамастан, шактый тәҗрибә тупларга өлгергән терлекчеләр. Шунысы да игътибарга лаек: алар ата-бабадан килгән мал-туар үрчетү осталары. Сариянең бабасы, авылның иң оста кибән куючысы гына түгел, терлек үрчетүдә кулы җиңел булу белән дә ил теленә кергән мөхтәрәм карт була. Әтисе исә ветеринар, дистәләрчә ел гомерен колхоз фермаларына багышлаган. Рәшитнең бабасын да мал-туарны нечкәләп таныган кеше итеп хәтерлиләр. Ул: «Сигез сыер асраганчы сигез сыер асра!» дигән хакыйкатьне күңеленә нык киртләп куйган булган. Әтисе Миңлевәли агай әле дә дуңгызлар фермасында мөдир.

Бала чактан терлек-туар белән мавыгып, аларны карап, өйрәнеп үскән кешеләр булганга, аларның колхоз терлекчелегендәге хәлләргә төпле карашына аеруча колак саласы килә. Яшь терлекчеләр бүген хәлиткеч көч кенә түгел, киләчәк казанышлары да алар кулында.

Производствоның төп терәкләре булган кешеләр фикеренчә, уңыш дүрт терәккә таянып туа. Шуларның берсе булмаса да, күпне өмет итәр хәл юк.

Иң әүвәле шул: мал-туар өчен һәммә шарты килгән торак кирәк. Шарты дигәннән, җылы, якты, вентиляцияле абзар күздә тотыла, автоэчергеч булу, азык өләшүне, тирес чыгаруны машинага көйләү таләбе куела. Үзеннән-үзе аңлашылганча, машина белән саву — заман әмере. «Ватан» колхозында бу таләпләрнең һәркайсы җиренә җиткереп үтәлә. Менә дигән «терлекчелек шәһәрчеге» төзелгән. Йөзәр баш сыерга исәпләнгән алты корпустан һәм терлекчеләр йортыннан торган комплексны монда шулай атыйлар.

Икенчедән, терлекләрнең токымы яхшы булырга тиеш. Күл-Черкен фермасында бу җәһәттән соңгы елларда гаҗәеп зур эш гамәлгә ашырыла. 1972 елда Литва ССРның Капсукас районыннан Шешупе елгасы буйларында үскән 61 баш кара-чуар тана сатып алалар. Бер елдан соң Ленинград өлкәсенең Выборг районыннан шул ук токымдагы 180 баш тана алып кайтыла. Шулай итеп, ферма өр-яңадан оештырылды булып чыга. Ерак элгәрләре Голландиянең атаклы сөтлебикәләре булган бу маллар «Ватан» колхозчыларының өметен тулысынча аклый. Киләчәктә колхоз үзе күршеләргә нәселле яшь терлекләр сатачак.

Өченче зур шарт — ныклы азык базасы булдыру. Монысы да йөз процентган үтәлеп бара. Тупас азыклар, силос һәм сенаж, комбиазыклар елның-елында мул әзерләнә. Шунлыктан маллар кытлык белмиләр. Сугарылулы көтүлекләр дә савым сыер башына 0,60 гектар туры килә. Әлеге күрсәткеч республика дәрәҗәсеннән караганда да әйбәт дия торган.

Инде төп шартларның иң мөһиме — кадрлар мәсьәләсе. «Ватан»да бу проблема уңышлы хәл кылынган дип авыз тутырып әйтергә мөмкин. Сыер савучылар барысы да урта белемле, бик күбесе класслы терлекче. Тәҗрибәлеләр яшьләргә бик теләп булышалар, фермага яңа килүчеләр исә күңел биреп өйрәнәләр. Зооветеринария укулары нәтиҗәле булсын дип үткәрелә, турыдан-туры бүгенге бурычларга бәйләп алып барыла. Эш шартлары һич кенә дә зарланырлык түгел. Ике смена белән эшли-

ләр. Ялга да, өй эшләрен карарга да, семьяда булырга да вакыт кала. Алай гына да түгел, кинога, спектакльләргә йөрергә, телевизор карарга, матур әдәбият укырга мөмкинлек зур.

Төп хезмәттән тыш вакыт булганга күрә дә, терлекче яшьләр үзешчән сәнгатьтә актив катнашалар. Рузия Гыймадиеваның сәхнәдә җырлавын, Сария Хаттапованың спектакльләрдә катнашуын авылдашлары яратып карыйлар һәм тыңлыйлар. Хәер, ферма мөдире үзе дә бу яктан күпләргә үрнәк. Койган да куйган артист. Аның Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры»нда Басыйр ролен башкарганын, мәсәлән, тиз генә онытырлар микән?! Ә бит Рәшит Сәлахетдинов техникум тәмамлаганнан соң Казан дәүләт ветеринария институтында читтән торып белем ала. Вузда укуның күпме вакыт даулаганын һәркем чамалый булса кирәк.

Чираттагы ялларын алгач, кызлар Балтик буе республикаларына һәм халык демократиясе илләренә барып кайттылар.

Кыскасы, терлекләрнең баш санын ишәйтү өчен дә, продукцияне мул җитештерү өчен дә шартлар җитәрлек.

Ветераннар бүгенге яшьләр өчен сөенеп, үзләре тырышып-тырмашып сыер сауган еллардагы хәлне хәтерлиләр. Һаҗәр Хәлиуллина: «Хәзерге яшьләрнең эш шартларына, тормышның муллыгына сокланып бетәрлек түгел»,— ди икән, ул бит үтә хаклы. Һаҗәр сыер сауган чорда (ул хәзер бозаулар карый) байтак колхозларда сөт алу хәзерге белән чагыштырганда юк дәрәҗәсендә аз була. Сәбәпләре бер генә төрле булмаган аның. Торак җитмәгән, ашатырга азыкны көч-хәл белән теткәзәләр, хезмәткә түләү кадәре дә быеллардагы белән һич чагыштырулы булмый. Белгечләре дә соңгы еллардагы шикелле укыган да, тәҗрибәле дә түгел... Хәлләр бик авыр булса да, таң карасыннан төн карасына кадәр эшләргә туры килә.

Тугызынчы бишьеллыкның беренче елында ук «Ватан» сөтчеләре үзләре белән ярышучы «Коммуна» колхозының сыер савучыларын узა: һәр сыердан 2 898 килограмм сөт алына. Җитмеш өченче елда бу сан 3 163 килограммга, җитмеш дүртенче елда 3 318 килограммга җитә. Колхоз сөт савып алу буенча районда беренче урынга чыга. Яшьләр фермасында исә сыер башына 3 333 килограмм продукция туры килә. Бишьеллыкны тәмамлау елында да сынатмый алар — һәр сыердан өч мең биш йөз килограмм сөт саварга дигән сүзләре үтәлә.

Халык хак әйтә: хезмәтенә күрә хөрмәте. Ферма-лауреатның тугызынчы бишьеллыктагы күркәм эшләренә бәя — СССР Авыл хуҗалыгы министрлыгы, авыл хуҗалыгы һәм хәзерләүләр эшчеләре һәм хезмәткәрләренең профсоюзлар үзәк комитеты биргән Почет грамотасы, РСФСР Министрлар Советының һәм ВЦСПСның байрагы, ВЛКСМ Үзәк Комитетының вымпелы, Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең медальләре...

Лауреатны «адашлары» да онытмый. Әдәбият-сәнгать өлкәсендә Муса Җәлил премиясе лауреатлары шагыйрьләр Илдар Юзеев, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, драматург Туфан Миңнуллин комсомол-яшьләр фермасы коллективына үзләренең китапларын бүләк итәләр. Аларның автографларында ил табынына мул сый куючыларның эшләрендә яңа уңышлар теләү язылган.

Хәзер — унынчы бишьеллыкта — яңа зур бурычлар, яңа биеклекләр. Аларга менү ансат булмаячак. Ферма урталыкта барганда, алга ыргылу чагыштырмача җиңелрәк була. Ник дигәндә, файдаланылмаган резервлар күз алдында, уч төбендәге кебек күренеп торган чак. Алар хәзер дә бар, ләкин табып эшкә җигү өчен караш үткеррәк, акыл зирәгрәк булырга тиеш. Мәгәр шикләнми әйтергә мөмкин, комсомол премиясе лауреаты булган ферма коллективы ул биеклекләрне яуларга сәләтле! Герой-шагыйрьнең сүнмәс-сүрелмәс рухы замана яшьләренә көч-кодрәт өсти.

## Самат Шакир

# МУСА БЕЛӘН ОЧРАШКАН БАҺАДИР

«Мин синең апрельдә язган хатыңны алып, шунда ук җавап яздым. Командованиегә язган хатыңны үземдә саклыйм әле. Редакторга күрсәттем. Ул минем эшемә хәленнән килгән кадәр ярдәм итәргә: мине үземә кирәкле җиргә җибәрергә вәгъдә итте. Без аның белән миңа кая китәргә яхшырак булуы турында сөйләштек. Беренче чиратта, хәрби походыбызның дәвамында (без хәзер аерым положениедә) бер пунктка җитү белән, миңа самолетта авиаполкка очарга дип сөйләштек. Шул авиаполкта ике тапкыр орден алган герой-штурман, капитан Гали Борһан хезмәт итә. Ул 118 тапкыр хәрби очыш ясаган һәм өч тапкыр Берлинны бомбага тоткан. Мин аның белән болай күрмичә генә таныш, аның сугыштагы батырлыкларын беләм, ләкин үзен күргәнем юк әле...»

Бу — Муса Җәлилнең 1942 елның 3 июнендә Волхов фронтыннан язучы Гази Кашшафка язган хаты.

Муса Җәлил бу батыр очучы турында очерк язарга теләгән. Ул Гали Борһанны күргәнме, аның белән сөйләшкәнме? Очерк язылганмы, юкмы? Чолганышта калу һәм яралы хәлдә пленга эләгү нәтиҗәсендә бу очерк та фашистлар кулына эләкмәгәнме? Бу турыда без бернәрсә дә белми идек. Моны ачыклау өчен башта штурман Гали Борһановны эзләп табарга кирәк иде. Безгә Борһанов фамилиясендәге берничә очучы-штурманның адресын бирделәр. Ләкин берсе дә без эзләгән Гали Борһанов булып чыкмады. Ә менә Волхов фронтындагы ике Борһановның икесе дә очучы-штурман булуы һәм икесенең дә һава сугышлары вакытында һәлак булулары мәгълүм булды. Шулай итеп, очучы-штурман Гали Борһановны табу өмете сүрелде.

Архивларда күп эзләнә торгач, без Гали Борһановның Ульяновск өлкәсенең Николаевск районы, Курмаевка авылында туганлыгын белдек. Бу авылга хат язып салдык. Ниһаять, шатлыклы хәбәр килде. Гали Әмин улы Борһановның сугыштан исән-сау кайтуы, хәзерге көндә Куйбышев шәһәрендә торуын яздылар. Шулай итеп, озак еллар буе эзләгән кешене таптык һәм аның белән элемтәгә кердек.

Борһанов Гали Әмин улы 1912 елда туган. Үз авылларында — Курмаевкада берникадәр торганнан соң, әтисе үлеп китү сәбәпле,

балалар йортында тәрбияләнә, тырыш укучыларның берсе була. Бала вакыттан ук әдәби китаплар укырга ярата, үзе дә җырлар, бәетләр яза. Татар халык шагыйре Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури һәм Һади Такташ китапларын йотлыгып укый. Балалар йортына татар телендә чыга торган газета-журналлар килеп тора. Яшүсмер Гали андагы шигырьләрне күңеленә ятлый һәм концертларда сөйли. Аның «Чаян» журналындагы сатирик шигырьләрне аерата оста сөйләве халыкка ошый. Ул әнә шул елларда атаклы очучылар, батыр сәяхәтчеләр һәм гражданнар сугышы каһарманнары турында бик кызыксынып укый. Үсә төшкәч, Гали Борһанов тирә-күрше авыллардагы сабан туйларында көрәшкә катнаша. Аны үз авылларында «көрәшче Гали» дип йөртәләр. Аннан соң Гали Борһанов Мәләкәсс шәһәренә килә, совет-партия мәктәбендә укый. 1932 елны үзе теләп Кызыл Армия сафына китә. Казанда хәрби училище тәмамлый һәм отделение командиры була. Бала чагыннан ук күңеленә сеңгән очучы булу теләген тормышка ашырырга тырыша. Ниһаять, ул Оренбургтагы хәрби очучылар мәктәбендә. Хәрби мәктәпне уңышлы тәмамлый һәм лейтенант званиесе алып, авиачастьта хезмәт итә башлый.

Немец фашистлары Ватаныбызга бандитларча басып кергән көннәрдә Гали Борһанов инде өлкән лейтенант була. Ул башта Үзәк фронтта сугыша, дошманның танкларын һәм үзйөрешле орудиеләрен бомбага тота. Бу куркусыз очучы иң каты һава сугышларында катнаша, Лондонны, Парижны, Афинаны бомбага тоткан, ике-өч тимер тәре алган фашист очучыларын бәреп төшерә.

1941 елны немецлар Мәскәүне бомбага тота башлагач, безнең батыр очучыларга, аларга җавап итеп, Берлинны бомбага тотарга приказ бирелә. Фашизм оясын беренче тапкыр бомбага тотуда татар халкының батыр улы Гали Борһанов та катнаша.

Фашистлар разведкасы сугыш башланыр алдыннан Гитлерны тынычландырып: «Бер генә Совет самолеты да Берлинга кадәр килеп җитә алмаячак һәм шәһәр өстенә бер бомба да ташлый алмаячак», — дигән мәгълүмат бирә. Чөнки ул вакытта безнең илебездә еракка оча торган самолетлар бик аз әле, алары да зур һәм авыр бомбаларны күтәрерлек хәлдә булмый. Шуның өчен сугышның беренче атналарында немецлар авиациясе һавада өстенлек итә һәм фашистлар бөтен дөньяга: «Безнең самолетлар иң тиз һәм иң ерак очалар, авыр бомбаларны җир шарының иң ерак шәһәрләренә илтеп ташлый алалар!» — дип шапырыналар. Геббельс һәм аның ялчылары: «Немец самолетлары Мәскәүне бомбага тотып җимереп бетерделәр!» — дип, радиодан акыралар, газеталарга язалар. Безнең хөкүмәт җитәкчеләре бу ялган уйдырманы юкка чыгару өчен бөтен чараларны күрә. СССР Оборона Халык Комиссариатында самолетларның сыйфатын яхшырту, аларның, авыр йөк күтәргән хәлдә, тиз һәм еракка очуларын булдыру, яңа тип конструкциядәге самолетлар эшләп чыгару, очучыларның очу осталыгын күтәрү мәсьәләсе карала. Верховный башкомандованиенең күрсәтмәсе нигезендә иң оста һәм батыр очучы-штурманнарны генштабка чакыралар. Монда иң мөһим мәсьәлә хәл ителә: гитлерчылар авиациясенең өстенлеге турындагы мифларны юкка чыгару планы эшләнә.

Моңа кадәр сыналган батыр очучы-штурманнарга җаваплы задание бирелә: еракка оча торган самолетлар белән Берлинга барырга һәм фашизм оясын бомбага тотарга!

Очучы-штурманнар белән аерым-аерым әңгәмә үткәрелә, врачлар аларның сәламәтлекләрен кабат карыйлар, очучы-сынаучылар яңа төр самолетларга сынау үткәрәләр, аларның очу тизлекләрен һәм

авыр бомбаларны күтәрү мөмкинлекләрен җентекләп тикшерәләр. Хәзерлек тәмам булганнан соң, очучы-штурманнар Кремльдә булалар. 1941 елның август башларында алар һавага күтәреләләр һәм Берлинга юл тоталар. Гали Әмин улы Борһанов та, югарыда әйткәнебезчә, атаклы очучылар белән берлектә, Берлинны бомбага тотуда катнаша.

Совет самолетлары Берлинны бомбага тотып киткәч, моңа кадәр булган җиңүләр белән башы әйләнгән Гитлер, бу хурлыклы хәлгә чыдый алмыйча ярсыган хәлдә, генералларның күбесен эшеннән алып ташлый.

Берлинны бомбага тотудагы батырлыклары өчен СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән Гали Әмин улы Борһановка Ленин ордены бирелә. Соңга таба ул капитан дәрәҗәсенә күтәрелә һәм Волхов фронтына — Икенче Удар армиягә җибәрелә. Монда да Гали Борһанов дошманның бик күп техникасын һәм җанлы көчләрен юкка чыгара. Аның батырлыклары турында фронт газетасында да берничә тапкыр язып чыгалар.

Муса Җәлил белән капитан Гали Борһанов берничә тапкыр очраша, Муса бу штурман белән бик кызыксына, аның сугышчан очышлары турында блокнотына күп нәрсәләр язып ала.

Гали Борһанов бу турыда болай сөйли:

— Җәйге көннәрнең берсе иде. Тирә-якта сугыш гарасаты. Янып төшкән самолетлар, җимерелгән танклар, үзйөрешле орудиеләр, үлгән солдатлар һәм офицерлар. Немецлар, Германиядән өстәмә көчләр китертеп, фронтның бу участогына һөҗүм арты һөҗүм ясыйлар. Дошман самолетлары, дулкын-дулкын булып килеп, безнең гаскәрләр өстенә авыр бомбалар коя. Менә шундый авыр һәм күңелсез, борчулы көн иде. Без, дошманның җанлы көчләрен һәм техникасын бомбага тотып, үз базабызга кайттык. Бу вакытта Волхов фронтында эшләр шәптән түгел иде. Кәеф начар, эч поша, ирексездән туктаусыз тартасың. Менә шулай тәмәке көйрәтеп йөренгән вакытта миңа бер очучы ягымлы тавыш белән эндәште:

— Капитан Борһанов! Сезнең янга бер политрук килгән. Сезнең белән сөйләшергә тели.

Мин борылып карадым һәм әлеге политрукны күреп:

— Исәнмесез! — дип кул суздым. Без кул кысышып күрештек. Ул миңа ягымлы карап:

— Муса Җәлилов булам! — диде.

Башта мин аның шагыйрь Муса Җәлил икәнен белми тордым. Ул кыр сумкасын ипләбрәк куеп, минем белән сөйләшә башлады. Озак сөйләшеп торырга вакыт бик тар, шуның өчен турыдан-туры минем Берлинны бомбага тотуым турында сораулар бирде, Волхов фронтына кайчан килүем, соңгы вакытта күрсәткән батырлыкларым, немец самолетларын яндыру һәм таранга алуым турында кызыксынды. Мин сөйли башлагач, кыр сумкасын ачып, аннан блокнот һәм карандаш чыгарып, тиз-тиз генә яза башлады. Аерата ул Берлинга кайчан барып җитүебез, нинди бомбалар ташлавыбыз, дошманның зенит тупларыннан аткан снарядлардан ничек котылуыбыз, янып торган Берлин күренешләре белән кызыксынды. Күбрәк бергә очкан дусларым турында сөйләргә тырыштым. Әмма Җәлилов мине бүлдереп:

— Үзең турында да сөйлә. Мин синең батырлыкларың турында язу өчен махсус рәвештә фронт газетасыннан килдем, — диде.

Без озак сөйләштек. Мин үземнең тормыш юлым турында да, очучы булып кайчаннан бирле хезмәт итүем турында да әйттем. Политрук Җәлилов блокнотына минем сөйләгәннәрнең барысын да

тиз-тиз генә яза барды. Соңыннан ул үзенең шагыйрь Муса Җәлил икәнлеген әйтте. Мин исә, тере язучыны беренче күргәнлектән, гаҗәпләнеп аңа карадым. Ул моны аңлады булса кирәк, аркамнан кагып:

— Нигә гаҗәпкә калдың? — дип сорады.

Мин кыяр-кыймас кына әйттем:

— Тере язучыны беренче тапкыр күрәм. Сезнең китапларны укыганым бар иде. Ә үзегезне күргәнем юк.

Нәкъ шул вакытта еракта туп гөрелтеләре ишетелде. Безнең «Катюша»лар фашистлар өстенә ут яудыра башладылар.

— Фашистларның көннәре санаулы! Ләкин алар, кетмәгәндә һөҗүм иткәнлектән, безнең җиребезгә шактый тирән үтеп керделәр. Сугыш озак барыр әле. Кем белә, бәлки туган якларга исән-сау кайтып, семьялар, туган-тумачалар белән күрешеп тә булмас. Сугыш корбансыз булмый бит ул. Әмма сугышта үзең үлсәң дә, үлгәннән соң сине телгә алырлык батырлык эшләргә кирәк! — ди аңа Муса.

Гали Борһанов бала вакытында Муса Җәлилнең шигырьләрен бик яратып укыган, кайберләрен күңелдән белгән. Шагыйрь белән очрашу аңа зур тәэсир итә һәм икенче мәртәбә очрашканда алар кочаклашып күрешәләр. Муса Җәлил аның фашизм оясы — Берлинны бомбага тотуы турында өстәмә материаллар ала. Үзенең яңа язган шигырьләрен укып күрсәтә.

Соңгы тапкыр очрашканда Муса Җәлил Гали Борһанов турында очерк язуын, киләчәктә аны зурайтып «Татар халкының батыр улы» дигән исемдә китап итеп чыгарачагын әйтә. Ләкин Муса китеп озак та үтми, фронтта зур үзгәрешләр була, фашистлар Икенче Удар армияне чолгап алалар, көн-төн каты сугышлар дәвам итә...

Очучы-штурман Гали Борһанов турында очерк фронт газетасында басылып чыкканмы, юкмы, без белә алмадык. Муса Җәлил эшләгән фронт газетасы «Отвага»ның күп саннары югалган. Ә очеркның төп нөсхәсе Муса Җәлил тарафыннан юкка чыгарылган, яки фашистлар кулына эләккән булуы мөмкин.

Ә штурман Гали Борһановның батырлыклары турында чыннан да аерым китап язарлык. Менә шулардан бер эпизод.

Дошманның көче тупланган зур станцияне бомбага тотарга приказ бирелә. Совет очучылары һавага күтәреләләр. Алар арасында Ленин ордены белән бүләкләнгән Гали Борһанов та була. Көтмәгәндә «Мессершмитт»лар килеп чыга. Кара тәреле самолетларга каршы атыш башлана. Һава дуэле озак дәвам итә. Гали Борһанов иң алда килүче фашист козгынына пулеметтан ата. «Мессершмитт» өстендә ялкын һәм төтен күтәрелә. Икенче немец самолетын ул винт белән кистерә. Моны күргән өченче фашист качу ягын карый... Кыю штурман аның артыннан куа китә һәм пулеметтан атып җиргә мәтәлдерә. Самолет артыннан кара төтен баганасы гына сузылып кала.

— Сезгә күптән шул кирәк! — ди Борһанов.

Алар, фашист самолетларын тар-мар итеп, тиешле урынга барып җитәләр. Немецларның зенит туплары туктаусыз атып торуга да карамастан, станцияне бомбага тоталар, бик күп танклар төялгән эшелоннарны, бензин бакларын яндыралар. Станция өстендә ут-ялкын күтәрелә...

Командование батыр очучыларга зур рәхмәт белдерә һәм орденнар белән бүләкли. Бу батырлыгы өчен очучы-штурман Гали Борһанов Кызыл Байрак ордены ала.

Дошманны бөтен фронт буенча куу башлана. Көнчыгыш Пруссия өчен сугышларда очучылар аерата батыр көрәшә. Немец генералы фон Ляж бер адым да чигенмәскә һәм капитуляция ясамаска дип боера. Хәтта ул кан коюны туктатырга һәм капитуляция ясарга ча-

кырып җибәрелгән парламентерларны аттыра. Бу хәбәрне ишеткәч, Совет Армиясе сугышчылары дошманга җирдән, судан һәм һавадан бик каты һөҗүм башлыйлар. Борһанов бу һөҗүмнәргә актив катнаша. Совет Армиясе сугышчыларына алга юл яра.

Берлин өчен каты сугышлар башлана. Бу вакытта Гали Борһанов һава армиясенең штурман бүлеге начальнигы була. Икенче Балтик буе фронты сугышчылары белән берлектә Гали Борһанов җитәкчелегендәге очучы-штурманнар да фашизм оясын — Берлинны бомбага тоталар. Атаклы очучы Гали Борһанов яңадан Берлин өстендә. Дөньяны яулап алырга хыялланган гитлерчылар оясы тәмам җимерелгән инде. Хәзер анда — аста — Берлин төрмәләренең берсендә баһадир шагыйрь Муса Җәлилнең фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелүен белми әле Гали Борһанов.

Бөек Ватан сугышы безнең җиңү белән тәмам булды. Бу вакытта инде Гали Борһанов — авиация полковнигы. Ул Совет Армиясенең Хәрби һава көчләре академиясе каршындагы өлкән штурманнар курсында укый.

Полковник Гали Борһанов 1959 елда пенсиягә чыга. Ләкин хезмәт сөюче тынгысыз кеше эшсез тора алмый — ул Куйбышев шәһәренең үзәк аэродромында штурман булып эшли.

Безнең якташыбыз штурман Гали Борһанов батырлыклары өчен ике Ленин ордены, өч мәртәбә Кызыл Байрак ордены, Ватан Сугышы ордены, Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә. Ул барлыгы 216 сугышчан очыш ясый, фашистларның бик күп техникасын һәм җанлы көчләрен юкка чыгара. Герой-шагыйрь Муса Җәлил мондый кешеләр турында болай дип язды:

Тар-мар итеп коллык, караңгылык
Саклап яткан дошман оясын,
Каны белән халык саклап калды
Кешелекнең якты кояшын!

Зәки Әхмәтҗанов

# ДАЛА ЕГЕТЕ

*«1943 елның 25 августыннан 6 октябрена кадәр Киев юнәлешендә барган сугышларда үзен кыю, тапкыр, көчле ихтыярлы һәм тәвәккәл сугышчы итеп танытты.*

*Полкта, автоматчылар ротасының парторгы буларак, сугышчылар белән һәр вакыт ныклы бәйләнештә булды.*

*Немец-фашист гаскәрләренә каршы көчле сугышларда ротаның бөтен сугышчыларын үзенең шәхси батырлыгы белән җиңүгә рухландырды».*

*(СССР Оборона министрлыгы архивы, 33 фонд, 793756 тасвирлама, 1 эш, 144 бит. Советлар Союзы Герое Сәлим Айткуловның бүләкләү кәгазеннән.)*



Полк командирының приказы бу юлы Сәлим өчен аеруча коры һәм таләпчән булып яңгырады.

— Нәрсә эшләргә кирәген аңладыгызмы? — диде гвардия подполковнигы Маковецкий, аның күзләренә туры карап, — кабатлагыз!

— Әйе, аңладым, иптәш подполковник, — диде ефрейтор һәм честь биреп приказны кабатлады:

— Отделение белән дошман тылына үтеп керергә, аларның алгы сызыктагы көчләрен күзәтергә һәм «тел» алып кайтырга.

— Сезнең бу операцияне төгәл үтәвегезгә бик күп нәрсә, барыннан да бигрәк, бик күп сугышчыларның язмышы бәйле, иптәш Айткулов. Мин сезнең кыюлыгыгызга, сабырлыгыгызга ышанам.

— Барысы да эшләнер, иптәш подполковник, — дип, Сәлим командирның сүзләрен хуплап башын иде. Аннан соң өлегә кадәр аркасына аскан автоматын салып кулына тотты да штаб землянкасының ишегенә эленгән одеялны ачып чыгып китте.

— Сүз тидереп булмый, Урал, Себер егетләре яхшы сугышалар, — дип куйды полк командиры, Айткуловны озаткач...

Урал...

Әйе, Сәлим Айткулов армиягә Урал буйларыннан, Уральск шәһәреннән алынган. 1905 ел чуалышлары вакытында әти-әниләре Татарстан җирләреннән бәхет эзләп киткән. Ә Сәлим 1913 елда Көнбатыш Казагыстан өлкәсендә Җаегалин районы, Мухар авылында туган. Сәлимгә 5 яшь вакытта әтисе Нигъмәт абзыйны ак казаклар җәзалап үтергәннәр. Әнисе икенче тормыш корганда, 6 яшьлек Сәлимне көтүчелеккә биргәннәр. Ул алты ел буена Казагыстан далаларында көтү көтеп тамак туйдырган. 1926 елда

аны Уральск шәһәренә китереп, балалар йортына тапшырганнар. (Сәлим Айткулов үзенең хатында шул ук балалар йортында күренекле композитор Нәҗип Җиһановның да тәрбияләнүе турында яза.) Анда беренче баскыч мәктәпне тәмамлагач, авыл хуҗалыгы техникумында укыган, комсомол сафына кабул ителгән. Соңрак бухгалтерлар курсын тәмамлаган һәм сугышның беренче көннәренә кадәр бухгалтер булып эшләгән.

Бөек Ватан сугышы башланып бер ай үтүгә, Сәлим армия сафына чакырыла. Иң элек ул Ерак Көнчыгышта хезмәт итә. 1942 елның декабрендә Үзәк фронтта хәрәкәт итүче 75 нче Кызыл Байраклы гвардия укчы дивизиясе составындагы 231 нче гвардия укчы полкында автоматчы-укчылар отделениесе командиры булып сугышчан юлын башлый. Башыннан ахырына кадәр Орел-Курск дугасында булган сугышларга катнаша, һәм менә алда — киң Днепр, Киев...

Полк командиры янынннан үзләренең блиндажына кайткач, Айткулов иптәшләренә куелган бурычның ни дәрәҗәдә мөһим булуын аңлата. Операция вакытында кемнең кайсы төркемдә хәрәкәт итәчәген билгели.

Караңгы төшү белән разведчиклар юлга чыгалар. Шактый вакыт бер урында оборонада торганлыктан, алдан ук җентекләп өйрәнелгән, күзәтелгән участок аша үтүе әллә ни кыен булмый. Алар тавыш-тынсыз гына, иң мөһиме — югалтуларсыз, дошманның полк участогындагы ут ояларын санап, урыннарын билгеләп, таң атканчы әйләнеп тә кайталар. Үзләре белән куллары артка бәйләнгән, уртача буйлы, салам төсле чәчле немец обер-ефрейторын да «ияртәләр». Айткулов өчен беренче операция уңышлы тәмамлана. Разведчиклар барысы да «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнәләр.

Разведчик. Аның беренче коралы — батырлык, тапкырлык, кыюлык. Дөрес, бу сыйфатлар безнең һәр сугышчыга да хас. Ләкин разведчик өчен алар аеруча кирәк. Чөнки разведчикның кыюлыгына, бик тиз дөрес карарга килеп хәрәкәт итүенә еш кына йөзләрчә иптәшләренең, хәтта бөтен бер сугыш операциясенең дә язмышы бәйләнгән була. Шуңа күрә разведчикка һәр куелган бурычны үтәгәндә үзенең бөтен сыйфатларын, бөтен осталыгын җигеп, күп көч куеп эшләргә туры килә.

*
* *

Безнең гаскәрләрнең Орел һәм Курск янындагы зур җиңүеннән соң дошман, яраланган ерткычтай, һәр мөмкин булган урынга теш-тырнагы белән ябышып, каршылык күрсәтеп чигенә.

Бахмач-2 станциясе янында безнең частьлар да оборонага урнашырга мәҗбүр булалар: ике ай дәвам иткән каты сугышлар нәтиҗәсендә шактый сирәгәйгән техниканы һәм подразделениеләрне тулыландырырга, сугышчыларга ял бирергә кирәк. Ә разведчиклар өчен оборона вакытында да эш тукталып тормый. Чөнки оборона ул ял итүдән, я булмаса үз участогың аша дошманны үткәрмәүдән генә түгел, ә алдагы, булачак һөҗүмгә әзерләнүдән дә гыйбарәт.

Мәсәлән, һөҗүм башлана. Автоматларын югары күтәреп, «Ура!» кычкырып сугышчылар атакага ташланалар. Алда аларны нәрсә көтә? Ыжгырып алга баручы танкларга каршы дошман нинди көчләр куя һәм аларны кай урында туплаган? Кай җирдә нинди резервлар урнашкан? Пехотаның төп дошманы — пулемет оялары кайларга куелган? Менә шундый бик күп сорауларга җавапны бары тик разведка гына бирә ала. Тикмәгә генә разведканы фронтның күзе димиләр, күрәсең.

Полк оборонага урнашып беткәч, ефрейтор Сәлим Айткулов разведчик хезмәтенең бөтен авырлыгын, җаваплылыгын җаны, йөрәге белән тоеп, отделениесен икенче сугышчан бурычны үтәргә алып китә.

Бу юлы аларга, немецларның тылына үтеп, чиркәү гөмбәзенә урнашкан, әледәнәле безнекеләр өстенә ут чәчеп торучы пулемет оясын юк итәргә, станция юлларында күп санда тупланган икмәк һәм сугыш кирәк-яраклары төялгән эшелоннарны алып китәргә мөмкинлек бирмәскә — юлларны шартлатырга дигән бурыч куела.

Хәвеф-хәтәрсез генә фронт сызыгын үтеп, төн караңгылыгына сыенып, разведчиклар станциягә барып керәләр. Чиркәү янында бәрелеш бик кыска була. Немец пулеметчылары разведчикларны үзләре янына ук килеп җиткәч кенә күреп алалар. Каушап, югалып калган фашистлар тәртипсез төстә төрле якка ата башлыйлар. Ыгы-зыгыдан файдаланып, Сәлим ике разведчикны алып чиркәүнең эченә ташлана. Озак та үтми, көчле шартлау тавышы ишетелә. Җиргә түбә калайлары, кирпеч кисәкләре коела. Пулемет тынып кала. Пулемет урнашкан гөмбәз эченнән яралы немецларның ярдәм сорап ыңгырашулары гына ишетелә.

Ләкин көтелмәгән хәл килеп чыга.

Чиркәү янындагы шартлауныммы, я булмаса кычкырган тавышларны ишетепме, немецларның вокзал бинасына урнашкан каравыл взводы һәм поезд көтеп торучы солдатлар, тревога сигналы буенча, чиркәү мәйданына ташланалар. Шул ук вакытта чиркәү ишегалдындагы агач ботакларына бәрелеп беренче мина да шартлый.

— Тимер юлга таба китәргә, — диде Сәлим иптәшләренә, — юлны шартлатасы бар, ашыгырга кирәк!

Алар чиркәүне урап алган тимер койма ярыгыннан бер-бер артлы чыгып, станция читендәге семафор ягына, стрелкачы будкасына таба шуышалар. Ике йөз метрлар җир үткәч, аларның янынnан ук, кайда нәрсә икәнен үзләре дә белмичә, бер төркем немец солдатлары ата-ата чиркәүгә таба йөгереп үтә.

Үзәк юлдагы зур эшелон таккан паровоз ак пар бөркеп пошкыра башлау белән рельслар өстенә гранаталар оча. Төн караңгылыгын ярып, станция юлларындагы йөзләрчә вагоннарны тоныкъ кына яктыртып, күккә яшел ракета күтәрелә.

Бу — разведчикларның бурыч үтәлде, һөҗүм башларга мөмкин дигән сигналы.

Икенче көнне Бахмач-2 станциясенең вокзал гөмбәзе өстендә кызыл флаг җилферди.

Ә дивизиягә «Бахмач» исеме бирелә.

*
* *

*«1943 ел, 29 сентябрь.*
*Дошман полк участогында эре көчләр туплап һөҗүм башлагач, взвод командирының яралануын күреп, Айткулов командалык итүне кыю төстә үз кулына алды. Иң каты сугышлар барган уңъяк флангта взводын 4 тапкыр атакага алып барды. Дошманның 9 атакасын кире кайтарды. Үз позициясен нык тотты. Немецларның ике взвод солдатын юк итте».*
*(Геройның бүләкләү кәгазеннән.)*

Фронт Днепрга килеп җитә.

22 сентябрьдә Воронеж һәм Үзәк фронт гаскәрләре беренче булып елганы кичә башлыйлар. Ләкин немецлар үзләре күп югалтулар исәбенә басып алган, хәзер хурлыклы төстә калдырып чигенгән Украина җирен кире кайтарып алудан һич өметләрен өзмиләр әле.

24 сентябрьдә 231 нче укчы полк, якын көннәрдә Днепрны кичү һәм Глебовка авылын яулап алуны күздә тотып, Тарасовичи авылының көньягына килеп урнаша.

Полк командиры Днепр аша беренче чиратта 76 миллиметрлы пушкалар батареясе белән 1 нче һәм 3 нче укчы батальоннарны чыгарырга дигән карарга килә. Ләкин кичке сәгать 6 җиту белән бу карарның үтәлүе шик астында кала. Саперлар тарафыннан бик күп тырышлык һәм хезмәт куеп эшләнгән кичү корылмасын фашистларның 20 штурмовик самолеты бомбага тотып, җимереп китә. Әлегә кадәр җәяүле сугышчыларны елга аша ташып торган «Николаев» пароходы да сафтан чыга. Бу пароходның безнең сугышчылар кулына элегү тарихы да бик кызыклы.

231 нче укчы полк белән янәшә хәрәкәт итүче 212 нче полк штабы елга аръягындагы хәл турында разведчиклардан мәгълүматлар алгач, өлкән лейтенант Гаврилин командалыгындагы 2 нче укчы батальонның калган подразделениеләрен һич кичек-

мәстән Днепр аша чыгарып, 6 нчы рота плацдармын ныгытырга боерык бирә. Иртәнге сәгать 7 дә батальон Днепрга килеп җитә. Шул чакта алар елганың уңъяк ярына ышыкланып акрын гына йөзгән немец пароходын күреп алалар. Пароходка тагылган баржага Киевтан куып китерелгән эшчеләр төялгән. Палуба өстендә, тоткыннарга акырып-бакырып, түшләренә автоматлар аскан ун немец солдаты — конвоирлар арлы-бирле йөри. Сул яктан ачылган артиллерия һәм пулемет уты пароходны һаман саен ярга сыенырга мәҗбүр итә. Азрак баргач, ул, һич нәрсәдән шикләнмичә, лейтенант Кондаков командалыгындагы 6 нчы укчы рота урнашкан плацдарм ярына туктап, якорь ташлый. Шул минутта ук Кондаков ут ачарга команда бирә. Пароходта паника башлана. Шуннан файдаланып, взвод командиры, гвардия кече лейтенанты Яршин үз сугышчылары белән палубага йөгереп менә. Кыска, ләкин каты бәрелештән соң исән калган немецлар кулларын күтәрә. Пароход, баржасы белән, безнең гвардиячеләр кулына төшә.

Сугышка кадәр Идел пароходчылыгында машинист булып эшләгән Яршин һәм елга пароходында штурвальный булган сугышчы Сухунин аны шунда ук сулъяк ярга алып киләләр һәм дивизия подразделениеләрен Днепр аша ташый башлыйлар. Бу пароход дивизия өчен көтелмәгән зур табыш була.

Ләкин бу кичтә фашист самолетлары пароходны һәм баржаны да сафтан чыгаралар.

Шулай да төн буена авылдан җыелган төрле көймәләрдә 1 нче укчы батальон һәм 2 нче укчы батальонның 4 нче ротасы дошманның көчле уты астында Днепрның уң ягына чыгып урнашырга өлгерәләр. Немецлар аларга иртәгесен дә туктаусыз ут яудырып тора. Гвардиячеләрнең хәле сәгать саен кискенләшә бара. Яулаган плацдармны ныгыту өчен ничек кенә булса да бу яктан өстәмә көчләр чыгаруны тизләтергә кирәк. Бер төркем сугышчылар көн буе өлеге ватык баржаны төзәтү белән шөгыльләнәләр. Авыл кешеләре дә тагын берничә көймә табып китерә.

Төн җиткәч, баржа, Днепр аша ике рейс ясап, 2 нче укчы батальонны һәм бер артиллерия полкын чыгара. Таң ату белән, гитлерчылар тагын өермәдәй көчле ут ачалар. Гвардиячеләр плацдармын тузан һәм төтенгә каплап, бөтен тирә-якны тетрәтеп, авыр бомбалар шартлый. Фашистлар ничек кенә булса да бу «кечкенә җир»не юк итәргә, сугышчыларны изәргә тырышалар. Көндезге сәгать 12 ләр тирәсендә Глебовка авылы ягыннан безнекеләр позициясенә таба немецларның күп кенә вак группалары якыная башлый. Ләкин окопларга бары йөз метрлар калгач, күп мәетләр калдырып, кирегә йөгерергә мәҗбүр булалар. Аларның юлын безнең артиллерия уты кисә.

26 сентябрьдә кич сәгать 4 тә 120 миллиметрлы миномет батареясы ярдәмендә полк Глебовка һәм Дымер авылларына һөҗүм башлый. Бу һөҗүмне немецлар бөтен төр коралларадан дәһшәтле ут ачып каршылыйлар.

27 сентябрьдә дә шул ук хәл кабатлана. Фашистлар бу плацдармдагы кыю гвардиячеләр өстенә йөзләрчә тонна металл яудыралар. Төштән соң кара тәреле 27 самолет алар өстенә дистәләрчә бомба ташлап, пуля сиптереп китә. Полк үз позициясеннән чигенми.

Төн буе немецлар тылында күзәтеп йөргән разведчиклар мөһим мәгълүматлар алып кайталар. Казаровичи, Глебовка, Барки авыллары рубежында дошманның эре көчләр туплавы билгеле була. Разведчиклар тырышлыгы аркасында полк участогында немецларның 2 көчәйтелгән батальоны, ике артиллерия полкы, 4 үзйөрешле орудиесе, 7 танк барлыгы ачыклана. Глебовка авылының үзәк өлеше һәм төньягы аеруча көчле ныгытылган булуы да хәзер инде безнең командование өчен сер түгел.

138 нче миномет полкы елга аша чыккач, полк яңадан һөҗүм башлый. Ләкин дошманның тыгыз, көчле уты гвардияче укчыларны тагын җиргә сыенырга мәҗбүр итә.

Днепрның уңъяк ярын ныгытуга Гитлер генераллары аеруча әһәмият бирәләр. Зурлыгы ягыннан Идел һәм Дунайдан кала Европада өченче урында торган күп сулы, урыны-урыны белән 900 метрга кадәр җәелеп ага торган киң Днепрга фашистлар командованиесе алдан ук зур ышаныч баглый.

Днепрның уңъяк яры биек һәм текә, оборона өчен уңайлы. 231 нче укчы полк участогында алдан ук әзерләнгән ныгытмаларда ут ояларының тыгыз туплануы һөҗүмне җәелдерүгә нык комачаулый.

29 сентябрь.

Глебовка, Ясногородка, Барки, Казаровичи торак пунктлары янында да фашистлар һөҗүм итүче совет сугышчыларына каты каршылык күрсәтәләр. Плацдармны киңәйтү нияте белән укчылар атакага күтәрелгәч, Ясногородка белән Глебовка авыллары арасындагы юл буйлап сузылган куаклыктан немецларның үзйөрешле өч орудиесе туры наводка белән ата башлый. Автоматчылар беркадәр алга үрмәләгәч, бу орудиеләргә алты көпшәле ике миномет та кушыла.

Азрак хәл җыйгач, көндезге икеләр тирәсендә подразделение кабат һөҗүмгә күчә.

Артиллерия һәм пулеметларның көчле уты астында, зур югалтулар хисабына булса да, безнең автоматчылар 150 метрга кадәр алга үтеп, яңа окопларга урнашалар. Флангларда исә сугыш кызганнан-кыза бара. Сәлим Айткулов отделениесе разведчиклары бу сугышларда һәр вакыт иң алда, иң җаваплы участокта үз-үзләрен аямыйча сугышалар. Сәлим үзе монда да шәхси батырлыгы белән таныла.

Тирә-якта ут өермәсе уйнаганда кемнеңдер:

— Взвод командиры һәлак булды, — дип карлыккан тавыш белән кычкыруын ишетә ул. Ишетү белән, тавыш килгән якка шуыша.

Яньчелеп изелгән флягасыннан һушсыз яткан командирның авызына су сала, ясалма сулыш алдыра. Ләкин күзләре көзге болытлы күккә текәлеп хәрәкәтсез калган яшь командирга инде бу чаралар ярдәм итми.

Сәлим ирексездән күзләрен каплаган яшь тамчыларын җиңе белән сөртеп ала да, автоматын тоткан уң кулын өскә күтәреп, аягүрә баса һәм бөтен көченә: «Минем команданы тыңлагыз!» — дип кычкыра.

Шул көнне автоматчылар взводы Айткулов командалыгында немецларның берсеннән-берсе аяусызрак тугыз контратакасын кире кайтара. Взводы белән дүрт тапкыр үзе атакага бара. Нәтиҗәдә ике взводка якын немец солдаты һәм офицеры Днепр ярында мәңгегә ятып кала.

Полк, зур авырлыклар кичереп, акрынлап алга хәрәкәт итә.

2 октябрь көнне гитлерчылар, көчле артиллерия һәм миномет утына ышыкланып, яңа көчләр белән тагын контратакага күчәләр. Кайбер участокларда алгы сызыктагы окопларга ук килеп җитәләр. Ләкин күп кенә мәет калдырып, яралыларын да ташлап тагын артка тәгәриләр. 15 сәгать 30 минутта 1 нче һәм 2 нче батальон Ясногородка авылына һөҗүм башлый. Гвардиячеләр, фашистларның каршылыгын сындырып, юлда очраган ут ояларын юк итеп, авылга бәреп керәләр, мәктәп бинасын алалар һәм Ясногородка — Глебовка юлына чыгалар.

3 октябрьда Ясногородканың көньяк өлеше гитлерчылардан бөтенләйгә чистартыла. Әмма фашистлар бер полк кадәр җәяүле солдат туплап, артиллерия һәм алты көпшәле минометлар уты ярдәмендә позиция өстенә йөзләрчә төтен шашкалары ташлап, Ясногородканың көнбатышында урнашкан тегермән янынннан яңа һөҗүмгә ташланалар. Зур югалтуга дучар булсалар да, авылның төньяк-көнбатыш өлешен кулга төшерәләр. Шуның белән рухланып, алар тагын дүрт тапкыр контратакага күтәреләләр. Ләкин һәркайсында гвардиячеләрнең тимер ныклыгына очрап, артка тәгәриләр.

Бу бәрелешләрдә Сәлим Айткулов үзен курку белмәүче тапкыр сугышчы итеп кенә түгел, бәлки яхшы оештыручы, сәләтле командир итеп тә таныта...

*

* *

6 октябрь көнне дошман алга баручы безнең частьларны туктату өчен тагын бер омтылыш ясап карый. Полкның Айткулов взводы урнашкан флангысында фашистлар яңа көчләр белән психик атакага ташланалар. Рота парторгы Сәлим Айткулов бу юлы да сугышчыларны үзенең батырлыгы белән җиңүгә рухландыра. Аның взводы бу көнне немецларның бер-бер артлы кабатланып торган, берсеннән-берсе ярсулы өч контратакасына батырларча каршы тора.

Фашистларның флангтан удар ясап, гвардиячеләрнең алга хәрәкәтен туктату планы тагын барып чыкмый.

Соңгы атака вакытында Сәлим яраланып җиргә егыла. Ләкин ул сугыш кырыннан китүдән катгый баш тарта, күп кан агудан хәлсезләнгән килеш, взвод белән командалык итә. Менә ул икенче тапкыр яралана. Сәлим, яраларын бәйләтеп, сугышуында дәвам итә.

Бу кыюлар позициясен каршы яктан килеп җимерә алмавына ышангач, немецлар, ике як флангтан һөҗүм итеп аларны боҗрага алырга һәм юк итәргә дигән карарга киләләр. һәм озак та үтми, взвод фашист солдатларының тыгыз боҗрасы эчендә кала. Көчләр тигез түгел. Боҗра һаман кысыла бара. Немецлар якын ук килеп җиткәч, Сәлим беренче булып сикереп тора да алар өстенә бер-бер артлы берничә граната томыра. Алар шартлавыннан 4 офицер һәм берничә солдат үлә. Ләкин граната кыйпылчыгыннан Сәлимнең үзенең дә аягы яралана. Яраны карарга вакыт юк. Ул дошман өстенә гранаталар ыргытуын дәвам итә.

Гитлерчылар качарга мәҗбүр булалар. Сәлим үзе тагын берничә тапкыр яралана һәм, күп кан югалтудан хәле бетеп, җиргә һушсыз ава.

Кыю командирның батырлыгы белән рухланып, взвод сугышчылары бердәм атакага ташланалар һәм тагын 20 немец солдатын юк итәләр.

Атышлар тынгач, Сәлимне иптәшләре сугыш кырыннан алып чыгып медсанбатка озаталар. Аннан Череповец шәһәре, озак айларга сузылган госпиталь көннәре...

Госпиталь койкасында ятканда Сәлим Айткулов Днепр янындагы сугышларда күрсәткән батырлыгы өчен СССР Верховный Советы Президиумының 1943 ел, 17 октябрь Указы белән үзенә Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелүе турында ишетә. Бөек бүләкне аңа 1944 елда, госпитальдән чыккач, Михаил Иванович Калинин тапшыра.

Госпитальдән соң өлкән сержант Сәлим Айткуловны ул елларда Уральск шәһәренә күчеп килгән Одесса пехота училищесына җибәрәләр.

1945 елның март аенда училищены уңышлы тәмамлап, ул кече лейтенант званиесендә яңадан фронтка юл тота. 395 нче тау укчы дивизиясенең разведка взводы командиры сыйфатында тагын сугышка керә.

Җиңү таңын Сәлим тугандаш Польша җирендә, Бельск шәһәрендә каршылый.

1945 елның декабрендә Сәлим Айткулов Уральск шәһәренә кайта. Партиянең Уральск өлкә комитеты аны өлкә потребительләр союзына эшкә җибәрә. Аннан соң ике ел Уральск шәһәренең Приреченск райкомы секртаре булып, аннары шәһәр комитеты аппаратында эшли. 1949 елдан Сәлим Айткулов өлкә потребсоюзында оештыру бүлеге начальнигы була.

Илебезнең бәхетле бүгенгесе өчен күп кан койган солдат, 1943 елда окопта партиягә кабул ителгән Сәлим Айткулов тыныч көннәрдә дә бәхетле киләчәгебез өчен үз-үзен аямый хезмәт итә.

# ГРУЗИН ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

## Александр Абашели

### Киләчәк буыннарга

*Өзек*

Хыялларым ерак-ерактагы
Киңлекләрне иңләп-урап коча,
Киләчәктә яшәр буыннарның
Матур җырын тыңлар өчен оча.

...Үзем күрдем тәүге нур балкышын,
Яктыра барып шушы нур хәзер дә
Караңгының калдык каралыгын
Күмә һаман тирән гүр-кабергә.

...Заманында безнең куллар тиде
«Аврора»ның салкын тимеренә,
Броневикка менеп баскан Ленин
Истә калды бөтен гомеремә.

Күп мактарсыз, күп зурларсыз әле
Яңа дөнья ачкан улларны сез,
Күп укырсыз, күп җырларсыз әле
Без калдырган шигъри юлларны сез.

## Симон Чиковани

### Кем әйтер...

Кем әйтер: Картли ул, имеш, бәп-бәләкәй?
Уч хәтле җир итеп чамалар кем аны?
Мондый уй җирлексез, бу фикер уйдырма!
Туган як дигән җир кечкенә буламы?!

Я, куеп кара син тауны тау өстенә,—
Биектә ялтырасын ак томан күбеге,
Һәм тыңла бөркетләр, боланнар авазын...
Беркайда юк моның Картлида кебеге!

Таудагы мәһабәт крепостьлар көченә
Бәяне күңелең күзләре бирсеннәр.
Бездә ул мең төрле төскә бай урманнар, —
Ялкынлы моңнары җырыңа керсеннәр.

Чамалап һәм үлчәп кара син — тарлавык
Эчендә дулаган давылның канатын,
Я күреп хәйран кал тар елга ярсуын:
Очкындай тамчыны ул күпме таратыр!

Кулыңны тидереп чал Дербент ташына
Капшасаң Картлиның нинди юл үткәнен,
Тик шунда аңларсың син минем ил-бакчам —
Мәңгелек бакчасы — чиксез киң икәнен!..

## Алио Мирцхулава

### Тирәк

Мин — тирәк. Тарлавык читендә үсәм мин
Кулларны киң җәеп. Һәр кулым — бер ботак.
Кем ярдан ычкына, мин шуңа кул сузам.
Барча яшь тирәктән күкрәүле яшенне
Читләтү юлларын бирәдә мин сызам.
Түбәмә күгәрчен оялый — хәтерлим
Баласын уйнатып очырган көннәрен.
Мин тиеш җиңәргә котырган җилләрне,
Көзләрнең караңгы һәм юеш төннәрен.

Тамырым ташларга береккән булса да,
Йөрәгем таш түгел — утлы бер оя ул.
Саргайган һәм кипкән яфрагы юк аның,
Бары тик утлы һәм нурлы сүз коя ул...

Ватаным, син әйткән бер постка бастым да
Янадым яшенгә, карыштым ташкынга.
Һәм шыксыз илбасар упкынга төште бит,
Һәм сугыш сүнде бит үз көле астында.

Аннары... яңадан ялтырап кабынды
Тәнемдә яралар — ул сугыш эзләре.
Пуляның бик яман сызгырып үткәнен,
Борчулы йөрәкнең ашыгып типкәнен,
Тар окоп төннәре бик озын икәнен
Яңадан күрделәр күңелем күзләре...

Ватаным! Мин синең мәңгелек бер сакчың,
Бер якта бары син, бер якта тик үлем
Булганда — нык басып арада мин тордым,
Сиңа дип төбәгән пуляның очышын
Үземә юнәлтеп зур яуда мин бордым.
Тукталды һөҗүмнәр һәм туплар тындылар,
Күкләрдә дәһшәтле болытлар күренми,
Яралар.төзәлә, әрнүләр басыла...
Һәм сиңа мәхәббәт сүнми һәм сүрелми!

## Иракли Абашидзе

### Капитан Бухаидзе

Мин — грузин Бухаидзе идем.
Пуля екты Кавказ тавында.
Терелә алсам әгәр тагын кинәт
Шул тауларның бер тын таңында.—

Йөрәгемне тагын бирер идем
Яуларда мин — туган ил өчен,
Мин яңадан үләр идем — мине
Каплап торган шушы җир өчен.

Бу тавышны минем ишет, илдәш,
Мендер аны биек үрләргә,
Белсен дөнья: яуда курыкмыйча
Кердек шулай кысан гүрләргә.

Миңа аткан дошманның да башы
Безнең куллар белән киселде.
Мин үлмәдем. Ватан сакчысы дип
Әйтегез сез минем исемне.

Васыятем шул сезгә, якташларым:
Таш кыяга көчне тиңләгез —
Яклаганда Дербент һәм Дарьялны
Сыкрана һәм курка белмәгез.

## Карло Каладзе

### Тынычлык җыры

Бик күп дуслар йөрәгенә
Без якты сукмак салдык.
Авыр яуда тынычлыкны
Якладык, саклап калдык.

Җиде кат җир асларында
Калды бик күп корбаннар.
Сафка басты алар эшен
Дәвам итә торганнар.

Һәм Бөек Җиңү яуланды,
Тыныч көн килде җиргә, —
Җилферди аның байрагы
Күченеп илдән илгә.

Дошман көйдергән җирләрне
Уңышлы кыр иттек без,
Гөлләр һәм сандугач җырын
Иң якын җыр иттек без.

Хезмәткә кайтты, туган як,
Синең дә кыю уллар,
Җир җимешен йолдыз итеп
Күтәрә хәзер куллар.

Күпләп бирде грузин-әнкә
Илгә чын батыр ирне,
Өйрәтеп иҗат итәргә
Һәм җимертмәскә җирне.

...Безнең җыр — тынычлык җыры
Җир шары буйлап үтә,
Сугышны хөкем итә ул —
Үлемгә хөкем итә.

## Григол Абашидзе

### Таулар одасы

Тантаналы һәм куркыныч алар,
Кара шомга алар төренә.
Ераклардан Каджет крепостеның
Вышкалары булып күренә.

Алар биек. Алар какшамас үр.
Ә нинди соң ул үр дигәндә,
Әйтик шуны: таулар башы — күктә,
Ә болытлар йөзә түбәндә.

...Таулар кырыс. Таулар сыный алар,
Таләп итә синнән батырлык.
Сокландыра таулар матурлыгы,
Ул — саран һәм кыргый матурлык.

Кемдер эзли тигез киңлек күркен,
Ә мин исә тауны яратам.
Әнә анда упкын өсләрендә
Очкан бөркет каурый тарата.

Шунда үскән бәсле куакларны
Коча күңел өскә ашкынып,
Тарлавыкта шаулап-гөрләп әнә
Шуннан төшә ташлар ташкыны.

Шул үрләрдән кояш нуры ява,
Ак болытлар шунда туганнар.
Халкым, сиңа күпме гасыр буе
Шушы таулар бишек булганнар.

Таулар, таулар... Нигезләре тирән
Икәнлеген алар аңлыйлар.
Көч, бөеклек һәм гүзәллек — җирдә
Тирәнлексез була алмыйлар.

## Хута Берулава

### Ленинга

Кабер ташына ике сан языла —
Күптән белә моны бөтен кеше:
Берсе аның туган көн датасы,
Үлү көне була икенчесе.

Еллар саный синең зур гомерне
Тик бердәнбер дата белән генә!
Мең сигез йөз җитмешенче елны
Зурлыйм мин дә җырым белән менә.

Шарлавыклар булып шаулар көннәр
Болытларны җилләр куу белән.
Һич янәшә була алмас ләкин
Җирдә үлем синең туу белән.

## Медея Кахидзе

# Көтәм

*Өзек*

Мин көтәм. Ә диңгез чайкала, чайпалз.
Һич белми ул мине бер егет яры дип.
Бер дулкын җилкәмә шәл булып уралды...
Син минем йөрәкнең иң якын яры бит!

Мин көтәм. Ялгызлык — газаплар газабы.
Каршылап чыктым бит мин үзем. Мин үзем!
Ә менә, уйлардан шашынып, дулкындай
Сикерә башласам нишләрсең син үзең?

Юк, диңгез кебек үк, син миннән качмас җан.
Диңгезне мин синең күзләрдә таптым бит.
Шуларга ай-кояш булып мин батарга
Телим бит... Ерак яр, син миңа якын бит!

ЗӘКИ НУРИ
тәрҗемәләре.

# Микаил Мөшфикъ

Шигъриятне шашып сөюче зур талант иясе, кайнар хисле, тирән фикерле, җаны-тәне илһам белән өртелгән шәхес... Әйе, Мөшфикъ турында уйлаганда беренче нәүбәттә шушы сыйфатлар күз алдына килә. Яңа әзербайҗан әдәбияты күгендә ул якты йолдыз булып балкыды, аның нигез салучыларыннан берсе булу дәрәҗәсенә күтәрелде.

Микаил Мөшфикъ (Микаил Мирза Габделкадыйр углы Исмәгыйл-задә) 1908 елда Бакуда туа. 1915 елдан укый башлый. Әзербайҗанда Советлар власте урнашкач, урта белем алып, 1927 елда университетка, тел-әдәбият факультетына керә. 1931 елда аны тәмамлап, җиде елга якын Баку мәктәпләрендә укыта.

Мөшфикъ яшь килеш әдәбият дөньясына керә. Вакытлы матбугатта аның «Беренче көн» дигән шигыре 1926 елда чыга, ә «Җилләр» исемле беренче китабы 1930 елда дөнья күрә. Кыска вакыт эчендә Мөшфикъ үзенең ун китабын чыгарып өлгерә. «Шарлавык» дигән унберенче китабын әзерли. Ләкин аны чыгару насыйп булмый, егерме тугыз яшьлек шагыйрь 1939 елда һәлак була.

Заманының ялкынлы шагыйре буларак, ул үзенең талантлы шигырьләрендә кояшлы Әзербайҗанның мул һәм юмарт җирен, аның табигый байлыгын, гаҗәеп манзараларын, нефтьчеләрен-эшчеләрен, аларның теләк-уйларын, кешелек хисләрен җырлый. Мөшфикъ эпик әсәрләр маһире булып та үзен таныта. Аның «Таулар трагедиясе», «Көтүче», «Минем дустым», «Азатлык дастаны», «Сынган саз» һәм башка әсәрләре — моның дәлиле. Шагыйрьнең лирикасы Әзербайҗан әдәбиятында әле бүген дә новаторлык үрнәге булып тора. Ул, беренчеләрдән булып, шигъриятебездә классик форма саналган робагыйны яңа эчтәлектә җанландырып, лириканы һәм фәлсәфәне заман рухы белән аваздаш иткән шагыйрь.

Сәнгатьтән югары идея, тирән мәгънә таләп итү белән бергә, Мөшфикъ чын, зур әдәби осталык та таләп итте. «Мәхәббәтсез һәм илһамсыз гына язучы затлар шагыйрь булуны юкка үзләренә максат итеп куялар. Алар шигърият мәйданыннан хәзер үк һәм гомергә китәргә тиешләр!» — ди иде Мөшфикъ.

Халык йөрәгендә Мөшфикъның шигырьләре дә, үзе дә яши. Шуңа күрә дә ул безгә дә, бездән соңгы буыннарга да замандаш булып кала.

**ГЮЛЬГУСЕЙН ГУСЕЙНОГЛУ,**
**әзербайҗан язучысы.**

## Җилләр

Иртәләр, кичәләр... Кичәләр, иртәләр...
Һәр заман шук җилләр исәләр, исәләр,
Бик якын дуслардай тәрәзәм чиртәләр,
Җырчыдай бу җилләр — төрле моң көйлиләр,
Шат җилләр, саф җилләр ил гизеп йөриләр.

Кайбере куркыныч, кайбере бик тыныч,
Кайсысы тойгылы, кайсысы тойгысыз,
Кайбере йокыда, кайбере йокысыз,
Исәләр салкынча саф җилләр, исәләр,
Һәр җирдән хуш исләр аларга күчәләр.

Әй, салкын җилләрем, шашынып искәндә,
Багларның бал-мәен суырып эчкәндә,
Күкләргә үрелгән зур таулар кичкәндә
Мине дә алыгыз, очыйм мин тауларга,
Күңелемдә нәрсә бар — ачыйм мин тауларга!

Шаулагыз, минем дә сәнгатем шауласын!
Давылым, өермәм, кодрәтем шауласын!
Яшенем, ялтыра-күкрә, төн шауласын!
Җилләр, сез бит мине ирекле җан иткән,
Дәшегез таулардан — күз җитмәс биектән!

1929

## Хәятка мәхәббәт

Ничек мин көннән-көн ямьләнә барган
Бу якты тормыштан ваз кичә алыйм?!
Җир белән, күк белән көрәштә янган
Юлдаштан, чын дустан ваз кичә алыйм?!

Син язгы таңнарда әйләнмә чыкка,
Ялкынлан, йөрәгем, кояштай чык та.
Ничек мин — гаугасы җиткән болытка —
Бу бөек көрәштән ваз кичә алыйм?!

Дан җире яктыра иртәнге чакта,
Дус-ишләр баскан җыелып сафка.
Ничек бу — көмештәй ерак-еракка
Җәелгән даламнан ваз кичә алыйм?!

Табигать ул шундый — бай да, саран да,
Инженер күпме көч сала аңарга.
Мин дә бу ташларга хисләр салам ла,
Ничек соң алардан ваз кичә алыйм!

Бер якта лачыннар, томанлы үрләр,
Бер якта көртлекләр, көзгедәй күлләр,
Бер якта былбыллар, чәчкә дә гөлләр...
Ничек мин алардан ваз кичә алыйм!

Хәят дип аталган бу гәҗәп җайдан,
Йөрәктән — һәр заман утларда янган,
Көннәрдән, төннәрдән, кояштан, айдан,
Күкләрдән ничек мин ваз кичә алыйм!

Алдымда дулкынлы тимер океан,
Тетрәтә гел аны давыл да туфан,
Ничек ал күбектә чәчәкләр аткан
Шигырьдән-хыялдан ваз кичә алыйм!

Йолдызлар — фикремнең чыраг-майлары,
Болытлар — хыялым-уем кәрваны,
Ә биек күк йөзе — хисләр сарае,
Ничек мин алардан ваз кичә алыйм!

Шигърият яңадан кунды башыма,
Сөекле яр гынам басты каршыма,—

Ә Мәҗнүн йөрәгем сорады шунда:
— Ничек бу Ләйләдән ваз кичә алыйм?!

Чәчәкләр сулуын уйламый былбыл,
Сайрый ул, күләгә — былбылга бер гөл.
Гел: — Хәят, хәят! — дип талпына күңел,
Ничек мин сөюдән ваз кичә алыйм!

Азыгың-нектарың — яңа хисләрдән,
Әй, минем яшь каләм, талма син һәр дәм!
Дусларым, әйтегез, мин бу һөнәрдән,
Ничек бу илһамнан ваз кичә алыйм?!

1935

## Шагыйрь

Аһ, нинди зур бәхет шагыйрь булуы,
Күңелләр аулауда маһир булуы!
Ни яхшы — йөрәккә үтеп керәлсәң
Кинәт, туп-туры,
Бар яман нәрсәне читкә сөрәлсәң,
Белми куркуны.

Илемнән рухланып, биек түреннән
Кычкырам дөньяга — халкым үреннән,
Шул вакыт танышса ихлас йөрәктән
Илләр минем лә [1],
Кем булыр «акылга» мине өйрәткән:
«Күп бел, аз сөйлә»?

Алдымда ямь-яшел җирләр күрәм мин,
Сәләтле, гайрәтле ирләр күрәм мин,
Күрәм мин зур бәйрәм, табын — бай мәҗлес, —
Яңа туй анда,
Күрәм мин алдымда кайный ТетерГЭС —
Пулат каналда.

Китсеннәр эшлексез тел бистәләре.
Килсеннәр ирләрнең эш эстәрләре,
Мин алар тарафлы, шиксез алар да
Безнең тарафдар,
Ә шагыйрь булудан — шундый җаннарга —
Артык нәрсә бар?

Яшәгән заманым бакыр канатлы,
Таш, тимер җанлана, — ярсыган атмы!
Мин горур, — алдыма зур эшләр басса,
Күкләрдә башым.
Шигърият туганчы, шатлыктан башта
Түгелә яшем.

Аһ, нинди зур бәхет шагыйрь булуы,
Күңелләр аулауда маһир булуы!

[1] Минем лә — минем белән.

Ни яхшы — йөрәккә үтеп керәлсәң
Кинәт, туп-туры,
Бар яман нәрсәне читкә сөрәлсәң,
Белми куркуны!

1936

## Синең көлүең

Каршымда назланып тагын көләсең,
Беләмсең көлүең нинди, серле каш?
Кабатлап тормыйм ла, үзең беләсең,
Ул лалә гөлендә ал чыкка охшаш.

Көлүең җил кебек җиләс, кагылса
Теләгем чәчәге китә ачылып,
Елмайса иреннәр — гыйшык агыла,
Җаныма йолдыздай ява чәчелеп.

Көлүең ишетү насыйп булмаса,
Елмайсаң — аны да күрү хуш икән.
Көлүең айларга барып тоташа, —
Йөзүче болытмы, очар кош микән?

Көлүең, акыллым, яз иртәсеннән
Хисемә, фикеремә сала төсләрен.
Көлче, көл, җырларым төрләнеп синнән
Яңгырасын, чыңласын, белми ишләрен!

Син көлсәң — бәхетле, шат минем көннәр,
Күк аяз, тирәмдә якты яз туа,
Алдымда, өстемдә уйный яшеннәр,
Коялар ләйсәннәр, суга җир туя.

Бу дөнья — сулмаучы гүзәл бер бакча,
Ярыймы көлмичә — гамьгә төшүгә?
Кызганыч каравы чытык кабакка,
Күр, нинди килешә көлү кешегә!

1936

## Кил диңгезгә

Нинди матур кич бу, җанга шифа,
Кара чәчле гүзәл кыздай зифа.
Җир якты, күге якты,
Нур кочкан тирә-якны.
Әй, сөеклем, ярга кил әйдә,
Сәйран итәргә.
Йолдыз яуган бизәп бөтен җирне,
Шат дулкыннар — шук малайлар өере,
Кулларында ай — туп урынына.
Ак яулыгың бәйлә дә шунда
Кил, сылу, ярга,
Диңгез карарга.
Кабат булмас бәлки мондый күренеш:
Күләгәдә һәр төш,
Күләгәләр җемелдәшә,
Яфраклар нидер сөйләшә.

Ефәк чәчләреңне тарыймчы бер,
Синең белән яшәп калыймчы бер,
Бер генә дәм [1], җаным,
Тузган толымнарың
Төшсен инде йөзләремә...
Колак салчы сүзләремә.
Нинди матур киче, җанга шифа!
Кара чәчле гүзәл кыздай зифа:
Җире якты, күге якты,
Нур сарган тирә-якны, —
Бәхет-шатлык сыймый бар җиһанга,
Елмаюдай җыр яңгырый анда,
Һәрбер хыял гүя җанлы канат!
Болар бар да безнең гүзәл хәят!

1936—37

## Шигырем

Син яратылмыштай якты — моңа шик бармы?
Син йөрәге аның, акылы — моңа шик бармы?
Синеке — көндезен кояш, кичен тулган ай,—
Үзең бер галәм!
Бар да матурая җирдә, син дә матурай,
Тормыштан ал ямь!

Син яратылмышның төсе, аһәңе, моңы!
Син чәчәкләр бәйләме, син нурларның нуры!
Сандугач алдында ачыл — чәчәк ат илгә,
Кызыл гөл төсле.
Һәр шәй тирән мәгънә ала, тирәнәй син дә,
Зур күңел төсле.

Гади булса бик әйбәт ул тирәнлек-хикмәт.
Шигырь тирән түгел икән, аннан ни көтмәк?
Син мәгънәле моңнар көйлә, хак, нәфис сөйләш,
Каманча [2] кебек.
Бөтен нәрсә гадиләшә, син дә гадиләш,
Тормыштан күреп.

Хәлсезлек тә, йомшаклык та сиңа хас түгел,
Куәтлән син, юлдаш булсын сиңа көр күңел.
Коралланa бөтен илләр, кораллан син дә,
Илләргә карап!
Чын күңелдән сөй җиреңне, сакчы бул илгә,
Бул батыр солдат!

Һәркем белә, бу хәятның ахыры үлем,
Бөтен ахырлардан яман ахыргы көнең.
Шигырем! Безне дә бер алыр бу уен, бәгърем,
Китәрбез бергә.
Миннән соң да булсын синең ятагың-кабереӊ
Ил күкрәгендә.

1936

Нури АРСЛАН тәрҗемәләре

---

[1] Дәм — кыска вакыт арасы.
[2] Каманча — уен коралы.

# КЫЙММӘТЛЕ ДОКУМЕНТЛАР

*Халкыбызның революцион көрәш юлын яктырткан яңа материаллар көн саен диярлек табылып тора. Алар арасында татар пролетар әдәбиятына нигез салган ялкынлы публицист Гафур Коләхметов эшчәнлегенә карагашнары да шактый.*

*1971 елның маенда, Г. Коләхметовның 90 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә, «Татарстан коммунисты» һәм «Казан утлары» журналларында язучы иҗатына багышланган күп кенә яңа документлар басылган иде. Хәзер менә аларга И. Абдуллин тапкан материаллар өстәлә.*

*Дөрес, И. Абдуллин мәкаләсендә китерелгән документларның барысы да өр-яңа дип булмый, кайберләре матбугат битләрендә элегрәк тә телгә алынган булган. Әмма ул тәкъдим иткән материалларның күпчелек өлеше моңарчы билгесез иде. Алар татар халкының революцион көрәш сәхифәләренә караган кайбер вакыйгаларны аңларга, аеруча Г. Коләхметов һәм башка татар большевикларының киң революцион хәрәкәт белән бәйләнешләрен ачарга мөмкинлек бирәләр, аның тирән интернационалистик төс алганын күрсәтәләр. Бу соңгысы исә — аеруча әһәмиятле яңалык.*

*Без кулларында шундый материаллары булган иптәшләрдән аларны вакытында матбугатка чыгара баруларын көтеп калабыз.*

*БӘЯН ГЫЙЗЗӘТ.*

## Искәндәр Абдуллин

## Гафур Коләхметов большевиклар белән эшләде

Гафур Коләхметов үзенең иҗат эшчәнлеген большевистик прокламацияләрне татар теленә тәрҗемә итү һәм эшчеләр арасында марксистик әдәбиятны пропагандалаудан башлый. Аның киң кырлы иҗаты әдәбият галимнәренең махсус хезмәтләрендә яктыртылды. Әмма тирән конспирация таләп иткән революцион эшчәнлеге, бигрәк тә аның большевиклар белән бәйләнеше, тулысынча өйрәнелгән дип әйтергә бик иртә.

Һәм бу табигый да. Һәр минут, һәр секунд полиция күзәтүе астында булган революционерлар кечкенә генә саксызлык та бөтен оешманы һәлакәткә китерәчәген яхшы аңлаганнар. Шуның өчен дә оешма членнарының тулы исемлеге төзелмәгән. Отчетларда һәм башка төр документларда теге яки бу эшне кем үтәгәне күрсәтелмәгән. Идән асты көрәшенең үз кануннары, үз кагыйдәләре булган...

Әмма бер генә кешенең дә эше эзсез югалмый. Давыллы революция елларында изелгән халыкларга азатлык яулап алу өчен кулына корал һәм каләм тотып көрәшкән ялкынлы публицист Гафур Коләхметовның эшчәнлеге халык күңелендә дә, жандармерия кәгазьләрендә дә эз калдырган. Бу материалларның бер өлеше төрле




*Г. Коләхметовның Хөсәен Ямашевка бүләк иткән фоторәсеме. Беренче тапкыр басыла.*

вакытларда төрле уңай белән дөнья да күрде. Шулар арасында иң әүвәлгесе һәм, безгә калса, иң әһәмиятлесе — аның ленинчыл «Искра» газетасын укып төшкән фоторәсеме. Бу документ булачак пролетар язучысының революцион көрәшкә марксизм-ленинизм идеяләре белән коралланып килүен, аның дөньяга карашы марксизм-ленинизм тәгълиматы тәэсирендә формалашуын шик астына алырга берниндн урын калдырмый.

Алафузов заводы эшчесе М. Гайсин һәм язучының сеңлесе Суфия Коләхметоваларның (ул да бу фотода бар) истәлекләренә караганда, Гафур Коләхметов ленинчыл «Искра» газетасын якыннары белән генә укып калмыйча, эшчеләр арасында да пропагандалаган.

1902 елда, Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлап, Г. Коләхметов Пороховой бистәгә — Алафузов заводы эшчеләре арасына укытырга күчә. һәм аның яшерен революцион эш алып баручы Хөсәен Ямашев белән элемтәсе тагын да ныгый төшә. Үз вакытында Б. Гыйззәт Х. Ямашев һәм Г. Коләхметовлар кул куйган телеграмма турында язган иде. Бу телеграмманы ул 1904 елда Бакуда әзербәйҗан телендә басылган бер китаптан таба. Моннан тыш, Татарстан АССР Дәүләт музеенда Гафур Коләхметовның галимнәр игътибарыннан читтә калып килгән бер фоторәсеме бар. Бу фото Х. Ямашевның тормыш иптәше Хәдичә Ямашевадан калган әйберләр арасыннан килеп чыга. Аның артына Г. Коләхметов үз кулы белән «Хусаину Ямашеву. Г. Кулахметьев. 19/III—1904 года» дип язган.

Болар, әлбәттә, шәхси бәйләнеш шаһитлары. һәм менә РСДРПның Казан комитеты кушуы буенча татар яшьләре һәм эшчеләре арасында социал-демократик түгәрәкләр оештыручы Х. Ямашев белән булган бу бәйләнешнең нәтиҗәләре: укытучылар мәктәбе студентлары һәм Крестовников заводы эшчеләре өчен оештырылган социал-демократик түгәрәк утырышлары 1904—1905 елларда Гафурның апасы — Шәмсекамәр Коләхметова квартирасында, ә Алафузов заводы эшчеләреннән торган социал-демократик түгәрәк җыелышлары Гафур квартирасында уза [1]. Бу түгәрәк утырышларында аның «Цензлы дума һәм аңа сайлауларга кат-




*Г. Коләхметовның шул рәсем артындагы истәлек язуы.*

[1] Р. Таһиров. Г. Коләхметов биографиясенә карата кайбер материаллар. «Совет әдәбияты», 1946 ел, 5 сан, 83—84 битләр.

нашуның әһәмияте» һәм «Нәрсә ул өстәмә кыйммәт» исемле рефератлар укуы да билгеле [1]. Соңгы рефератта сүз марксистик политэкономиянең иң әһәмиятле төшенчәләреннән берсе турында бара...

Г. Коләхметовның үз тормышын большевиклар партиясе эшенә, эшчеләр арасында марксизм-ленинизм идеяләрен таратуга багышлавын раслый торган моңдый фактлар күп кенә башка истәлекләрдә дә очрый. Мәсәлән, Алафузов заводы эшчесе, революция ветераны К. Хәйруллин Гафур Коләхметов кушуы буенча большевистик прокламацияләр, «Марсельеза»ның татарча текстын таратуы турында сөйли [2]. Бу фактларның күбесе М. Гайнуллин, Б. Гыйззәт, Р. Нәфиков хезмәтләрендә китерелә, ә кайберләре әле үзенең тикшерүчеләрен көтә.

Беренче рус революциясе елларында татар большевистик матбугаты һәм татар революционерлары турында Казан, Саратов, Әстерхан, Мәскәү архивларында материал туплаганда без дә күп кенә яңа документларга тап булдык.

1905 елның октябрь көннәрендә Казан эшчеләре һәм студентлары, полицияне коралсызландырып, халык милициясе оештыралар һәм шәһәрдә революцион тәртип урнаштыралар. В. И. Ленин тарафыннан үз вакытында югары бәя алган (Ленин. Әсәрләр. 9 том, Казан, 1957, 450 бит) һәм башында РСДРПның Казан комитеты секретаре Н. И. Дамперов торган бу милиция сафларында Гафур Коләхметов та була. Ул РСДРПның Казан комитеты җитәкчеләре И. А. Саммер, С. А. Дридзо-Лозовский, Н. И. Дамперов, Л. Бернгейм (С. Бакинский) белән бергә карагруһчыларга һәм патша гаскәрләренә каршы сугышта катнаша. Әммә бу турыда документлар тулысынча дөнья күргәне юк иде. Менә шуларның берсе:

«Яшерен

Галиҗәнап
Казан губернаторына
Казан полицеймейстерыннан

Рапорт.

Үткән елның 21 октябренда шәһәр Управасы бинасыннан патриотик партиягә ут ачканы өчен кулга алынган 135 кешенең исемлеген Казан Округ Суды Прокуроры аша алдыруны кирәк тапмассызмы, дип, Сез Галиҗәнаплардән түбәнчелек белән үтенүне үземә мәртәбә саныйм. Полиция бу исемлек буенча ул кешеләрнең эшләрен күзәтә алыр иде.

Полицеймейстер Васильев.

№ 4084, 1906 ел, 11 ноябрь» [3].

12 ноябрьда рапорт губернатор канцеляриясенә килеп керә, һәм шул ук көнне Казан губернаторы М. Стрижевский әлеге исемлекне соратып ала. Прокурор җибәргән исемлектә, кулга алынган большевиклар белән бергә, Г. Коләхметовның да исеме күрсәтелә. Дөрес, бу документта аның фамилиясе «Юнусов-Кулахметов» дип бутап язылган. Ләкин Казан губерна жандарм идарәсе өчен Казан үзәк төрмә начальнигы төзегән икенче бер исемлектә: «Учитель Габдул-Гафур Юнусов **Кулахметьев»** [4], дип төгәл күрсәтелә.

Ул көннәрдә шәһәр коммунасы председателе булып эшләгән карт большевик, РСДРПның Казан комитеты члены Н. Н. Накоряков Гафур Коләхметовны илле елдан соң да хөрмәт белән искә төшерә һәм аны «Хөсәен Ямашевның иң якын дусты һәм ярдәмчесе» дип атый [5]. Ә бу булачак язучының большевиклар арасында авторитет казанган булуы, үзенең революцион эшчәнлеге белән алар хәтерендә җуелмас эз калдыруы турында сөйли.

---

[1] «Кызыл Татарстан», 1927 ел, 19 январь; Г. Коләхметов мәҗмугасы. Мәскәү, 1925 ел, 21 **бит.**
[2] Социалистик Татарстан», 1971 ел, 27 январь.
[3] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы, 200 фонд, I тасвирлама, 3012 эш берәмлеге, 233 кәгазь.
[4] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы, 199 фонд, I тасвирлама, 666 эш берәмлеге, 51 кәгазь.
[5] ТАССРның дәүләт музее, истәлекләр фонды.

*
* *

1907 ел. Хөсәен Ямашев җитәкчелегендә Оренбургта чыккан «Урал» газетасын Казан большевиклары эшче-крестьяннар арасында тараталар. РСДРПның Казан комитеты члены С. Бакинский (игътибар итегез: Г. Коләхметов белән шәһәр думасында иңгә-иң торып сугышкан большевик!) үз истәлекләрендә Казан большевикларының газета өчен даими рәвештә акча җибәреп торулары турында сөйли[1]. Карт большевикның бу сүзләре РСДРПның Казан комитетына буйсынган Алафузов районының рәсми отчеты белән дә раслана. Анда: «Алафузов эшчеләре арасында социал-демократик «Урал» газетасы таратылды»[2], — диелгән.

Газетаны комитет кушуы буенча кем тараткан соң? Карт большевик, Алафузов заводы эшчесе Миңнулла Вахитов Г. Ибраһимов белән бер әңгәмә вакытында: «Гафур Коләхметов иптәш «Урал» гәзитенең сотрудникы иде. Безнең эшче бистәсендә учитель чагында эшчеләр арасыннан «Урал»га подписка җыючы ул булды. Аның аркылы «Урал» безнең эшчеләр арасына керде», — дип, бу мәсьәләгә тиешле ачыклык кертә[3]. Ул гына да түгел, «Урал» газетасының рәсми нашире Тимерша Соловьев истәлекләреннән күренгәнчә (бу истәлекләр аның улы, хәзер пенсионер-укытучы Исмәгыйль ага Соловьевта саклана), Гафур Коләхметов татар телендә беренче большевистик газета чыгару турында алдан сөйләшүләрдә катнаша.


> «1906 ел җәй башында мин Хөсәен Ямашевтан Уфага чакырып язган хат алдым, — ди Т. Соловьев үзенең истәлегендә. — ...Бераз соңарып булса да Уфага килгәч, аннан ерак түгел авылда кымызда булган Хөсәен Ямашев янына бардым. Авылда Х. Ямашев, аның хатыны Хәдичә Ямашева, Гафур Коләхметов һәм кавказлы Садыйк[4] исемле бер шагыйрь бар иде... Садыйк үзебезгә аерым («Вакыт», «Казан мөхбире»ннән башка) газета чыгарырга кирәк, ди... Хөсәен: «Башлап җибәрер өчен 500 [сум] табарга өмет бар. Соңга таба ничек булыр», — диде... Киңәшә торгач, түбәндәге карарга килдек: газетаны саф татарча масса телендә чыгарырга. Цензурный условие буенча, бигрәк тә газетаны бастыру, тарату буенча иң яхшы урын Оренбург булганга күрә, газетаны Оренбургта чыгарырга. Гәзит саф эшчеләр гәзите булырга тиеш».

Әлбәттә, эшчеләр өчен газета чыгару уе белән большевиклар күптән янып йөриләр. Газета чыгару мәсьәләсен Урал өлкә комитеты хәл итә. «Урал» аның булышлыгы белән чыга[5]. Оста конспиратор Х. Ямашевның Т. Соловьевка бу турыда җәелеп сөйләмәве гаҗәп түгел. Ләкин ничек кенә булмасын, татар телендә беренче большевистик газета чыгарырга типография хуҗасын күндерү, патша чиновниклары алдында абруйлы нашир табу, подписка оештыру кебек практик мәсьәләләрне хәл итүдә Гафур Коләхметовның катнашуы аның биографиясенең кызыклы битен ача.

*
* *

Кеше гомерен көнләп-сәгатьләп күздән кичергәндә, шуңа игътибар итәсең: үз агымы белән, тыныч кына, көндәлек эшләр белән күмелеп аккан тормыш кисәк кенә бөтерелеп-бөтерелеп китә. Мондый чакларда вакыйгалар берсе өстенә икенчесе өелүчән була. Гафур Коләхметовның тормыш күгенә шундый кара, куркынычлы болытларны 1908 елның февраль-март айлары китерә. Ул ике ел буена бөтен власть материаль байлыклар тудыручы эшчеләр сыйныфы кулында булырга һәм социализм

[1] «Совет әдәбияты» журналы, 1942 ел, 3 сан, 67 бит.
[2] Листовки казанских большевиков 1903—1907 годов. Рус телендә. Казан, 1941 ел. 264 бит.
[3] «Атака» журналы, 1931 ел, 1 сан, 13 бит.
[4] Бу исемне ачыклау өчен, әзербайҗан шагыйрьләренең тормыш юллары белән танышып чыгарга, әзербайҗан әдәбиятчылары белән сөйләшергә туры килде. Ләкин бу елларда Уфада яки аның әйләнә-тирәсендә яшәгән Садыйк исемле бер генә әзербайҗан шагыйре дә табылмады. Күңелгә, ихтыярсыз, Хөсәен Ямашев һәм Гафур Коләхметовның якын көрәштәше Зариф Садыйков исеме килә. Патша хөкүмәтенә каршы пропаганда алып барган өчен хөкемгә тартылгач, Ялтадан качкан З. Садыйковның Уфага, РСДРПның Уфа комитеты члены Х. Ямашев янына килеп чыгуы бик мөмкин эш. Һәм, күрәсең, ул шулай булгандыр да. Ләкин бу мәсьәлә әле ныклап тикшеренүне сорый.
[5] «Уральский рабочий» газетасы, 1907 ел, 1 декабрь.



За
Начальника
Самарскаго
Губернскаго
Жандармскаго
Управленія.
Марта 26 дня 1908 г.
№ 1939
Г. Самара.

По Раіону.-

Секретно.-

Входящій № 6881
Ж 30 МАРТ 1908 Ж
Дѣло № 15 -

У привлеченнаго при Астраханскомъ Губернскомъ Жандармскомъ Управленіи къ дознанію въ порядкѣ 1035 ст.Уст.Угол.Суд. крестьянина Симбирской губерніи Федора Антонова С и д о р о в а, обвиняемаго по 102 и 126 ст.ст.Уг.Улож., обнаружены слѣдующіе адреса:

1/ Бакалдинская ул.д.А с а н о в а Катерина Тимофѣевна, Ш у р к ѣ и В ѣ р к ѣ;

2/ Екатерининская улица д.Юнусова кв. Шамсие Камаръ К у л а х м е т ь е в о й, Гафуръ Пороховая Слобода; и

3/ Ибрагимъ М у р а т о в ъ, Казань.-

Сообщая объ изложенномъ Вашему Высокоблагородію, имѣю честь просить распоряженія о выясненіи лицъ, къ коимъ относятся означенные адреса и о сообщеніи мнѣ всѣхъ

Начальнику Казанскаго Губернскаго Жандармскаго Управленія.-

*Самара жандарм идарәсенең 1908 елның 26 мартында Казан жандарм идарәсенә җибәргән хаты.*

төзү өчен төрле миллләт эшчеләре үзара берләшергә тиешләр дигән идеяне сәхнә әсәре аша тарату уе белән яна. Ниһаять, 1908 елның башына «Яшь гомер» драмасы язылып бетә, нәшриятка тапшырыла һәм... патша цензоры Н. Ф. Катанов кулына килеп керә. Ул әсәрне нишләтер? Социализм идеяләрен таратуда гаепләп, дөньяга чыгарудан тыймасмы? Драматург беренче сәхнә әсәренең язмышы өчен борчыла башлый.

1908 елның 23 февралендә Казаннан ерак түгел Ямаширмә авылында, «крестьяннарны төрле налоглар белән талаучы патша хәзрәтләренә каршы котырткан өчен», Гафурның энесе укытучы Каюмны кулга алалар. Тентү вакытында полиция аннан социал-демократик басмалар, шул исәптән В. И. Ленинның «Думаны тарату һәм пролетариатның бурычлары» исемле брошюрасын таба [1]. Авыл кулаклары һәм муллалар-мунтагайлар Каюм янына еш килеп йөргән һәм һәр килгән саен ярлы крестьяннарда патша хөкүмәтенә ризасызлык уяткан абыйсы турында да онытмыйлар. Һәм жандармнар сорау алганда аның туганнары, бигрәк тә укытучы Гафур белән аеруча

[1] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы. 200 фонд, 4 тасвирлама, 3547 эш берәмлеге, 8 кәгазь.

кызыксына башлыйлар. Тикшерү март азагына кадәр сузыла. Менә шул көннәрдә Казан губерна жандарм идарәсенә Самара охранкасыннан (Идел буендагы барлык губерна жандарм идарәләре аңа буйсынган була) түбәндәге язу килеп төшә:

«Казан Губерна Жандарм Идарәсе начальнигына

Яшерен.

Әстерхан Губерна Жандарм Идарәсендә Суд эшләрен алып бару кануннарының 1035 статьясы тәртибендә сорау алуга тартылган һәм Җинаять кодексының 102 һәм 126 статьялары буенча гаепләнгән Сембер губернасы крестьяны Федор Антонов Сидоровта түбәндәге адреслар табылды:

1) Бакалтай урамы, Асанов йорты, Катерина Тимофеевна, Шурка һәм Веркага;

2) Екатерининская урамы, Йонысов йорты, Шәмсекамәр Кулахметьева квартирасы. Гафур — Пороховой бистәсе һәм

3) Ибраһим Моратов, Казан.

Сез Галиҗәнапларга язылганнарны хәбәр итеп, күрсәтелгән адресларда яшәүче кешеләрне ачыкларга һәм алар турында үзегездә булган бар мәгълүматларны хәбәр итәргә күрсәтмә бирүегезне сорауны үземә мәртәбә саныйм.

Самара район охранное отделениесе начальнигы.

1908 ел, 8 март»[1].

Охранка моның белән генә канәгатьләнми. Ул үз кул астындагы Әстерхан губерна жандарм идарәсенә Казанга тулырак мәгълүматлар җибәрергә тәкъдим итә. Нәтиҗәдә тагын бер документ барлыкка килә:

«Казан Губерна Жандарм Идарәсе начальнигына

Яшерен

Миңа тапшырылган идарә каршысында Суд эшләрен алып бару кануннарының 1035 статьясы тәртибендә сорау алуга тартылган һәм Җинаять кодексының 102 һәм 126 статьялары буенча гаепләнгән Сембер губернасы Курмыш өязе Тельпино волосте Ащерино авылы крестьяны Федор Антонов Сидоровта тентү вакытында куен дәфтәре табылды. Бу дәфтәрдә түбәндәге адреслар бар: (...) «2 — Бакалтай урамы, Асанов йорты, Катерина Тимофеевна, Шурка һәм Веркага», «Казан, Екатерининская урамы, Йонысов йорты, Шәмсекамәр Кулахметьева квартирасы, Гафур — Пороховой бистәсе» (...), «Ибраһим Моратов, Казан».

Язылганнарны хәбәр итеп, мин Сезгә тапшырылган районнардагы адреслар буенча яшәүче кешеләрне ачыклавыгызны һәм ул кешеләр турында үзегездә булган барлык мәгълүматларны безгә җиткерүегезне үтенәм. Әйтелгәннәргә өстәп, Сидоровның, аның күрсәтмәләре буенча, моңарчы Оренбургта яшәвен белдерәм (...).

Әстерхан губерна жандарм идарәсе начальнигы
полковник Буроломов.
1908 ел, 18 март, № 871»[2].

Жандармнар ашыгалар, Әстерхандагы кулга алулар хәбәре башка шәһәрләргә ирешкәнче аларның күбрәк революционерларның эзләренә төшәселәре килә. һәм атна үтәр-үтмәс, ягъни 26 мартта, Самара губерна жандарм идарәсе начальнигы адреслары күрсәтелгән кешеләр бик тиз ачыкланырга тиешлеген Казан губерна жандарм идарәсе начальнигының кабат исенә төшерә[3].

Рус большевигы, РСДРПның Әстерхан комитеты члены Ф. А. Сидоровның куен дәфтәренә Гафур Коләхметов һәм Ибраһим Моратов исемнәре ничек килеп кергән соң? Бәлки бу гади очраклылык кынадыр? Җавап эзләп Г. Коләхметов турында ба-

---

[1] Саратов өлкә дәүләт архивы, 51 фонд, 1 тасвирлама, 1908 ел, 7 эш берәмлеге, 22 кәгазь.
[2] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы, 199 фонд, 1 тасвирлама, 1435 эш берәмлеге, 169 кәгазь.
[3] Шунда ук, 170 кәгазь.



*Зариф Садыйковның 1904 елның 24 июлендә Ш. Коләхметовага бүләк иткән фоторәсеме. Беренче тапкыр басыла.*

сылган хезмәтләргә, замандашларының истәлекләренә мөрәҗәгать итәм. Берниндә дә очраклылык яки аңлашылмаучылык юк икән. Гафур Коләхметовның сеңелесе Суфия ханым Агееваның истәлекләренә караганда, Ибраһим Моратов (аның чын исеме Зариф Садыйков) 1904—1905 елларда ук, Гафур Коләхметов һәм Х. Ямашевлар белән берлектә, РСДРПның Казан комитеты прокламацияләрен бастыру һәм таратуда актив катнашкан[1]. З. Садыйковның (Ибраһим Моратовның) большевистик прокламацияләр басуын «Яшь гомер» драмасында Г. Коләхметов үзе дә искә ала: «Гали. Ибраһимнар нишләп яталар? Эшләре барамы? Вәли. Басып бетерәмез, диләр»[2]. Гафурның бертуган апасының кызы, язучы һәм тәрҗемәче Гайшә Шәрипова архивында исә бер фоторәсем бар. Һәвәскәр фотограф Пороховой мәктәбе бакчасында төшергән бу фотода Гафур Коләхметов һәм Садыйков йөзләре ачык күренә.

Әстерхандагы рус большевигының куен дәфтәренә Шәмсекамәр Коләхметованың адресы язылуның да сәбәбе бар. Гайшә Шәрипова архивында кадерләп сакланган материаллар арасында Зариф Садыйковның тарихчыларга билгесез тагын бер фоторәсеме бар. Рәсем артына: «Шәмсекамәр Коләхметов[а] ханымга Зариф Садыйковтан, 1904 сәнә, 24 ндә, июнь» диелгән. Бәлки бу да шәхси




*З. Садыйковның шул рәсем артындагы истәлек язуы.*

[1] Г. Коләхметов мәҗмугасы. Мәскәү, 1925 ел, 19—20 битләр.
[2] Г. Коләхметов. Яшь гомер. Казан, 1908 ел, 31 бит.

дуслык истәлеге генәдер? Казан татар укытучылар мәктәбендә оештырылган социал-демократик түгәрәк члены Барый Әминов һәм Суфия Коләхметова истәлекләре мондый шикләнүләргә юл калдырмый: бу түгәрәк утырышлары, алда әйтеп үткәнчә, 1904—05 елларда Шәмсекамәр Коләхметова квартирасында уздырыла һәм түгәрәк эшендә Зариф Садыйков актив катнаша!

1904 елдан партия члены, «яшь татар социал демократиясенең иң турылыклы эшлекелләреннән берсе»[1] булган профессиональ революционер Зариф Садыйков 1905 елның җәендә Кырымга китә[2]. Политик җинаятьчеләрне бөтен Россия буенча эзләү материалларыннан күренгәнчә[3], З. Садыйков Кырымда революцион пропаганда алып барган өчен кулга алына, ләкин озакламый кача һәм 1906 елның июль айларында Ибраһим Моратов исеме белән Әстерханга җибәрелә. Әстерхан татар эшчеләре арасында пропаганда-агитация эшен җәелдереп, аларны рус эшчеләре белән берлектә самодержавиегә каршы көрәшкә туплауда гаять зур көч куйган Ибраһим Моратов РСДРПның Әстерхан комитеты секретаре итеп сайлана[4].

Истәлекләргә караганда, 1907 елның җәендә Гафур Коләхметов Әстерханга килә һәм Ибраһим Моратов квартирасына туктала. Шунысы игътибарга лаек, РСДРПның Әстерхан комитеты каршында татар группасы тарафыннан татар телендә басылган прокламация нәкъ шушы вакытта тарала.

Ф. А. Сидоровның куен дәфтәрендә Ибраһим Моратов Казанда дип күрсәтелгән. Архив материалларыннан күренгәнчә, Ибраһим Моратов, жандармнарның эзәрлекләвен сизеп, 1907 елның ахырында Әстерханнан кача һәм 1908 елның 8 августында туган ягында — Казан губернасының Кукмара волосте Олы Кулбаш авылында үзенең чын исеменә паспорт ала. Күрәсең, Казанда ул Г. Коләхметов белән күрешә, ә Ф. А. Сидоровның куен дәфтәрендәге язу И. Моратовны Казанда кайдан табу өчен кирәк булган. Шәмсекамәр Коләхметова квартирасы татар большевиклары өчен очрашу урыны һәм почта ящигы хезмәтен үтәве истәлекләрдән билгеле иде. Китерелгән документ Гафур Коләхметов һәм апасының адресы башка шәһәрләрдәге большевистик комитетлар, шул исәптән рус большевиклары өчен дә яшерен очрашу урыны булып хезмәт итүен ача һәм Г. Коләхметовның большевиклар белән тыгыз бәйләнештә булуын дәлилли.



*З. Садыйковның 1905 елның 25 августында Ялтадан Ш. Коләхметовага җибәргән ачык хаты.*



---

[1] Сайфи. Среди татар. Зариф Садыйков. «Невская звезда» газетасы, 1912 ел, 29 май.

[2] Бу уңайдан бер төгәлсезлеккә игътибарны юнәлтәсе килә. Тарихчылар, Г. Ибраһимовның «1905 елда татарлар» исемле хезмәтенә таянып, З. Садыйков, 1905 елның декабрендә Казанда кулга алынулар башлангач, Астраханьга качкан, диләр. Гайшә Шәрипова архивында Кырым күренешен сурәтләгән зур бер фоторәсем моңа да ачыклык кертә. Рәсем астына З. Садыйков үз кулы белән русча: «Ш. Коләхметовага Ялтадан, Садыйковтан истәлеккә, 1905 [ел], 25 август, дип язган.

[3] Казагыстан ССРның Үзәк дәүләт тарих архивы. 64 фонд, 1 тасвирлама, 5663 эш берәмлеге, 118 кәгазь.

[4] Ул кул куйган һәм РСДРПның Әстерхан комитеты мөһере басылган таныклык Саратов өлкәсенең дәүләт архивында саклана (51 фонд, 1 тасвирлама, 1907 ел, 62 эш берәмлеге, 6 кәгазь).

Түбәндәге документ исә бу бәйләнешнең ныклыгын тагын бер кат раслый. Әстерхан өлкә дәүләт архивындагы губерна жандарм идарәсе материаллары арасында пехтәләп төпләнгән калын дәфтәр саклана. Аның титул битенә «Осман Мусин давал показания» дип язылган. Баштанаяк доносларданторган бу кара коленкор тышлы дәфтәрнең эче дә кара. Дәфтәр хуҗасы — Пермь губерна жандарм идарәсенең түләүле агенты, Әстерханга Осман Мусин исеме белән җибәрелгән атаклы провокатор «Шаһ» — Шаһиәхмәт Вәлиев. 1909 елның башында Уфада Зариф Садыйковны (И. Моратовны) жандармнарга тоттырган һәм Әстерханга аның көрәштәшләрен, бәйләнешләрен ачыкларга җибәрелгән бу провокатор 1911 елның 8 февралендә үз дәфтәренә түбәндәге сүзләрне язып куя:

> «Бер татар сүзләренә караганда, Ибраһим Моратов Севастополь төрмәсеннән качкан вакытта үтерелгән. Ләкин бу тәгәл мәгълүмат түгел. Бу турыда тәфсилләрәк итеп Казанда, Пороховой урамында яшәүче Гафар Кулахметьев белә» [1].

Ибраһим Моратов (Зариф Садыйковның) язмышы турында провокатор ялгышкан. Әмма 1905 елны Казанда Зариф Садыйковлар белән бергә эшләгән һәм 1908 елдан охранканың түләүле агентына әйләнгән сатлык җан Гафур Коләхметовның элеккеге революцион эшчәнлеген дә, хәзерге көндәге бәйләнешләрен дә яхшы белгән. Бу уңайдан Гафур Коләхметов һәм Зариф Садыйковның соңгы көннәренә кадәр дусларча, үзара ярдәмләшеп яшәүләрен әйтеп китәргә кирәк. Үләренә бер ай кала, 1912 елның 27 мартында, Кырымнан туганына язган хатында З. Садыйков: «Гафурга барып, ни сәбәпле хат язмаганын белешеп язсана» [2],— дип сорый.

1908 елда Гафур һәм Ибраһим Моратовның кем икәнлеген ачыклый алмаган Казан жандармнары (Самара губерна жандарм идарәсе начальнигына 1908 елның 3 апрелендә язган җавабында Казан губерна жандарм идарәсе начальнигы полковник Калинин бары тик Шәмсекамәр һәм Суфия Коләхметовалар турында гына мәгълүмат бирә) [3] провокатор Осман Мусин доносыннан соң Гафур Коләхметовның эшчәнлегенә җентекләбрәк карый башлый.

> «**Сентябрь**, 27. Җәйге тәнәфестән соң татар яшьләренең түгәрәге үзенең эшен дәвам итте. Хәзер аның башында... Казан университеты студенты Хөсәен Ямашев тора... һәм түгәрәккә ул социал-демократик төс бирергә тырышачак»,—

диелә икенче бер провокаторның доносында. Бу түгәрәк әгъзалары арасында укытучы Коләхметов фамилиясе дә күрсәтелә (Казан губерна жандарм идарәсе начальнигының 1911 елның 6 октябрендә Идел буе охранкасына рапорты) [4].

Провокатор 1911 елның 7 ноябрендә ясаган доносында, түгәрәк җитәкчесе Ямашевның марксистик тенденция бирергә тырышуы аркасында, түгәрәктән милләтчеләрнең китүен һәм анда барлыгы 6 кеше генә, шул исәптән укытучы Коләхметовның, калуын хәбәр итә [5]. Жандармнар игътибарыннан Г. Коләхметов катнашкан бер генә түгәрәк утырышы да, ул әйткән бер генә сүз дә читтә калмый. «Житель», «Борис» исемнәре белән яшеренгән провокаторлар 1913 елның 31 мартында Г. Коләхметовның татарлар арасында профессиональ белем алу мөһимлеге турында сөйләве [6], аның большевик Галимҗан Сәйфетдиновның милләтчелеккә каршы чыгышын яклавы [7], Киев студентлары съездына Казаннан делегат булып Г. Коләхметов бару мөмкинлеге [8] турында жандармнарга төкми-чәчми хәбәр итеп торалар.

Гафур Коләхметовның иҗтимагый эшчәнлеге турында төрле сүзләр йөри башлагач, Г. Ибраһимов үз вакытында: «Г. Коләхметов большевиклар белән эшләде»,— дип чыккан иде. Фактлар карт революционерның никадәр хаклы булуын раслыйлар. Алда яңа эзләнүләр, яңа тикшеренүләр булыр, Г. Коләхметов биографиясенең яңа сәхифәләре ачылыр... Тик шунысы ачык — Г. Коләхметов үзенең тормышын һәм революцион публицистик эшчәнлеген большевиклар белән бәйләгән һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр бу эшкә турылыклы булып калган.

---

[1] Әстерхан өлкә дәүләт архивы, 286 фонд, 2 тасвирлама, 514 эш берәмлеге, 23 кәгазь.
[2] Х. Хәсәнов. Революционерның соңгы хатлары. «Казан утлары», 1975 ел, 11 сан, 114 бит.
[3] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы, 199 фонд, I тасвирлама, 1435 эш берәмлеге, 171 кәгазь.
[4] Саратов өлкә дәүләт архивы, 51 фонд, I тасвирлама, 1911 ел, 44 эш берәмлеге, 98 кәгазь.
[5] Шунда ук, 114 кәгазь.
[6] Саратов өлкә дәүләт архивы, 51 фонд, I тасвирлама, 1913 ел, 25 эш берәмлеге, 70 кәгазь.
[7] Шунда ук, 590 кәгазь.
[8] Шунда ук, 82 кәгазь.

# ФРОНТТАН ХАТЛАР, ФРОНТКА ХАТЛАР

*Татарстан Дәүләт архивындагы тарихи документлар белән танышканда, язучыларыбызның Ватан сугышы елларында Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе булып эшләгән Гали Динмөхәммәтов исеменә язган хатларына игътибар иттем. (3610 фонд, 1 тасвирлама). Минә герой шагыйребез Муса Җәлил имзасы куелган хатлар. М. Максуд, Ә. Ерикәй, Ш. Маннур хатлары... Шунда ук Г. Динмөхәммәтовның фронтовик язучыларга җавап хатлары саклана.*

*Язучылар фронт хәлләре турында сөйлиләр, иҗат планнары белән уртаклашалар, республика тормышы белән кызыксыналар, тылда яшәүче семьялары турында кайгыртуны үтенәләр. Республика президенты исә аларны Татарстан тормышы белән таныштырып тора, аларга иҗат уңышлары тели.*

*Әдәби һәм фәнни кыйммәткә ия булуларын искә алып, әлеге хатларның бер өлешен укучылар игътибарына тәкъдим итәргә булдык.*

*АЛЬБЕРТ АПНЕТДИНОВ.*

## Язучыларның хатлары

23 январь, 1942 ел

Хөрмәтле Динмөхәммәтов ага!

Сезгә кайнар сәламемне юллап калам.

Казанда мине язучы, композитор, артист иптәшләр искиткеч җылы каршы алдылар һәм бик зурлап озаттылар. Аеруча партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре, безнең Татарстан тарафыннан шундый тирән игътибар һәм сизгер кайгыртучанлык күрсәтелүгә мин чиксез шатланам. Моңарчы эшләгән эшем бик кечкенә булса да һәм мин андый игътибарга, кадерләүгә лаек булмасам да, партия һәм хөкүмәт җитәкчеләребез — сезнең тарафтан күрсәтелгән бу игътибарны мин, киләчәк эшләремә наказ төсендә аңлап, бөтен көчем белән акларга тырышачакмын. Бу, әлбәттә, ялгыз бер миңа күрсәтелгән игътибар түгел. Моны мин татар совет культурасы — сәнгате һәм әдәбиятына карата күрсәтелгән кайгыртучанлык дип аңлыйм. Мин сезнең һәм Казандагы бөтен иптәшләремнең бу игътибарына киләчәктә әдәбият һәм фронттагы зур эшләрем белән җавап бирергә тиешмен дип уйлыйм.

Мин китәсе көнне иптәшләр зур мәҗлес җыйганнар иде. Сез районда булып килә алмадыгыз булса кирәк. Мөхәммәтов[1] һәм Тинчурин[2] иптәшләр дә бар иде. Мондый махсус кичә җыеп, анда Имаметдинов[3] һәм Кутуйның[4] миңа карата зурлатып, күпертеп речь сөйләүләре миңа, әлбәттә, бик уңайсыз булды. Бу инде артык эшләнгән эш иде. Мин моның өчен бик борчылдым, бик уңайсызландым. Оялып, кая керер урын тапмый аптырап утырдым. Чөнки артыграк мактап, артыграк күпертып җибәрделәр. Шулай да иптәшләрнең шундый җылы карашы һәм чын күңелдән әйткән теләкләре мине бик дулкынландырды. Мин моңа тирән рәхмәт белдерәм.

Семьям мин юкта хөкүмәт кешеләре тарафыннан үзенә зур игътибар һәм кайгыртучанлык күрсәтелгәнен сөйләде. Моның өчен сезгә шулай ук зур рәхмәт укыйм. Кыскасы, без — язучылар һәм шулардан берсе мин — сезнең тарафтан зур игътибар белән чолганып алынганбыз. Моны һәр адымда күрергә туры килә. Мин моны аңлыйм.

Моңарчы 5 айлык фронт-курс тормышымда, үз бурычымны иң алдынгы отличник булып үтәү белән бергә, 20 ләп боевой шигырь яздым (1—2 сен кичәдә укыдым). Моннан соң фронтовик һәм шагыйрь булып эшемне дәвам иттерермен.

Хәзер мин әле резервта. Шушы 2 көндә Көнбатыш фронтына хәрәкәттәге Армиягә китәм. Приказ көтәм. Фронттан сезгә шиксез язып торачакмын. Хушыгыз!

Кайнар сәлам белән сезнең

**Муса Җәлил.**

[1] Самат Мөхәмматов ул вакытта КПССның Татарстан өлкә комитетында секретарь булып эшли.
[2] Закир Вәли улы Тинчурин — Татарстан китап нәшрияты директоры.
[3] Төхфәт Имаметдинов.
[4] Күренекле язучы Гадел Кутуй.

2 июнь, 1942 ел

Хөрмәтле Динмөхәммәтов ага!

Сезгә йөрәгемнән чыккан кайнар боевой сәламемне сөйләп калам.

Мин армиягә киткәннән бирле, фронт эшеннән бушаган арада, Сезгә шундый сәлам хатлары язуны гадәт иттем. Сез моның өчен миңа ачуланмый торгансыздыр бит?

Моннан элек язган хатларымны вакытында алгансыздыр дип ышанам. Казаннан киткәннән соң мин бераз вакыт Мәскәүдә резервта булдым. Аннан мине Төньяк-көнбатыш фронтына (Волхов юнәлеше) батальон военкомы итеп җибәрделәр, ә монда, минем язучылык һәм газета эшендәге тәҗрибәмне искә алып, Хәрәкәттәге удар армия газетасына литератор-инструктор итеп билгеләделәр. Шул көннән алып мин фронтта военкор. Болай тыныч эштер кебек тоелса да, ләкин фронтта ул алай ук түгел. Миңа, военкор буларак, атнага 2 генә көн редакция землянкасында (шалашында), ә 5 көн рәттән фронтның алгы позицияләрендә, полк, батальон, рота рубежларында, блиндажлардан-блиндажларга боевой походта йөреп үткәрергә туры килә. Чөнки шунсыз газетаны оператив һәм боевой итеп чыгарып булмый. Фронтның чын геройларын, шулай ук командир һәм сугышчыларны газетада яктырту, анализ ясау өчен, боевой эпизод һәм боевая операцияләрне бары фронтның алгы сызыгында гына күреп була. Мин, үз фронтыбызның бөтен почмагында булып, шактый нәрсә күрергә, шактый хәлләр баштан кичерергә өлгердем инде. Зур батырлыклар күрсәтеп, орден-медаль алган байтак татар егетләрен дә күрдем. Алар турында «Кызыл Татарстан»га язам, шулай ук әдәби әсәр язарга җыенам. Шулай итеп, монда чынчынлап, шигырьдә әйткәнчә, бер үк вакытта каләм һәм автомат белән сугышырга туры килә. Мин үз эшемнән бик разый. Бу эштә күп нәрсә күрергә, күп нәрсә кичерергә мөмкин. Тик шулай да мин, Фадеев[1] тәкъдим иткәнчә, «Кызыл Татарстан»ның махсус военкоры булып, милли частьларда йөрергә, татар геройлары турында язарга теләр идем. Татар язучысы булганга, мин рус газетасына күп файда китерә алмыйм. Бу турыда «Кызыл Татарстан»га яздым. Барып чыкса, яхшы булыр иде, көтәм. Әгәр сез бу эштә ярдәм итсәгез, бәлки, чыннан да, барып чыгар иде. (Татар халкының Ватан сугышында катнашуын чагылдыру һәм шуңа тарихи материал җыю өчен дә минем хезмәтемә киң юл ачылыр иде.)

Сезгә, Гали ага, тагын бер зур үтенечем бар: минем тормыш иптәшем Әминәгә Мәскәүгә барып килергә пропуск кирәк иде. Аның әти-әнисе Мәскәүдә. Ул, 5 яшьлек кызым Чулпанны әти-әнисенә илтеп куеп, үзе эшкә урнашырга тели. Аннан әтисенең саулыгы начар, шуңа борчыла. Сез, мөмкин булса, Әминәгә кызым белән

[1] Күренекле рус совет язучысы Александр Фадеев.

Мәскәүгә барып килергә ничек тә пропуск алуда ярдәм күрсәтсәгез икән. Моны инде бик үтенеп сорыйм.

Үзем язу эшемне дәвам иттерәм. Байтак шигырь һәм җыр яздым. Буш арада Сезгә күчереп җибәрермен әле.

Хушыгыз. Сәлам һәм ихтирам белән

**Муса Җәлил.**



5 декабрь, 1942 ел

Хөрмәтле Гали Афзалетдинович!

Бу хатны ерактан язам. Казаннан киткәндә Сезне күрә алмадым, бик кызганыч. Сез күрсәткән искиткеч кызык материалларны язып ала алмадым, бик кызганыч. Чакыру килеп, ашыгыч төстә частька китәргә туры килде, шуңа ул материалларны үзем белән алып китә алмадым. Китәр алдыннан ип. Колыбанов [1] янында булдым, ул миндә әйбәт тәэсир калдырды. Аңа сәлам әйтегез.

Хөрмәтле Гали Афзалетдинович, миңа бик зур эш тапшырдылар. Аны үтәү өчен бөтен көчемне бирәчәкмен. Шул ук вакытта, күп елләр буе искиткеч ярдәмчел кеше икәнегезне белгәнгә күрә, Сезнең булышлыкка өмет баглап торам. Кайчан да булса ярдәм сорап мөрәҗәгать итсәм, кире какмассыз дип ышанам...

Мәскәүдә шушы көннәрдә минем китап басылып чыгарга тиеш, берәр данәсен алуга Сезгә, һичшиксез, җибәрермен.

Тирән ихтирам белән

**Әхмәт Ерикәев.**

Бу хатны Ә. Ерикәй рус телендә язган.

[1] Колыбанов — Татарстан партия өлкә комитетының беренче секретаре.

12 апрель, 1943 ел

Хөрмәтле Гали ага!

«Кызыл сугышчы»ның Сезнең мәкалә басылган номерын җибәрәм. Сез бәлки аны алгансыздыр да инде. Чөнки «Кызыл сугышчы» Сезнең исемгә җибәрелеп тора. Шулай да, на всякий случай, үзем тагын җибәрим, дидем. Вакыт табып, газета турында фикерләрегезне әйтсәгез, яхшы булыр иде.

Мин яңа гына Вязьмадан кайттым. Шәһәр урынында тоташ хәрабәләр. Немец мерзавецлары бөтен йортларны шартлатып һәм яндырып киткәннәр. Немецларның андагы ерткычлыклары турында «Совет әдәбияты» журналы өчен озын очерк язам.

Фәтхуллин [1] турында очерк яздым. Татгосиздат тапшыруы буенча 2 табаклы китап яза башладым һәм бер сәхнә әсәре язуны өмет итәм. Бу эшемдәге ярдәмегез өчен Сезгә рәхмәт укыйм. Либретто турында бер фикергә дә килгәнем юк әле, чөнки моның өчен Фәтхуллинның частенда булып кайтырга кирәк. Ә Җиһанов [2], булса тиз булсын, диде. Хәрби кешенең вакыт бюджеты үз теләвенә генә карап йөрми бит.

Казанда Фәтхуллинның хатынын, балаларын күрдем. Кыш көне Сез аларның тормышын тикшереп ярдәм күрсәтергә кушкансыз икән, бу ярты юлда калган, балалар киемсез икән. Мин аңар Сезнең бу мәсьәләгә зур игътибар итүегезне сөйләдем.

Минем Сезгә үземнең дә бер үтенечем бар, Гали ага. Улым Феликс озак вакытлар авырды, слабыйланды, бу турыда врачтан справка да бар (ул справка Шаһиморатовта [3]). Шул баланы яхшы бер санаторийга җибәрү турында ярдәмегезне үтенер идем. Мондый мәсьәләләр белән Сезнең вакытыгызны алу мәгънәсезлек икәнен белсәм дә, язарга кыюлык иттем, ачуланмагыз.

Хөрмәт һәм сәлам белән

**М. Максуд.**

[1] Ф. Фәтхуллин — Бөек Ватан сугышы герое.
[2] Композитор Нәҗип Җиһанов.
[3] Драматург Зәйни Шаһиморатов.

13 апрель, 1943 ел

Исәнмесез, ип. Динмөхәммәтов!

Бу хатны Сезгә Бари Корбанов дигән кеше яза. Мине хәтерли булсагыз кирәк: сугышка кадәр мин Зеленодольск шәһәрендә завод газетасының редакторы идем. Сугыш башланганнан бирле — Хәрәкәттәге армиядә. Хәзер... фронтында чыга торган татар газетасының редакторы булып эшлим. Монда татарлар бик күп һәм яхшы сугышалар. Илдар Маннапов та биредә. Ул бу арада хөкүмәтнең икенче бүләген алды. Сездән килгән бүләкне дә алды ул. Күп рәхмәт һәм сәлам тапшыра.

Сезгә бер үтенеч бар: безнең фронт газетасында басып чыгару өчен «Помощь Татарии фронту» исемендә бер 100—150 юллык бер мәкалә язып җибәрүегезне сорыйбыз. Моны бу фронттагы татарлар телиләр. Зинһар, бу теләгебезне үти күрегез. Мәкалә рус телендә булса бигрәк тә яхшы булыр. Ул вакытта рус газетасында да басып чыгарыр идек. Бик көтәбез.

Ялкынлы сәлам белән
майор **Бари Корбанов.**
1943 ел

Хөрмәтле Гали ага!

Сезгә 3 нче Украина фронтыннан сәлам җибәреп, зур, җаваплы эшләрегездә матур уңышлар телим.

Мин фронт газетасының татарчасын редактировать итәм. Вакыт сыйдырган кадәр язгалыйм да. Сезгә сентябрь аена кадәр газета җибәреп торган идек, шуннан политуправление читкә газета җибәрүне тыйды. Шул сәбәпле җибәрүебез өзелеп калды. Хәзер мин Сезгә Хәсән Хәйри иптәш артыннан кайбер номерларны, шулар арасыннан Татарстанга багышланган һәм Сезнең мәкаләгез басылган сәхифәлесен җибәрәм. Вакыт табып, хат язсагыз, киңәшләр бирсәгез, шат булыр идем.

Фронт хәлләрен Хәйри иптәш сөйләр. Татар егетләре немец мәлгуньнәрне нык тукмыйлар.

Сәлам белән
**Мәхмүд Максуд.**

20 январь, 1944 ел

Хөрмәтле Гали ага!

Сезгә сугышчан сәлам күндереп, зур җаваплы эшләрегездә зур уңышлар телим.

Фронтыбыздагы татар егетләреннән Сезгә сәлам. Бөек Ватаныбызның барлык милләт уллары белән бергә, татар егетләре фрицларны нык тукмыйлар.

**...Бәйгедә без балкытырбыз Татарстанның данын,**
**Үч сусынын кандырырбыз, агызып дошман канын!..**

— диләр алар («Казанга — фронт сәламе» шигыреннән).

Мин Сезгә Хәсән Хәйри артыннан бер хат җибәргән идем, алгансыздыр дип уйлыйм.

Гали ага, октябрь аенда газетабызда Сезнең «Татарстан — фронтка» дигән мәкаләгезне баскан идек. Аннан соң героик традицияләр турындамы бер мәкаләгез булган дип ишеттем. Үкенечкә каршы, аны үзем күрә алмадым — безгә килмәде.

Инде Кызыл Армия көне җитә. «Гражданнар сугышында татарлар» яки «Фронт белән тыл бердәмлеге» темаларына (почтаның озак йөрүен искә алып, тиз вакыт эчендә) бер мәкалә җибәрсәгез, безгә зур ярдәмегез булыр иде.

Хөрмәт һәм сәлам белән
**М. Максуд.**

P. S.

Декабрь аенда семьям Казаннан Мәскәүгә кайтты. Күрсәткән ярдәмнәрегез өчен, балалар исеменнән һәм үземнән Сезгә күп рәхмәтләр.

1 март, 1944 ел

Кадерле иптәш Динмөхәммәтов!

Сезгә ерак фронттан кайнар сәлам язам.

Бу хатның болай гади кәгазьдә карандаш белән генә язылуы өчен гафу итегез. Минем яшәү һәм эшләү шартларым шундыйрак. Мин хәзер, татар газетасыннан алынып, дивизия газетасына җибәрелдем. Ватанга хезмәт итү, әлбәттә, кайда булса да бер төрле, тик намус белән хезмәт итәргә кирәк. Ә минем үз намусыма тап төшергәнем юк. Ләкин шунысы кызганыч, мин хәзер татар әдәбияты өчен бер нәрсә дә эшли алмыйм. Моның өчен хезмәт һәм тормыш шартлары бер дә мөмкинлек бирми. Хәтта байтак вакытлардан бирле әзерләгән җыентыгымны да эшләп бетерә алмыйм.

Кыскасы, хәлләр менә шулай. Әлбәттә, мин татар әдәбияты өчен дә хезмәт итә алсам, яхшырак булыр иде.

Иптәш Динмөхәммәтов, Сезгә бер үтенечем бар: минем семьям Чепья районында, Түнтәр авылында яши. Иптәшем мәктәптә укыта. Аның язуына караганда, алар 2 айдан артык инде бер грамм да икмәк алмыйлар икән. Моның төп сәбәбе миңа билгеле түгел...

Ярый, хәзергә хушыгыз. Сезне һәр вакыт ихтирам итүче

**Ш. Маннур.**

27 март, 1944 ел

...Хөрмәтле Гали ага!

Тарихи көннәр җитә. Безнең фронт гаскәрләре дә дәүләтебезнең изге чикләренә якынлашып баралар. Шундый тантаналы, шатлыклы көннәрдә сугышчыларыбызга Татарстанның ничек яшәвен, фронт өчен ничек эшләвен белдерә торырга кирәк. Материаллар оештыру һәм шрифтлар алу өчен, коммунист, яшь журналист Г. Әхмәтшинны фронтыбызның Политуправлениесе Казанга җибәрә. Аңар ярдәм итүегезне үтенәм һәм үзегезнең мәкалә бирүегезне сугышчылар исеменнән үтенеп сорыйм. Сезнең берничә мәкалә һәм чыгышларыгызны бастык. Алар агитаторлар өчен бик кыйммәтле материал булып хезмәт итәләр.

Газетабызның кайбер номерларын җибәрәм. Фикерләрегезне һәм замечаниеләрегезне язсагыз, бик яхшы булыр иде.

Үзем исән-сау. Редакторлыктан тыш, иҗат эшләрен дә дәвам иттерергә тырышам. Байтак шигырьләр яздым.

Заһид Хәбибуллин «Кара йөзләр» операсын тәмамлап килә икән дип ишеттем. Бу эштә Сезнең тарафтан ярдәм һәм внушение булгандыр дип уйлыйм. Талантлы егет ул. Яхшы бер опера бирсен иде.

Ком. сәлам һәм хөрмәт белән

**М. Максуд.**

23 ноябрь, 1942 ел

Хәерле көн, ип. Баян!

Хатыгызны алдым. Аңа бик шатландым...

Ип. Баян, барыбыз да — бөтен совет халкы сугыша. Берәүләребез үзләренең изге бурычларын, кулларына корал тотып, фронтның алгы сызыгында үти. Сез һәм Сезнең кебек икенчеләребез дошманга каршы матбугат дигән корал белән сугышалар, өченчеләребез тылдагы фидакарь хезмәтләре белән дошманны җимерәләр. Һәм безнең һәркайсыбыз Туган илнең азатлыгы һәм иминлеге өчен үзенең бөтен көчен, кирәк икән гомерен дә бирә. Шуңа да без совет патриотлары. Әмма Сез хаклы, үлем турында түгел, фашист хәшәрәтләрен тар-мар иткәннән соң туачак бәхетле тормыш турында уйларга кирәк. Һәм шул чагында Сезнең бокалга башка бик күпләр дә кушылыр.

Ә хәзергә Сезгә уңышлар телим. Редакциягезнең барлык хезмәткәрләренә сәламемне һәм иң изге теләкләремне җиткерегез.

Коммунистик сәлам белән
**Г. Динмөхәммәтов.**

---

Шагыйрь Нур Баянга адресланган бу хат рус телендә язылган.

28 декабрь, 1942 ел

Исәнмесез, хөрмәтле Ерикәев иптәш!

Кайгыгызны уртаклашам, китәр алдыннан кабат очрашырга туры килмәде шул. Шулай да тиздән очрашырбыз һәм син үзеңне кызыксындырган материаллардан теләгән кадәр файдаланырсың дип ышанам.

Сезнең ярдәмгә өмет баглап торам дигәнсең. Бу очракта язу машинкасын җибәрүне кузгә тоткансыңдыр дип уйлыйм. Машинканы якын көннәрдә җибәрербез. Сиңа тапшырылган җитди эшне башкарып чыгуда ярдәм итеп торуны алга таба дә үземнең бурычым дип санаячакмын.

Уңышлар телим.

Хатыңнан һәм малайдан сәлам.

Китабыңны һәм хатларыңны көтәм.

Сәлам белән
**Г. Динмөхәммәтов.**

---

Рус телендәге бу хат Ә. Ерикәйнең 1942 ел. 5 декабрь тарихлы хатына җавап рәвешендә язылган.

22 февраль, 1943 ел

Сәлам сиңа, ип. Ерикәев!

Хатыңны алдым. Безнең машинка яшен тизлегендә синең арттан чаба һәм җиңү көненә кадәр ничек тә куып җитә икән, мин моңа һич каршы түгел. Киресенчә, сугышны машинкасыз гына ерып чыгуга үзең дә каршы килмәссең дип ышанам. Син үз частең белән немецларны куганда, әйдә, гуляйть итеп йөри бирсен...

Бәлки кирәге чыгар, газетагыз өчен бер мәкалә җибәрәм. Әгәр ул барып җитсә, якташларыбызга республикадагы практик эшләр хакында укуы күңелле булыр дип уйлыйм.

Бик кызганыч, иҗат эшләрең турында конкретрак язмагансың. Иҗат өчен материал, төрле тәэсоратлар, героика хәзер синдә кирәгеннән артык.

Күптән түгел ип. Бубенновтан[1] хат алдым. Фронт хикәяләрен җибәргән. Киләчәктә язар өчен, бик күп материал тупладым дигән. Хәер, миңа калса, ул хәзер дә күп яза төсле. Үзеңнең эшләрең хакында яз.

Уңышлар телим.

Хатыннан, Мараттан сәлам. Ул техник артиллерия мәктәбенә укырга китте.

Кайнар сәлам белән
**Г. Динмөхәммәтов.**

---

Хат рус телендә язылган.
[1] Танылган рус совет язучысы Михаил Бубеннов. Сугышка чаклы «Советская Татария» газетасында эшләгән.

1943 ел

Иптәш Гадел Кутуй!

Хатыгызга бераз соңгарып җавап бирәм. Үпкәләмәгез, вакыт булмады — республика районнарында йөрдем.

Сез хаклы, безнең республикада әдәби әсәрләр язу эше бик шәп тормый. Бу өлкәдә беренче адымнар, кем әйтмешли, яралгылар гына бар. Нихәтле генә гаҗәп тоелмасын, бүгенге көнгә кадәр геройларыбызны сурәтләгән заманча, капиталь әсәрләребез юк, ә геройларыбыз хәзер бик күп. Якын көннәрдә бу мәсьәләне директив органнар каршына куярга уйлыйбыз, гонорар мәсьәләсе дә төзәтелер һәм Татарстан Язучылар союзына мәгълүм юнәлеш бирелер дип ышанам.

Гаиләгезнең авырганлыгын алар терелгәч кенә белдем. Күрәсең, тормыш иптәшегез артык тыйнак кеше, шуңа күрә бу хакта вакытында хәбәр итмәгәндер, мин озак вакытлар республика районнарында булдым, яки шул чорга туры килгәндер.

Сезнең гаиләгез турында кайгыртып, мин бары гражданлык бурычын гына үтәдем.

Хатларыгызга шат булачакмын. Вакыт табып — языгыз.

Дусларча сәлам белән
**Г. Динмөхәммәтов.**

---

Хат рус телендә язылган.

8 сентябрь, 1943 ел

Хәерле көн, Гадел!

Яңа гына хатыңны алдым, бик шатландым. Бу юлы шәп килеп чыкты, алуга җавап язам. Соңгы вакытта Казанда бик аз булам, вакытның күбрәк өлеше районнарда уза. Бездә хәзер эш күп: урак урасы, дәүләткә икмәк тапшырасы, көзге чәчүгә чыгасы бар. Казанга шушы көннәрдә мин югында җыелган ашыгыч эшләрне хәл итү өчен генә кайттым.

Хөкүмәтебезнең югары бүләген — Кызыл Йолдыз орденын алуың белән чын күңелдән котлыйм. Шәп булган! Совет язучысы каләм белән генә түгел, штык белән дә көрәшә ала икән, бу тагын бер мәртәбә шул хакыйкатьне раслый.

Гозерегезне үтәдем — хатыныгызны үз йортына якын булган госпитальгә эшкә күчерү турында ТАССР Сәламәтлек саклау халык комиссары ип. Прокушевка шалтыраттым. Ул шунда ук бу хакта тиешле күрсәтмә бирде.

Немец-фашист илбасарларына каршы көрәштә уңышлар телим.

Сугышчан эшләрегез, тормыш-көнкүрешегез хакында языгыз.

Дусларча сәлам белән
**Г. Динмөхәммәтов.**

---

Хат рус телендә язылган.

8 сентябрь, 1943 ел

Хәерле көн, ип. Баян!

Беренчедән, хөкүмәт бүләге — Кызыл Йолдыз ордены алуыгыз белән чын күңелдән котлыйм.

Икенчедән, шуны хәбәр итәм: семьягыз начар яшәми, алар хакында Татарстан Язучылар союзы кайгырта.

Сез, әлбәттә, хаклы, фронтны бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итү һәм халык хуҗалыгының теге яки бу тармагында артта калуны булдырмас өчен, тылдагы хезмәткәрләрдән зур һәм киеренке эш сорала. Кызганычка каршы, безнең республикада авыл хуҗалыгы һаман да артка калган тармак булып килә әле. Татарстан партия оешмасының бөтен көче әлеге участокны төзәтүгә юнәлдерелгән. Без бу өлкәдә эшне нык көчәйттек, шуның аркасында Сезгә җавап язарга соңардым да. Мине тиргәмәссез дип уйлыйм.

Кызганычка каршы, республика газеталарын җибәрә алмадым, тиражлары бик чикләнгән.

Немец-фашист илбасарларына каршы көрәштә уңышлар телим.

Сәлам белән
**Г. Динмөхәммәтов.**

---

Хат рус телендә язылган.

10 апрель, 1944 ел

Иптәш Маннуров!

Сезнең хатыгызны алдым. Искә төшереп язуыгыз өчен рәхмәт.

Сез дивизия газетасына күчкәнсез икән. Бик яхшы һәм Сезнең өчен файдалы эш. Сез бу газетада эшләү дәверендә үзегезгә зур иҗат азыгы таба алачаксыз. Семьягыз турында язгансыз. Хәзер тормыш шартлары авыррак шул. Шулай да мин шушы көннәрдә үк Сезнең семьягызга нормаль тормыш шартлары тудыру буенча Чепья район советы башкарма комитеты председателенә мөрәҗәгать итәрмен.

Ватанга хезмәт итү һәм татар әдәбиятын баету буенча алып бара торган эшегезне уңышлы дәвам итегез!

Кулыгызны кысып, сәлам белән **Г. Д.**

---

Эчтәлегеннән күренгәнчә, бу хат Шәйхи Маннурның 1944 ел, 1 марттагы хатына җавап итеп язылган.

22 апрель, 1944 ел

Хәерле көн, ип. Маннур!

Хатыгызны һәм газеталарны алдым. Минем мәкаләне шәп урнаштыргансыз. Шул кадәресен дә әйтергә кирәк, соңгы вакытта газетагыз гомумән яхшырды. Материаллар карарга матур, укырга җайлы итеп урнаштырыла. Сизелеп тора, редакция хезмәткәрләре үз газеталарын яраталар һәм аның турында нык кайгырталар. Газетаның һәр саны үзегезне генә түгел, укучыларны да канәгатьләндерәдер дип уйлыйм, бу исә — бик мөһим нәрсә.

Тормышыгыз ничек? Ип. Гыймадиев [1] ничек килеп җитте? Ул моннан бераз канәгатьсезлек хисе белән китте кебек. Ярар, үпкәләмәсен, тагын кайтырсыз әле.

Сау булыгыз. Уңышлар телим.

Иптәшләргә сәлам.

**Г. Д.**

---

Шәйхи Маннурга адресланган хатларның бусы рус телендә язылган.

[1] Минһаҗ Гыймадиев — журналист, «Алга, дошман өстенә» исемле газетаның редакторы.

22 апрель, 1944 ел

Максуд!

Сезнең хатыгызны алдым. Искә төшерүегез өчен рәхмәт.

Фронтта татар сугышчыларының батыр сугышулары мине шатландыра... Газетагызга булган фикер һәм замечаниеләрне бу хатта яза алмыйм, чөнки вакытым бик тар. Тагын шуны әйтергә кирәк, Сезнең газеталар миңа бик сирәк килә, күп номерлары килми.

Хәзерге вакытта безнең дә монда эш кызу. Язгы чәчү вакыты килеп җитте. Әле бүген генә районнан кайттым, кайтуыма мине Сезнең хатыгыз көтә иде.

Фронтовикларның уңышлы рәвештә немец фашистларын кыйнауларына җавап итеп, язгы чәчү планын тулы рәвештә һәм кыска срокта үтәп чыгарга уйлыйбыз.

Фронт Политуправлениесе җибәргән журналист Г. Әхмәтшинга ярдәм итә алмадым, хәтта ул кешене күрә дә алмадым. Өйдә юк идем.

Эшегезне уңышлы дәвам иттерүегезне теләп:

**Г. Д.**

12 июль, 1945 ел

Хәерле көн, Михаил Васильевич!

Котлау җибәргән өчен рәхмәт. Совет Татарстанының 25 еллыгы гаять күтәренке шартларда, шатлыклы обстановкада узды. Бу көннәрдә Сезнең биредә була алмавыгыз бик кызганыч. Барыбыз да язучыларыбызның тизрәк туган илгә кайтуларын һәм иркен шартларда әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлауларын телибез. Бу теләк якын атналарда тормышка ашар дип уйлыйк.

Очрактан файдаланып, күңелсез хәбәр җиткерәм. 16 июньдә, каты авырудан соң, талантлы фронтовик язучы Гадел Кутуй үлде. Ялкынлы патриот буларак, сугыш елларында ул дүрт тапкыр хөкүмәтебезнең бүләген алган иде. Барлык язучылар җәмәгатьчелеге яраткан каләмдәш дусларын хөрмәтләп искә алалар, аның исеме халык күңелендә мәңге сакланыр.

Иң изге теләкләр яусын. Сезгә нык сәламәтлек һәм эшегездә уңышлар телим.

Дусларча сәлам белән

**Г. Динмөхәммәтов.**

---

М. Бубенновка адресланган бу хат рус телендә язылган.

Хәерле көн, ип. Гыйльманов!

Соравыгызны искә алып, газетагызга мәкалә җибәрәм. Кызганычка каршы, аны Кызыл Армия көненә өлгертә алмадым, әмма мәкаләдә китерелгән фактлар искермәс дип уйлыйм. Димәк ки, Сез аны шикләнми файдалана аласыз.

Тормышыгыз ничек бара?

Иптәшләрегезгә сәлам.

Сәламәтлек һәм уңышлар телим.

Сәлам белән

**Г. Д.**

---

«За Родину» исемле газетаның редактор урынбасары Гани Гыйльмановка адресланган бу хат рус телендә язылган, язылу вакыты билгесез.

## Рафаэль Мостафин

# ЭТЮДЛАР

ТӘНКЫЙТЬЧЕНЕҢ КУЕН ДӘФТӘРЕННӘН

*Язучыларныкы кебек ук, тәнкыйтьченең дә куен дәфтәрләре була. Ул аларга иҗат мәсьәләләре һәм тормыш күренешләре хакындагы күзәтүләрен, теге яки бу язучы иҗаты, я булмаса аерым әсәр уңае белән туган фикерләрен теркәп бара.*

*Аларның күбесен, чимал буларак, төрле мәкалә һәм рецензияләр язганда файдаланасың. Ә кайберләре, беркая да сыймыйча, куен дәфтәрендә торып кала.*

*Төрле елларда теркәлгән шундый фикерләрнең кайберләрен укучылар игътибарына тәкъдим итәм.*

*АВТОР.*

## Талант

Күптәнге бер афоризм искә төште: талант — хыялга тапкырланган акыл ул. Гаять тә акыллы, ифрат зур белемле кешеләрне очратканым бар. Ләкин аларның байтагы әдәбият-сәнгать өлкәсендә берни дә булдыра алмады, чөнки иҗади хыяллары ярлы һәм канатсыз булып чыкты.

Шул ук вакытта мәсьәләнең икенче ягын да истән чыгармаска кирәк: иҗат эшен оештыра, аңа юнәлеш бирә торган акыл көченнән тыш, хыял үзе генә уңышка ирешә алмый. Нәкъ арифметика законындагыча — тапкырланучыларның берсе ноль булса, тапкырчыгыш та нольгә тигезләнә.

## Үз-үзеңне бүлгәләү

Матур әдәбият әсәрләренең һәркайсында диярлек язучы үзе, аның рухи дөньясы һәм холык-характеры чагыла. Күренекле француз язучысы Флобер бер дә юкка гына: «Мадам Бовари — ул мин үзем», — димәгән.

Гомәр Бәшировның «Намус» романындагы Нәфисә образында язучының үзенә хас кайбер сыйфатларны очратырга мөмкин: басынкылык, ихлас күңеллелек, гаделлеккә омтылу, кешеләргә карата игътибарлы һәм ихтирамлы булу... Әмирхан Еники белән Фатих Хөсни геройларына мөрәҗәгать итсәк тә, шул ук хәлне күрәбез.

Матур әдәбиятның закончалыгы шундый, күрәсең. Әдәби персонажлар тере һәм тулы канлы булсын өчен, язучы үз-үзен бүлгәли, үзендәге ниндидер сыйфатларны геройларына бирергә тиеш. Автор үз күңеленең, җанының ниндидер өлешен геройларына бирә алганда гына образлар ышандырырлык була.

## Тәнкыйтьченең гаделлеге

Кайвакыт тәнкыйтьне бал корты белән чагыштыралар. Күп кеше корт чакканны яратмый, әмма аның шифасы барлыгын яхшы белә. Тәнкыйть фикере белән дә шундый ук хәл. Ничек кенә ачы һәм авыр тоелмасын, әгәр гадел тәнкыйть икән, аның язучыга файдасы тими калмаячак. «Үзе ясаган яраларны хакыйкать үзе дәвалый», — дигән Гёте.

## Сүзнең нерв үзәге

Тышкы яктан никадәр генә төзек һәм шома булмасын, бер әсәр сине битараф калдыра, ә икенчесе ниндидер тылсымы белән үзенә тарта, сокландыра, гаҗәпләндерә. Нилектән бу?

Яшь язучыларның бер киңәшмәсендә, шушы мәсьәләгә тукталып, Ә. Еники болай дигән иде:

«Яңа хикәя яки повестьның беренче вариантын кәгазьгә төшергәч, ничектер, бушанып калгандай буласың. Ләкин күп тә үтми, күңелне яңадан шөбһәле уйлар бимазалый башлый. Әсәрнең кимчелекләре, йомшак яклары күзгә ташлана. Сизеп, күреп торам: сүзләр үз урыннарында түгел, һәр сүз аерым, үзбаш яши. Янәшә тору алар өчен уңайсыз, хәтта газаплы кебек. Аларның төрлесе төрле тавышка кычкыра. Һәм мин үземнең көчсезлегемә үзем таң калам.

Аннары эшкәртү-шомарту эшенә тотынам. Сүзләрне тегеләй дә, болай да үлчәп карыйм, авырлыклары, төсе-тәме, хуш исе һәм яңгырашларына карап, аларны берсе-берсенә җайлыйм. **Сүзләрнең нерв үзәген эзлим.** Газаплы һәм ялыктыргыч эш бу. Ләкин сәнгатьтә башка төрле юлларны мин танымыйм. Бер тапкыр күчереп чыгуга шунда ук яңадан башлыйм. Баштан ахырга кадәр биш-алты тапкыр шулай эшләп чыкмыйча торып, әсәремне каләмдәш иптәшләремә күрсәтергә батырчылык итмим. Ләкин аннан соң да әсәрне эшкәртү дәвам итә әле».

Сүзнең нерв үзәге... Чыннан да, яшь язучыларга уйланырлык нәрсә бар монда.

## Сюжет

Сюжетны без еш кына бер-бер артлы тезелеп килгән вакыйгалар тезмәсе дип аңлатабыз. Ләкин вакыйгалар тезмәсен теләгән кадәр сузарга, өзлексез дәвам итәргә мөмкин. Түбән зәвыклы укучы шуңа да канәгать булачак. Чөнки аны, барыннан да бигрәк: «Тагын ни булыр икән?» — дигән сорау кызыксындыра.

Хәлбуки, сюжет ул — вакыйгалар тезмәсе ярдәмендә әсәрнең мәгънәсен, аның идеясен чагылдыра торган чара. Икенче төрле әйтсәк, сюжет ярдәмендә язучы укучыга җиткерергә теләгән төп фикерен гәүдәләндерә.

## Иреклe шигырь

Классик үлчәм кысаларына сыймаган һәр тезмә әсәрне иреклe шигырь дип йөртү киң таралган. Әмма ирекле шигырьнең дә үз законнары һәм үз тәртибе, ниһаять, үз эчендә төрләргә бүленеше бар. Әйтик, ритмик проза (татар әдәбиятында нәсер дип

йөртелә) бар, төгәл үлчәүле ак шигырь бар, ассоциациягә корылган ирекле шигырь бар.

Ирекле шигырь нинди дә булса төгәл үлчәүгә корылмый, ләкин аның да тирәндә яткан үз эчке ритмы була. Дөрес, ирекле шигырьдә рифма юк, ләкин әсәрнең умыртка сөяген тәшкил иткән образ, шул образның үсеш логикасы бар.

Һәрхәлдә, ни генә димик, классик шигырьне теләсә ничек бозу, элеккеге кагыйдәләрне инкарь итү юлы белән генә ирекле шигырь тудырып булмый.

## Исемең шагыйрь икән...

Шигырьне бездә яраталар, шагыйрьләргә хөрмәт белән карыйлар. Шагыйрь исемен йөрткән кешегә, теләсәң-теләмәсәң дә, Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлилләр данының шәүләсе төшә...

Ләкин шагыйрь дигән олы исемне йөртергә кыюлыгың җиткән икән, син инде мактауларга гына түгел, ә авырлыкларга һәм газапларга да әзер булырга тиешсең. Дан ул, Аладин лампасы кебек, тылсымлы нәрсә. Махсус рәвештә дан артыннан куып йөрүчеләргә ул сирәк эләгә.

Башкаларга гафу ителә торган кимчелекләр шагыйрьгә гафу ителми. Чөнки шагыйрь ул — кыю һәм намуслы, зирәк һәм миһербанлы, принципиаль һәм туры сүзле кеше. Һәрхәлдә, шундый булырга тиеш. Шагыйрь гади кеше түгел, ул — байрак. Ә байракта тап була алмый.

Шагыйрь бай рухи тормыш белән яшәргә, һәр чак янып яшәргә тиеш. Ирешелгән уңышлар белән канәгатьләнеп, күңелендәге утны сүндерә һәм тынычлана башладымы — укучы аңардан шунда ук йөз чөерәчәк. Шагыйрьнең картаерга, дөнья ваклыклары артыннан куарга, куркак һәм өркәк кеше булырга хакы юк. Шагыйрь исеме аңардан хакыйкать өчен көрәшче булуны, башкалар кайгысын үз кайгысы итүне һәм тормыш ваклыкларыннан өстен торуны таләп итә. Шунсыз ул нинди шагыйрь булсын?!.

**Я жил, я был —**
**За все на свете**
**Я отвечаю головой,—**

дигән А. Твардовский.

Халык, тарих алдындагы җаваплылык хисе иҗат кешесен чын шагыйрь итеп үстерәдер дә, мөгаен.

## Сүзгә-сүз тәрҗемә

Кайчак үзеңә таныш берәр шигырьнең башка телгә тәрҗемәсен укыйсың да гаҗәпкә каласың. Сүзләре таныш та кебек, әмма оригиналның пафосы, рухы, хисси эчтәлеге бөтенләй югалган була.

Бөтен бәла аның сүзгә-сүз тәрҗемә ярдәмендә эшләнгән булуында. Хәлбуки, сүзгә-сүз тәрҗемә — сүнгән учак ул. Һәм тәрҗемәче еш кына оригиналның үзен түгел, бөтенләй башка ялкынны дөрләтергә азапланган булып чыга.

## Шигырь укыганда...

Бер шагыйрьнең шигырьләрен укыйм. Рифмасы, ритмикасы, образлары — барысы да урынында кебек. Ләкин һич күңелгә ятмый. Чүбек кебек чәйнәлеп беткән фикерләр, төссез, рухсыз юллар...

Чын шигырь, минемчә, акыл һәм хискә тәэсир итәргә, йөрәкне ашкындырып, күңелне кузгатып җибәрергә, кайнарлыгы белән бәгыреңә үтәргә, шатландырырга, я кайгыга салырга — тик битараф кына калдырмаска тиеш. Шигырь укыгач, кеше

йөрәгендә нинди дер яңа, җылы хис калырлык, ул инде элеккечә яши алмаслык булсын.

Мин артыгын өмет итмимме? Ләкин сүз чын шигырьләр турында бара бит...

## Иҗатны автоматлаштыру

Теләсә нинди эшкә, хәтта шигырь язарга да өйрәнеп-күнегеп була. Әмма иҗатны автоматлаштыру сәнгать логикасы, сәнгать законнары белән сыеша алмый. Шуңа күрә дә яшь шагыйрьнең бик үк өлгереп җитмәгән беренче әсәрләре кайчак, һәр ягы килгән «автоматик» шигырьләргә караганда, күңелгә якынрак тоела, укучыга көчлерәк тәэсир ясый.

Шагыйрь хезмәтен формаль логика законнары белән генә үлчәргә ярамый. Сәнгать ул хәтта сүз белән әйтеп булмый торган хисләрне дә белдерә ала.

## Читләр әрнүе

Тәуратның бер урынында: «Күп акыл җыйсаң, күп хәсрәт табарсың, белемен арттырган кеше хәсрәтен дә арттырыр»,— диелә.

Моңа ни дип җавап бирергә? Хәсрәтле акыл томана иминлектән хәерлерәк, ә аңлы кешенең шөбһәсе ваемсызлыктан яхшырак, диптер, күрәсең.

Матур әдәбиятның роле дә шундый ук: чит кешеләр язмышына, аларның кайгысына якынайтып, ул безне кешелеклерәк итә.

## Оригинальлек

Һәркемгә мәгълүм, бары кабатланмас талантка ия шагыйрь генә укучының ныклы игътибарын яулый ала. Ләкин кайберәүләр укучы игътибарын ансат юл белән яуларга тырышалар. Алар бәхәссез хакыйкатьләрне, әзер образларны тискәре ягы белән әйләндереп куялар. Әйтик, ата-ананы хөрмәт итәргә кирәк, дигән һәркемгә билгеле хакыйкать бар. «Оригинальлек»кә омтылучы шагыйрь аны кире ягына әйләндерә: ата-ананы ихтирам итәргә кирәкми, ди. Бөтен кеше аһ итә, нәфрәт белдерә, дөрес түгел, ди. Оригиналь шагыйрьгә шул гына кирәк тә: аны күрсеннәр, аңа игътибар итсеннәр.

## Яхшы булсын, төрле булсын...

Бер үк әсәр берәүләрне тетрәтә, ә икенчеләрне артык дулкынландырмый. Нилектән бу? Хикмәт берәүләрнең югары культуралы, ә икенчеләрнең түбән зәвыклы булуларында гына түгел, әлбәттә. Эш шунда ки, әдәби әсәрдә сурәтләнгән уй-хисләр укучыга күпмедер дәрәҗәдә алдан таныш һәм якын булса гына аны дулкынландыра ала. Нәкъ шуңа күрә шигъри әсәргә бәя биргәндә бер генә төрле фикер — хәтта ул иң таләпчән, иң укымышлы кешенең фикере булса да,— өстенлек итәргә тиеш түгел. Шигърият кебек үк, тәнкыйть фикере дә яхшы гына түгел, төрле дә булсын.

## Уйланырга мәҗбүр итәргә...

Шигъриятнең төп сыйфаты укучының фикер һәм хисләрен бер ноктага тупларга сәләтле булуында.

Шул ук вакытта шигырьдә бармак белән төртеп күрсәтү дә шәп эш түгел. Шигъ-

рият укучы алдына сораулар куя, яңача яшәүең зарурлыгын аңларга булыша. Ә ничек яшәү кадәресен һәр кеше үзе хәл итә.

## Шигърият һәм хәтер

Кайчак кеше хәтере яшел яфраклары корып, ботаклары сынып-коелып беткән агач кәүсәсен хәтерләтә. Хәтер үткән вакыйгаларның коры склетын гына саклап калган, ә исләр һәм төсләр кебек «вак-төяк»ләр инде юкка чыккан була.

Шигърият исә безне беренчел тойгылар сафлыгына алып кайта.

## Йөрәк рәвешендә

Рәссам — буяулар, скульптор — мәрмәр таш, шагыйрь исә гап-гади сүзләр ярдәмендә иҗат итә. Ләкин таш та, буяулар һәм сүзләр дә үзләре генә сәнгать әсәре була алмый.

Сәнгать әсәре художникның җанында туа. Бөтен эш аның рухының һәм җанының нинди — биекме, әллә түбәнме, киңме, әллә тармы, олымы, әллә вакмы булуында. Шигъриятгә форманы мин, барыннан да элек, кеше йөрәге рәвешендә күз алдына китерәм. Шуңа күрә шигърияттә очрый торган кимчелекләрнең иң хәтәре — шагыйрь җанының чикләнгән булуы. Ялтырап торган шома әсәрләр була, ә фикере — әнә очы кадәр генә. Һәм шагыйрь дөньяга энә күзеннән карап бәя бирә. Мондый шигырь кемгә тәэсир итә алсын? Шигъриятнең иң биек максаты — кеше күңеленә тәэсир итү, ахыр килеп, әйләнә-тирәдәге дөньяны үзгәртү.

Сабырлык, тырышлык белән генә сәнгатьтә бар нәрсәгә дә ирешеп булмый. Күп көч куеп та уңышсыз чыккан әсәрләр азмыни?! Ихтимал, чын иҗатның сере сүзләрнең бернинди көчәнүсез, үзләреннән-үзләре тууындадыр. Ләкин моның өчен сүзләр, гәрәбә нурлар кебек тулышып, күңелдә өлгереп җиткән булырга тиеш.

## Классиклар һәм «модный» шагыйрьләр

Авырлыгы граммнар белән үлчәнә торган метеор кайчак Кояштан да зуррак йолдызларны күмеп китә. Әмма метеор бер ялтырап ала да сүнә. Йолдызлар исә, тигез яктылык сирпеп, миллион еллар буена яна.

## Юмартлык

Үткән җәйләрнең берсендә, каты корылык булу сәбәпле, Казан елгасы нык саегып калды. Су киткән җирләрдә шунда ук билчән, алабута, бака яфрагы, үги ана яфрагы һәм ат кузгалагы кебек үләннәр тертеп чыкты. Хәтта әнә шундый, алдан күрергә мөмкин булмаган очрак өчен дә табигать ничаклы орлык запасы саклап торган!

Табигать, әнә шундый сакчыллык һәм хәстәрлек белән бергә, чиктән тыш юмартлык та күрсәтә. Йөз меңнәрчә уылдыкның бик азы гына мәһабәт чөгә балыгына әверелә, диләр. Әмма бу — аклана торган юмартлык. Табигатьтә гасырлар буенча килгән тәртип шундый: тереклек ияләренең иң көчлеләре, кырыс шартларга җайлаша алганнары гына исән кала.

Шигърият тә юмарт булырга, сайлау мөмкинлеге калдырырга тиеш. Бирәү дә гениаль әсәрләр генә яза алмый. Сайлау эшен иң башта шагыйрь үзе эшли, аңардан соң редакторлар, тәнкыйтьчеләр, укучылар сайлый. Ниһаять, төп хөкемдар — вакыт эшкә керешә. Матбугат битләрендә дөнья күргән әсәрләрнең бик азы гына киләчәк буыннарга барып җитәргә мөмкин.

## Сүз җитмәгәндә...

Сүз — әдипнең төп коралы. Ләкин сүзләрнең дә төрлесе була. Кипкән иреннәргә тамган яңгыр тамчысы кебек шифалы һәм кадерле сүзләр бар. Һәм, архив киштәләренә кунган тузан кебек, коры, файдасыз сүзләр бар.

Төрле-төрле төс бизәкләрдән, аваз һәм хуш ислардән торган реаль дөнья теләсә нинди тасвирлардан чагыштыргысыз баерак. Күп художниклар, хәтта бөек исем алганнары да, җир йөзендәге төсләрнең бетмәс-төкәнмәс төрлелеге алдында үзләренең көчсез булуларын аңлаганнар, реаль дөньядагы мөнәсәбәтләрнең чиксезлеге белән телнең чикләнгән мөмкинлекләре арасындагы конфликтны тоеп газап чиккәннәр. Бу каршылык күптәннән килә һәм, күрәсең, һәр вакыт булачак.

Әмма илһам килгән мизгелләрдә ул каршылык чишелә. Сәнгать — гаять күп белем, тәҗрибә һәм осталык сорый торган авыр хезмәт ул. Илһам уты кабынган минутларда художник берничә төгәл сүз белән тормышның бөтен панорамасын тергезеп күз алдына бастыра, дөньяны иңләрлек кодрәткә ия сурәт-буяулар таба. Фикерен әйтерлек сүз таба алмаган икән, димәк, шагыйрьгә «илаһи көч тә, илһам да» килмәгән диген сүз.



## Шигърият вазифасы

Шагыйрьләр һәм художниклар икмәк тә үстерми, корыч та коймый, йортлар да салмыйлар. Нигә кирәк соң алар?..

Ә, алайса, каеннар шаулавы, яшел болынны тутырып үскән чәчәкләр, роза, лалә гөлләре нигә кирәк? Коры рационалист күзлегеннән караганда, хәтта алма бакчалары да кирәксез нәрсә булып күренүе бар. Казармаларны гына калдырып, зиннәтле сарайларны да җимереп ташларга мөмкин...

Ләкин андый дөнья күңел өшеткеч котсыз булыр иде, җир йөзендә торасы килмәс иде...

## Ак кәрләләр

Ак кәрләләр дип йөртелгән йолдызлар бар, алар зур түгел, әмма бик яктылар. Ул йолдызларның җисемнәре шул кадәр тыгыз ки, бер кубик сантиметры, галимнәр әйтүенчә, дистәләрчә тонна авырлыгында.

Чын шигырьләр дә әлеге йолдызлар шикелле. Фикер һәм хисләр тыгызлыгы, мәгънәви эчтәлекләре ягыннан алар кайбер калын повесть яки романнарга тиңләшә алалар.

## Чехов киңәше

Антон Павлович Чехов, хикәяне язып бетергәч, аның башын һәм ахырын сызып ташларга киңәш иткән.

Максат — озынга сузылган һәм укучыны ялыктыра торган урыннардан, геройларның биографияләрен сөйләүдән котылу. Укучының хыял куәтенә ышанырга, аның зирәклегенә таяна белергә кирәк. Әгәр дә геройлар тулы канлы, тормышчан булып тусалар, алар алдагы тормышларын укучы күңелендә дәвам итәчәкләр. Кыскасы, А. П. Чеховның киңәше шуңа кайтып кала: сюжет-фабуладан, вакыйга сюжетыннан фикер сюжетына борылыш ясарга вакыт.

## Күңел бизү

Һәр эшнең эчке бер рәхәтлек белән җиңел эшләнгән чаклары һәм күңел биздергән чаклары була.

Кайчак баштан ук эшкә күңел ятмый. Һәм син суза башлыйсың. Аны «соңыннан»га калдырып, игътибарыңны башка нәрсәләргә юнәлтәсең.

Әмма күңел бизү дигән нәрсә, күбесенчә, эш башлап бер-ике сәгать узгач килә. Чөнки беренче дәрт инде сүрелгән, ә үзең чынлап торып мәсьәләгә әле кереп китә алмаган буласың. Һәм бу эшне калдырып тору, ял итәсе килү, һич югында, шөгыльне үзгәртү теләге туа. Ләкин үзеңне-үзең кулга алып, шушы минутларны үткәреп җибәрә алсаң, сиңа яңа көч, икенче сулыш килә. Нәкъ менә шул чакта чын эш эшләнә дә.

## Метафора хакында

Метафора — поэтик сөйләмне матурлау өчен кулланыла торган бизәк кенә түгел ул. Метафора үзе белән хис һәм фикер алып килә. Г. Тукайның мәгълүм юлларын хәтергә төшерик:

**Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,**
**Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы.**

Никадәр тирән фикер әйтелгән бу юлларда! Рәхимсез чынбарлыкка нәфрәт тә, тормышның мәгънәсезлеген күреп, җан әрнү дә, таянычы, яклаучысы булмаган шагыйрь йөрәгенең атылган коштай бәргәләнүе — барысы да бар. Һәм очсыз-кырыйсыз моң... Боларның берсе дә туп-туры әйтелмәгән бит һәм без бу хакта уйламыйбыз да. Тукай метафорасы чәчкән орлыклар күңелдә сиздермичә генә шытым бирә...

Күренешнең асылын чагылдыра алган образ гына яхшы була. Асылташ — табигый хәлендә, бернинди бизәксез-нисез дә гүзәл. Әгәр башына иске эшләпә кигертеп куйсаң, иң гүзәл таш сын да сәер һәм мәзәк булып калачак, бакча карачкысын кәтерләтәчәк.

# СҮЗ ТӘРТИБЕНЕҢ СЕРЛӘРЕ

Күренекле сүз остасы А. П. Чехов үзенең бер хатында язучы осталыгының сере — синтаксиста, хосусан, җөмләдәге сүз тәртибендә дигән фикер әйтә. Чыннан да, җөмләдә сүзләрнең урнашу тәртибе сөйләмгә матурлык, фикергә төзеклек бирә. Зур әдипләрнең, әсәр өстендә эшләгәндә, сүз тәртибенә аеруча нык игътибар итүләре, стилистик алым буларак, аның мөмкинлекләреннән киң файдаланулары очраклы хәл түгел.

Кызганычка каршы, татар телендә сүз тәртибе, күп галимнәрнең кызыксыну объекты булып килүенә карамастан, тирәнтен һәм һәрьяклап тикшерелгән дип әйтеп булмый. Дөрес, соңгы елларда язучылар теле, әдәби тел мәсьәләләре, халык авыз иҗатында һәм әдәбиятта гасырлар буенча тупланып, чарланып килгән тел-стиль чаралары, телнең эчке хасиятләре ныграк тикшерелә башлады. Әмма сүз тәртибен билгели торган факторлар, аның стилистик мөмкинлекләре бөтенләй диярлек өйрәнелми, теге яки бу сүз тәртибенә нигезләнгән стилистик чаралар барланмый килде. Казан дәүләт университеты доценты Флера Сафиуллинаның Татарстан китап нәшриятында чыккан «Татар телендә сүз тәртибе» исемле китабы — шул кирәкле һәм күптән көтелгән эшнең уңышлы башлангычы.

Флера Сафиуллина фәндә яңа кеше түгел. Аның татар синтаксисының актуаль мәсьәләләре турындагы фәнни мәкаләләре, әдәби телнең үсеш мәсьәләләренә багышланган докладлары галимнәр арасында да, әдәби җәмәгатьчелек арасында да зур яңгыраш тапты.

Яңа хезмәтендә автор татар телендә сүз тәртибе закончалыкларын ачуны максат итеп куя. Ул, төрки, угро-фин, рус, герман һәм гомум тел белемендә бу темага мөнәсәбәтле махсус әдәбиятны (библиографиядә генә дә өч йөзгә якын хезмәт китерелә!) җентекле өйрәнеп, төрле фикерләрне анализлый, гомумиләштерә, аерым галимнәрнең фикерләрендә очраган каршылыклы якларны тотып алып, бу каршылыкларның сәбәпләрен ачыкларга тырыша. Бай фәнни мирасны шул рәвешчә өйрәнү аңарга бердәнбер дөрес юлны сайлап алырга һәм алдында торган бурычларны, әле хәл ителмәгән яки тирәнтен яктыртылмаган мәсьәләләрне ачыкларга мөмкинлек биргән.

Һәр телнең үзенә генә хас, аны башка телләрдән аера торган үзенчәлекле сыйфатлары (авазлар системасы, сүзлек хәзинәсе, морфологик төзелеше һ. б.) була. Җөмләдә сүз тәртибе — шундый үзенчәлекле сыйфатларның берсе һәм, безгә калса, иң үзенчәлеклесе. Әйтик, бериш саф татар сүзләре урынына алынмалар кулланырга яки аерым грамматик формаларны синонимдашлары белән алыштырырга мөмкин. Әмма билгеле бер грамматик кушымчалар алган саф татар сүзләрен теләсә нинди тәртиптә төзү фикер буталчыклыгына һәм гасырлар буена канунлашкан сүз тәртибенең бозылуына, ахыр чиктә, телнең үзенчәлеге югалуга китерер иде.

Кагыйдә буларак, сүз тәртибе закончалыклары язма тел материалында, гадәти тыныч сөйләмне чагылдырган җөмләләрдә тикшерелә килгән. Бу традицияне дәвам итеп, Ф. Сафиуллина да икенче бүлекне гадәти тыныч сөйләмдә сүз тәртибен анализлауга багышлый.

Җөмләгә яңа сүзләр өстәмичә, бер үк сүзләр белән төрле фикер белдерергә мөмкинме? Әйе, мөмкин. Моның өчен җөмләдә-

ге сүз тәртибен үзгәртү дә җитә. Әйтик, Н. Фәттах үзенең «Бала күңеле далада» романында: «Беренче булып тракторын Һарун кабызды» дигән икән, ул, әлбәттә, бригададагы тракторчылар арасында беренче булып Ислам да, Мансур да түгел, ә Һарун кабызуын белдерергә теләгән. Инде шул җөмләне «Һарун беренче булып тракторын кабызды» дисәк, Һарун башка эшләр арасыннан иң беренче булып трактор кабызган икән, дигән фикерне аңлыйбыз. Күрәсез, тел никадәр сыгылмалы! Сүзләрнең урынын үзгәртеп кенә дә төрле фикер әйтеп була икән. Эш нидә соң? Хезмәттән күренгәнчә, һәр җөмлә мәгънәсе ягыннан гадәттә ике кисәккә бүленә. Аның беренче өлешендә тыңлаучы яки укучыга электән мәгълүм нәрсәләр турында сүз бара һәм җөмләнең мондый кисәге сөйләм предметы дип йөртелә. Җөмләнең икенче өлешендә исә тыңлаучы өчен билгеле булмаган яңа мәгълүматлар хәбәр ителә. Без әле генә тикшергән беренче җөмләдә ул «Һарун», ә икенче җөмләдә «тракторын» сүзе. Бу кисәк (сөйләм яңалыгы) гадәттә хәбәр алдыннан урнаша, яисә хәбәр үзе яңалык алып килә. Яңалык сөйләмдә әйтелеше белән дә аерылып тора, ягъни логик басым кабул итә. Персонаж репликаларында логик басымны кая куярга белмичә тилмергән артистлар, һәвәскәрләр һәм, гомумән, сәхнә сөйләмен җентекләп өйрәнергә теләүчеләр өчен бу гаять гыйбрәтле күзәтү дияргә кирәк.

Гадәти тыныч сөйләмдә беренче җөмләдәге сөйләм яңалыгы икенче җөмләдә, үзенең яңалык булуын югалтып, сөйләм предметына әверелә, нәтиҗәдә хәбәр алдындагы урыныннан җөмләнең башына күчә. «Авыл читендәге калкулыктан алдагы 31 нче разъезд күренә. Разъездда акларның поезды бар. Аның тирәсендә халык җыелган. Алар, сафларга тезелеп, юлдан читкә китәләр» (Ш. Усманов. «Легион юлы»). Күргәнебезчә, хәбәр алдындагы сүз алдагы җөмлә өчен үзенчәлекле трамплин хезмәтен үти: сөйләүче, шул сүзләрне эләктереп алып, яңа фикер әйтә. Моны оныту хикәядә логик эзлеклелек югалуга китерер иде.

Авторның тикшеренүләренә караганда, тыныч сөйләмдәге мондый сүз тәртибе башка телләргә дә хас. Аерма кайсы сүзнең җөмлә башына куелуында гына. Әгәр рус телендә һәр яңа җөмлә үзеннән алдагы җөмләнең ахырында килгән сүздән башланса, татар телендә ул алдагы җөмләнең хәбәре алдында торган сүздән башлана. Әлбәттә, бу бердәнбер һәм катгый закон түгел, әмма ике тел арасындагы принципиаль аерманы билгеләгәндә һәм татар теленең үзенчәлеген күрсәткәндә әлеге күренеш белән санашмый мөмкин түгел. Рус һәм татар телләрен үзара чагыштырып өйрәнгәндә, ике телнең чагыштырма грамматикасын язганда гына түгел, тәрҗемә практикасында да моның теоретик һәм практик әһәмияте бар.

Хәбәр алды позициясенең бу әһәмиятле роленә күп кенә галимнәр, шул исәптән татар телчеләре дә, игътибар иткән. Әмма татар синтаксисында җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше, сөйләм предметы һәм бигрәк тә сөйләм яңалыгының нинди грамматик чаралар (мәсәлән, гына, ук, дә, хәтта кисәкчәләре, нинидер, кайбер алмашлыклары, юклык күрсәткечле фигыльләр, каршы куелган соңгы кисәк һ. б.) белән белдерелүе, бары сөйләм яңалыгын гына белдерә торган җөмләләр (әйтик, хикәяне башлап җибәргән яки табигать күренешләрен сурәтләгән бер составлы җөмләләр, сорауларга җавап булып килгән ким җөмләләр, әкият, сөйләк, хикәяләрнең башлангыч җөмләләре, менә сүзе белән башланган бер составлы исем җөмләләр), җөмләдә сүз тәртибен билгели торган грамматик факторлар (рифма, интонация, традиция һ. б.) бөтен тирәнлеге белән беренче тапкыр Ф. Сафиуллина хезмәтендә яктыртыла.

Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше турындагы фән татар тел белемендә әле үзенең беренче адымнарын гына ясый. М. Зәкиевнең татар синтаксисын өйрәнүгә багышланган хезмәтләрендә беренче тапкыр көн тәртибенә куелган бу проблема Ф. Сафиуллина китабында гаять бай фактик материал нигезендә төрле яклап махсус тикшерелә. Моңарчы язылган хезмәтләрдә җөмлә кисәкләренең гадәти урыннары гына күрсәтелеп, теге яки бу тәртипнең сәбәпләре ачыкланмыйча кала иде. Ф. Сафиуллина китабында актуаль кисәкләргә бүленеш һәм җөмлә кисәгенең коммуникатив йөкләнеше һәр җөмлә кисәгенең урынын билгеләүдә төп рольне үтәве ачык күрсәтелә. Моны хәтта тиңдәш булмаган аергычларның урнашу тәртибендә дә күрергә мөмкин. Мәсәлән, коңгырт зур күзме, әллә зур коңгырт күзме? Ефәк ак шәлме, әллә ак ефәк шәлме? Тел практикасында очрый торган күп төрле мондый сорауларга бу китапта тулы җавап табарга мөмкин.

Фәндә аерым телләрне сүз тәртибе тотрыклы яки, киресенчә, ирекле булган телләргә бүлеп йөртәләр. Рус теле, мәсәлән, сүз тәртибе грамматик яктан ирекле булган телләргә кертелә. Ә татар теле бу ике төркемнең кайсына карый? Татарча сөйләгәндә яки язганда теләсә кайсы сүзне теләсә кайсы урынга куярга ярыймы, әллә һәр җөмлә кисәгенең гасырлар буена канунлашкан үз урыны бармы? Татар тел белемендә бу мәсьәләгә капма-каршы ике караш яши. Бер төркем галимнәр (Г. Алпаров, Х. Вәли) татар телендә сүз тәртибе тотрыклы, ә икенче берләре (мәсәлән, Ф. Хәмидуллин) ирекле дип саный. Бу фикер каршылыгы нидән килеп чыккан һәм аларның кайсы хаклы?

Ф. Сафиуллина фикеренчә, мондый каршылык телдә төрле стильләр булуын онытудан, тыныч сөйләм белән эмоциональ сөйләм, әдәби һәм җанлы сөйләм стильләрен истә тотмаудан килеп чыккан. Авторның күзәтүләренә караганда, гади тыныч сөйләмдә (фәнни, рәсми, тыныч хикәяләү стильләрендә) сүз тәртибе тотрыклы, ягъни хәбәр иялән соң килә һәм башка кисәкләр дә шуларга мөнәсәбәтле рәвештә урын алалар. Эмоциональ сөйләмдә, бигрәк тә шигъри әсәрләрдә, нәсерләрдә кире тәртиптә дә килергә мөмкин. Ягъни беренче урында сөйләм яңалыгы (хәбәр), икенче урында сөйләм предметы (ия) килә. Әйтик, «Автобуска бик матур бер кыз килеп керде. Бар бит дөньяда чибәр кешеләр!» (И. Гази) дигән җөмләдә бар бит хәбәре артка, үзенең гадәти урынына күчерелсә, ул көчле логик басым ала алмас иде. Хәбәрне җөмлә башына чыгару аны көчлерәк басым белән әйтергә мәҗбүр итә.

Шигъри сөйләмдә сүз тәртибе, ритмга, рифмага карап, һәрвакыт кире (инверсияле) булырга тиеш дигән фикер хөкем сөрә. Ф. Сафиуллинаның күзәтүләренә караганда, шигъри әсәрләрдә инверсия без уйлаганга караганда күп аз, иң күренекле шагыйрьләрнең әсәрләрендә дә әдәби телнең төп синтаксик нормаларыннан читкә чыкмый икән. Авторның бу күзәтүе моңарчы ятып килгән, аксиома итеп кабул ителгән фикерләргә тәнкыйть күзе белән карарга мәҗбүр итә. Чыннан да, шигъри һәм эмоциональ сөйләмнәрдә сүз тәртибе чагыштырмача ирекле, әмма һәр очракта ул аңлы рәвештә, билгеле бер максатлардан чыгып кына эшләнә.

Дөресен әйткәндә, халыкның гадәти җанлы сөйләм теле моңарчы галимнәрнең игътибарыннан читтә кала килде. Ул гына да түгел, галимнәрнең әлеге сөйләмнең бик ачык чагылышы булган драматургия телен өйрәнүне дә башлап җибәргәннәре юк. Ф. Сафиуллина үзенең хезмәтендә, татар тел белемендә беренче булып, халыкның җанлы сөйләм теле синтаксисын тикшерә башлый, җанлы сөйләмнең фәндә моңарчы теркәлмәгән күп кенә үзенчәлекләрен ача. Авторның киләчәк эше дә шушы юнәлештә барса, без аның драматургия синтаксисына да игътибар юнәлтүен теләр идек.

Җанлы сөйләмгә хас үзенчәлекләр, әдәби телнең үсеш тенденцияләре турында сүз йөрткәндә, безнең фикеребезчә, сөйләм культурасын бер генә минутка да истән чыгарырга ярамый. Моның күңелсез мисалларын кайбер эш кәгазьләрендә, вакытлы матбугатта еш очратырга мөмкин. Русча оригиналдагы сүз тәртибен механик рәвештә кабатлап, «Бирелә бу справка шул хакта»... дип башланган канцелярия стиле әдәби телнең үсеш тенденцияләренә туры киләме соң? Автор мондый тел бозу үрнәкләренең әдәби телнең үсеш тенденцияләре белән бернинди уртаклыгы булмавын күрсәтә. Әмма тел бозуның башка очракларына карата аның позициясе бик үк ачык түгел. Хәлбуки, тел шапшаклыгы, телдәге имла, сүз, мәгънә, грамматика хаталары гомер-гомергә тәнкыйтьләнеп киленде. 1911 елда ук халык шагыйре Г. Тукай үзенең «Русчадан дөрес тәрҗемәләр» памфлетында матбугатта еш очрый торган «Мин чыктым аркылы күпер», «Булды миңа яшьләр сигез» кебек механик, сүзгә-сүз тәрҗемә үрнәкләреннән ачы көлеп, аларның татар теле рухына никадәр чит булуын ачык ышандырырлык итеп күрсәткән иде. Бу мәсьәлә үзенең актуальлеген әле хәзер дә югалтмаган. Әмма шуны да истә тотарга кирәк: татар телендә сүз тәртибенең һаман да сыгылмалырак була баруы, кайбер галимнәр уйлаганча, бары рус теленең тәэсиренә генә бәйләнмәгән. Телнең синтаксик төзелешендәге үзгәрешләр, камилләшү, яңа күренешләрнең барлыкка килүе җанлы сөйләм теленең тәэсире белән аңлатыла һәм бу фикер төрле жанрларда һәм төрле гасырларда язылган әдәби истәлекләрдән китерелгән мисаллар белән ышандырырлык итеп расланa.

Хезмәтнең зур өлеше сүз тәртибенең стилистик мөмкинлекләрен ачыклауга багышланган. Төрки телләрнең агглютинатив (ялганмалы) табигате һәм сүз тәртибендәге

кайбер катгыйлык аның стилистик функциясен бераз чикли, әлбәттә. Ф. Сафиуллина беренче булып сүз тәртибенә нигезләнгән дистәләрчә синтаксик сурәтләү чараларын барлый, тәртипкә сала, тасвирлый. Мисалларга килик. Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясе болай башлана: «Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә алар». Күрәсез, үзенчәлекле настроение һәм интонацияне тудыру өчен, язучы янәшә килгән ике җөмләдә ияхәбәрнең урынын инверсияләп, ягъни хиазма кулланып эш итә.

Китапта татар халык иҗаты әсәрләренең аерылгысыз үзенчәлеге булган синтаксик параллелизмның да сүз тәртибенә нигезләнгән булуы ачык күрсәтелә. Моннан кала композицион ялгау, анафора, эпифора, хәбәрнең постпозициясе, хәбәрләрнең рифмалашуы, бәҗралы кабатлаулар һ. б. да бик кызыклы һәм уңышлы мисаллар җирлегендә карала. Автор татар әдәбиятында һәр алымның кулланылыш тарихын классик әдәбияттан башлап хәзерге көнгә кадәр күзәткән һәм үсеш тенденциясен билгеләгән. Хезмәттә куелган тезисларның дөреслеге һәм ышанычлы булуы шуның белән дә аңлатыла.

Бу күзәтүләр һәр язучының, шагыйрьнең үзенчәлекле стилен билгеләүдә зур роль уйнавын ачыкларга мөмкинлек бирәләр. Автор шул үзенчәлекләрне бик оста тотып алган һәм язучыларның язу манерасын, иҗат лабораториясен ачу өчен әдәбият белгечләрен дә кызыксындырырлык фикерләр әйткән. Шуның белән бергә, һәр вакыт бер үк төрле сурәтләү яки грамматик чаралар (өстәмәләр, чамасыз инверсияләр, һәр вакыт җөмләне «иде» белән тәмамлап кую һ. б.) белән мавыгуга карата авторның мөнәсәбәтен тагын да ачыграк күрсәсе килгән иде. Ә. Еники, Г. Бәширов, Ф. Хөсни һәм башка сүз осталарының тел өстендә эшләүләрен ачыклау, аларның иҗат лабораторияләренә күз салу да яшь язучылар, журналистлар өчен кыйммәтле материал бирер иде.

Авторның зур табышы булып саналырлык тагын берничә мәсьәләгә тукталмый мөмкин түгел. Ф. Сафиуллина татар һәм төрки тел белемендә беренче булып җанлы сөйләмнең иң характерлы үзенчәлеге дип саналган өстәлмәләрне тикшерә. Мәсәлән: «Шигырьдән түгел, поэмалардан башлап китте Әхсән Баян. Уи ел элек, 1959—60 елларда. Ике буын уртасында. Шәүкәт Галиевләр белән Равил Фәйзуллиннар буыны арасында». (С. Хәким); «Әнә сез туп-туры теге шомырт куаклары янына барыгыз. Колонка күрерсез. Эчә торганны». (Г. Мөхәммәтшин.) Хезмәттә өстәлмәләрнең грамматик-структур типлары тикшерелә, аларның күп санлы стилистик функцияләре ачыклана.

Төп җөмләгә өстәмә хәбәр, мәгълумат алып керә, авторның мөнәсәбәтен чагылдыра, төрле хисләр белдерә торган керешмә конструкцияләрне тикшерү дә укучының игътибарын һичшиксез җәлеп итәчәк. Тойгыны белдерүдә искиткеч тәэсирле булган күзаллауы ясә ялгыз баш килеш тезелмәсе дә («Агыйдел рапсодиясе. Беркем, беркайчан ишетмәячәк аны». Ә. Баянов; «Диңгез, диңгез, диңгез! Ул гүя бөтен табигать өстеннән хакимлек итә». Ә. Еники) татар тел белемендә беренче тапкыр күтәрелә һәм аның структур-грамматик типлары шактый тулы тикшерелә.

Шунысы кызык, бу төзелмәләр, нигездә, татар әдәбиятында XX йөз башында гына күренә башлый һәм соңгы елларда безнең әдәбиятның иң характерлы синтаксик үзенчәлекләренә әйләнә. Персонаж сөйләмен табигый итеп сурәтләүдә, мәсәлән, өстәлмәләргә тиң синтаксик чара юктыр да. Бу чаралар сөйләмнең иркен агышын барлыкка китереп, хикәяләүгә яңа төсмер өстиләр, аны интонацион яктан баеталар, экспрессиясен арттыралар. Бу төзелмәләрне тарихи планда карау, әдәби тел һәм җанлы сөйләм теле арасындагы мөнәсәбәтләрне, үзара йогынтыны ачыкларга омтылу әдәби телнең үсеш тенденцияләрен билгеләргә ярдәм итә. Бу — хезмәтнең тагын бер уңышлы ягы.

Хезмәтнең янә бер үзенчәлекле сыйфатын күрсәтеп китү кирәк. Лингвистик хезмәтләр, кагыйдә буларак, саф грамматик планда языла. Әмма бу китапта куелган проблемалар гомуми филологик характерда хәл ителә һәм тел-сурәтләү чараларының әдәби әсәрдәге функцияләре язучыларның иҗат осталыгына бәйләп бирелә. Хезмәттә грамматика өчен генә түгел, әдәбият тарихы өчен дә кызыклы һәм нечкә күзәтүләр бар. Мәсәлән, синтаксик параллелизмга мисал итеп, автор М. Җәлилнең «Тозлы балык» дигән 8 юллык шигырен китерә. Шул ук шигырьнең карачай халык җыры дип саналуын ачу (кара: «Къарачай халкъ джырлаа», М., 1969.) әдәбиятчылар өчен дә яңалык булыр дип уйлыйбыз. Бу факт, беренчедән, синтаксик параллелизмга нигезләнгән ши-

гырьнең җырга әйләнеп китүе турында сөйләргә мөмкинлек бирсә, икенчедән, М. Җәлилнең иҗатын һәм тормышын өйрәнүчеләр өчен дә кечкенә генә бер җеп булмасмы икән дигән ышаныч уята.

Хезмәт күп кенә яңа проблемалар күтәргәнгә, анда яңа атамалар да еш очрый. Кайберләрен автор үзе ясаган. Шактый уңышлылары белән беррәттән (өстәлмә, актуаль кисәкләргә бүленеш, сәхнә сөйләме, керешмәләр һ. б.), колакка ятышсызлары да бар (мәсәлән, өйрәтмә, бәйле текст һ. б.) Сөйләм теле һәм сөйләмә тел кебек кайбер терминнарның да эчтәлеген ачыклау турында уйлану кирәк иде.

Китапта җыелган һәм анализланган тел материалы искиткеч бай, күп төрле һәм уңышлы. Шуның белән бергә, телнең сафлыгын, төзеклеген, яңгырашын боза торган синтаксик төзелмәләрне тикшерү һәм бәя бирү дә хезмәтнең кыйммәтен күтәргән булыр иде.

Күренекле сүз остасы Ф. Хөсни әйткәнчә, сүзләрнең «нәкъ үз урыннарында булуларына, нәкъ үз нурларын сибеп, шул күелган урынны һәм язучының әсәрдә куйган максатын яктыртып торуларына тиешенчә игътибар итәргә» кирәк. Бу юлда Флера Сафиуллина китабы өлкән һәм яшь язучыга, тәҗрибәле һәм матбугатка әле аяк баскан журналистка һәм, гомумән, үзенең сөйләм культурасы турында уйланучы-кайгыртучы һәркемгә файдалы кулланма булып хезмәт итә. Әлбәттә, анда яшь язучылар өчен әсәрләрне ничек язу рецептлары юк (ул чор үтте инде). Әмма үз ана теле, аның нечкә хасиятләре белән кызыксынучылар өчен шактый гыйбрәтле фикерләр, нечкә күзәтүләр һичшиксез табылыр.

Гомум тел белеме югарылыгында һәм бай фактик материал нигезендә язылып, татар һәм төрки тел белемендә күп кенә кызыклы һәм яңа мәсьәләләр күтәргән бу хезмәт төрки телләрнең синтаксик төзелешен өйрәнүдә дә зур әһәмияткә ия булыр дип ышанабыз.

**А. ИСКӘНДӘР.**

# ХИКӘЯЛӘР БАКЧАСЫНДА

**«Казан утлары» журналында басылган хикәяләргә күзәтү**

Көзен алма бакчасына кергәнегез бармы? Булса, кызарып пешкән матур алмаларга карап, сокланмый калмагансыздыр. Һәм, әлбәттә, бакчаның хуҗасын мактагансыздыр. Алмагач чәчәкләрен салкын кыраулардан саклый белгән, вакытында суын сипкән, туфрагын йомшарткан өчен.

«Казан утлары» журналының 1974 елгы саннарында басылган хикәяләр белән танышканда да мин үземне бакчада — хикәяләр бакчасында йөргәндәй хис иттем.

Инде бу бакчаның да көзе җиткән. Җимешләре нинди аның? Журналда басылган хикәяләр әдәбиятыбызга нинди яңалык алып килә, аларның күтәргән проблемалары ни дәрәҗәдә актуаль, әдәби эшләнешләре ничегрәк — кыскача гына булса да шул сорауларны ачыклап үтәсе килә.

Журналның беренче саны Нур Хәмидинең «Фәүзия кияүгә чыга» дигән хикәясе белән ачыла. Исеменнән үк күренгәнчә, хикәя мәхәббәт, гаилә кору кебек мәсьәләләргә багышланган.

Әсәрнең төп герое—балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүче Фәүзия исемле хатын. Берничә ел элек ул Гамил исемле офицер егеткә кияүгә чыккан булган. Кияүгә аны бирәү дә көчләп, димләп бирмәгән. Үзе теләп, ярагып чыккан. Ләкин яре белән тату гына яшәп китә алмаганнар. Гамил хатыны белән, аның теләкомтылышлары белән санашмаган. Фәүзия исә принципиаль була белмәгән, йомшаклык күрсәткән.

Ярар, буласы эш булган. Фәүзиябез, кыр казы сыман, ялгызы калган. Менә шул хатын хәзер икенче бер кешегә кияүгә чыгарга җыена. Элекке күршеләре Гөлҗамал апа аны үзенең кияве Салихка димли. Хикмәт шунда, моннан ике ел элек Гөлҗамал апаның кызы, Салихның беренче хатыны Сөмбелә йөрәк авыруыннан кинәт үлеп киткән. Карчыкны яраткан киявенең ялгыз яшәве һәм аннан да бигрәк бердәнбер оныгының ятим булып үсүе борчый икән...

Хикәя белән танышып чыккач, күңелдә төрле сораулар туа. Тормышта, матур гына гаилә корып та, мәхәббәтләрен саклый белмәү аркасында күңелсезлеккә юлыккан кешеләр аз түгел, әлбәттә. Автор, укучыны кисәтеп, гаилә кору мәсьәләсенә җитди карарга өйрәтеп, дөрес эшли. Тик шунысы бар, Фәүзияне җиңел генә икенче берәүгә «кияүгә биреп», ул үзе үк мәсьәләне шактый ансат хәл итә шикелле. Салих дөнья бәясе кеше, ди автор. Шулай да аның гаилә кору кебек эшне Гөлҗамал апа аркылы йөртүе бераз сәер тоела. Гомумән, хикәядә Салих образы кирәкле дәрәҗәдә тулы ачылмаган.

Миңа әсәрнең исеме дә ошап җитмәде. Җеп очын яшерәсе урында, автор безгә алдан ук Фәүзиянең кияүгә чыгасын, башкача әйткәндә, хикәянең ничек тәмамланасын сиздереп куя.

Хикәя башында Фәүзиянең тәрбияче булып эшләвен хәбәр итүгә ярты биттән артык урын бирелә. Аны төшереп калдырганда да әсәргә әллә ни зыян килмәс иде кебек. Гөлҗамал апаның Кавказ табигате белән хозурланулары да әсәрнең идеясен ачуда артык зур роль уйнамый. Болар барысы да әдәби осталык җитеп бетмәүдән килеп чыккан нәрсәләр.

Ә менә башкорт язучысы Кирәй Мәр-

гәннең «Солдат хаты» (3 сан) исемле хикәясе бу яктан һич кенә дә тел-теш тидерерлек түгел. Җиңел, йөгерек тел белән язылган, җылы юмор белән сугарылган бу әсәрне мавыгып һәм яратып, кызыксынып укыйсың.

Улы солдат хезмәтенә киткәч, Мөнирә җиңгигә Фәнүзә исемле бер кызны фатирга кертәләр. Озынрак телле хуҗабикә белән юаш табигатьле яшь кыз баштан ук бер-берсен өнәп бетермиләр. Әлеге дошманлык, ярашмау торган саен көчәя генә бара. «Ходаем, киленең шундый була күрмәсен», — дип уйлый хуҗабикә. «Кайнанаң шундый була күрмәсен», — ди Фәнүзә дә эченнән генә.

Инде улының шушы «өтек» кыз белән хат алышуын да сизгәч, Мөнирә җиңги бөтенләй аптырап кала. Һәм ул исәнимин чакта Фәнүзәдән котылырга кирәк дигән карарга килә. Улы Зөфәр кайтыр вакыт җиткәч: «Егетле өйдә кыз баланың булуы килешмәс», дигән сылтау белән аны бөтенләй фатирдан чыгарып җибәрә.

Хезмәт срогын тутырып, зураеп һәм матурланып, авылга Зөфәр кайтып төшә. Берничә көн кунак булута, идарәгә барып эш турында сөйләшә һәм өйгә килен алып кайта. «Мөнирә җиңги егылып китә язды: аның алдында Фәнүзә басып тора иде.

— Әнкәй! — диде Фәнүзә аңа таплнып.

— Килен! — диде Мөнирә җиңги, аны кочаклап».

Хикәя әнә шулай һич көтелмәгәнчә тәмамлана. Билгеле, тормышта мондый хәлләр сирәк буладыр. Ләкин әсәр ышандыра. Бригадир белән хуҗабикәнең сөйләшүе дисеңме, Фәнүзә белән Мөнирә җиңги арасындагы мөнәсәбәтләр дисеңме — барысы да тормышчан, барысы да табигый. Автор детальләр белән оста эш итә белә, кеше характерларын ачканда алардан бик тулы файдалана. Иң отышлысы шул, язучы хикәянең «ачкыч»ын дөрес тапкан. Мондый материалны бары юмор планында гына хәл итәргә мөмкин.

Хикәядә үзенчәлекле характерлар бар. Мөнирә җиңгине алыйк. Барлык аналар шикелле, ул бөтен яктан килгән, тәртипле, кешелекле һәм уңган килен турында хыяллана. Инде үзе «өнәп» бетермәгән Фәнүзә килен булып төшкәч, ул аны да ачык чырай белән каршы ала, кеше алдында сер бирми. Кыскасы, Мөнирә җиңги коеп куйган фәрештә дә, эштән чыккан кайнана да түгел. Һәм, ни генә булмасын, аның бердәнбер килене белән гөрләтеп яшәренә чын күңелдән ышанып каласың. Хикәянең ахыры шул фикерне раслау белән тәмамлана.

Безнең әдәбиятта хикәянең озыны да, кыскасы да очрый. Билгеле, аларның икесе дә яшәргә хаклы. Әмма мин үзем кыска хикәяне күбрәк ярата төшәм. Кыскалыкта осталык, ди бит халык. Кирәй Мәргәннең «Солдат хаты» һәм Үзбәк Саттаровның «Айлы төндә» (6 сан) дигән хикәяләре кыска, җыйнак булулары белән мактауга лаек.

Үзбәк Саттаров хикәясендә дә сүз яшьлек хисләре, мәхәббәт турында бара. Ләкин автор мәсьәләне башкарак планда хәл итә. Әсәр шактый моңсу, укучының күңелен нечкәртерлек юллар белән башлана. Олы яшьтәге Галимә апаның борчулы уйлары табигать күренешләре һәм гаять тормышчан детальләр белән үрелеп бирелә. Менә ул «ни эшләгәнен дә белмичә, бармак очлары белән кулына беренче очраган үлән яфракларын әләкләрдә... Аның авызына бармакларыннан әрем ачысы тулды.

— Күңелемдәге ачы җитмәгән, авызыма да ачы тулды тагын, — дип зарланып алды Галимә апа, апыга-апыга юынгыч янына килешли».

Аның күңелен, әрем ачысыдай, нәрсә борчый, дисәрсез. Галимә апаның көн дә вакытында кайтып йокларга ята торган бердәнбер кызы бүген өенә кайтмаган. Ана кеше түзми. Сәйдәсен эзләп урамга чыга, тапмый кире керә. Кайларда гына йөри икән бу кыз?..

Ниһаять, таң алдыннан гына Сәйдә кайтып керә. Аның кызы Рәшит исемле матур да, батыр да егет белән урманга барган, алар Галимә апа өчен дә кадерле булган истәлекле урыннарда йөргәннәр. Кызы Сәйдә йөрәгендә дә мәхәббәт уты кабынган. Автор яшьлекнең, мәхәббәтнең буыннан-буынга күчеп баруын раслый, кеше күңеленең матурлыгын ача. Хикәянең кыйммәте, минемчә, әнә шунда.

Безнең хикәяләрдә ирен сугышта югалткан тол аналар байтак очрый. Хикәя авторларының һәркайсы диярлек аларның ирләре турында, ничек һәлак булулары турында озаклап сөйләргә ярата. Ү. Сат-

таров исә мондый алымнан качарга тырышкан һәм, әйтергә кирәк, дөрес эшләгән. Галимә апаның ире ничек, ни өчен үлгән — билгесез. Әмма бер нәрсә бәхәссез: аның ире, һичшиксез, изге юлда вафат булган. Шулай булмаганда, Галимә апа ире белән бергә ишегалдына тезгән ак ташларга карап горурлык хисләре кичермәс, изге хатирәләргә бирелмәс иде. Ак ташлар — намус һәм сафлык билгесе. «Бу гади таш юл түгел, хасиятле таш юл бу. Аның хасиятләре бик күп: мисал өчен, ул юлдан капкага табан да, ишеккә табан да вакытында гына үтәргә кирәк; ул юлга юньсезләрнең аяк басуы һич кирәкми; ул юлга үзеңә дә, башкаларга да саф күңел, керсез намус белән генә басарга кирәк».

Никадәр тирән, фәлсәфи фикер салынган бу юлларга! Мондый сүзләр яза алган автордан киләчәктә тагын да яхшырак әсәрләр көтәргә хакыбыз бар.

Шул ук 6 санда журнал укучыларга Әнәс Камалның «Олы Әкбәрнең кече Әсгаре» дигән хикәясен тәкъдим итә. Авторның үзе сурәтли торган тормышны һәм чорны яхшы белүе күренеп тора. Ул кызыклы детальләр аша унтугызынчы йөздәге Казан тормышын күз алдына китереп бастыра. Суыкта катып үлгән чыпчыклар, зәмһәрир салкыннан кая качарга белмичә җан-фәрман чабучы мәчеләр, Яңа бистәдәге янтык йортларның кыйшык морҗаларыннан һавага күтәрелгән төтен баганалары, чиркәү чаңы тавышлары, урам чатындагы бутышник — болар һәммәсе дә шул чордагы тормышны, обстановканы тулырак һәм җанлырак итеп күз алдына китерергә хезмәт итә.

Ә. Камал хикәясе, бер яктан, укучыга чын мәгънәсендә эстетик ләззәт бирсә, икенчедән, аны укып, без татар драматургиясенә нигез салган әдип турында шактый бай мәгълүмат алабыз.

Сабир Шәриповның казакъ халкы тормышыннан алып язылган «Сөлек» (7 сан) дигән хикәясен берәү дә салкын-тыныч җан белән укый алмагандыр. Хикәянең тәэсир көче гаять зур, язучы ярлы халыкның кайгы-хәсрәтен һәм фаҗигасен бөтен тирәнлеге белән ачып бирә.

Әсәр бер-берсенә тыгыз бәйләнгән ике линия буенча үсә. Беренче линия Исхак хаҗи һәм аның явызлыклары белән бәйләнгән. Икенчесе — халыкта социаль аң уяна башлау. Хикәядәге барлык вакыйгалар менә шушы ике үзәк тирәсенә туплана. Язучы сыйныфлар арасындагы аерымлыкны тарихи җирлектә, реаль вакыйгалар аша ачып бирә.

Исхак хаҗиның нинди рәк кеше булуы турыдан-туры әйтелми. Әмма вакыйгалар барышында укучы аның кем икәнлеген, явыз ниятле һәм астыртын кеше булуын бик тиз аңлап ала. Кыш авыр киләчәк, меңәр баш малларны ничек асрап чыгарга да ничек аларга печән җиткерергә? Менә шушы кыен хәлне Исхак хаҗи табыш китерү чарасына әйләндерә. Соңыннан кайтарып бирү шарты белән, малларын ярлы халыкка өләшә.

Ун еллап вакыт үтә. Исхак хаҗиның ярлы халыкта тоткан савым сыерлары өч йөз баштан артып китә. Ләкин күпләр бу эшнең алдау икәнлегенә төшенә башлый. Малларны кайтарып бирмәскә өндәүчеләр табыла. Кырык өйле кечкенә генә казакъ авылында сыйнфый аң уяна! Нәфрәттән ярсуы ташыган халык мулла-мунтагайны, хаҗиның улларын, волость агайларын кыйнап ыргыта. Әмма стихияле бу көрәш аларга бик кыйммәткә төшә: җайдаклар килеп, авыл халкын канга батырып китәләр. Моның белән генә дә чикләнмичә, кышкы буранда ярлы халыкны ачык далага куып чыгаралар. «...Берәүләрнең башы ачык, икенчеләре ялан аяк; барысының да диярлек өсте-башы ертылып беткән. Котырынып искән җил аларның ачык өсләренә кар сибә, яннарына көрт өя».

Хикәядә аеруча тулы эшләнгән образларның берсе — Бәкер исемле кеше. Исхак хаҗиның ярлыларга сыер өләшүен ишеткәч тә, ул:

— Мең елкыга хуҗа була белгән Исхак хаҗи ахмак түгел ул. Ни өчен элек тамчы да тамызмый торган кеше кинәт шулай юмартланып китте икән? — ди.

Бәкер — үсештә бирелгән образ. Шактый аек фикер йөртә ала торган кеше булса да, ул баштарак әле вакыйгаларга турыдан-туры катнашмый, читтәрәк кала. Инде Исхак хаҗиның чын йөзен аңлап алгач, аны халык тәненә ябышкан сөлек дип атый. Нәкъ шул урында хикәянең исеменә салынган мәгънә дә кинәт ачылып, конкретлашып китә.

Фазыл Мостафинның «Кенәриле Галимҗан» (8 сан) дигән хикәясе исеме белән үк ниндидер серле, кызыклы нәрсәләр вәгъдә итә кебек. Хикәяне укып бетерәсең, ләкин көтеп алган әлеге сер ачылмый кала.

Карт мастер Галимҗан абзый бала чагыннан ук кошларны, аларның «әнкәй назын да, әткәй иркәләвен дә алмаштырырлык моңын» яраткан. Ул үзенең эш урынында да кенәриле читлек тота. Телгә алып сөйләрлек бөтен вакыйга менә шул.

Бик тырышканда, язучының тел төбен аңларга мөмкин: карт мастерның әле икенче «кенәриләре»—җир астыннан нефть чыгаручы дуслары, хезмәттәшләре бар. Әйе, Галимҗан абзый нефтьче дусларын бик ярата. Институт тәмамлап килгән Тәүфыйк исемле яшь инженерны аеруча үз күрә. Көннәрнең берендә Галимҗан абзый Тәүфыйкны складка алып керә һәм аңа, документсыз-нисез, сынау өчен кайтарылган бораулары биреп җибәрә. Шул бораулар ярдәмендә Тәүфыйк район күләмендә яңа рекорд куя! Иң кызганычы шул: хикәядә күңелне кузгатып җибәрердәй, әсир итәрдәй вакыйга юк. Анда хикәя жанры өчен бик тә кирәкле булган конфликт юк.

Талха Гыйниятуллинның «Солдат үлеме» (10 сан) дигән хикәясе темасы һәм стиль үзенчәлекләре белән журналдагы башка хикәяләрдән нык аерылып тора. Шактый озын булганга күрә, ул башта куркытып та куйган иде. Бер укырга тотындыңмы, аерылып булмый икән. Хикәядә —үлем белән тартышучы солдатның саташулы, әрнүле, сагышлы һәм татлы уйлары, хыяллары, газаплары... Гайса солдат кадерле өен, хатынын, балаларын сагына, аларны соңгы тапкыр күрү максаты белән михнәтле юллар кичә. Язучы аның шушы көчле омтылышын тормышчан детальләр аша тасвирлап бирә. Үзеннән-үзе Ә. Еникиның «Кем җырлады» исемле хикәясе искә төшә. Уйлап карасаң, икесендә дә бер үк нәрсә — үлем белән тартышучы солдатның туган ягына булган көчле сагышы. Сүз дә юк, «Кем җырлады» хикәясендә лиризм, драматизм көчлерәк. Ләкин Әмирхан ага Еники ясаган психологик ачыш Т. Гыйниятуллин хикәясендә үзенчә яңгырый. Укучы әле солдатның кайда, ничек ятуына тиз генә төшенә алмый. Шуңа күрә ул, аның белән бергә, балчыкны ишә-ишә окоптан шуып чыга, башын бәрә-бәрә вагонда чайкалып бара, мең газаплар белән солдатның таныш якларына килеп чыга. Хикәя ахырындагы соңгы җөмлә укучыны берьюлы эзгә төшерә һәм солдат язмышы турында тагын бер кат уйланырга мәҗбүр итә. Әйе, фашистлар тарафыннан көчләп тагылган сугыш күпме кешенең гомерен кисте, күпме кешене туган йортыннан, хатыныннан, газиз балаларыннан аерды. Хикәя явыз фашизмга ләгънәт булып яңгырый, исәннәрне тагын бер кат уяу булырга чакыра.

Хикәя сөючеләрнең күңелен канәгатьләндерү йөзеннән булса кирәк, 11 санда журнал берьюлы өч хикәя баскан. Альберт Мифтахетдиновның «Хан-Гәрәйнең сәер көннәре» дигән хикәясендә Чукотка ягы һәм аның кешеләре тасвирлана. Вакыйгаларның һәм геройларның гадәти булмавы әсәрнең буеннан-буена сизелеп килә.

Алдан ук әйтеп куйыйк: хикәя әйбәт, яратып укыла. Әмма шуның белән бергә, күңелдә күпмедер канәгатьсезлек хисе дә кала. Ни өчен? Чөнки җитди уңышлары белән бергә, хикәядә кайбер кимчелекләр дә очрый. Шуларның берсе — аерым моментларның мотивлаштырылмаган булуы. «Чибәр рус хатыны» дигәне кем ул, аның Илдар белән ни бәйләнеше бар? Ә бит телгә алынган һәр образ әсәрнең идея-эстетик юнәлешен билгеләүдә, авторның әйтергә теләгән фикерен ачыклауда билгеле бер роль уйнарга тиеш.

Әлеге кимчелекләр бигрәк тә хикәянең баш өлешенә кагыла, калган җире исә ачык, эзлекле бара. Мәхәббәтнең серле һәм тынычнак кичерешләре ахыр чиктә серле табигатьле Илдарны да «кояшлы» кешегә әверелдерә. Күзләренә «...шул кадәр кызыксыну, самимилек, балаларга гына хас гөнаһсызлык» тулган Света Илдарның болытлы күңелендә тирән һәм якты борылыш ясый. Сирән гына сүзләр ярдәмендә мәхәббәтнең көче, матурлыгы ачыла. Автор кирәкле урында нокта куя белә, вәгазь укып укучыны ялыктырмый.

Рөстәм Кутуй — уңышлы повесть-хикәяләре белән рус һәм татар укучыларына күптән таныш. Аның «Яңгыр шавы» дигән хикәясе дә нык кул, тәҗрибәле каләм белән язылган.

Хикәянең исеме символик мәгънәгә ия. Аны гомер шавы, туган як шавы дип тә аңларга мөмкин. Автор укучының эрудициясенә ышана, аның тирән фикер йөртә алуына исәп тота. Әмма урыны-урыны белән мотивлаштырылмаган урыннар да очрап куя. Әйтик, Энҗе образы нигә кирәк булды икән? Документаль материал белән художество алымнарының бергә кушылган булуы автор өчен кыенлык тудырган булса кирәк.

Шушы ук санда, «Елмаеп-көлеп кенә» дигән баш астында, Радик Исаевның «Ур-

нәкле кияү» хикәясе бирелгән. Әйе, елмаеп-көлдереп ала торган урыннар хикәядә шактый. Авторның юморга бай теле бар, кызыклы гына детальләре күп. Ләкин әсәр ышандырмый. Мин шартлылыкка, сәнгатьчә уйланмага каршы түгел. Ләкин аның да чиге, чамасы булырга тиештер...

Шулай итеп, бер ел дәвамында «Казан утлары» журналында басылган хикәяләрне күздән кичереп чыктык. Хикәяләр бакчасында төрлесе: өлгереп җиткәннәре дә, әлегә яртылаш кына пешкәннәре дә бар икән. Бер ел эчендә басылган хикәяләрдән чыгып кына зур нәтиҗә ясау дөрес булмас. Әмма шунысы хак: яхшы хикәяләр аз языла. Соңгы елларда бездә хикәя жанры нык бирешә.

Моннан бер-ике ел элек «Литературная газета» битләрендә хикәя жанрына багышланган кайнар бәхәсләр булып узды. Берәүләр хикәя жанрының бетүгә таба йөз тотуын, икенчеләр, киресенчә, аның күтәрелеп китүен расларга тырыштылар. Минем уйлавымча, аларның беренчеләре кимчелекле һәм күңелсез фактларга таянып эш итте, икенчеләре исә уңай фактларны гына алга сөрде — фикер каршылыгы фәкать шунда. Яхшы хикәяләрнең аз булуы яки гомумән хикәяләр санының кимүе — бу әле хикәянең бетүе дигән сүз түгел.

Сүз ахырында тәнкыйть колагына да берничә сүз әйтеп узасы килә. Бездә ел саен күпме хикәя чыга. Әмма тәнкыйтьнең алар хакында авыз тутырып сөйләгәне юк дияргә була. Рафаил Төхфәтуллин гына «Социалистик Татарстан» газетасы аша журналда ярты ел эчендә чыккан хикәяләр турында беркадәр фикер язып чыкты. Ләкин ул да берничә сүз әйтү белән канәгатьләнде, сөйләшүне башлап җибәрүдән узмады. Әдәби тәнкыйть күбрәк роман һәм повестьлар белән мавыга. Фатих Хөсничә «Хикәя укыйсым килә!» дип чаң кагуыбызга карап кына яхшы хикәяләрнең саны әллә ни артмас артуын. Ләкин тәнкыйтьнең авторитетлы сүзе һәм объектив бәясе хикәяләр бакчасының һавасын яхшыртуда, туфрагын йомшартуда тиешле ролен уйнамый калмас. Моны бездән хикәя жанрының бүгенге торышы үзе таләп итә.

**РАШАТ НИЗАМИЕВ.**

# ЯШЬ КҮҢЕЛЛӘРГӘ ШИФА БУЛСЫН

Бүгенге яшь укучыны китап кибетләрендә дә, китапханәләрдә дә матур итеп бизәлгән бик күп китаплар көтеп тора. Ниндиләре генә юк алар арасында! Җаның кайсын тели, шунысын сайлап ал...

Минем исә нәни укучыларыбыз игътибарын күптән түгел дөньяга чыккан яңа бер китапка юнәлтәсем килә: «Менә бусын укып карамассызмы?» Ул «Октябрятлар шәһәре»[1] дип атала. Авторы — Хәкимҗан Халиков. Моңа кадәр укучылар аның «Йолдызлар ничәү?» (1969 ел), «Шук бабай» (1970 ел), «Тынычлык гөле» (1971 ел), «Энәбикә» (1973 ел), «Озын колаклы батыр» (1974 ел) дигән җыентыклары белән таныш иде. Х. Халиковның ул китаплары уйчан кызлар һәм шук малайлар, наян аю балалары һәм батыр куяннар, зирәк керпе малайлары һәм төрле-төрле кошлар турындагы шигырьләре белән хәтергә калган. Әлеге җыентыкларга кергән шигырьләре белән танышкач, тагын шул нәрсә ачыклана: Хәкимҗан Халиков йөрәге һәм акылы кушканча иҗат итә, дөньяны балалар күзе белән күрә белә, балаларга аңлаешлы, образлы, йөгерек тел белән яза. Ул гадәттә кыска гына шигырьдә дә тәмамланган төгәл картина яки вакыйга бирергә омтыла. «Йолдызлар ничәү?» китабындагы «Җәйге кич» шигыренә күз салыйк:

Җәйләүдән кайтканда,
Абыем Айтуган:
— Кара,— ди,— нәкъ синең
Җәяң күк ай туган.
Шул вакыт ай-җәя,
Күрәсең, тартылды:
Бер йолдыз ук булып
Еракка атылды.

Шагыйрь пейзаж лирикасының укучы күңелендә матурлык хисе тәрбияләвен нык аңлап эш итә. Чыннан да, табигать һәм

[1] Х. Халиков. Октябрятлар шәһәре. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1975 ел.

кеше һәр вакыт тыгыз бәйләнештә бит. Кеше күңелендә дә, табигатьтәге кебек үк, халык җырыдай, халык моңыдай табигый матурлык, камиллек яши. Авторның «Җәйге буран», «Көз» («Йолдызлар ничәү?» китабында), «Яңгыр хәбәрчеләре» («Энәбикә»дә) кебек шигырьләре исә, матурлык хисе тәрбияләү белән бергә, балаларга фәнни мәгълүмат та бирәләр. Хәзер, илебездә проблемалы уку-укыту эше киң колач ала барган бер вакытта, укучыларга яңа мәгълүмат бирү дә бик кирәк. Хәкимҗан Халиков шигырьләре бу яктан да заманча яңгырый.

Авторның «Октябрятлар шәһәре» исемле яңа җыентыгында да укучылар күңеленә хуш килердәй шигырьләр байтак. «Кайдан белгән?», «Онытмаган», «Телен тешләде», «Өч кыз», «Зиләнең курчагы» кебек шигырьләре аеруча нык хәтердә кала. Бу шигырьләрендә ул әзергә хәзер булып ятучы Хикмәт, Гарифуллалардан, Азат кебек ялганчы малайлардан көлә, хезмәт сөючә тырыш балаларны мактый.

Күптән түгел республикабызның яшьләр газетасында «Янгын яныннан гитара асып...» дигән мәкалә чыккан иде. Урманда — янгын!.. Шунда бер төркем яшьләр, гитара чиртеп, янгынны тамаша кылалар. Ул гына да түгел, кайткач дусларына күрсәтеп мактану нияте белән булса кирәк, аны рәсемгә дә төшереп алалар... «Октябрятлар шәһәре» китабындагы «Язгы бакча», «Ялгыз нарат», «Һәйкәл утырттык» кебек шигырьләрне укыган балалар, һичшиксез, әлеге яшьләр төсле булмаячаклар.

Хәкимҗан Халиков — ритм, рифма белән сак эш итүче шагыйрь. Шул ук вакытта ул һәр вакыт яңа формалар эзли. Баланың аңына ничек тәэсир итәргә? Бала характерындагы тискәре якларны ни рәвешле тәнкыйть утына алырга һәм аларны булдырмау чарасын ничек алдан күрергә? Шагыйрь буларак, аны әнә шул сораулар борчый.

Яшь кешенең холык-фигылен тирәлек, мохит тәрбияли. Менә шуларны истә тотып булса кирәк, шагыйрь безне әйләнәтирәбезгә хөрмәт белән сокланып-гаҗәпләнеп тә, игътибар белән уйланып-эзләнеп тә, кирәк икән, тәнкыйтьчел дә карарга өйрәтә. Автор үзенең бу теләгенә төрле алымнар аша ирешә. Бер очракта җылы гына юмор куллана ул. Икенче вакытта шигырьгә, үзен артык сиздермичә генә, үгет-нәсыйхәт килеп керә. Һәм боларның һәркайсы аклана, үзенә йөкләнгән бурычны үти.

Хәкимҗан Халиков, тормышта алай күзгә бәрелеп торган шаян-җор кеше булмаса да, ул — бала җанлы кеше. Ул, тәҗрибәле укытучы-остаз кебек, чаманы белеп кенә укучыларны көлдереп тә ала («Онытмаган», «Хикмәт»), аларга «җәза» да бирә («Сезме, минме командир?!», «Гарифулла», «Юмартланган», «Кем батыр?»), алар белән киңәшләшә, фикер уртаклаша («Китап докторы», «Безнең йолдызчык» һ. б.).

Ләкин әнә шундый матур шигырьләр белән беррәттән, китапта күңелне борчырдай әсәрләр дә юк түгел. Х. Халиков күп вакыт гади генә нәрсәне дә энәсеннән җебенә кадәр тәфсилләп сөйләп чыга, аңлатып бирә, халык әйтмешли, «чәйнәп каптыра». Автор укучысына: «Ул әле бик кечкенә, яше дә бит өч кенә...» дип карый, ахрысы. Бу хәл шигырьне ялыктыргыч итә.

«Йолдызлар» шигыренә игътибар итик. Ул һавадагы йолдызларны сурәтләү белән башлана:

Һавада йолдызлар
Кушучлап сипкән күк.
Кайберсе, тунгандай,
Дерелдәп киткән күк.

Кайберсе ялт кына
Атыла ук кебек.
Ә укның койрыгы
Нәкъ көмеш чук кебек.

Башта укучы җиңелчә генә шомланырга тиеш: йолдызлар атыла!.. Аннары автор турыдан-туры йолдызларның сүнүен сурәтләүгә күчә:

Йолдызлар, йолдызлар...
Сез бит бер сүнәсез.
Көндез дә нур сибеп
Тормыйсыз нигә сез?

Боларның барысы да, янәсе, укучы күңеленә Кызыл йолдызның бөеклеге, мәңгелек булуы турындагы фикерне тирәнгәрәк салу өчен кирәк булган...

Ә Кызыл йолдыз ул
Мәңгелек ут кебек.
Дусларга — кояш ул,
Дошманга — туп кебек.

Менә шуннан соң инде түбәндәге строфа китерелә:

Утта да янмый ул,
Суда да батмый ул,
Бер җирдә тапталып,
Хур булып ятмый ул.

Авторның нияте, әлбәттә, изге: ул күп каһарманнарыбыз гомерен биргән азатлык, дуслык, тынычлык, Ватанга булган олы мәхәббәт символына әверелгән йолдызга — Кызыл йолдызга дан җырларга теләя. Бу кадәресе аңлашыла. Әмма шигырьдә хәтер-

дә калмый торган төссез юллар күп, аннары ул алдан ук: «Бу шигырь Кызыл йолдызның җирдә тапталып, хур булып ятмавы турында!» дип, оран салып тора. Бәлки бәйләндең инде шул бер куплетка! диючеләр табылыр. Ләкин балалар өчен әдәби әсәр язарга алынган кеше һәр җөмләгә, һәр сүзгә гаять игътибарлы булырга тиеш. Шушы ук шигырьдә, мәсәлән, Советлар йолдызы «иң ерак айда да» көрәшеп йөри дигәнрәк фикер дә бар. Айның әле иң якыны да (бирегә пространствоара турында сүз бара) буламы икәнни? Әнә шундый төгәлсезлекләр шигырьне ямьсезли һәм боза.

Икенче бер шигырендә автор баладан мондый сүзләр әйттерә:

Чаба-чаба
Килеп керде
Бала-чага.

(«Уенчыклар остасы».)

Биш-алты яшьлек малай үзенең иптәшләренә һәм дусларына, ай-һай, болай дип әйтерме икән?! Юк, аның үзенең якын дусларына «бала-чага» дип әйтүе ышандырып бетерми.

Бәхеткә каршы, китапта мондый төгәлсезлекләр күп түгел. Җыентыкта әйбәт әсәрләр, кызыклы табышлар, көтелмәгән борылышлар күп. Әйтик, «Октябрятлар шәһәре» дигән шигырь якты шатлык иле булып күңелдә кала. Шигъри җыентыкта балалар китапларны да, уенчык куяннарны да «дәвалыйлар». Әйе, бу — балалар ватып кына калмый, ә ясый да беләләр, әйбәт һөнәргә — төзү-төзекләндерү һөнәренә өйрәнеп үсәләр дигән сүз. Алар үзләрендә әдәпсезлек-начарлыкка, ялкаулыкка — нәфрәт, белемгә-хезмәткә, җиргә-табигатькә мәхәббәт тәрбиялиләр. Ә мондый акыллы яшьләр — яңа төзелешләрнең ялкынлы эшчеләре һәм яшь колумблары — безнең җәмгыятебезгә, фән, техника прогрессының гаять әһәмиятле мәсьәләләре бер-бер артлы тормышка ашып, илебез халыкларының һәм материаль, һәм мәдәният дәрәҗәсе үсә баргач чакта һава кебек кирәк.

**Ф. САФА.**

## Галимҗан Латыйп

### Акбабай

Мансур кайтты авылдан,
Дәү әнидә ял итеп.
Кайтасы да килмәгән,
— Сагындым, — ди, — бары тик.

И су буенда халык, — ди,
И балык анда, балык, — ди.
Менәбез яр буеннан, — ди,
Без һаман соңга калып, — ди.

Тотабыз кармак белән, — ди,
Тотабыз иләк белән, — ди.
Акбабайның балыгы, — ди,
Була гел чиләк белән, — ди.

Балыкчы ул Акбабай, — ди,
Колхозга балык тота, — ди.
Кызык анда елгада, — ди,
Балыкны балык йота, — ди.

Акбабайны сез аны, — ди,
Белмисез шул, белмисез, — ди,
Сез бит һаман калада, — ди,
Бернәрсә дә күрмисез,— ди.

Акбабайның сакалы да,
Мыегы, кашы да ак, — ди.
Өстендәге киеме дә,
Күңеле дә, башы да ак,— ди.

Аның тоткан балыгы да,
Ашаган ашы да ак,— ди,
Сөт тә катык, манный гына...
Ә әйткән һәр сүзе хак, — ди.

## Барган идем

Барган идем
Әти белән
Урманга.
Нинди генә
Сайрар кошлар
Юк анда!

Куакларда
Сандугачы,
Былбылы.
Моңа кадәр
Күргәнмени
Мин моны.

И тыңладым
Сайрауларын
Кошларның.

Урман тулы
Гел моң икән,
Ышандым.

Кайберләре
«Уел» көен
Сыздыра.
Берсе гүя
Малайларча
Сызгыра...

Искитмәле
Урмандагы
Яңалык.
Өйгә кайттым
Мин бөтенләй
Яңарып.

## Җиләкчеләр

Ике малай, ике кыз
Җиләктән кайтып килә.
Илгиз, Равил, Наилә,
Дүртенчесе Җәмилә.

Малайларның тырыста
Күренми шул берни дә.
Ә үзләре юл буйлап
Сызгырып атлый бирә.

Ә кызларда, кызларда
Җиләк дисәң дә җиләк!
Шатланышып кайталар
Үзара нидер сөйләп.

Сүз кушам малайларга:
— Эреме җиләгегез?
Берар уч кына миңа да,
Я, биреп җибәрегез.

Равил җавабын таба,
Калмый бер дә аптырап:
— Безнең җиләк яшел, — ди, —
Кызларныкы яхшырак.

Көтүдәге кәҗә кебек,
Элдерә алар алдан, —
Без өзәсе җиләкләрдән
Яфраклар гына калган.

— Юк, абый, — ди Җәмилә, —
Ышанмагыз Равилгә.
Аланда да, яланда да —
Аерылмадык — гел бергә.

Аның шул инде һаман,
Акланырга тырыша.
Алар җыйды тел астына,
Ә без җыйдык тырыска.

## Улым белән авылга кайткач

Кызык та соң улыма,
Сораштыра, йөгерә.
— Теге нәрсә, бу нәрсә?
Тели барын белергә.

Ташбаш тоттык унлапны,
И сөенде, и шатлык.
Бака кабырчыклары
Ике кисә, бер башлык.

Су буеннан менгәндә
Килеп чыкты күркәләр.
Безне сәламләгәндәй,
Голдыр-голдыр итәләр.

Шүрләде минем улым,
Йөгереп килде яныма.
Пышылдап кына әйтте
Ул минем колагыма:

— Әти, кара әле, кара,
Нинди олы тавыклар! —
Тарткалый җиңнәремнән: —
— Якынрак алып бар.

Ярый әле, кайтканбыз,
Кайтмасак, күрмәс иде,
Күркәнең тавык түгелен
Ул әле белмәс иде.

## Безнең Акбай

Безнең Акбай
Бакча саклый.
Көнен саклый,
Төнен саклый.

Өрә икән
Безнең Акбай
Белеп өрә:
— Бакчабызга
Кермә, кермә.
Бу тирәдә
Йөрмә, йөрмә!

Бездә алма,
Бездә чия
Кызыл җәймә
Япкан төсле.

Кайберләре
Кара-кучкыл,
Кайберләре
Ал кан төсле.

Малайларның
Муеннары
Гел бу якка
Борылалар.
Ә күзләре
Ялт-йолт килә,
Алмаларга
Кызыгалар!

Тик Акбайның
Колаклары
Ә дигәнче
Үрә тора.

Әткәй аңа
Куәт биреп,
«Эһһем!» диеп
Тамак кыра.

Иренми ул
Безнең Акбай,
Тамак тук дип,
Йоклап ятмый.
Сукмаклардан
Көнен атлый,
Төнен атлый —
Безнең Акбай
Бакча саклый.

## Тәрәзә ватылмады

Безнең тәрәзә төбенә
Песнәкләр килеп куна.
Әнием дә, мин үзем дә
Бик сөенәбез шуңа.

«Кыш бик салкын — туңабыз
Шуңа монда кунабыз.
Уңайлы да, ышык та,
Безне моннан кумагыз!»

Якынайсак: «Фр да фр»,
Бездән никтер шүрлиләр.
Арада бит тәрәзә бар,
Алар шуны белмиләр.

Тора-бара өйрәнделәр,
Курыкмый башладылар.
Хәтта бер көн җимне дә
Учымнан ашадылар.

...Сеңелем песи ярата дип,
Алган идек ак песи,
Үзе уңган, үзе булган,
Һәр нәрсәгә сак песи.

Шул песи бит песнәкләрдән
Һич кенә дә күзен алмый.
Үзе тәрәзәгә карый,
Үзе иренен ялый.

Песиебез бер көнне
Сикереп тә карады.
Пыялага бәрелде дә
Борын очы канады.

Ярый әле, нык икән,
Ватылмады пыяла.
Песнәкләр «пырх-пырх»
Барып кунды коймага.

Сөенәләр үзләре:
— Тәрәзә ватылмады,
— Тәрәзә ватылмады!..
Песи дә юашланды,
Яңадан атылмады.

# СУГЫШ ЕЛЛАРЫ ЮМОРЫННАН

*Журналыбызның узган елгы бишенче санында Бөек Ватан сугышы елларында туплар һәм танклар, автоматлар һәм пулеметлар шикелле ук җиңү коралы булып саналган юмор һәм сатира материалларының бер тупланмасы инде басылган иде. Шуңа тагын шактый мул өстәмә табылды һәм аның әле киләчәктә дә табыла торуы бик мөмкин. Бу юлы укучылар игътибарына безнең матбугат битләрендә басылган фольклор материаллары гына түгел, ә сугышның авыр газапларын шулай ук кичергән чех һәм словак халыклары мәзәкләреннән, болгар юморыннан һәм немецларның үз анекдотларыннан да кайбер үрнәкләр тәкъдим ителә.*

I

## КЫСКА ӘЙТҮ—ОСТА АТУ

СОВЕТ МАТБУГАТЫ БИТЛӘРЕННӘН

### ҺӨҖҮМ ТЫНГАН АРАДА

— Миңа обер-лейтенант Людвигны бик тиз генә табарга кирәк иде.
— Әллә полктан берәр ашыгыч әмер бирделәрме?
— Әйе. Аның гәүдәсен теләсә кайдан эзләп табып, тиз генә күмәргә боердылар.

### ПАТРОН БЕТКӘНЧЕ

— Син ник болай берөзлексез атасың да атасың әле, Ганс?
— Ә бит полковник безгә соңгы патронгача атарга кушты: руслар күренгәнче очыртып бетерергә кирәктер бит пуляларны?!.

### НИЧЕК САКЛАНЫРГА!

— Әгәр күкрәкне калкан белән капласак, рус пулясы тишә алмас иде бит?!
— Ә, ник күкрәкне? Арканы диген син.

## КЕМ ПЛАНЫ БЕЛӘН БИТ

— Безнең бу чигенү очраклы хәл түгел, ә план буенча бара икән бит.

— Бәлки шулайдыр. Әмма ул план безнеке түгел, ә русларныкы икәнен беләсеңме?

## РЕЗЕРВ КИЛГӘЧ

— Кичә безгә резерв килде. Обер-лейтенант, шуны тизрәк роталарга бүлеп таратыгыз!

— Алар бүленделәр инде, полковник әфәнде.

— Роталаргамы?

— Төрле җирдәге төрле каберләргә...

## ФЮРЕР БЕЛӘН АДЪЮТАНТ ГӘБЕ

— Бөтен генералларны тиз генә минем янга киңәшмәгә җыегыз!

— Генералларның күбесе инде әсир икәнен искә алсак, киңәшмәне Россиядә үткәрү кулайрак булмас микән, фюрер?

## ШУЛАЙ БУЛЫП ЧЫГА

— Бу белдерүдә «Партизан Данилны үтергән кешегә 300 марка акча бирелә» дип язылган. Димәк, безнең һәркайсыбызның башы берәр сум итеп бәяләнгән?

— Ничек алай?

— Ә менә шулай: партизан Данил кичә, мина шартлатып, безнең нәкъ өч йөз солдатыбыз торган казарманың көлен күккә очырган бит.

## ДӨРЕСЕН ЭШЛӘҮ

— Син ишеттеңме әле? Безнең дустыбыз Ганс үз башын әнә теге авылда калдырган ди.

— Дөрес эшләгән. Чөнки «чигенгән чакта барлык артык нәрсәне ташлап китәргә» дигән команданы ул үзе биргән иде бит.

## УРЫНСЫЗ КУАНЫЧ

— Аллага шөкер, Курт, үзебезнең туган якларыбызга һәм туган йортларыбызга һаман саен якынлаша барабыз бит!

— Болай тиз барсак, өй турыбыздан да йөгертеп узлырырлар әле.

## КАЙСЫ ЯХШЫРАК!

— Руслар чамасыз көчле ут яудыра башлады, хәтта баш күтәрергә дә мөмкин түгел.

— Башларны күтәрмичә, үкчәләрне генә ялтыратсак яхшырак булмасмы?

## БОРЫЛЫП КАРАУ КАЯ УЛ

— Беләсе иде, русларның нинди частьлары безне шулай каты талкыды икән?
— Һич әйтә алмыйм, полковник, артка борылып карарга минем вакытым булмады...

## БЕРЛИНДА СӨЙЛӘШҮ

— Безнең немец солдатларының еш кына рус хатыннарына күңелләре төшә икән дип сөйлиләр.
— Булыр-булыр. Минем улым да фронттан: «Ниндидер бер «Катюша» искә төшү белән безнең барча солдатлар акылдан шашар чиккә җитә», дип язган.

## КУЫП БАРА

— Син кая чабасың әле болай, Фриц?
— Үз ротам артыннан куып.
— Ә кая соң ул рота?
— Зиратта диделәр...

## КУНАККА КИТТЕЛӘР

— Әби кеше, әйт әле, бу авылда безнең солдатлар бармы?
— Юк, әфәнде.
— Ә кая киттеләр соң алар?
— Кичә бирегә партизаннар килгән иде, офицер әфәнде. Алар сезнең солдатларны кунакка чакырдылар.
— Һәм безнекеләр шунда китте дәме?
— Аркаларына мылтык терәгәч, китмичә ни эшләсеннәр?

## БЕР ГЕНӘ ЯККА

— Көнчыгыш фронтта сугышу өчен фашистлар яңа төр самолет уйлап тапкан: тизлеге элеккегечә үк, ә бензинны бермә-бер ким тота икән.
— Ничек инде ул алай?
— Чөнки ул самолетлар бары көнчыгышка таба гына очалар...

## ЭЗЛӘР

— Полковник әфәнде, минем рота партизаннар эзенә төште бит...
— Котлыйм сезне. Бик әйбәт эш бу.
— Ләкин безгә партизаннар үзләре һөҗүм иттеләр шул һәм... минем ротаның эзе дә калмады.

## АЛГАННАР

— Ишеттеңме, фрау Мина? Фриц миңа Мәскәүдән хат җибәргән.
— Нәрсә, әллә алганнармы?
— Алганнар.

— И ходаем, нинди зур шатлык бу! Мәскәүне алганнар!..
— Юк, Мәскәүне түгел, Фрицны әсир итеп алганнар.

## РЕЦЕПТ

Көнчыгыш фронтта гаскәрләре җиңелә башлагач, Гитлер каты чиргә сабыша. Дәвалау өчен Венадан атаклы докторны китерәләр. Авыруны карагач, доктор аны тирән ванналар белән дәваларга куша.

— Ничек дәваларга кирәк дигән сүз була инде бу? — дип сорый фюрерны караучылар.

— Бик тә гади ысул булыр бу, — ди доктор. — Сырхауны ваннага өч мәртәбә чумдырырга да судан ике генә тапкыр чыгарырга кирәк.

## БЕРҮЗЕ КАЛГАЧ

— Безнең полкта хәзер югалтулар аз булачак.
— Каян беләсең?
— Чөнки полкта, лейтенант әфәнде, бер мин генә исән калдым.

## ҖИҢӘ ТОРГАН КОРАЛ

— Полковник әфәнде! Безнең туптан атып, большевиклар офицеры безнең бөтен пулеметларны кырып ташлады.

— Безнең коралның җиңүе турында штабка ашыгыч хәбәр итегез.

## ЭЛӘКТЕ...

— Ой, полковник әфәнде! Русларга бездән бүген нәрсәләр эләккәнен белсәгез икән!..

— Кирәкләрен шәп бирдегез, димәк?

— Бик тә шәп булды шул. Безнең ун танк, өч туп, йөз илле пулемет һәм җиде йөз солдат әсир эләкте аларга... Тизрәк ычкыныгыз, юкса, үзегезнең дә кармакка кабуыгыз ихтимал!..

## ҖӘЙ ҺӘМ КӨЗ

— Нәрсә турында шулай бик моңаеп уйланасың әле син, Август?
— Безнең июльдәге һөҗүмебез искә төште.
— Әйтәм җирле йөзләреңә сентябрь төсе чыккан...

## МӘҢГЕЛЕК УРЫН

Офицер: — Безнең фюрер сүзне җилгә очырмый ул. «Рус җирләренә мәңгелеккә керәбез» дип әйткән иде бит! Менә без инде рус җирендә!

Солдат:— Әйе шул. Бу дөреслек бигрәк тә безнең күрше батальонга кагыла: кичә ул батальон бу җиргә тулысынча күмелде.

## БИЛГЕСЕЗ ЮНӘЛЕШ

— Кая шулай чаба әле бу лейтенант Драхман?
— Билгесез юнәлештә.
— Ничек алай?
— Аңа совет тубыннан нәрсәдер тигән булса кирәк.



## ТЕРЛЕК БАРМЫ? БАР...

Немецлар комендатурасыннан бер сатлык җан авылда җан исәбе алырга килә:

— Я, мужиклар, авылда терлек-туар, ягъни мәсәлән, хайван дигән җан ияләре бармы сезнең?
— Бер дә юк түгел, бар әле, бар, пан.
— Кайда һәм күпме?
— Әйтик, мәсәлән, немецлар куйган староста.

## КЕМ КУЛ КУЯР?

— Шайтан алгыры! Рус снаряды нәкъ безнең команда пунктына килеп төшеп, командирның үзен һәлак итте. Совет артиллериясен тармар итү турында сводкага инде кем кул куяр икән?

## ЧАБЫП БАРГАНДА СӨЙЛӘШҮ

Немец генералы:— Бәйдән ычкындың мәллә?! Кая йөгерәсең болай шашып? Безнең чигенүне ут ачып каплап тор һәм нәтиҗәсен миңа әйтерсең...

Итальян полковнигы: — Нәтиҗәне ничек әйтә алыйм ди инде мин, генерал әфәнде, сез миннән кызурак чабасыз бит!

## ҮЗ КЕШЕ

— Доктор! Нишләп болай иттегез соң әле сез?! Бер аягы урынына икесен дә кискәнсез бит солдатның!!!

— Шаулама, тик тор! Белеп эшләдем мин моны, чөнки ул минем үз кешем. Көнчыгышта басып алынган җирләрне беренче чиратта сугыш инвалидларына бирәчәкләр бит!

## БЕЛЕШЛӘР ТҮГЕЛ ИКӘН

Безнең батальон комиссары немецча яхшы сөйләшә белә. Сорау алганда, әсир ителгән немец майорына аның беренче сүзе шул була:

— Сез Иоганн-Вольфганг Гетене беләсезме?
— ...Ул бәлки бүтән полктандыр. Без танышлар түгел.
— Ә Генрих Гейнене?
— Монысы, күрәсең, бүтән фронттандыр. Дөресен әйткәндә, бер генә тапкыр да очрашканыбыз юк...

II

# АСАРГАМЫ, ӘЛЛӘ АТАРГАМЫ?

## ЧЕХЛАР ҺӘМ СЛОВАКЛАР МӘЗӘКЛӘРЕННӘН ТЕЗМӘ

*
* *

— Бездә югары уку йортларының ни өчен өч елга ябылганын син беләсеңме?

— Беләм: культура үсеше ягыннан немецлар безне куып җитмәсен өчен.

*
* *

Германиядә кешеләр оптимистлар һәм пессимистлар дигән ике төркемгә бүленә. Оптимистлар: «Бу сугышта без оттырачакбыз!» дип белдерәләр. Ә пессимистлар исә: «Монысын без үзебез дә беләбез, ләкин кайчан?» дип әйтә.

*
* *

— Син немец телен беләсеңме?

— Ә нигә мин аны өйрәнергә тиеш? Немецлар бит без соңгы сулышка, соңгы кешебезгә хәтле сугышачакбыз диләр. Алар калмагач, кем белән сөйләшергә тиеш соң мин?

*
* *

Фирма директоры кабинетына эленгән Гитлер портреты идәнгә өзелеп төшә.

Идән җыештыручы ханым шуны кулына алып әйләндереп-әйләндереп карый да башлыктан сорый икән:

— Асаргамы моны, әллә атаргамы?

*
* *

Гавличек исемле артистны немецлар алдында чыгыш ясарга мәҗбүр итәләр. Сәхнәгә ул уң кулын югары күтәргән кыяфәттә чыгып баса. Көчле алкышлар тынгач исә әйтә:

— Мин театрдан кайтканда минем этем дә шулай югары сикерә,— ди.

Монын өчен аны бер айга төрмәгә утырталар. Җәзадан соң исә ул сәхнәгә кулын тагын да югарырак күтәреп чыга. Аны тагын да көчлерәк алкышлыйлар. Алкыш тынгач артист:

— Мин төрмәдән кайткач, минем этем нәкъ шундый югарылыкка сикерде, — ди.

III

# КАРШЫЛЫК ОПТИМИЗМЫ[1]



### НИЧЕК МӨМКИН — ШУЛАЙ КАЧ

— Германия бирелсә сез нишләрсез? — дип сорыйлар Геббельстан.
— Анадан тума калып чишенәм дә,— ди ул,— Берлинның зоологияя бакчасындагы маймыллар арасына барып керәм. Анда исә руслар мине таный да, таба да алмаячак.
— Ә маймыллар сезне үз компанияләренә алырлар дип уйлыйсызмы?

### ГЕСТАПОДА СӨЙЛӘШҮ

Иптәше белән сөйләшкәндә бер немец «Гитлер — ул акылдан язган кеше» дип әйтә. Шушыны ничектер ишетеп алган гестапо ничек инде аны допроска чакырмый калсын.
— Сез фюрерны мыскыллап сөйләдегезме?
— Мин бит үземнең күршем Адольф Шнапс турында сүз алып бардым, ә фюрер турында түгел.
— Алдыйсыз! Сезнең сүзләр нинди Адольф турында икәнен без беләбез инде!

### ИҢ МӨҺИМЕ

Гитлер: — Шуны истә тотыгыз, хәзер иң кирәклесе — вакыт оту.
Штаб начальнигы: — Әйе, әмма... вакыт отар өчен Кызыл Армия безгә һич кенә дә вакыт бирми бит.

IV

# КОЛАК ЯРГЫЧ ПЫШЫЛДАУ

НЕМЕЦ АНЕКДОТЛАРЫ

*
* *

Бомбадан кача торган базда Гитлерның бик бирелгән хезмәткәре горур тавыш белән белдерә:
— Әгәр фюрерыбыз булмаса, хәзер кайда булыр идек без!
Базның караңгы почмагыннан кемнеңдер тавышы ишетелә:
— Түшәктә ятар идек!

*
* *

Көнчыгыш фронтта, һичшиксез, җиңү өчен фюрер хатыннарның йөкле булу срогын тугыз айдан дүрт айга чаклы кыскартырга әмер бирә...

---

[1] Дамян Бырникованың (Болгария) шул исемдәге китабыннан.

*
*   *

Ике йөз марка акча салырга теләп, берәү банкка килә дә:

— Бу сумма югалмасмы? — дип сорый.

— Әлбәттә, югалмаячак.

— Әгәр сезнең банк шартласа, мин нишләрмен?

— Бөек рейх андый очракта да акчагызның сезнеке булып калачагына ышандыра.

— Ә рейх үзе шартласа ни булачак?

— Моның өчен ике йөз марка акчаны кызгану урынлы булыр идеме икән?

*
*   *

Хәрби көчләребезнең баш командованиесе түбәндәгене белдерә: «Әгәр аталары фронтта икәнлеге турында белешмә китерсәләр, яшьләре алтмыштан узган ирләр фольксштурмда хезмәт итүдән азат була алалар».

*
*   *

Һава тревогасы вакытында базга төшеп качарга килүчеләрдән кем дә булса «Хәерле кич!» дип әйтсә — ул әле йокламаган кеше булыр. «Хәерле иртә» диючеләр — бер-ике сәгать черем иткән булырга тиеш. Ә инде «Хайль Гитлер» дияргә тел күтәрүче кешеләр табыла икән — димәк, алар әле ахырынача уянмаган дигән сүз.

*
*   *

1945 елның апрелендә берлинлылар: «Дөньяда иң арзан транспорт — безнеке!» дип сөйләделәр.— Нибары егерме пфеннинг акча түләп метрода Көнбатыш фронттан Көнчыгыш фронтка кадәр барып була».

*
*   *

Сугыш беткәч, Гитлер, Гиммлер, Геббельс, Геринг һәм фельдмаршал Кейтель дарга асылачаклар. Шул минутларның иң соңгысында хәрби һава көчләренең башкомандующие Геринг якын юлдашы Кейтельгә әйтеп калачак: «Бу сугыш һавада хәл ителәчәк» дип, һәр вакыт тәкрарлый килдем бит мин сиңа, Кейтель».

*
*   *

Стенага эленгән үз портреты каршына басып, көннәрнең берендә сорый икән Гитлер:

— Киләчәктә безгә нәрсә буласын, ичмаса, син белмисеңме?

— Мине алып ташларлар, ә син асылачаксың.

*
*   *

— Бәла нәрсә ул?

— Әгәр Гитлер рейхстаг балконыннан егылып төшсә — ул аның өчен генә бәла, ә инде ул җиргә төшеп тә үлмичә калса — монысы инде бөтен халыкка бәла дигән сүз.

Үзбәк Саттаров

# ТЕЛЕВИЗОР ТИРӘСЕНДӘ

ХИКӘЯ



Ни чыкса шушы Наилдән чыга инде. Бүген дә ул безгә үзенең батыр кеше генә түгел, һөнәр иясе икәнлеген дә тагы бер тапкыр күрсәтте. Бүген минем хатыным Галиянең туган көне. Шуны ничек үткәрү турында план корып иртәнге чәйне эчеп утыра идек, көтмәгәндә ишек шакыдылар. Барып ачсак, ишек төбендә авызын колакларына чаклы ерып, ап-ак тигез, эре тешләрен ялтыратып Наил тора. Кулында үзе буе озын зур төргәк, янында хатыны. Наил ерылган авызын җыеп бетергәнче, хатыны елмаеп аның алдына чыкты:

— Галияне туган көне белән тәбрикләргә килдек! — дип, бусаганы атлап керде дә иренә таба борылып:

— Галияне күрдем дигәч тә, һушыңны җибәреп ишек төбендә басып торма инде, өйдә кер, — дип, кулы белән ишарәләде. Наил җәһәт кенә бусагадан атлады. Гәүдәсе алты потлы булса да, үзе бик җиңел йөри. Минем хатын: «Наилнең авырлыгы корсагына җыелмаган ич аның», — дип, миңа еш кына ишарә ясаштыргаласа да, мин аны аңламаганга салышам. Наил бик аз сүзле кеше ул үзе. Кайбер көнне ул безгә кич утырырга да килә. Килеп кергәч тә әйткән «Исәнмесез!»е белән, чыгып киткәндәге «Сау булыгыз!» дигәнен санамасаң, кич буена авызыннан бер дистәдән артык сүз чыгармас.

Менә ул хәзер дә кереп: «Исәнмесез!» — диде дә төргәген сүтә башлады. Аның урынына хатыны Ләмига телгә килде.

— Галиянең туган көненә бүләк ясар өчен булган икән, яз көне үк хәзерли башлаган иде ул сыек тал чыбыкларын. Мин: «Наил миңа алма җыярга кәрзин я булмаса бакчада тирбәлеп утырырга дуга аяклы кресло ясарга йөри инде», дип уйлаган идем, Галиягә киштә ясауда булган икән аның нияте. Ләмиганың сөйләве буенча киштәнең нәрсә икәнен дә, аның ничек ясалганын да аңладык. Наилне дә, Ләмиганы да мин күптәннән бик яхшы беләм. Шулай булгач,

Ләмиганың сөйләшмичә тора алмавы миңа бик аңлашыла. Мин үзем дә күп сөйләшергә яратмыйм. Әчемнән генә: «Мин, Наил һәм Ләмига сөйләгән сүзләрне җыеп өч кешегә тигезләп бүлсәң, өч нормаль кешеме, әллә өч тел бистәсе чыгар иде микән?» дип уйланып тора идем, Наилнең теле ачылды.

Ул киштәне бүлмә уртасына куйган. Янында үзе басып тора:

— Бу киштәдә бер генә кадак та юк. Ул фәкать агачтан гына ясалган. Аның... — дип, тагы нәрсәдер аңлатмакчы булып авызын ачкан иде дә, сүзен Ләмига бүлдерде:

— Аның менә бу бөҗрасына чүлмәкле гөл утыртасың. Менә монда, өскә, вазага салып суга утырткан чәчәкләр куясың. Астагы өстәленә теләсәң телефон куясың, әгәр күңелең хуш тапса, бизәнү әйберләре куйсаң да ярый, — диде дә, киштәне үзе ясаган кеше кебек горурланып, бер миңа, бер минем хатынга карап куйды.

Киштә бик ошады миңа. Күзләреннән күреп торам: ул минем хатынга да ошый. Йөгерешеп кызларым килде. Аларның да күзләре ялтырый. Кече кызым түзмәде:

— Менә бу этажерка, ичмасам! — дип куйды. «Шундый, кибән хәтле зур гәүдәле, тузган башмак кебек җәенке куллы кеше имән ботагы шикелле таза, юан бармаклары белән шундый нәфис сырлар үреп ничек ясый алды икән мондый матур сәнгать әсәрен», дип уйланып тора идем, Наилнең калын тавыш белән:

— Галия, сине туган көнең белән тәбрик итәм! — дигән сүзләре уйларымны бүлдерде. Ул өченче адымын атлаута, минем хатын янына килеп тә җитте, аны кочаклап та алды. Галиянең күзләре әле һаман киштәдә иде. Минем күз Наилнең Галияне кочаклаган зур җәенке кулларына төште. Колагыма хатынымның кабыргалары чытырдаган сыман тавыш чалынгандай булып китте.

— Наил, чамалап, кешене сытарсың, — диюемә, Ләмига телгә килде:

— Чамалап диләр бит сиңа, аю, ул бит сиңа мин түгел, — дип, йодрыгы белән Наилнең аркасын төя башлады.

Наил, Галияне кочагыннан чыгармыйча, иреннәрен аның битеннән алып тирән генә сулады да:

— Тормышыгыз җимерелмәслек нык кына түгел, менә шушы этажерка кебек нәфис тә булсын! — дип, хатынымның икенче битеннән дә үбеп алды.

Ләмига миңа: «Син ни карап торасың?» дигән сыман күз салды да:

— Җитте инде сиңа, аю! — дип, иренең аркасына, шаярып булса да, шактый нык итеп сугып куйды. Наил бармаклары белән мыегын сыпырып:

— Кайчан юабыз соң инде Галиянең пәпиен? — дип сорады.

Галия:

— Кичке алтылар тирәсендә, — дип сүз башлаган иде, минем аның күзләренә туры караганны сизеп алып, аптырап, туктап калды.

— Алтыда хоккей башлана. Әйдәгез, хоккей беткәч, — дидем мин.

Ләмига да дөресләгән сүз иң дөрес сүз була инде, ул шик калдырмаслык итеп:

— Галия, хоккей вакытында мәҗлес ясап булмый ул, шартласаң да, хоккейларыннан аерып булмый ирләрне, риза бул, хоккей беткәч җыелырбыз инде, яме! — диде.

Бу фикерне Галиянең әнисе дә куәтләде:

— Кич белән телевизордан Илһам Шакиров концерты да була, бергә тыңларбыз, — дип куйды.

Алар чыгып китте. Без үзебез генә калдык. Хатынымның туган көнен бәйрәм итүгә хәзерлек башланды. Бүлмәнең уртасына өстәлне чыгардык. Өстәл кырыеннан ике яклап келәм җәйдек. Ике келәм арасына телевизорны, телевизор кырыена, келәм өстенә Наил китергән киштәне куйдык. Алып килеп үлчәп карадым — гөл чүлмәкләренең берсенә киштәнең боҗрасы үлчәп ясаган кебек төгәл булып чыкты. Кичә мин алып кайткан чәчәкләр куйган вазаны киштәнең өстенә кунаклаттык. Галия үзе бүлмәләрне, өстәл өстен җыештыра башлады, әнисенең кухняда савыт-саба шалтыратканы, табада май чыжылдаганы ишетелде. Озакламый өйгә тәмле ис таралды. Эш белән мәшгуль булгангадыр инде — күткән вакыт тиз килеп җитте. Мин телевизорны ачтым да йомшак креслога килеп чумдым. Озакламый хоккей башланды. Бу минутларда, минем кебек, «иң кирәкле һәм иң мөһим төшен күрми калмыйм тагын» дип куркып, тирән итеп суларга да базмыйча телевизор алдында утыручылар күпме икән? Аз булмас, чөнки бөтен дөнья беренчелеге өчен көрәш бара. Шуның өстенә, бүген безнекеләр чехлар белән уйный!..

Беренче период үтеп тә китте. Тәнәфес вакытында кухняга кереп чыктым. Әби пешергән пәрәмәч белән, кашыкны тутырып-тутырып карлыган вареньесе каба-каба, бер стакан чәй эчтем. Күңел зур нәтиҗәләр белән безнекеләр җиңгәндәге кебек хушланып китте.

Икенче периодның яртысы узуга, яныма кызым килеп, бик баллы тел белән:

— Әти, нәрсәсе бар инде шул хоккейның, әйдә Казанны тыңлыйбыз, — диде. Чыннан да, аннан Илһам Шакиров җырлавын тапшырыр вакыт җиткән иде. Кызымның кем тарафыннан минем янга җибәрелгән «илче» икәнен шундук төшендем, шулай да аның сүзләрен игътибарсыз калдырдым. Уен эшмени — бөтен дөнья чемпионаты бара, сүз озайтып торырга вакыт юк. Озак та үтмәде, бүлмәгә Галиянең әнисе керде. Ул мәсьәләне туп-туры ярып салды:

— Илһам Шакиров концерты башланды бит. Көшәкә белән боз өстендә шайба куганны карап утырганчы концерт тыңласаң, бераз файдасы булыр иде, — диде.

Галия дә, бүген үзенең туган көне икәнен истә тотыптыр инде, бик кискен генә:

— Калганын бераздан радиодан да әйтерләр, һич булмаса, иртәгә газетадан укырсың. Шундый сирәк була торган концерт вакытында хоккей карап утырып булмый ич инде! — диде.

Мин, бүгенге хоккей гади хоккей түгел, ул бөтен дөнья чемпионаты, чемпионат елга бер генә була, телевизорда Илһам Шакиров концерты ял саен диярлек була икәнен аңлатыйм дип авыз ачкан идем, чехлар капкасы янында ыгы-зыгы башланды. Кызым әнисенең сүзенә каршы минем бер сүз дә әйтмәвемне Казан программасына күчәргә ризалык бирүем дип уйлады булса кирәк, барды да телевизорны Казан программасына күчерде. Бүлмәдә Илһам Шакировның үзенә генә хас моңлы авазы яңгырады. Әбисе дә, әнисе дә кызыма «дөрес иттең» дигән шикелле карап куйдылар. Мин бер мизгел һушсыз калдым кебек. Нишләргә? Чехлар капкасы янындагы хәлнең ни белән беткәнлеген генә карыйм әле дип, телевизорны Мәскәү программасына күчерер өчен сикереп торып бер генә адым атлаган идем, аякларым идәнгә җәйгән келәмгә эләкте. Келәм тартылып, Наил китергән киштәне кыйшайтты. Күземә киштә өстендәге сулы вазаның ава башлаганы чагылганда, аягым келәмнән ычкынып, үзем өстәл өстенә егылып кайнашканымны абайладым. Анна-

ры, егылу уңаена, өстәл өстеннән беләгем белән бер тәлинкә тозлы помидорны эләктереп, әби алдына барып аудым. Минем артта ниндидер чытырдау катыш пышылдаган тавыш ишетелде. Борылып карасам, чәчәкләр телевизор өстендә, ваза идәндә ята, аның суы эченә түгелгән, телевизорның өстеннән пар чыга, астыннан идәнгә су саркый. Киштә идәнгә ауган. Телевизор экраны берничә тапкыр елт-елт итеп алды да сүнде. Өйгә көйгән койка исе катыш янган резина сасысы таралды.

Мин помидор тәлинкәсен кочаклаган килеш аягыма бастым. Тәлинкәдә калган помидорлар бер-бер артлы әбинең итәгенә коелды. Тиз генә барып телевизорны сүндердем дә, ни эшләргә белмичә, кулымдагы тәлинкәне хатынга күрсәттем:

— Галия, кара әле, тәлинкә ватылмады! — дидем. Галиянең ни дип җавап биргәнен белмим, чөнки хәтеремә яңадан хоккей төште. Ни белән бетте икән чехлар капкасы янындагы хәл?..

Хоккейның калган өлешен күршеләрдә карап бетереп өйгә кайткач, ишек шакыйм — ишек ачучы юк. Тагын катырак итеп шакыйм, тагын көтәм. Эчтә тып-тын. Киемгә сеңгән тозлы помидор суы тәнне ачыттыра, чалбар балагы ботка ябыша. «Ни булды икән боларга?» дип шулай аптырап торганда, подъездда аяк тавышлары ишетелде. Борылып карасам — Наил белән Ләмига киләләр. Алар мине күреп аптырап калдылар. Булган хәлләрне сөйләп бирдем, тик, ни хикмәт, алар моңа аз гына да шаккатмадылар. Ләмига фәкать:

— Сездә дә шундый ук хәл булуын күңелем сизгән иде, чөнки без дә ачуланыштык. Наил хоккейны күршеләргә кереп карады, — диде.

Бераздан әнисе белән Галия һәм кызларым кайттылар. Алар да концертны күршеләргә кереп карап бетергәннәр икән. Әби, тозлы суын чупылдатып суыра-суыра, помидор ашый, үзе:

— Рәхмәт төшкере, бер помидор кесәмә кереп калган! — дип сөйләнә.

Кызларым:

— Яхшы әле, телевизор ватылды, хәзер инде төсле телевизор сатып алырбыз, — дип шатланышалар.

Ләмига гына үзенекен тукый:

— Тапканнар хоккей чемпионаты белән Илһам концертын бер вакытта куярга! Әллә Казан телестудиясендә Мәскәү программасын укымыйлармы икән? — ди.

Әйттем бит мин сезгә Ләмига бик күп сөйләшә дип, ышанмаган булсагыз, менә хәзер ышандыгызмы инде! Ә үзе бит ул телевизор программасын төзү бик четерекле эш икәнен дә белми! Шуның өстенә әле, үзенә нәрсә ошаса, башкаларга да шул ошарга тиеш дип уйлый.

## ИЛЕБЕЗДӘ МУСА ҖӘЛИЛ КӨННӘРЕ

### ТАНТАНАЛЫ КИЧӘ

Республикабызда М. Җәлил көннәренең үзәк вакыйгасы—каһарман шагыйрьнең 70 еллык юбилеена багышланган тантаналы җыелыш—13 февральдә әдипнең исемен йөртүче Татар дәүләт опера һәм балет театры залында булды. Муса Җәлил—шушы театрны оештыручыларның берсе, ә театр ачылгач, ул анда әдәби бүлек мөдире булып эшләгән, репертуарны яңа әсәрләр, либреттолар белән баетуда күп көч куйган.

Тантаналы кичәдә катнашу өчен илебезнең төрле төбәкләреннән: Украина, Белоруссия, Литва, Казагыстан, Үзбәкстан союздаш республикаларыннан, Башкортстан, Кабарда-Балкар, Удмуртия, Мордовия, Чувашия, Мари автономияле республикаларыннан, илебезнең башкаласы Мәскәүдән әдәбият вәкилләре, герой-шагыйрьнең исән калган сугышчан көрәштәшләре, шулай ук М. Җәлилнең тормыш иптәше Әминә һәм кызы Чулпан Җәлиловалар килгән иде.

Президиум составында — КПСС Үзәк Комитетының культура бүлеге секторы мөдире К. М. Долгов, КПСС өлкә комитетының икенче секретаре Ф. И. Панин, ТАССР Верховный Советы Президиумы председателе С. Г. Батыев, ТАССР Министрлар Советы председателе Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитеты секретарьлары М. Ф. Вәлиев, Ф. Г. Гайнуллин, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары А. М. Котов, КПССның Казан шәһәр комитетының беренче секретаре Р. М. Мусин, ТАССР Халык контроле комитеты председателе М. М. Репеев иптәшләр.

Залда герой-шагыйрь юбилее тантанасына республикабыз шәһәр һәм районнарыннан җәмәгатьчелек вәкилләре, хезмәт алдынгылары, фән работниклары, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре җыелган иде.

Тантаналы кичәне кереш сүз белән КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев ачты. Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗат юлы турында Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов сөйләде. Докладтан соң тугандаш әдәбиятлар вәкилләре, язучы һәм шагыйрьләр, сәнгать эшлеклеләре сүз алды. РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре Сергей Орлов, украин язучысы Алексей Новицкий, белорус шагыйре Микола Аврамчик, башкорт шагыйре Гыйлемдар Рамазанов, удмурт әдибе Флор Васильев, казакъ шагыйре Сагынгали Сеитов, Мәскәүнең «Молодая гвардия» нәшрияты баш редакторы Владимир Синельников, «Современник» нәшриятының баш редакторы урынбасары Николай Нефедов, Татарстан Композиторлар союзы идарәсе председателе Нәҗип Җиһанов, М. Җәлилнең көрәштәшләреннән берсе Рушат Хисаметдинов, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, балкар шагыйре Кайсын Кулиев герой-шагыйрь, прогрессив кешелек дөньясын таң калдырган «Моабит дәфтәре» авторының үлемсезлеге, аның шагыйрь һәм гражданин буларак күрсәткән тиңсез батырлыгы хакында, Муса Җәлилнең татар халкы һәм татар әдәбиятының гына түгел, бөтен совет әдәбиятының горурлыгы булуы, барлык тугандаш халыклар, гаделлек һәм прогресс өчен көрәшүче барлык кешеләр өчен какшамас рухи ныклык һәм фидакарьлек символына әйләнүе турында сөйләделәр.

Тантаналы кичә Татарстан сәнгать осталарының зур концерты белән тәмамланды.

### ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институты һәм Татарстан Язучылар союзы тарафыннан оештырылган бу гыйльми утырышта (11—12 февраль), Казан галимнәреннән тыш, Мәскәү, Минск, Вильнюс, Алма-Ата, Ташкент, Дүшәмбе, Фрунзе, Уфа һ. б. шәһәрләрдән килгән әдәбият һәм тел галимнәре, тарихчылар, әдипләр һәм сәнгать белгечләре катнашты.

Конференцияне кереш сүз белән КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев ачты. Аннары М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким Муса Җәлил традицияләре һәм бүгенге татар поэзиясе турында сөйләде. М. Җәлилнең гаять бай һәм киң колачлы иҗат мирасын өйрәнүнең барышы, киләчәктә бу өлкәдәге бурычлар хакында док-

лад белән Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институтының әдәбият секторы мөдире, филология фәннәре докторы Н. Г. Юзеев чыкты. Конференциядә Муса Җәлил иҗатының идея-эстетик эчтәлеге, төп сыйфатлары һәм үзенчәлекләре, тугандаш әдәбиятлар белән тирән бәйләнеше, Җәлил биографиясенең төрле чорлары, аның күпкырлы эшчәнлеге, сәнгатебезнең төрле тармакларында М. Җәлилнең тоткан урыны, Җәлил мирасының әһәмияте һ. б. темаларга филология фәннәре кандидаты Р. Г. Бикмөхәмматов (Мәскәү), Р. А. Нутфуллина (Алабуга), филология фәннәре кандидатлары В. Г. Воздвиженский һәм М. Ш. Маннурова, Р. Ә. Мостафин (Казан), И. Х. Зәбиров (Ташкент), шагыйрь Сагынгали Сеитов (Алма-Ата), филология фәннәре докторлары Г. Х. Әхатов, Г. З. Рамазанов (Уфа), филология фәннәре кандидатлары Ю. Лаурушас (Вильнюс), Є.-М. Х. Акбиев (Каспийск), Н. Н. Орочко (Минск), Е. С. Сидорова (Чабаксар), Х. Шодикулов (Дүшәмбе), К. Абделдабеков (Фрунзе), педагогия фәннәре кандидаты Ф. И. Мостафин, филология фәннәре кандидатлары Х. Р. Корбатов (Казан), Т. Н. Галиуллин (Алабуга), А. З. Нигъмәтуллин, С. Г. Сафуанов (Уфа) һ. б. ларның барлыгы өч дистәдән артык доклады тыңланды.

Конференциядә шулай ук «Үлемсез җыр» драмасының авторы драматург Риза Ишморат һәм скульптор Бакый Урманче чыгыш ясадылар.

Фикер алышуда катнашучылар Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗат мирасын фәнни нигездә өйрәнү эшендә бу конференциянең зур өлеш кертүен билгеләп үттеләр, бу өлкәдә әле тикшереләсе һәм тирәнтен өйрәнеләсе мәсьәләләргә игътибарны юнәлттеләр. Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институты директоры М. К. Мөхәррәмов конференциягә йомгак ясады.

## ТУГАНДАШ ӘДӘБИЯТЛАР КИЧӘСЕ

12 февраль көнне илебезнең төрле өлкәләреннән килгән кунак-әдипләр—тугандаш халыклар әдәбиятлары вәкилләре, татар язучылары һәм шагыйрьләре белән бергә, Казан дәүләт консерваториясе залында патриот-шагыйрь М. Җәлил юбилеена багышлап, әдәбиятлар дуслыгы кичәсе үткәрделәр.

Кичәгә җыелган күп санлы әдәбият сөючеләр алдында тугандаш әдәбиятларның танылган әдипләре—күренекле балкар шагыйре Кайсын Кулиев, рус шагыйрьләре Сергей Орлов һәм Юрий Кузнецов, казакъ әдибе Сагынгали Сеитов, башкорт шагыйре Гыйлемдар Рамазанов, Белоруссиядән Микола Орочко, Удмуртиядән Флор Васильев, Таҗикстаннан Х. Шодикулов, тәрҗемәчеләр Рувим Моран, Вил Ганиев чыгыш ясадылар. Татар әдипләреннән кичәдә Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Зәки Нури, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Әдип Маликов катнашты. Әдипләр татар әдәбияты һәм илебездәге күп милләтле башка әдәбиятлар арасында үзара якын бәйләнешләр, бу бәйләнешләрдә Муса Җәлил әсәрләренең нинди зур урын тотканлыгы, үсә баручы иҗади хезмәттәшлек һәм уртак казанышлар хакында сөйләделәр, үз иҗатлары белән таныштырдылар, яңа әсәрләрен укыдылар. Кичәне Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре, М. Җәлил исемендәге комсомол премиясе лауреаты шагыйрь Равил Фәйзуллин алып барды.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ТУГАН ЯГЫНДА

Муса Җәлил исеме Оренбург өлкәсе хезмәт ияләре өчен аеруча якын, бигрәк тә кадерле. Бу җир каһарман шагыйрьнең бала чак һәм үсмер елларын хәтерли, аның давыллы комсомол яшьлегенең кайнар эзләрен саклый. Җәлил шигъриятенең беренче очкыннары шушы җирдә кабынган, батырлык юлы шушыннан башланып киткән. Шуңа күрә дә, герой-шагыйрьнең 70 еллык юбилеен Оренбург ягы зур горурлык хисен тоеп, үзенә бер күтәренкелек белән тантана итте. Муса Җәлил көннәре монда өлкә һәм Оренбург шәһәренең аерым хезмәт коллективлары, клублар, китапханәләр, мәктәпләр, әдәби түгәрәкләр һәм үзешчән сәнгать коллективлары оештырган төрле кичәләр, очрашулар, укучылар конференцияләре, концертлар белән башланып китте.

16 февральдә Оренбург шәһәренең Мәгариф йортында тантаналы кичә булды. Кичәдә шагыйрьнең көрәштәшләреннән Фәрит Солтанбеков, Гарәф Фәхретдинов, әсирләр лагерендә Муса Җәлил белән очрашкан һәм аралашкан үзбәкстанлы Хәбибулла Фәйзуллаев, М. Җәлил иҗатын өйрәнүче үзбәк галиме Исхак Зәбиров, шулай ук Мәскәү һ. б. шәһәрләрдән килгән әдипләр катнашты. Татарстан Язучылар союзыннан монда күренекле драматург Риза Ишморат һәм әдибә Рәйсә Ишморатова булды. СССР Язучылар союзының Оренбург бүлеге җитәкчесе А. Г. Рыбин М. Җәлилнең тормышы һәм ялкынлы иҗаты хакында доклад сөйләде. Аннары герой-шагыйрьнең әсирлектәге көрәштәшләре, якташлары, әдипләр сүз алды.

Иртәгесен кунаклар Шарлык районына юнәлделәр, В. И. Ленин исемендәге колхозда мәктәп укучылары һәм колхозчылар, Шарлык район Культура йортында хезмәт ияләре белән очраштылар.

Аннары кунакларны Мостафа авылы хезмәтчәннәре каршы алды. Шагыйрь исемен йөртүче колхозның хезмәтчәннәре авылдашларының бу юбилей көннәренә авыл тарихында җуелмас эз калдырырлык итеп әзерләнгәннәр. Кунаклар катнашында ул көнне авыл уртасында Муса Җәлил һәйкәле, яңа төзелгән Культура йорты ачылды. Ике йөз урынлы ул культура учагының бер бүлмәсендә М. Җәлил музее оештырылган. Культура йортында үткән кичәдә колхоз эшчәннәре алдында шагыйрьнең көрәштәшләре, татар язучылары Риза Иш-

морат, Рәйсә Ишморатова чыгыш ясады, укучылар башкаруында Җәлил шигырьләре яңгырады. Кичәдә герой-шагыйрьнең туганы Хәдичә Җәлилова катнашты.

## РЕСПУБЛИКАНЫҢ НЕФТЬ РАЙОННАРЫНДА

Җәлил поселогы хезмәт ияләре герой-шагыйрь Муса Җәлилнең 70 еллык юбилеен зур хәзерлек белән билгеләп үттеләр. Мәктәпләрдә шагыйрьгә багышланган дружина сборлары уздырылды. Нефтьчеләр, төзүчеләр һәм мәктәп балалары көндез Җәлил һәйкәле янына митингка җыелдылар, шагыйрьгә чәчәкләр китерделәр.

Техника йорты бинасында Муса Җәлил музее ачылды. Анда шагыйрьгә кагылышлы истәлекле әзүлар, көрәштәшләренең хатлары, Җәлилнең төрле телләрдә басылган әсәрләре куелган. Музейны оештыруга поселок Советы һәм Җәлил исемендәге дружина пионерлары күп көч салганнар.

Кичен Техника йортында герой-шагыйрьгә багышланган тантаналы кичә булды. Кичәне Сарман райкомы секретаре Люция Зиннурова ачты. Докладчы, Җәлил поселогы Советы председателе Азат Исмәгыйлов, кичәдәгеләргә каһарман шагыйрьнең тормыш юлы, батырлыгы хакында сөйләде.

Кичәдә Татарстан Язучылар союзы Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Ә. Маликов, шагыйрь Г. Афзал чыгыш ясады, язучылардан Ю. Әминов, Х. Хәйруллин катнашты. Муса Җәлилнең көрәштәшләреннән, шагыйрьнең тормыш иптәше Әминә ханым Җәлиловадан һәм кызы Чулпаннан килгән телеграммалар, хатлар укылды. Ахырдан үзешчәннәр һәм мәктәп балалары көче белән концерт куелды.

*

* *

Әлмәт шәһәренең Техника йортында шундый ук тантаналы кичә булды. Шагыйрьнең тормыш һәм көрәш юлы турында доклад белән партиянең Әлмәт шәһәр комитетының беренче секретаре В. Е. Борисов чыкты. Фойеда Әлмәт художество мәктәбе укучыларының һәм укытучыларының Җәлилгә, аның көрәштәшләренә багышланган рәсемнәреннән зур күргәзмә һәм китап сәүдәсе оештырылды.

*

* *

15 февральдә Лениногорск шәһәре хезмәт ияләре һәм җәмәгатьчелек вәкилләре герой-шагыйрь Муса Җәлилнең 70 еллык юбилее кичәсен үткәрделәр. Аны КПССның шәһәр комитеты секретаре Малик Халикович Сәлимов ачты. М. Җәлилнең тормышы һәм иҗаты хакында язучы Шамил Бикчурин сөйләде.

Шәһәрнең «Чишмә» әдәби берләшмәсе членнары Җәмит Рәхимов, Разим Вәлиуллин, Әсрар Галиев, Рәшит Бәшәров, Ф. Нуруллин, Җәдит Хәбибуллин, Таһир Шәмсуаров, Альберт Хәсәнов, Шәрига Таһирова, Исмәгыйл Әхмәдиев кичәдә М. Җәлил шигырьләрен һәм үз әсәрләрен укыдылар. Үзешчән композиторлар Фәйзи Хөснуллин, Разим Вәлиуллин, җырчылар Илдус Тарханов, Фәнис Посыпов, Әхмәт Фәйрушин М. Җәлил сүзләренә язылган җырларны һәм үз иҗат үрнәкләрен башкардылар.

*

* *

Пермь шәһәрендә Муса Җәлилгә багышланган кичә өлкә язучылар оешмасының «Лукоморье» исемле иҗат клубында үтте. Анда шәһәр җәмәгатьчелеге вәкилләре, язучы һәм журналистлар, студентлар җыелган иде. Кичәне язучы Лев Давыдычев ачты. М. Җәлил иҗаты һәм тормыш батырлыгы хакында Ягъфар Камалов доклад ясады. Шәһәрнең драма театры артистлары Ю. Найдена һәм Ю. Крендель башкаруында патриот-шагыйребезнең шигырьләре рус телендә яңгырады. Шигырьләрне татар телендә медицина фәннәре кандидаты Ф. Вәлиева укыды.

*

* *

Башкортстан АССРның Октябрьск шәһәрендә патриот-шагыйребез юбилеена багышланган кичә нефтьчеләрнең культура йортында булды. М. Җәлилнең иҗаты турындагы сүзне әдәбият укытучысы Г. Г. Ахметова әйтте. Укытучы-пенсионер Г. Г. Гафуров Демблин лагеренда Җәлил белән очрашуы турында сөйләде. Халык театры артистлары шагыйрьнең әсәрләрен укыдылар, аның сүзләренә язылган җырларны башкардылар. Нефтьчеләр китапханәсе «Үлмәс җыр» дип исемләнгән фотокүргәзмә оештырды.

## ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ МУЗЕЕНДА

Татарстан дәүләт музееның татар әдәбияты бүлегендә Җәлилгә багышланган экспозиция даими эшләп килә. Герой шагыйрьнең кульъязмалары, хатлары, шәхси әйберләре, төрле документлар һәм китаплар теле белән бу экспозиция әдипнең тормышы, иҗат юлы хакында сөйли. Әлбәттә, экспозициядәге иң кыйммәтле экспонат — атаклы «Моабит дәфтәре»нең төп нөсхәләре.

М. Җәлилнең 70 еллыгына музейда яңа күргәзмә ачылды. Биредә шагыйрьнең төрле телләрдә чыккан китаплары, истәлекләр, фәнни хезмәтләр, Җәлилгә багышланган күп санлы матур әдәбият әсәрләре, театр спектакльләреннән, кино һәм телевизион фильмнардан фотографияләр куелган. «Җәлил һәм балалар» дигән аерым бүлектә республиканың художество мәктәпләре

укучылары арасындагы үткән елгы конкурстан сайлап алынган утыздан артык рәсем күрсәтелә.




Рәсемдә: *күргәзмәгә куелган китапларның тышлыклары.*

## М. ҖӘЛИЛ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премияләр комитеты 1975—1976 еллар өчен республика премияләре бирү турында карар кабул итте. Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә премияләргә герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗатын өйрәнүдә күп хезмәт күрсәткән Гази Кашшаф (үлеменнән соң) һәм Рафаэль Мостафин лаек булдылар.

М. Җәлил премиясе шулай ук «Комсомол-яшьләр бригадасы», «Кама өстендә акчарлаклар», «Җәлил», «Җәлил һәйкәле янында», «Юл», «Авылның яңалыгы» дигән әсәрләре өчен рәссам В. Н. Скобеевка бирелде.

## МУСА ҖӘЛИЛ ӘСӘРЛӘРЕ — ИЛ ҺӘМ ДӨНЬЯ МАТБУГАТЫ БИТЛӘРЕНДӘ

М. Җәлилнең 70 еллык юбилее көннәрендә Германия Демократик Республикасы Фәннәр академиясенең әдәбият тарихы буенча Үзәк институты «Кешелекне яклап» дигән җыентык дөньяга чыгарды. Җыентыкта М. Җәлил иҗатына багышланган бүлекчә күренекле урын алып тора.

«Фольк унд Вельт» нәшрияты М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре»н немец телендә кабат бастырып чыгарырга әзерләнә. Бу яңа басмада электән билгеле булган күп кенә шигырьләрне татар теленнән турыдан-туры тәрҗемә итү күздә тотыла.

*

* *

Татарстан китап нәшрияты Муса Җәлил әсәрләренең дүрт томлыгын бастырып чыгарды. Беренче томга патриот-шагыйрьнең Бөек Ватан сугышына кадәрге шигъри иҗаты тупланган, икенче томда М. Җәлилнең сугыш чорында язган шигырьләре, тоткынлыкта иҗат иткән «Моабит дәфтәре», шулай ук либреттолар һәм аларның вариантлары урын алган. Өченче томда шагыйрьнең 1925-1941 елларда иҗат иткән поэмалары, Пушкин, Некрасов, Шевченко, Маяковский әсәрләреннән тәрҗемәләр урнаштырылган, монда шулай ук «Бибкәй кыз» исемле музыкаль пьеса беренче тапкыр басылган. Дүртенче томда каһарман әдипнең публицистик чыгышлары, мәкалә һәм рецензияләре, хатлары җыеп бирелгән.

«Подвиг» китапханәсе сериясеннән илле мең тираж белән М. Җәлилнең шигырьләр җыентыгы басылып чыкты. Монда «Моабит дәфтәре», Бөек Ватан сугышы чоры лирикасы кертелгән. «Моабит дәфтәре» шулай ук кечкенә форматта сувенир басмасы итеп тә чыгарылды. М. Җәлил юбилее алдыннан нәшрият балаларга герой-шагыйрьнең балалар өчен язган әсәрләреннән «Сандугач һәм чишмә» исемле төсле һәм рәсемле китап бүләк итте.

Төрле елларда композиторларыбыз тарафыннан Муса Җәлил сүзләренә язылган җырлар да ноталары белән «Сагыну» исемле җыентыкта дөнья күрде.

«Җырларым». 1943 елның ноябрендә Моабитның үлем камерасында язылган бу үлемсез шигырьне, илебездәге егерме дүрт телгә тәрҗемәсе белән, нәшрият аерым басма итеп дөньяга чыгарды.

## МУСА ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА ИЛЕБЕЗ МАТБУГАТЫ

«Правда» газетасы 13 февраль санында КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. А. Табеевның «Коммунист шагыйрьнең батырлыгы» исемле күләмле мәкаләсен урнаштырды. «Известия» газетасында (15 февраль саны) М. Львовның «Ватанга тугрылык» дигән мәкаләсе басылды. «Литературная газета»ның 11 февраль санында Г. Ахуновның, «Литературная Россия» газетасында (13 февраль саны) А. Шпирт, И. Зәбировның, «Комсомольская правда»да Р. Фәйзуллинның, «Учительская газета», «Советская Россия», «Труд», «Красная звезда» газеталарында П. Седов, С. Хәким, С. Щипачев, К. Владимировларның мәкаләләре дә герой-шагыйребезгә багышланган.

*

* *

Үзәк журналларның февраль саннарында да М. Җәлил юбилее уңае белән басылган мәкаләләрне күпләп очратырга мөмкин. «Москва» журналында Ю. Корольков, «Новый мир»да Р. Мостафин, «Молодая гвардия» битләрендәге А. Мәхмүдов мәкаләләре әнә шундыйлардан. «Наш современник» журналында патриот-шагыйрьнең шигырьләре урын алган.

*

* *

Казанның кинохроника студиясе «Җәлил. Көрәш сәхифәләре» дигән документаль кинофильм чыгарды. Фильм герой-шагыйребез турындагы төрле документлар, сугыш еллары кинохроникасы, М. Җәлилне күреп белгән кешеләрнең истәлекләре нигезендә эшләнгән.

# ПАРТИЯНЕҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

Шушы елның март аенда партиянең Татарстан өлкә комитеты бюросы республикабыз Язучылар союзы партия оешмасының эшен тикшерде.

Бу мәсьәлә буенча кабул ителгән карарда язучыларның идея-политик дәрәҗәсен үстерү, иҗат һәм җәмәгать активлыкларын күтәрү, аларны совет әдәбияты алдына партиябез куйган бурычларны үтәүгә туплау буенча язучылар партия оешмасының шактый зур эш алып баруы билгеләп үтелә.

Партия җыелышлары, диелә карарда, чын мәгънәсендә политик тәрбия мәктәбенә әйләнде. Союзда политик укулар ныклы бер тәртип нигезендә алып барыла. КПССның XXIV съездыннан соң партия оешмасы иҗат мәсьәләләре белән конкретрак шөгыльләнә башлады. Партия җыелышларында, партбюро утырышларында иҗат секцияләренең, аерым авторларның, союз җитәкчеләренең отчетлары тыңлана. Яшь авторлар белән эшләү активлаша төште. Язучыларның производство коллективлары белән элемтәсен ныгыту, аларны халыкка эстетик тәрбия бирүгә тарту юнәлешендә дә шактый эш алып барыла.

Партия оешмасы алып барган бу эшләр язучылар арасында аның авторитетын күтәрде, әдәби хәрәкәткә булган йогынтысын көчәйтә төште. Соңгы елларда татар әдәбияты йөз белән заман проблемаларына борылыш ясады. Язучыларыбыз хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләрлек күп кенә уңышлы әсәрләр иҗат иттеләр. Әдәбиятта эшче темасы елдан-ел күбрәк урын ала бара.

Шул ук вакытта КПСС өлкә комитеты бюросы Язучылар союзының партия оешмасы эшендә җитди генә кимчелекләр булуын да билгеләп үтә.

Аерым очракларда партия җыелышлары җитәрлек хәзерләнмәгән килеш үткәрелә һәм андый җыелышлар коллектив тормышына тиешле тәэсирне ясамый. Җыелыш карарларын үтәү буенча җитәрлек эш алып барылмый. Партия бюросы язучыларның политик укуларын яхшырту юнәлешендә тиешле ныклык күрсәтми. Партбюро һәм Союз идарәсе коллективта югары таләпчәнлек атмосферасы тудыру турында җитәрлек кайгыртмыйлар. Язучыларның бер өлеше җәмәгать һәм иҗат оешмасының эшендә пассив катнаша. Яңа әсәрләрне тикшергәндә, вакыты белән, либерализм һәм йомшаклык күрсәтелә. Язучылар союзының производство коллективлары белән элемтәсе тормыш куйган таләпләргә тулысы белән җавап биреп бетерми. Иҗат секцияләре эшендә җитешсезлекләр очрый.

Бюро, күрсәтелгән җитешсезлекләр язучыларның идея-политик һәм профессиональ осталыклары күтәрелүгә, әдәбиятыбыз үсешенә тискәре йогынты ясый, дип билгеләп үтә. Идея-сәнгатьчә эшләнеше йомшак булган төссез әсәрләр әле булса чыгып тора. Кайбер авторлар чынбарлык күренешләренә сәнгатьчә тирән анализ ясамыйлар, үз әсәрләрендә алар заман проблемаларын гадиләштереп, өстән-өстән хәл итәләр. Аерым язучылар тормышны тирәнтен өйрәнүне таләп итә торган зур темалардан читләшәләр, совет җәмгыяте үсешендә, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдә иҗтимагый әһәмиятле булган проблемалар алар иҗатында җитәрлек чагылыш тапмый.

КПСС өлкә комитеты бюросы партия оешмасына күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү, барлык политик һәм оештыру эшләрендә КПСС Үзәк Комитетының КПССның XXV съездына отчет докладында иптәш Л. И. Брежнев тарафыннан күтәрелгән положениеләр һәм бурычларга таянып эш итү, иҗат интеллигенциясенә игътибарлы булу, аның иҗади эзләнүләрендә игътибарлы мөнәсәбәтне принципиальлек, югары таләпчәнлек белән бәйләү, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең иҗат һәм җәмәгать активлыгын, социалистик идеяләр белән коралланулары һәм художество осталыкларын тагын да яхшырту турындагы съезд күрсәтмәләрен эзлекле рәвештә тормышка ашыру бурычын йөкләде; язучыларның көчләрен хәзерге заман совет чынбарлыгын, совет кешесенең югары мораль сыйфатларын ышандырырлык итеп, дөрес чагылдырган яңа әсәрләр тудыруга юнәлтү кирәклеген күрсәтте.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Сезне журналыбызның 6 санында басылачак әсәрләр белән таныштырабыз. Бу санда сез Нури Арсланов, Фәния Чанышева, Булат Сөләйманов, Равил Бикбаев һәм яшь шагыйрь Акъегет шигырьләрен, Рөстәм Мингалимовның «Юл өстендә торгай» дигән поэмасын укырсыз. Азат Вергазовның «Дулкыннар ни сөйли?» дигән повесте эшче яшьләр тормышын чагылдыруы белән кызыклы. Диас Вәлиевның «Синең тормыш бүләк итәм» дигән пьесасы республикабызда гына түгел, илебезнең башкаласы һәм бүтән шәһәрләрендә зур уңыш белән барды, туганлаш халыклар телендә, чит илләрдә тәрҗемә итеп басылды. Сезнең игътибарыгызга әнә шул әсәрне тәкъдим итәбез.

Республикабыз хезмәт ияләре КПССның XXV съездына «КамАЗ» машиналары колоннасын бүләк итеп җибәргән иде. Аның турында «Беренче маршрут: Чаллы — Мәскәү» дигән язма бирелә. Журналист Җәүдәт Кәлимуллинның «Яшьлеккә тартыла күңел» дигән очеркы производствода яшь эшче тәрбияләү проблемасын күтәрә.

Шушы елның декабрендә татар театрының 70 еллыгы билгеләп үтеләчәк. Театр тарихына караган берничә материал белән укучыларыбызны таныштырган идек. Бу санда Х. Гобәйдуллин һәм И. Ингварның «Мәгънәви театрыбыз остазы» дигән мәкаләсе урнаштырыла. Ул — Габдулла Кариев турында.

«Тел белеме», «Культурабыз тарихына...» дигән бүлекләрдә дә күп кенә кызыклы материаллар бирелә.

Әдәби тәнкыйть тулысы белән әдәбият дәреслекләрен анализлауга багышлана.

Юмор бүлегендә Туфан Миңнуллин хикәяләре бар. Һәр сандагыча, әдәбият һәм сәнгать яңалыкларын укырсыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210